ISSN 0206-4189
Индекс 73210

# Казан утлары

4.2009






**И туган тел...**

**Казан утлары**
**Qazan utları**

2009

# 4
**(1038)**

***ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:***
*Татарстан хөкүмәте,*
*Татарстан Язучылар берлеге,*
*Редакциянең хезмәт коллективы*

***НАШИРЕ:***
*«ТАТМЕДИА» ачык акционерлык җәмгыяте*



*БАШ МӨХӘРРИР*

**Равил Габдрахман улы Фәйзуллин**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Зилә Вәлиева**
**Разил Вәлиев**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Тәлгат Галиуллин**
**Миркасыйм Госманов**
**Алмаз Гыймадиев**
*(җаваплы сәркәтип)*
**Илфак Ибраһимов**
**Дамир Исхаков**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Назиф Мириханов**
**Гәрәй Рәхим**
**Розалина Шаһиева**
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Марат Закир, Камил Кәримов, Рашат Низами, Алмаз Хәмзин.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Гөлзадә Бәйрәмова, Радик Вәлиев, Лилия Гатауллина, Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Асия Рәхимова** (баш бухгалтер), **Эльвира Камалова.**


---


420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.
Баш мөхәррир—292-38-60.
Баш мөхәррир урынбасары—292-36-49.
Җаваплы сәркәтип, компьютер үзәге—562-11-28.
Шигърият, публицистика, фән һәм сәнгать бүлеге—292-38-61.
Чәчмә әсәрләр һәм әдәби тәнкыйть бүлеге—292-39-63.
Гамәли хезмәткәрләр—292-39-65.
Исәп-хисап бүлеге—292-93-16. kazanutlari@yandex.ru
**Факс**—(843) 562-11-28.
**E-mail:** kazanutlari@telebit.ru.

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ–НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ–СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Габдулла ТУКАЙ. Татар яшьләре. *Шигырь.* ... 5
Сәгыйдулла ХАФИЗОВ. Сәрви-Сәрвиназ. *Повесть.* ... 6
Бикә РӘХИМОВА. Бик кадерле ил бит бу!.. *Шигырьләр* ... 31
Рифат ҖАМАЛ. Күңелгә килми кышлар. *Шигырьләр.* ... 35
Нур ӘХМӘДИЕВ. Мөнирстан. *Роман.* ... 38
Рифкать ИМАЕВ. Нәрсә булган бу җилләргә?.. *Шигырьләр.* ... 98
Гөлзадә ӘХТӘМОВА. Киң илдә. *Шигырьләр.* ... 101
Әлфия СИТДЫЙКОВА. Эзләп тапкан бәхет кадерлерәк... *Шигырьләр.* ... 112

ТАТАР ХИКӘЯЛӘРЕ ХӘЗИНӘСЕННӘН

Мөхәммәт МӘҺДИЕВ. Бер моң ... 104

ХӘТЕР

КҮПРЕЛЕЗАДӘ. Габдулла Тукаев. ... 115
Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ. Тукайны Питер дә онытмый. ... 125
Мөдәррис ВӘЛИЕВ. Гыйбрәтләр аласы бар... ... 128
Әхмәт РӘШИТ. Һәркемнең... үз сукмагы. *Хатирәләр.* ... 162

ПУБЛИЦИСТИКА

Тәфкил ВАФИН. Мәкруһлар ... 132

ТАРИХ

Михаэль ФРИДЕРИХ. Козгын көнчыгышка оча... ... 136

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Фоат ГАЛИМУЛЛИН. Сембер шагыйрәсе
*(Иделбикә иҗатына бер караш)* ... 153

КИТАП КҮЗӘТҮ

Гүзәл ГАЙФИЕВА. Догалы корт тылсымы ... 158

ФӘН

Фирдәвес ГАРИПОВА. Авылларыбыз тарихы. ... 166
"Татар энциклопедиясе" битләреннән. ... 170

ЮМОР ҺӘМ САТИРА

Ренат ГАФФАР. Манзаралар. ... 174
Алмаз ХӘМЗИН. Шаян хикәяләр. ... 178
Тартмәле бит. ... 181
"Казан утлары" архивыннан. ... 182
Берлекнең яңа әгъзалары. ... 184
Укучы сүзе. ... 186
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ... 187

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*Журнал выходит один раз в месяц*


"Проза и поэзия": роман Н. АХМАДИЕВА "Мунирстан" (окончание); повесть С. ХАФИЗОВА "Сарви-Сарвиназ"; стихи Г. ТУКАЯ, Б. РАХИМОВОЙ, Р. ЗАМАЛА, Р. ИМАЕВА, Г. АХТЯМОВОЙ, А. СИТДИКОВОЙ.

"Из сокровищницы татарских рассказов": М. МАГДЕЕВ. "Мелодия сердца".

"Память": КУПРЕЛЕЗАДА. "Габдулла Тукаев"; Х. МИННЕГУЛОВ. "Петербург помнит Тукая"; М. ВАЛЕЕВ. "В назидание другим"; А. РАШИТ. "У каждого своя судьба" (окончание).

"Публицистика": Т. ВАФИН. "Отпавшие" (окончание).

"История": М. ФРИДЕРИХ. "Ворон летит на восток".

"Литературная критика": статья Ф. ГАЛИМУЛЛИНА о творчестве поэтессы Иделбикэ.

"Книжное обозрение": рецензия Г. ГАЙФИЕВОЙ на новую книгу Ф. Замалетдиновой "Молитва червя".

"Наука": Ф. ГАРИПОВА. "История наших деревень" (продолжение).

Страницы из "Татарской энциклопедии".

"Юмор и сатира": этюды Р. ГАФФАРА, юмористические рассказы А.ХАМЗИНА.

Новые члены Союза писателей.

Из фотоархива журнала.

Дневник общественно-культурной жизни.

На наших обложках: "Акмулла"—работа А.АБЗГИЛЬДИНА; ученый Анвар ХАЙРИ.


# IN THIS ISSUE:

*The magazine edits monthly*


"Prose and poetry: novel by N. AHMADIEV "Munirstan"(ending); novel by S. HAFIZOV "Sarva-Sarvinaz; poems by G. TUKAY, B. RAKHIMOVA, R. ZAMAL, R. IMAEV, G. AHTYAMOVA, A. SITDIKOVA.

"From Tatar stories treasury": M. MAGDEEV. " Heart melody."

Memory: KUPRELEZADA. "Gabdulla Tukay; H. MINNEGULOV "Petersburg remembers Tukay"; M. VALEEV. "Example to others", A. RASHIT. "Everybody has his destiny" (ending).

"Publicism": T. VAFIN. " Fallen down " (ending).

"History": M. FRIDERIH. "Raven flies to the East."

"Literary criticism": article by F. GALIMULLINA about creativity of poetess Idelbike.

"Book review: review by G. GAYFIEVA to new book by F. Zamaletdinova "Prayer of worm."

"Science": F. GARIPOVA. "History of our villages" (continuation).

Pages from the Tatar Encyclopaedia.

"Humor and satire: etudes by R. GHAFFAR, humorous stories by A.HAMZIN.

New members of the Union of writers.

From photo archive of magazine.

Diary of the social-cultural life.

On our cover: "Akmulla. Work by A. ABZGILDIN; scientist Anwar KHAIRY.


---


★ Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

★ Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

★ Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.


---


Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды.

Басарга кул куелды 26.03.2009, график буенча 26.03.2009.

Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.

Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ В–387 Тираж 4560.

Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән.

Теркәлү таныклыгы № 7. Индекс 73210. Бәясе ирекле.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.

Казан, Декабристлар урамы, 2



© «Казан утлары», 2009 ел.

Габдулла
Тукай

## ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ

Дикъкатә лаек хәзерге көн татарның яшьләре:
Аңламак, белмәк, тәрәкъкый, мәгърифәт, хикмәт белән.

Әйләнеп һәм нурланып тормакта һәрдәм башлары.
Мондый күрнеш сөйнеченнән инде мин алдан беләм:

Тик болар безгә кирәк диңгез төбе гауваслары.
Өстә бу ямьсез болыт баштан китәр, яңгыр явар,

Җиргә рәхмәт күк төшәр яшьләрнең изге касдлары.
Шаулап аккан су булып тау башлары, тау астлары.

Күк булып күкрәр һавада хөр яшәү даулашлары,
Ялтырар изге көрәшнең хәнҗәре, алмаслары.

Йөрмәсен бәгъре өзек милләт киеп кашсыз йөзек,—
Без аның бик зур фәхерле, чын бриллиант кашлары!

*1912*



Сәгыйдулла
Хафизов

## СӘРВИ-СӘРВИНАЗ

ПОВЕСТЬ

—Әһә... Һә... Һәй!

Кырык яшьләр чамасындагы, ыспай сынлы Салихның ерак юл үтеп, туган төбәгенә кайтып житкәч, тауга менеп, Жир-анага биргән сәламе иде бу. Килмәкнең бар ямен, бөтен хозурлыгын күрим дисәң, менә шушы Чирмеш тавына күтәрелергә кирәк шул! Салих иренмәде, күпме еллар аерылып торган туган авылы белән күрешү сөенечен иркенләп тату өчен, урау булса да, машинасын әлеге тауга юнәлтте.

Һәм менә аны тудырган, үстергән газиз төяк бар булмышы белән аста ята. Июль кояшының төшлектән кул яссылыгы гына төшкән мәле. Эсседән мәлжерәп жәйрәгән хәят өчен хәзер иң кадерлесе—су, күләгә. Бәлки, нәкъ шуңа күрәдер Салихның карашын иң элек көмеш камчы булып сузылган Сөлчә тартты. Ул, борылмалары, төрле төсләр белән балкыган үзән һәм ярлары, кош-кортлары һәм кешеләре белән мавыктырып, күз-карашны да үзе белән агарга әйди иде.

Килмәк белән бергә чуаш авылы Элмәлене дә тоташтырган, колмак үсентесе кебек үрләп Кармәткә дә сузылган, тирәсендә эреле-ваклы күлләр дә хасыйл иткән көмеш Сөлчә... Ә аннары күксел тау ышыгында, качыш уйнаган малай кебек, шым гына югала үзе. Моннан, тау башыннан, яшькелт хәтфә сузылып яткан көмеш чыбыркы сыман елга зәгыйфь тә, кыска да кебек күренә. Әмма янәшәсенә төшеп бара башласаң, уһу... Һу! Инде күптән, кайсыдыр сыйныфта укыганда, "атаклы шагыйрь Хәсән Туфан авылы» дип елга буйлап Кармәткә сәяхәт ясаганнар иде, Каф тавына барып кайткан кебек тоелды. Сөлчәнең зәгыйфь, юаш булып күренүе дә жәйге челләнең күз буу галәмәте генә. Язын казандагы сөт кебек кайнап ярларыннан ташып чыга, әллә ничә чакрымлы биләмәләр кора һәм дымы белән сугарып әрәмәләр үстерә ул. И-и, нинди генә жимеш белән сыйламый иде Салихларны ул юмарт әрәмәлекләр!

Кунак ир кыбырсык дулкынланулы карашын янә һәм янә елга, кыр,

Сәгыйдулла ХАФИЗОВ (1945)—*язучы һәм әдәби тәнкыйтьче; филология фәннәре докторы. Татарстан Язучылар берлегенең Ж. Вәлиди исемендәге премиясе лауреаты. Уфада яши.*

урман, тугайлар өстеннән йөгертте, ә хәтер дөньясында исә истәлекләр белән бәйле хисләре ташыды.

Бер караганда сәер һәм үтә гаҗәп халәт инде бу. Югыйсә, Салихның чит җирләрдә, менә хәзер яшәп яткан Пермь якларында да, Шишкин картиналарын төссезләндерерлек илаһи табигать ямьнәренә тап булганы бар. Анда күз соклана, акыл хәйран кала. Әмма никтер эчтә—таш алиһә тәэсире инә: кан уянмый... Ник алай? Никме, никме? Ә-ә, дип хәтере яктыра Салихның. Адәмгә ана булган табигатьнең җаны, хәтере бар бит... Әнә шул, янәшәдәге урман-сулар, болын һәм кырларга, тауларга уралып синең дә җанлы шәүләң, сурәтең кала. Вакыт уза, син үсәсең, читкә китәсең, әмма кайтып, туган җиргә баксаң, шул урман-сулар, болын һәм кырлар, таулар ышыгында серле көзгедәге кебек янә үзеңне, үзеңнең үткәнеңне күрәсең, истәлекләргә чумасың, дулкынланасың...

—Әти, кузгалыйк инде!—Салих, янәшәсенә килеп баскан малае Рәлифнең ризасыз һәм кинаяле карашын абайлап уңайсызланып куйды. “Мәрткә кителгән ләбаса!»...

—Кабыз, улым, машинаны, киттек!

Машинага утырып, янә олы юлга төшәр алдыннан Салих канәгать хәлдә уйлап куйды. Шөкер, туган җир белән күрешүе нәкъ ул исәпләгәнчә килеп чыкты. Сәламең дә бирде, күрәсең дә күрде... Инде менә кешеләр белән очрашуы ничек булыр? Дөресен әйткәндә, Салих шактый ук шүрләп тора. Чакырган булсалар да, әнисен күмешергә кайтмады бит... Бердәнбер абыйсын да җирләшә алмады ул... Кайта алмавын туган-тумача, кешеләр ничек бәяләр? Ходайның галәмәте, бер килмәсә килми икән шул ул. Әнисе дөнья белән хушлашканда ул аягын сындырып гипста ята иде. Ә абыйсының юл фаҗигасе корбаны булуын белгән көннәрдә үзе житәкләгән, хуҗасы да булган агач эшкәртү ширкәтенең язмышын хәл иткән бик хәтәр суд мәшәкатьләре очланырга тора иде. Үзе юкның күзе юк... Каршы яктан әллә нинди мәкерлекләр күтәргә була иде. Кайтып кайгы бүлешергә теләсә дә, матәмгә катнаша алмады шул... Хәер, бер читкә чыгып киткән кеше атаана, туган-тумача, авылы каршында бер гөнаһсыз кала аламы икән? Йә хат-хәбәре, сәламе юк, йә үзеннән бер сынык ярдәм, бүләк-мазар килми... Авыл үзенчә уйлый, исәпли шул ул. Төсе белән булыр-булмас, юк-бар белән тулыр-тулмас чемодан тотып читкә киткән егет-кызның үз тормышын корып, түл-мамык җыйганчы кичергән авырлык, газапларын төшләрендә дә күрми шул беркатлы авыл...

Хәер, юкка шикләнгән, урынсыз көяләнгән икән Салих! Каршында кисәк пәйда булган кунакны күреп, апасы Факиһә шатлыгыннан егылып китә язды.

—Ай, энем, сине Пермь урманнарында аюга әйләнгәнсең, юкка чыккансың дип курыккан идек. Менә күрешү язган икән, исән-сау икәнсең бит,—дип такмаклый-такмаклый Салихның башын ихластан күкрәгенә алып кысты. Аннары, балалар кебек, яшьле күзләрен йодрыгы белән сөртә-сөртә, товар караган кебек, тартынмый-нитми баштан алып аягына кадәр энесен күздән кичерде.—Сөбханалла, машалла, күзләр тимәсен, бигрәк матур, дастуйный иркәй булып киткәнсең, энекәем, бигрәк тә килешлесең, хас нәсел чәчәге инде менә!

Салих шул кичтә үк малае Рәлиф белән кардәш, тумача тиешле кешеләрне күреп, һәркайсына мул гына бүләк, күчтәнәчләр өләшеп, хәл-әхвәл белешкәч һәм каршы яктан да үзләренә карата изге теләкләр, рәхмәтләр ишеткәч, ниһаять, өстеннән тау төшкәндәй, бөтенләй тынычланып калды, чын кунак кыяфәтенә керде. Ашау байдан, үлем Ходайдан, дип рәхәт кичереп ялын уздырасы гына калды бу кунак иргә.

## 2

Килмәккә кайтуына өчме-дүртме көн үткәч, Салихны, апасы белән аның җәмәгатен һәм тагын берничә парны район үзәге булган Осланга кичке чәйгә алып киттеләр. Монда абзыйсының өлкән малае Шәүкәт төпләнгән икән. Бу олан Салихның хәтерендә букча сөйрәп мәктәпкә беренче сыйныфка төшкән чагы белән язылып калган. Туфлиләрен вакса белән ялтыратып, шнурларын бәйләп, бәләкәй энекәшен үзе дә озатышкан иде... Йа Алла, сукмагыңнан каршы килсә, танымассың да... Дөрес, атасы кебек кин җилкәле, олпат гәүдәле, салмак... Ә менә күзләре Миңлегөл җиңгәчәсенеке икән. Сөеп карый торган, дымлы, каймалы көрән күзләр... «Исәнме, Салих абый»,—дип ул ирләрчә кайнар итеп кочаклап алгач, кисәк Салих үзенә энекәше генә түгел, ә абзасы һәм җиңгәсе дә килеп сыенганнар кебек итеп тойды. Кинәт күзенә яшь бөркелде. Нидер әйтеп, нәрсәдер искәртеп тизрәк әлеге халәтеннән арынырга омтылды Салих:

—Кай ара болай үсеп өлгердең әле, Шәүкәт? Молодец, безнең сөяк, Хафизуллиннар сөяге...

—Тырышабыз инде!—дип җорланып җавап кайтарды эне кеше.

Шәүкәт атасы кебек шофер, районның ниндидер башлыгын йөртә икән. Мәгәр йорт-курасына һич тә сүз тидерерлек түгел, булдыклы хуҗа кулын сукыр да тоярлык. Бакча тулы—яшелчә, гөлләрнең дә ниндиләре генә юк. Иркен һавалы агач өй дә шәһәрчә зәвык белән бизәлгән, ягымлы көйләр аһәңе белән монда яшь, чибәр, сылу хуҗабикә сыны, тавышы ярашып тора... Салихның ишеткәне бар: хәләл җефетләрне кушканда Ходай бер матурга бер ямьсез, бер ялкауга бер уңган, бер мокытка бер елгырны пар китерә икән. Мәҗлестәгеләрне тыңлап, йә баш кагып, йә елмаеп ала торган Шәүкәт янәшәсендә Наилә хас кенәри кошы. Күздә нур, йөздә балкыш, ә тел туктаусыз сайрый... Рәвешенә карап укытучы-мазар булыр бу, дип уйлаган иде Салих. Тик фаразы дөрескә чыкмады, Осланның май заводында техник-оператор икән ул. Кыскасы, Наилә киленнең булмышы һөнәрдән түгел, ә асылдан килә дигән сүз инде бу.

Һәм менә шул Наилә, чәйләр, сыйлар көйләп йөргән мәлдә, тәмле теле белән олы кунакның ис-акылын җибәрерлек хәбәр китереп салды:

—Салих абый, бездә бит әле синең белән бер ханым кызыксына... Чибәрнең дә чибәре инде үзе... Мастер булып эшли... Сәрви исемле.

—Ялгышасыңдыр, килен,—диде Салих.—Минем Осланның май заводы белән һич алыш-бирешем булмады.

—Юк!—дип шундук аркылы төште Наилә.—Сәрви ханым синең белән, Салих абый, май заводында түгел, кирпеч заводында очрашкан бит. Мәктәптә укыган чагыгыз булган... Җәйге ялда эшләгәнсез... Кирпеч ташыгансыз... Исенә төшәме?

Салих Наилә әйткәннәрнең чынлап та үзенә, үткәннәренә төбәлгән булуын абайлап алды. Хәтергә кагылып, җебен тартканда, алга барысы да ап-ачык булып килеп басачагын да тойды ул. Тик саксыз кагылуның, ярага әрнү китерүе кебек, күңел дөньясын да актарып салуы мөмкин иде. Хәтер җебенә үреләсе, тынычлыгын җуясы килми иде әле Салихның. Әмма Наилә алдында, мәҗлестәгеләр каршында ул сүзсез калуны да килештермәде.

—Әйе, хәтерләдем, куышып йөргән идек шул,—дип салкын гына, битараф кына җавап кайтарды кунак.

Әмма Салихның авызыннан сүзе төшеп җитмәде, чәй-мәй ләззәтеннән кәефе күтәрелгән җизнәсе Минедар эләктереп тә алды.

—Иң матур ярату—әнә шул... яшь чакларда... бер-береңне куышып йөрү инде ул, каениш!

Һәм мәҗлес гөр килеп көлде. Бу—ике арада сүз көрәштерүнең Наилә файдасына мәрә ыргытылуы белән бер иде. Зирәк килен моны шундук төшенеп алды, һәм мал куган кебек, Салихны Сәрви белән бәйле истәлекләр дөньясына ныграк әйди барды.

—Сәрви ханым белән былтырдан бирле серләшәбез инде. Минем Килмәктән икәнемне белгәч тә, гел сорашты. Салих, Сабит исемле малайлар белән кирпеч заводында эшләгән идек. Шуларны беләсенме, диде. Мин Салих жизниләр гаиләсендә килен бит, дигәч, гаҗәпләнүенә чик-чама булмады. Гел сөйләтте. Өйләнгәнме, хатыны кем, кунакка кайтканнары бармы, дип сораша. Мин инде нәрсә белсәм, шуны сөйләдем. Ә белгән чамалы инде, өйдә ишеткәннәр генә...

—Алай..—дип сузды Салих.—Тик, килен, чибәр апаң—минем өчен дә карурман бит әле...

—И Салих абый, аның күргәннәре!—дип, кайнарланып дәвам итте Наилә. Авылларындагы бер хәрби кешегә кияүгә чыккан булган. Прапорщикмы шунда... Ир кеше Монголиядә хезмәттә булган, алып киткән Сәрвине. Әллә кайда чүлдә торганнар. Шул хәтле каралык икән анда... Аннары, СССР беткәч, ире ничектер Америкага китү җаен тапкан, ди. Сәрви ханым китмәгән, иреннән аерылып имчәк баласы белән янә Элмәлегә кайткан. Әти-әнисе белән тора, баласы үсә. Әй, кызы матур да соң! Инде мәктәпне бетереп килә...

Наилә сөйли торды, Салих жизнәсенең төрле-төрле хатирәләрен уята торды. Чынлап та, һәр кеше үзенә бер утрау икән, материк, Америка... дип уйлап алды кунак... Күреп бер сөйләшсәң, зыян итмәс иде шул...

Ну, Наилә, шайтаннарың бардыр, югыйсә, кеше күңелен шулай ачык күрә алмас идең—кунакларны Килмәккә озату ыгы-зыгысында ул җаен туры китереп, Салих жизнәсенә пышылдады:

—Дүшәмбе эштән соң Сәрви апаны алып кайтам, килерсез, ярармы?

## 3

Салих уй-хыял дөньясына чумып күңел нечкәртә торган кешеләрдән түгел. Берәр эш белән мавыга да, шуна бирелеп, шуны уйлап, юанып, һәртөрле авыр кичерешләрдән дә арына белә иде ул. Тик апасының ипле-көйле йортында мавыгырлык нинди шөгыль бар соң? Малаен утыртып, Сөлчәгә балыкка барып кайтты. Җәяүләп, ялгызы гына олы-кечесе белән сәламләшеп, хәл-әхвәлләр сорашып урам да әйләнде. Әмма уенда һаман киленнәре Наилә сөйләгән сүз булды, күзалдына әледән-әле, дулкыннар өстендә чайкалгандай уйнаклап, бер шәүлә килеп басты.

Сәрви...

Сирпеп караучы йомшак, сусыл конгырт күзләр җанланды. Ачык аксыл чырай елмайган халәттә хәтердә янарды. Ярым бөдрәләнеп, купшыланып торган сары чәч калын толым булып сул күкрәк өстендә ята.. Уйнаклап торган какча, җыйнак гәүдәгә җайлашып, бу толым песи койрыгы кебек уйнаклап ала... Күңелдә әнә шулай җисми, анык кыяфәт ала барган Сәрви очкынлы карашы белән ярым үчекләп, ярым көлеп: «Дон Жуан! Нихәл, Дон Жуан!»—дип тә кычкырып куяр төсле.

Салихның уйларын бөяләп торган буа ерылды. Ул, язгы ташкын иркенә бирелгән кеше кебек, Сәрвигә, үзенә, яшьлек елларына кагылышлы истәлекләр агышына иярде...

Салихның Сабит исемле яшьтәше белән икенче көн кирпеч заводына эшкә чыгуы иде. Завод димәсәң, хәтере калыр. Килмәк авылы янәшәсендәге битләүдә балчыкны кирпеч сугу өчен яхшы дип тапканнар да, шунда районның төзелеш оешмасы әтмәлләп куйган такта сарайлар тезмәсе

инде ул. Берсендә кирпеч сугалар, икенчесендә шул кирпечне киптерәләр, ә өченчесендә яндырып-чыныктырып төрле төзелешләргә озаталар үзен. Берсеннән-берсенә ташыйсың, ыргытасың, тезәсең дә сүтәсең кирпечләрне... Эше авыр, ялыктыргыч, ә акчасы аз. Шуңа күрә завод эшчегә туймый. Салихларны монда мәктәп директоры Мөстәкыйм абыйлары димләде. Карап торуга ак чырайлы, күзлекле, буйчан бу ир зыялы төсендә булса да, әллә чынлап бер исәр, әллә замана тәтене белән ысланган бер романтик иде, мәктәптә олысыннан башлап кечесенә кадәр һич тынгылык күрсәтмәде. Көз булса, укучыларны бәрәңге, кишер җыярга дип басуга озатудан туктамады ул. Кышын балалар колхоз өчен көл, күмер җыюдан арына алмадылар. Ә яз килгәч мәктәп коридорына «Җәйге каникулларны—социализм төзелешенә!» дигән лозунг элдертә иде Мөстәкыйм Гомәрович. Һәм китә укучыларга пионер, комсомол путевкалары өләшү. Салихлар классындагы 22 егет-кызны да ике-өч көн эчендә йә сабанчы, йә йөкче, йә кошчы итеп, басу-кырларга, фермаларга, ындыр табакларына тараттылар. Ә кирпеч заводына булган комсомол путевкасы Салих белән Сабит "бәхете»нә эләкте: «Ярышларда җиңгән титуллы спортчылар... Әхлаклары югары, булдыклы егетләр...» дип, комсомол җыелышында аерым игътибар итте аларга Мөстәкыйм Гомәрович.

Комсомол путевкасы, имеш.. Төкергән булыр иде Салих әлеге бүре билетына. Тик киләсе елда шул путевканы биргән директордан аттестат, характеристика аласы бар шул. Районның комсомол оешмасыннан эләктерергә хыялланган юллама да кодрәтле Мөстәкыйм Гомәрович фатихасы белән генә биреләчәк.

Теләсә дә, теләмәсә дә кирпеч заводына эшкә чыкты Салих. Кичә көнозын кирпеч төялгән вагончыклар эттеләр. Арыткан, бил, аяклар әрни. Бүген дә шул шайтан арбасына җигәрләр микәнни?

Кирпеч пресслау цехына җыелган эшчеләр радио дикторы Левитанныкы кебек көр, яңгыравыклы тавышлы, озын буйлы Әхтәм-мастердан боерыклар алып тора иде. Төенчекләр тоткан яшь кенә ике кыз килеп керде. "Антонимнар», дип кисәк уйлап алды Салих. Чынлап та, кызларның берсе аксыл, какча, ә икенчесе кара һәм юантык иде.

—Сез кемнәр?—дип сорады Әхтәм-мастер төркем каршында шактый ук каушап һәм аптырап калган ят кызларга карап.

—Мин—Сәрви, иптәшем—Улина,—диде аксылы.—Без Элмәледән. Сәлəнтәй Митрофанович заводка эшкә җибәрде.

Карасы, юантык гәүдәлесе сүзне ачыклауны кирәк тапты бугай, ашыгып өстәп куйды:

—Пез укучылар, сезкә ярдәмгә килдек...

Салихның янәшәсендәге Сабит көлкедән буылып иелде дә, иптәшенә пышылдап алды: «Малай, боларны да комсомол путевкасы белән җибәргәннәр бит...»

Ярдәмгә килгән кызлар оптимизмы мастерның мыегын да селкетмәде. Киресенчә, беркавым аларга карап торгач, ул гасабиланып, артистларча ике куллап башын тотты һәм шактый кырысланып әйтеп куйды:

—Соң, Сәлəнтәй абыегыздан мин кызлар түгел, малайлар, егетләр сорадым ласа...

—Малайларны колхоз җибәрми. Анда плугарьлар, грузчиклар, повозка йөртүчеләр кирәк,—диде аксыл чырайлы кыз мастерның пошынуына һич исе китмәгән кыяфәт белән.—Сәлəнтәй Митрофанович әйтте: заводта машиналар, эш җиңел, кнопкаларга гына басып торырга, диде.

Әле генә болыт кыяфәтле Әхтәм-мастерны алыштырдыларммыни—озын буе белән чайкалып, эчен тотып көлә үк башлады:

—Кнопкаларга гына басаргамы? Коммунизмдагычамы?

Мастерга карап, пресслаучы Гайшә апа һәм берничә хатын-кыз да елмаешып алдылар. "Ийе шул, Килмәк заводында коммунизм, кнопкаларга гына басып эшлибез», янәсе...

—Ярар, сенелләр,—диде Әхтәм-мастер кинәт янә үзгәреп, житдиләнеп.—Килүегезгә рәхмәт, тик Килмәккә әле коммунизм килеп житмәгән шул, кнопкалар бездә юк. Барыгыз кайтыгыз! Балигълык яшенә житмәгәнсез, берәр нәрсә булса, бәлагездән баш-аяк, жавап биреп бетерә алмассын... Кайтыгыз, кайт!

Әхтәм әлеге кызлар белән эшне беткәнгә санап, эшчеләргә янә үз сүзләрен житкерергә керешкән генә иде, кинәт Сәрви кызуланып анын каршына килеп басты һәм катгый тавыш белән әйтеп салды:

—Без кайтмыйбыз, кнопкагыз булмаса да эшлибез...

Һәм Сәрви янәшәсенә килеп елышкан Улина да еламсырап әйтте:

—Класста пездән көләрләр. Эштән качканнар, диярләр. Сәләнтәй Митрофанович та яратмас. Эшләтегез пезне!

Кырыс мастер сүздән туктап, аптыраулы кыяфәттә торып калды. Әлеге кызларнын сәер тотышы төркемне дә гажәпсендерде бугай, тынып калдылар. Һәм әлеге тынлыкта сүзчән Гайшә апа ярып әйтеп салды:

—Ну Элмәлеләр, ну кире халык! Боларнын кирелеге мангайларына ук язылган бит...—Һәм аннары кызларга карап, аналарга гына хас йомшаклык белән өстәп куйды—сон кызкайларым, бездә эш бик авыр бит. Түзмәле түгел бит. Бу бәләкәй кулларыгыз белән монда нәрсә генә майтара алырсыз сон сез?

Гайшә апаны жентекләп тынлаган Әхтәм мастер да анык карарга килде булса кирәк. Жәһәт кенә рельслар өстендә тезелешеп торган вагончыкларнын берсенә барып тотынды һәм кызларны үз янәшәсенә чакырды:

—Ягез, сенелкәшләр, эшлисез икән, менә сезгә эш—вагонетка. Кузгатыгыз шуны!

Салихнын хәтеренә бик яхшы уелган: менә Сәрви белән Улина төенчекләрен ашыгып жиргә куялар, вагончык янына киләләр. Менә Улина вагончыкнын алдына төшә, Сәрви анын артына тотына һәм алар үжәтләнеп, көчәнеп авыр тимер әржәне кузгатырга дип талпыналар. Менә вагончык, кузгалырга һич теләмәгән тискәре үгез сыман, авыр гына ынгырашып куя, рельслар буенча берничә метрга гына тәгәрәп китә... Һәм шунда берничә минут эчендә уфылдап тын алган, кызарышкан кызларга карап Әхтәм мастер нинди дер тантана белән әйтә: «Бу—әле буш вагонетка, кирпечлесен сез кузгата да алмыйсыз бит».

Элмәледән килгән чуаш кызларына төенчекләрен тотып кайтып китүдән башка чара калмаган иде инде. Әмма шунда көтелмәгән бер хәл булды. Сабит ничектер, кабыргасына кемдер төртеп кузгаткан кебек калкынып, мастерга якынлашты һәм: «Әхтәм абый, эшлиселәре бик килә икән, калсыннар сон, без парлашырбыз»,—дип тыныч кына әйтеп куйды.

Әхтәм мастер башта Сабитнын сүзләрен акыл белән түгел, йөрәк белән кабул итте булса кирәк. Югыйсә ул бөтенесен көлдереп: «Сезгә инде парлашу гына булсын. Бөтен уегыз шул парлашу!»—дип кычкырмаган булыр иде. Аннары аңышты, ахры, житдиләнеп, «Ничек парлашу ул, Сабит энем»,—дип, хәлгә төшенүне кирәк тапты.

—И Әхтәм абый,—диде Сабит.—Үртәрлек нәрсә бар сон? Вагонетканы Салих белән икәүләп эттек. Ә хәзер Салихка да, мина да напарниклар ясап кызларны куясыз да: сарыклар да исән, бүреләр дә тук була...—Һәм Салихка карап сорады ул.—Малай, син каршы килмисенме?

—Юк!—дип кистереп әйтте Салих.

Сабитнын бу тәкъдиме кызларны коткарды, алар эштә калдылар, егетләр белән бергәләшеп кирпеч ташый башладылар.

## 4

Салих иртә уянды. Факиһә апасының купшы әтәче иртәнге азанын әйтеп, йортта мал-туар, кош-корт белән әвәрә генә килә башлаганнар иде, кунак та аягына басты. Зәңгәрсу спортчылар трикосын киде, аягына җинел башмаклар элде һәм тәмәкесен кабызып, ихатага чыкты.

—Кая болай бик иртә, энем?—диде апасы сөтле чиләген күтәреп аның каршысына килешли.

—Йөреп кайтыйм әле, чишмә, тугайлар үз урыннарындамы икән?

—Бар, энем, бар! Туган җир—күңелгә сихәт,—диде апасы.—Сарайда кайдадыр җизнәннән кармаклары да тора. Алмыйсыңмы? Кайчагында кызылканатларны чиләге белән күтәреп кайта үзе. Бәхетеңне сынамыйсыңмы?

Факиһә апасы сөйләнә калды. Салих урамга чыгып, эре-эре адымнар белән үз юлына юнәлде. Аягы тарткан тараф—кирпеч заводы. Кайчандыр Салих исемле малай иртән торып шунда тәпили иде бит... Ничә еллап вакыт үтте икән? Ир исәп-хисапны ярата. Авырсынмыйча чутлап та чыгарды: егерме өч еллап булыр. Хәтта шешә белән сөт, ипи, кыяр сыман ризык салынган сумкасын күтәреп ничә рәт эшкә чыгуын да ачыклый ала икән ул. Өч ай ялсыз-нисез эшләделәр бит. Димәк, 90 көн яшь Салих Килмәк очындагы әлеге заводка тәпиләгән...

Менә монда, урам очланып килгән төштә, нәкъ егерме өч ел элек, Сабит басып торыр иде. Кулында шулай ук ризыклы букча. Йөзендә елмаю: «Арумы, малай?»

Әйтәсе сүзләр, бүлешәсе серләр әллә ничаклы—юлның калган өлеше сизелми дә.

—Салих, сиңа ничек? Безнең бу Элмәле кызларының егетләре бар микән?

—Йөриләр микән дисеңме, Сабит? Ә нәрсәгә ул сиңа? Ошый икән, тот та кыс! Өйрәнчеккә ярыйлар... Безнең авылда кемнең чуаш кызына өйләнгәне бар? Ә Сәрви матур! Безнең авылда андый чибәр кыз юк та. Ул—күзләре... Ул—кулының йомшаклыгы... Ул—йөреш!

—Салих, ә нишләп чуаш кызына өйләнмиләр соң? Үзең үк мактыйсың ласа, матур дисең, ошый дисең...

—Юләрләнмә, Сабит! Ошату—бер нәрсә, өйләнү—икенче. Чуаш безгә чит халык ул, беләсеңме? Ә син нәрсә, ник болай бик тирәнгә төштең әле... Гашыйк булдыңмы әллә? Сәрвигәме? Ошый икән, әйт. Сәрви сиңа булыр. Миңа Улина да ярый. Өйрәнчеккә! Үпкән-кочкан, җилгә очкан...

Алда калкулык. Шуңа күтәрелгәч, иркенлек, киңлек җәелеп китә. Малайлар каршына, җир астыннан чыккандай, ике яшь кыз килеп баса.

—Авани херзәми![1]—дип шатланып, кул болгап кычкыра Сабит.

—Авани! Авани!—дип көр җавап кайтара Улина.

Сәрвинең дә юри югары тонга куелган көмеш, яңгыравыклы тавышы ишетелә:

—Килмәк егетләренә—иртәнге саф комсомол сәламе!

—Сәламеңә—сәлам!—ди Салих һәм шул ара кызларның берәрсенә елышып, куштанлана ук башлый.—Улина, кичә тозлы гөмбәң бик тәмле булды. Бүген дә алып килдеңме, матурым? Тик Сабитка күрсәтә күрмә, сосып бетерер. Икәү генә ашарбыз, яме, матурым?

—Кыяр бирсәң генә ашарсың,—дип шыркылдый Улина.—Түлке син, Салих, кешенекен ашарга яратасың, үзеннекен пирмисең...

—Дөрес, Улина, Ходай бүлешергә кушкан,—дип сүзгә кушыла Сабит.

[1] Исәнмесез, кызлар!

—Һи, кыяр, гөмбә ризыкмы? Минә минем шикалат ашыйсым килә. Шикалат!—ди Сәрви юри назланып.—Сабит, син кайчан кавалер булырсың, мине шикалат белән сыйларсың?

—Завод зарплат бирсә, Килмәк кибетендәге 10 кап шикалат берсүзсез синеке, Сәрви туташ!—дип җавап кайтара Сабит.

Күнелле моназара күпме дәвам итәр иде, Алла белсен, тик пресслау цехыннан, әнә, чаң суккан тавыш ишетелә, Әхтәм мастер халыкны эшкә чакыра һәм Салихлар да үзләренең эш урыннарына ашыга...

Тик яшьлектәге юл хәзер инде куе үләнгә күмелгән. Йөк машиналары, арбалар гына түгел, халык та күптән инде бу юлны таптамый, күрәсең... Салих элекке завод ихатасында тик хәрабәләр, ватык-җимерекләр генә күрергә әзерләнгән иде. Әмма ни гаҗәп, монда адәмнән биек билчән, алабута, кырмавык туйрасы тантана итсә дә, озын завод каралтылары әле исән булып чыкты. Рельслар да үз урынында, тик тут кына каплаган аларны... Ә пресслау цехына кергәч, элекке механизмнарны һәм тәртипле тезелгән вагончыкларны күреп тәмам шаккатты Салих. Әйтерсең, кешеләр каядыр ялга гына киткәннәр, менә кайтырлар да янадан шау-гөр килеп тәгәрмәчләр әйләнә башлар...

Салих мәһабәт пресс машинасы янына килеп, аны тоткалый, боргалый башлаган иде, кемдер бик ямьсез итеп кычкырып җибәрде:

—Кем анда? Тукта!

Ялт итеп артына борылса, мылтык күтәргән кожанлы, итекле һәм кырыс чырайлы кешене шәйләп алды Салих. Әлеге кеше җәһәт кенә аның янына килеп басты, күзләрен кадап бер алдына, бер артына төште һәм инде мылтыгын иңенә элә-элә аптырап сорап куйды:

—Кем дип беләбез инде сине, господин? Бурмы, кунакмы, дигәндәй..

"Левитан!.. Левитан тавышы...» дигән уй кисеп үтте Салих зиһенен. Әхтәм мастер ләбаса бу!

—Саумы, Әхтәм абый!

—Салих энем, синмени бу?—дип кисәк җилләнеп, шатырдатып кунакны күкрәгенә кысты Әхтәм карт.—Кайтканыңны ишеткән идем шул. Тик килер дип кенә белмәгәнмен. Иртә дә бит әле. Бурмы әллә дим. Төне буе йөриләр ласа. Тактасын да, тимерен дә чәлдерергә генә торалар бит мәлгуньнәр.

Салих кесәсеннән затлы тәмәкесен, чакмасын чыгарды һәм икесе дә кин, шома сәкеле эскәмиягә кунаклап, тәмләп тарта башладылар. Әхтәм картны Салихның эшләре кызыксындырды. Ерак Пермьдагы зур бер заводның хуҗасы булуына, эшләре ырамлы баруына ихлас шатланды ул. «Килмәктән дә шундый зур промышленник чыгар икән?!» дип тел шартлаткалады. Инде Салих үз чиратында мондагы хәлләр турында сорашырга керешкәч, Әхтәм карт ярсып йодрыгын болгады:

—У...у, бу буржуйлар, нәфесләренә тончыккырылары, бутадылар бит замананы! Элек начармы-яхшымы, авырмы-җиңелме дигәндәй, төртергә үз вагонеткабыз бар иде. Ә хәзер... Әнә барысы да тупикта, күгәреп яталар. Ул атаны, кыз ананы белми, бөтенесе әзер акча артыннан чаба. Хөкүмәт тә безнең өскә налог артыннан налог ыргытты. Электр хакын дүрт-биш тапкырга күтәрде. Әйтерсең, бу илдә без—туземец! Хәерчедән акча сыгалар. Аннары көчләп банкрот ясадылар, кирпеч сугудан туктадык, энем. Мына хәзер берүзем охранник булып заводны саклыйм... Өметсез—шайтан гына. Кем белә, тормыш гел шулай тормас та. Может аякка да басып китәрбез. Безнең кирпеч яхшы бит, Салих энем. Һәм арзан да! Авылга кара син, күпме кеше безнең кирпечтән йорт корды. Алыпсатар кирпеченнән ызба түгел, пич тә салалмыйсың бит хәзер. Көтәм әле, бурлардан саклыйм әле заводны. Мына син үткәнеңне сагынып килгәнсең бит. Шулай кирпечен

дә сагынып килерләр заводның. Табылыр әле бер хуҗа...

Салих кара тутлы, чаларган чәчле Әхтәм картка күз салды. Элек кырку табигатьле һәм шактый ук дорфа күренгән бу кеше аның алдында бөтенләй икенче сыйфатлары белән ачылып китте. Менә шундый ныклап таяныр кешеләре бармы Салих хуҗаның? Күпме?

Әхтәм карт өенә, иртәнгә чәйгә китәргә җыенды. Салих завод ихатасын карап чыгарга ниятләп кузгалган иде, ниндидер ашыгыч йомышы бар кебек, аны Әхтәм карт туктатты.

—Ни, Салих энем, Сабит янына бардыңмы әле, сугылдыңмы син аңа? Көтәдер ул сине. Бигрәк җан дуслар идегез бит?

—Барам, Әхтәм абый!—диде Салих һәм ашыгып тәмәке капты, ут элдерде.

Кай игы беләндер әсирләр барагын хәтерләткән озын рельслы киптерү цехына кергәч, янә башка дөнья кешесе итеп тойды Салих үзен. Әнә бит, чынлап та, сарай ярыкларында уйнаган җил сызгыруына кушылып рельслар буенча элдерткән буш вагончык чыжылдавы ишетелә. Яшь тай кебек уйнаклап, Салих йөгерә. Ә вагончыкка менеп кунаклаган яшь, аксыл чырайлы кыз, чәчләрен җилгә сибеп, көмеш, яңгыравыклы тавышы белән аны һаман әйди:

—На, на, на! Һәй, жилләр, тотыгыз безне!

## 5

Сабитның "кызлар белән парлашабыз» диюе Салихның күңелен татлы итеп кытыклап куйды. Ул инде каршыдагы Элмәле кунакларын яшертен генә күзәтергә дә керешә. Сәрви дигәне, шиксез, чибәр, кәртинкә кебек. Тик бигрәк ябык, арык бит бахыр. Моның белән ничек вагончык төртәсең? Улинасы таза, балтырлары да йөк атыныкы кебек бүлтәеп тора. Эш рәтенә бер төшенеп алса, вагончыкны җилтерәтә генә инде бу! Әмма, абау... җәлпәк биттәге танавы бигрәк килешсез. Үрдәкнеке кебек киң, җәенкеме, әллә зурмы, озынмы шунда. Кыз булгач, күзне ала алмаслык булсын инде ул..

Тик парлашу көтмәгәнчә бик гадәти килеп чыкты.

—Бисмилла! Ягез, башлап җибәрик,—диде Гайшә апа һәм бирчәйгән, ирләрнеке кебек зур кулы белән кнопкага китереп басты. Куәтле пресслау машинасы җир калтыратып, дөбердәп, уфылдап эшләп китте. Ул транспортерлары белән балчыкны бер яктан суыра торды, икенче яктан пар бөркеп торган ялтыравык кызгылт массаны төртеп чыгара да башлады. Гайшә апа жонглер өлгерлеге белән гильотина арбачыгын йөгертә, ә таслап киселгән кирпечләрне югары очның Гайни Фәһимәсе вагонетка тактасына җайлап тезә тора. Менә икенчесе, өченчесе кирпеч белән тула. Һәм Фәһимә соңгы, алтынчы тактаны вагончыкка кертеп утырткач, Гайшә апа телгә килә:

—Салих, беренче арба синә. Напарнигың кем? Кем белән парлашасың?—Тегесенең ык-мык килеп торуын күргәч, ачуланып кычкыра.—Нәрсә инде, загска барасызмы әллә? Әй, ак кыз, менә бу егет белән парлаш!.. Ярар, «Горько!»—дип кычкырмыйбыз, алыгыз арбаны!

Салихта шырпы булып сөенеч уты кабынды. Әйе, янәшәсендә Сәрви булуын теләгән иде ул. «Рәхмәт, Гайшә апа!» Ул, вагончык алдына төшеп, инсәләренә калын аркан камытны элде һәм Сәрви әрҗәгә килеп тотынуга кычкырып куйды:

—Әй, ухнем!

Вагончык кичә Сабит белән төрткән кебек түгел—шактый авыр, әмма түзәрлек, арттан чибәр кыз бара бит..

—Сәрви, син бик көчәнмә, үз җаең белән эт!

—Ярар,—ди күндәм тавыш.

Вагончыкны рельслар буйлап күнелле генә тәгәрәтеп пресслау цехыннан ихатага чыктылар. Көмеш тасмалар бер-бер артлы тезелеп киткән киптерү цехлары янәшәсеннән үтә. Менә берсе, менә икенчесе. Өченчесе—аларныкы. Әхтәм мастер кирпечләрне бүген шунда ташыта. Ләкин анда керү өчен вагончыкны карусельгә утыртып туксан градуска борып куярга кирәк. Монысы ин авыры. Боруын бордылар, әмма цех линиясенә чыга башлаганда ал тәгәрмәчләр киртеккә килеп төште. Кызулап килергә иде дә, булмады шул. Хәзер инде ни алга, ни артка... Салих бар куәтенә камытны тарта, Сәрви көчәнеп-көчәнеп арттан этә, әмма вагончык кузгалырга да җыенмый. Ни эшләргә соң? Салих эчтән Сабитны, Сәрвине, үзен, бар дөньясын черетеп сүгә. Вәт хурлык... Кемнедер ярдәмгә чакырырга кирәк инде!

Янына бите кызарган, мангаен тир бөрчекләре баскан Сәрви килеп басты:

—Сез физика укыдыгызмы?—диде ул тыныч кына.

—Йә, укыдык та ди...—Салихның гаҗәпләнүенә чама юк.—Физиканың бу хәлдә ни катнашы бар соң?

—Соң безгә хәзер рычаг кирәк. Рычаглар белән Египет пирамидаларын салганнар...

Чынлап та! Салих тирә-юньнән лом, торба, йә булмаса кусәк табып алырга тиеш. Әһә, менә озын гына арматура кисәге ята икән. Шуны вагонетка күчәре астына тыгып икәүләп күтәргәннәр иде, вагончык берни булмагандай, рельс өстенә менде дә басты!

—Менә бит, котылдык!—диде Сәрви һәм сөенеп балаларча кулларын чәбәкләп алды.

—Ә син молодец!

Сәрви Салих каршында бер карыш үсеп китте. Кара син бу чикерткәне, борынга чиртте бит... Беләге юан берне егар, белеме юан меңне егар диләрме әле?..

Вагончыкны тигез, шома цех рельслары буенча тәгәрәтеп, киптерүчеләр кулына китереп тапшыруның инде бер кыенлыгы да булмады. Салих каршы юлда торган буш вагончык янына барып камытны иңенә элде дә, Сәрвигә эндәште:

—Әйдә, Сәрви, утыр. Җилдерәм!

Һәм, чынлап та, кыз әрҗәгә менеп кунаклауга, ул вагончыкны рельслар буенча җилтерәтеп чаптыра башлады...

Кирпеч заводындагы иң күңелле мәл—төшке аш вакыты. Әхтәм мастер чаң сугуга, яшьләр тишек-ярыклардан иркенгә пырхылдап очкан чыпчыклар сыман, завод ихатасын ташлап Сөлчә ярына чабышалар.

—Шә-ә-әп!—дип кычкыра Салих, күлмәк-башмакларын йөгергән килеш чөя-чөя һәм мул сулы завод буасына сикерә. Аның артыннан Сабит суга ыргыла. Баштарак кызлар куаклар ышыгына качып чәпердәшкәннәр иде. Тик Салих яннарына барып, чуртан кебек боргалана башлагач, кызлар чыр-чу килеп аның белән уйнарга, су сибешергә керештеләр. Гаурәт ояты калмады да бугай. Бит, кулларын юарга дип буага төшкән Гайшә апа суда бер-берсен куышып, кычкырышып үртәшеп уйнаган яшьләргә карап бот чапты: «Әстәгъфирулла, боларга коммунизм булган бит!»

Судан чыккач, алар яшел чирәмгә чүмәшеп уртак табын коралар. Билгеле, берәү дә ипи-сөт, күкәй кебек ризыкларны кеше авызыннан тартып алмый. Бүлешү, сыйлашу тозлы кәбестә, маринадлы гөмбә, яшел кыяр, кояшта пешкән помидор кебек тәм-томга гына кагыла. Әнә, Сабит букчасыннан төенчек чыгара. Әнкәсе какланган каз боты куйган икән.

Хуш исле, авыздан сулар китергән кызгылт итне пәкесе белән кискәли дә кызлар алдына этәрә:

—Рәхим итегез, туташлар!

—Ә мина?—ди Салих юри нәүмизләнеп.

—Сиңа тәмнишканың иң зурысы!—Сабит дустына ялар өчен сөяк суза.

Кызлар да үз чиратларында табындашларны сыйларга дип ризыклар алып килә. Бигрәк тә аларның төенчекләре чикләвек, кыяр, помидор ише тәм-томга бай була. Сабит берчак көлдереп тә алды: Элмәле Килмәккә караганда географик киңлекнең көньягындарак урнашкан икән. Шуңа яшелчәләр иртәрәк өлгергән Сәрвиләр авылында...

Табын тирәсендәге көндәлек гәпләр кызыклы бер ачышка китерде: барысы да тугызны тәмамлап унынчы сыйныфка күчкәннәр, яренгә кулларына өлгергәнлек аттестаты аласы кешеләр икән. Бу аларны тагын да якынайтты. Укыйсы фәннәр, укытучылар, имтиханнар һәм бигрәк тә алда торган тормыш юллары хакында сөйләшү, хыяллану күбәеп китте.

Әмма, кызганыч, нәкъ сүз күбәеп, бәхәс кызып киткән мәлдә пресслау цехында чаң кагыла—эшкә!

—Улина, әйдә, матурым, конвеерда безнең вагонетка, соңарсак, Гайшә апа тетмәне тетәр.—Юк, юк! Исемнәрне һич бутамый Салих. Аның хәзерге иптәше Улина. Ә чибәр Сәрви Сабит белән парлашкан. Тукта, бу үзгәреш кайчан булды һәм нилектән килеп чыкты соң әле ул?

Салих янә авызына сигарет алып капты, ашыгып ут элдерде. Капкачлар белән томаланган озын киптерү цехыннан кояш нуры, яктылык ишарәсе табарга теләгәндәй, хәтереннән әлеге сорауны ачыкларга омтылды.

**6**

... Бу юлдагы карусель чынлап та теңкәгә еш тия. Пресслау цехыннан вагончыкны кирпечләр белән тутырып чыгасың, аны Әхтәм мастер кушкан киптерү цехына каршы китереп борасың, ә менә карусельдән чыкканда рельслар арасындагы Ходай каргаган киртек, капкын кебек, вагончыкны эләктерми калмый инде! Аннары ни алга, ни артка... Вагончыкны кызурак этеп килсәләр, киртекне бар дип тә белмәсләр иде дә бит...

—Хәерсез... Салих, тагын батты бит!

Салих дәшми генә жилкәсеннән камытын төшерә, юл читенә кадап куйган ломны барып ала, һәм аны көпчәк астына китереп куя:

—Бер, ике, өч. Без күмәк көч!—Салих ломны киерелеп күтәргәндә, Сәрви әмергә буйсынып вагонетканы этә һәм арба тагын шайтан чокырыннан ычкынып, тигез рельслар буенча тәгәри башлый. «Молодец!»—ди егет. Кыз Салихка карап матур итеп елмаеп куя:

—Советлар Союзына хезмәт итәм!

Хәзер инде вагончыкны камыт киеп тартмасаң да була. Юлның калган өлешендә тәгәрмәчләр жинел тәгәри. Салих вагончык артына Сәрви белән янәшә баса да, икәүләшеп этә башлыйлар.

—Сәрви!

—Әү!

—Син татарча матур сөйлисең. Килмәк кызларыннан да уздырасың...

—Рәхмәт! Тел өйрәнү кызык мина. Сезнең белән эшли башлагач, әллә ничә сүз өйрәндем инде!

—Һе... Ә баштарак кемнән өйрәндең соң?

—Әтидән. Ул Аксу леспромхозында—босс. Профком рәисе була инде. Анда татарлар күп. Эшчеләр белән русча сөйләшми. Без бит төркиләр, ди. Татар гәзитләре алдыра. Карандаш төртеп укый.

—Шулаймы? Вәт кеше! Безнең авылда үз телендә гәзит, китап укымаган адәмнәр әллә ничә?!

—Әти кызык ул. Ачулана башласа, чуашча сөйли-сөйли дә, татарчага күчә. Мине орыша. «Ин яраткан сүзе «адәм имгәге». Дәресне карамасаң да—адәм имгәге, йомышын үтәмәсәң дә—адәм имгәге. Почмактан әни кычкыра: «Ник кызыңны татарча хурлыйсың? Чуашча әрлә». Әти әйтә, чит телдә сүгенү ансат, ди.

—Чынлап та шулай бит. Безнең авыл ирләре гел урысча сүгенә...

—Сүгенү—матур эш түгел... Теле ямьле булса, кеше үзе дә ямьле...

Салих—Сәрвидән бер башка озынрак. Ул кызның ак муенына, күлмәк изүе аша күренеп-күренеп киткән мәрмәр күкрәк, гаурәт чалымнарына еш-еш күз сала. Кыздан бөркелгән ниндидер ят, татлы ис борыннарга үтә, күңелләге, тәндәге яшертен тойгыларны кузгата. Кулның күпереп торган чәч толымын, муенны сыйпыйсы, уйнак билгә кагыласы килә...

—Сәрви!

—Әү!

—Менә бу кулны нишләп биш бармаклы иткәннәр икән?—Салих үз кулын Сәрвинең вагончыктагы кулына сала.—Кара син бу бармакларны... Бәп-бәләкәй, кеп-кечкенә, ә үзләре нинди матурлар...

Сәрви сусыл коңгырт күзләрен егеткә текәп тора, аптырап елмая.

—Йә Салих, син нәрсә? Кул-кул инде... Синең кул ни... минем кул ни...

Салих кулын ала. Вагон эткән җайлы аска карап, уңайсызланып йөткереп куя.

«Җебегән»,—ди Салихның күңел почмагына посып егетнең эчен-тышын күзәткән икенче "мин».—Ну, кул сыйпадың ди. Шуннан нәрсә? Кочаклыйсың киләме—кочакла! Үбәсең киләме—үп! Кызлар да эчтән тыела, ә тыштан якынлык тели бит. Кыз-егет—ике теләк, бер бөтен лә ул... Гайр абыең әйтмешли, каршылыклар берлеге.

"Сиңа җинел, тот та коч, имеш. Кеше ласа ул!»

"Кеше, кеше... Алай тирән уйласаң, бар, суфый бул! Янәшәдә кыз, ә син егет... Табигать нәрсә куша, сез шуны эшләргә тиешсез.

"Шуннан нәрсә?»

"Шуннан шул. Ходай сине егет, ир итеп яраткан. Чибәр женес каршында үз асылыңны онытма, җебемә, белдеңме?! Югыйсә, өйләнә дә алмассың...»

Аны уйларыннан Сәрви тартып алды:

—Салих, нинди уй басты сине?

Кызның күзләрендә ниндидер тартыну, уңайсызлану белән бергә егетне үз итү чалымнары ята кебек иде.

Вагон этеп әйләнгән, бөтерелгән чакта нәрсә генә булмый. Куллар кулга да тия, башлар да бер-берсенә бәрелеп куя. Ә бер мәлдә, аягы таеп, Сәрви бик шәплләп җиргә барып төшә язды. Егылган да булыр иде, ярый әле Салих тотып калды. Башта егет хәлне дә абайламады. Җилкәгә җинелчә кагылу тоеп, башын борса, кыз ике кулы белән дә вагончыктан аерылган, гәүдәсен тота алмыйча, аска, рельс өстенә төшеп бара иде... Егет мәче тизлеге белән бер кулы белән кызның билеңнән, икенчесе белән иңеннән тотты. Һәм Сәрви үзен-үзе аңышмыйча берничә секунд Салихның кочагында ятты. Рәхәт иде. Татлы иде бу мизгел! Ләкин кыз кисәк пружина кебек киерелеп, аягына басты, егеттән тартылды:

—Рәхмәт! Егыла яздым бит!

—Зарар юк,—диде Салих.

Күңел почмагындагы икенче "мин» мут елмайды, кулларын чәбәкләп алды: «Менә бу егетләрчә!»

Вагончыкны кирпеч киптерүче хатыннарга китереп тапшырдылар, ә бушы аларны күтәреп тора иде. Салих камытны иңенә ыргытты да, Сәрвигә эндәште:

—Утыр, туташ, җилдерәм!

Кызны кыстыйсы юк, такталардан арынган вагончыкның эченә кереп баса да, көмеш тавышы белән яңгыратып кычкырып җибәрә:

—Хөрмәтле пассажирлар, Мәскәү—Сочи поезды кузгала! Ту...Туу!

Салих вагончыкны җилтерәтеп чабарга керешкәч, Сәрвинең тавышы дәртле тактлы көйгә әверелеп, цехка тарала:

> Наш паровоз, вперед лети,
> В коммуне остановка...

Сәрвинең тавышы матур. Юк, күп кызларга хас назлы күкрәк тавышы гына матурламый аны. Анда ниндидер тантаналы югарылык, романтик аһәң бар. Нәкъ шул тембрлар әсирли Салихны. Ару да бетә, талчыгу да калмый. Зур максатка омтылган паровоз кебек, йөгерәсе дә, йөгерәсе килә. Һәм ашкынып типкән ярсу йөрәкне бер киртә дә туктата алмас, уйдагы һәр омтылыш, яшәү ритмына буйсынып, гамәлгә ашар төсле...

Тик Салихларның рельслары бик кыска шул. Менә карусель. Хәзер туктап вагончыкны пресслау цехына юнәлтергә кирәк.

—Тпру! Туташ, поездыгызга соңгы станция—«Березай». Кому нужно—вылезай!

—Их, ничек күңелле булды. Билетсыз тамаша! Рәхмәт, Салих!—ди Сәрви кояштай балкып.

Менә шунда Салих үзе дә юньләп аңламаган, акылына һич тә буйсынмаган һәм соңыннан да әллә күпме күз алдына килеп тә мәгънәсенә төшенә алмаган хәл булып алды. Хисләнү нәтиҗәсе булдымы, Сәрвигә булган кайнар тойгылар ташкыны булдымы ул... Кыз вагончыкны этәргә дип, янәшәсенә килеп басуга, Салих аны каты итеп биленнән кочып алды, күкрәгенә кысты.. Сәрвинең шатлык, сөенеч белән балкыган сусыл коңгырт күзләренә кинәт күләгә җәелде, курку ташкыны бәреп чыкты. «Салих, нишләвең бу? Юньсез!.. дип пышылдады ул.—Тукта, җибәр!»

Тик гәүдәсендә ташыган котырынкы хисләр колына әйләнгән егетнең кызны кочагыннан ычкындырырга көче дә, теләге дә юк иде. Аның миен тик бер уй яндырды. Сәрви карышмасын, иркәләүгә буйсынсын... Юк, алай гына түгел, ул да Салихны кочакласын, куллары белән назлап башыннан сыйпасын, татлы сүзләр әйтсен...

«Сәрви!»—дип иңрәде егет һәм кызның тыпырчынуына карамастан, үбәргә дип, битенә үрелде, иреннәрен эзли башлады...

Нәкъ шул вакыт егет сул чигәсендә кисәк тымса авырту, әрнү тойды. Сәрви кечкенә, әмма тояк кебек нык, каты йодрыгы белән егетнең яңагына тондырган иде:

—Нишлисең син, оятсыз!?

Һәм кыз, айнып киткән Салихның кочагыннан ычкынды да, вагончыкка терәлеп илереп еларга кереште:

—Чуаш кызы дигәч тә... Сине дус иткәч тә... Мыскылларга ярый дисеңме? Оятсыз икән син, Салих! Затсыз Дон Жуан икән бит син...

## 7

Салих хәзер, нәкъ менә хәзер, илереп елаган Сәрви каршында үзенең никадәр ямьсез бер хәлгә төшүен абайлап алды. Маньяк, иблис бит... Менә кем! Шул кыяфәте белән кыз күңелен яуларга җыена тагын. И исәр

акыл! Тамчылап җыйналганны мизгел эчендә актарасын да ташлыйсын бит син...

Аны уйларыннан шелтәле һәм көчле ир тавышы йолып алды:

—Нәрсә булды? Ник туктадыгыз? Сезнең аркада пресс эшләми тора.— Әхтәм мастер вагончык каршына килеп тукталды.—Ватылдымы?— Әмма башын иеп үксеп торган Сәрвине шәйләп, кисәк кыз янына килеп иелде.— Сеңлем, аягынны бирттенме әллә? Кай җирен авыртты?

—Юк, аякларым исән, Әхтәм абый.

—Соң алайса ник елыйсын?

Кыз эндәшмәгәч, Әхтәм мастер нидер сизенеп кызарынган, кулларын кая куярга белмәгән Салихка якынлашты. Коңгырт күзләрендә ачулы чаткылар биешеп алды.

—Нәрсә, син елаттынмы сеңелне? Кул суздыңмы? Әйтәм аны соңгы вакытта күзләрен бик ялтырый башлады шул. Юкка булмаган бу... Ярар, мин синен белән сөйләшермен әле. Ә хәзер вагонетканы ал да, элдерт!

Салих чынлап та Сәрви елавыннан, Әхтәм мастер әрләвеннән, үзенен вөждан әрнешеннән котылуның бердәнбер юлын тапкан сыман, вагончыкка барып ябышты һәм пресслау цехына элдертте. Шулай да колагына Әхтәм мастернын Сәрвигә тукыган тыныч, йомшак үгете килеп чалынды:

—Ярар, Сәрви сеңлем, юкка елама! Төкер, үскәндә була инде ул, төрлесен күрәсен... Әйдә, цехка барыйк, мин сине Сабит белән бергә куярмын. Сабит акыллы, әйбәт егет, килешеп эшләрсез... Әйдә, сеңлем, тынычлан!..

Шул вакыйгадан соң Сәрвине Салих янәшәсеннән алдылар, бу чибәр кыз Сабит белән парлашты. Ә Салих янына Улина килеп басты. Оттымы, оттырдымы Салих—монысын үзе дә аңламый. Тик таза, нык һәм эш рәтен белгән Улина белән вагончык төртә башлагач, йөк күпкә җиңеләеп китте. Элек җанга тигән рельс киртекләре дә каршы тормыйлар, тәгәрмәчләр чыжлап кына үтә. Анын каравы карусель өстендә лом тоткан Сабит, вагончык сыртын йолыккалаган Сәрви ешрак күзгә чалындылар. Биленә кул тисә, Улина һич тә каравыл кычкырмый, тайчанмый, киресенчә, шыркылдап көлә, серле елмая... Кеше белән кеше аерылган кебек, кызлар да төрледән-төрле икән...

Оттымы—оттырдымы Салих? Кәрт уенына хас бу тупас сорауның нечкә хисләр дөньясына ни катнашы бар? Хәер, бу сорауны үз-үзенә яшь Салих түгел, дөньяны тәҗрибә, акыл һәм фәлсәфәдән чыгып аңларга күнеккән кунак Салих бирә иде.

## 8

Салих, үлән баскан кирпеч заводы ихатасын калдырып авыл юлына төште. Ләкин Элмәле чатында туктап калды. Янә тәмәкесен капты һәм күзләрен якты, рәхәт кояш нурларына камаштыра-камаштыра юл тарафларын күзәтергә кереште. Элмәле кызлары менә шул юлдан кисәк каршыга чыгалар, шул юлдан китеп кисәк югалалар иде бит... Ничектер аулак һәм серле бу юл. Авылларнын зур дөньяга чыгу капкалары исә башка тарафта. Осланга бару өчен бу юлның хаҗәте юк. Шуңа да мосафир кеше сирәк күренә монда. Ә Элмәленең Килмәккә, Килмәкнең Элмәлегә йомышы хәзер аз төшә күрәмсең. Элек Чуваш бәләзмен яраткан сәрхушләр бу юлны еш таптыйлар иде таптавын, тик хәзер бу мәрәкә белән хәл ничек торадыр?.. Кирпеч заводы да тукталгач, юлнын томалана төшүе ачык инде. Әй, ни генә димә, бу кыйбла һәр авыл халкына кирерәк, биклерәк тараф шул. Һәркайсына чын кыйбла, сәҗдәле кыйбла—башка якта...

Тик Салих бу юлның һәр бөгелеш һәм үр-түшемен хәтерендә бик ачык саклый. Юл борылып бәләкәй тау чык артына кереп киткәч тә, иркен Сөлчә

үзәненә килеп чыга. Елга белән, кулга кул тотынышкандай, берничә чакрым янәшә бара ул. Аннары сулга борылып битләүгә күтәрелә. Монда таш, агач санәмле, балбаллы чуаш кирәмәте, галәмәт матур, чирәмле түгәрәк тугай бар... Шуларны үткәч, Элмәлегә кул сузарлык кына ара кала, авылга инде килеп ирештең дигән сүз...

Бервакыт Элмәле өстендә бик ямьсез кара болытлар эленеп, яшеннәр уйнап торганда, куркабыз дип кызлар егетләрдән озатып куюларын сорадылар. Берничә кат егетләр үзләре кызларны озата барды. Әй, булган бит сагынып искә алырлык чаклар... Ә тугайдагы концертны онытырга мөмкинме соң! Концерт? Әйе, чын-чынлап концерт булды шул ул.

Август урталарының якты кояшлы, җилсез һәм җылы бер киче иде. Бәлки нәкъ әнә шул ямьле кич хозурлыгына кызыгып, Сабит Салихны эштән соң Элмәле кызларын озата барырга димләгәндер дә. Кызлар егетләр белән уйнап чыр-чу килә, тегендә, монда үрелеп чәчәкләр җыйган була, ә үзләренең сөенечтән йөзләре балкый. Килмәк егетләре аларны озата бара бит...

Менә юл битләүгә күтәрелеп, яшел, түгәрәк тугай янына килеп чыкты.

—Иптәшләр, туктагыз!—дип, Сәрви алгарак узды һәм тавышына тантаналы, рәсми тон бирергә тырышып сибә башлады:—Менә сезнең алда Элмәле табигатенең матурлыклары. Сул ягыгызда челтер-челтер килеп Сөлчә ага. Ярыннан күтәрелгәч, әнә бодай басу җәйрәп ята. Сез анда эшләп яткан комбайннар, машиналар күрәсез. Элмәле хезмәтчәннәре шулай мул уңыш җыеп яталар. Ә хәзер, хөрмәтле иптәшләр, игътибарыгызны уң якка юнәлтүегезне сорыйм. Күзгә ташланган беренче нәрсә—тарих. Чуаш мазарлыгы бу. Авыл кешеләренең ташлар, сыннар булып яшәү рәвеше. Бик кызганыч, кеше мәңгелек түгел. Аңа берчак үлем килә. Улина иптәш, күз яшьләре кирәкми... Сезнең алдагы гомер—бер гасыр! Әйе... Шулай! Менә иптәшләр, аннан алдарак яшәү гимны—яшел, матур тугай. Элмәле яшьләре язын, җәен монда уенга чыга. Музыка уйный, биюләр, җырлар. Ля... ля... ля... Ягез, хөрмәтле иптәшләр, бүген яшел эстрадада ике авыл үзешчәннәре әзерләгән концертны карыйк! Беренче тур Элмәле үзешчәннәрен караудан гыйбарәт! Хәерле тамашалар, сезгә, иптәшләр!

Улина тыела алмыйча көлә-көлә кул чаба. Сабит та, Салих кебек үк Сәрвинең артистлык осталыгына шаккатканнар, ни әйтергә белми аптырап калдылар.

Тик үз фантазиясеннән үзе үк канатланган, очынган Сәрвинең туктарга һич исәбе юк иде бугай.

—Улина иптәш, сезнең урыныгыз сәхнәдә. Беренче номерда катнашучы артист буларак, бирегә күтәрелүегезне сорыйбыз. Һәм Сәрви тыела алмый көлгән Улинаны житәкләп тугай түренәрәк атлады.—Хөрмәтле иптәшләр, бүгенге Элмәле яшьләре концерты аншлаг белән бара, урыннар җитми. Кайбер әфәнделәрнең басып торуы шуны күрсәтә. Утырыгыз, әфәнделәр, өстәмә урындыклар бар.—Салих белән Сабитка яшел чирәм өстенә җайлап кунаклаудан башка чара калмады.—Менә шулай! Кул чабып каршы алуыгызны сорыйбыз. Улина Андрианова һәм Сәрви Савельева башкаруында дуэт—чуаш халык җыры «Урманда».

Кызлар янәшә бастылар да, җырлап җибәрделәр. Чынлап та, уңышлы дуэт бит бу! Сәрвидә яңгыравыклы, тантаналы тавыш—сопрано, ә Улина ирләр кебек калын, тигез тавыш белән җырлый—аңарда альт. Бу ике тавыш бергә кушылып, җырдагы сурәт-хисләргә тагын да ямь, тулылык өсти.

Җырнын барлык сүзләрен анлый алмасалар да, эчтәлегенә төшенде егетләр. Анда җырлаучы сөйгәнен урман күркен барып күрергә чакыра. Һәм икәү бергә урман сукмагын хозурланып үткән сыман, тормыш юлын

да шулай матур кичәргә хыяллана ул.

Салихның күз алдында Сәрви дә, Улина да үз егетләре белән житәкләшеп урман юлыннан барган кебек күренде. Тирә-юньдә ямь, хозурлык, кошлар сайрый, ә чәчәк исләреннән баш әйләнә. Кызларның телләренә дә гел сөю, ярату сүзләре килеп торадыр төсле. Сәрви белән Улинада да егетләр сагышы, ярату-яну хисләре бар микәнни?

Күңелдә дулкынлану кузгаткан жыр тәмамланды. «Молодец!», «Бишле!» дип кычкырды Сабит һәм икәүләшеп кызларга каты итеп кул чаптылар.

—Рәхмәт, хөрмәтле тамашачылар,—диде Сәрви янә үз роленә кереп. Күрүегезчә, Элмәле үзешчәннәренең концерты уңышлы чыкты. Ә хәзер, хөрмәтле тамашачылар, сезне икенче турга чакырабыз. Хәзер яшел эстрада Килмәк үзешчәннәренә бирелә. Рәхим итегез, Килмәклеләр! Һәм Сәрви Улинаны житәкләде дә тамашачылар кыяфәтенә кереп, алар яшел чирәмгә барып чүмәштеләр.

Сүз дә юк. Беренче тур—Элмәле «үзешчәннәре» концерты уңышлы чыкты. Ә менә икенче тур белән мәрәкә. Нишләргә соң? Килмәк егетләре әлеге ят тугайга күтәрелеп нинди һөнәр күрсәтсен? Салих жыр-биюгә авыр сөякле. Ходай кызганган ана мондый сәләтләрне. Коткарса, Сабит коткара инде...

—Сабит, миннән булмый, малай, берәр нәрсә тырыштыра күр!—диде ул иптәшенә ихлас ялварып.

Рәхмәт Сабитка! Тугай түренә өч-дүрт адым күтәрелде дә, эчкерсез елмая төшеп, нәкъ кирәкле сүзләрне әйтте ул:

—Элмәле туташлары концертын дәвам итеп сүзне Килмәк егетләре ала. Без дә сезне, хөрмәтле тамашачылар, ямьле кич һәм шушы бәйрәм белән котлыйбыз. Киләчәктә дә Элмәле һәм Килмәк яшьләре өчен әлеге тугай ачык эстрада булып торсын. Аралар бәйләнсен! Без үзебезнең программаны башлап, сезгә ялгыз жыр тәкъдим итәбез. Татар халык көе «Сәрвиназ». Башкара әлегә берни казанмаган, Килмәкнең гап-гади егете Сабит Бикмурзин...

Яшел тугай фонында кыска жиңле ак күлмәкле, килешле буйлы, сөйкемле чырайлы Сабит үтә матур рәвеш алды. Карашын өскә, зәңгәрлеккә юнәлдереп беркавым уйланып торды, илһамын эчтән көтеп алуы да биниһая килешле ана. Чын артистлар да сәхнәгә чыккач шулай итәләр, халыкны бераз көттереп торалар бугай. Инде тавышы гына ачыла күрсен!

Көн аяз, килә яз,
Чәчәккә күмелеп...

Илаһым, көткәннән дә әйбәтрәк, дип сөенде Салих. Көчле, ачык йомшак тембрлы, һаман саен күтәрелеп килүче тавыш инде жырчы сәләтенә карата шик-шөбһә калдырмады. Күңел вәсвәсәләрдән арынып көй, аһәң, жыр белән яшәүгә күчә барды.

Син дә кил, Сәрвиназ,
Шатлыклы көн кебек...

Салих шик-шөбһәсе өчен оялып та куйды. Соң бу бит—жырлап Килмәк халкының һушын бер тапкыр алган Сабит Бикмурзин ласа! Юк, авыл сәхнәсенә чыгып яисә Сабантуй мәйданына басып жырламады Сабит. Язын армиягә китүче өч некрутның берсе—Сабитның бик якын туганы булган. Шуны озатканда жырлады ул.

Килмәктә элек-электән некрутларны авыл урамнарын урап, жырлап

озатканнар. Башта пар атлар җигеп, аларга кыңгыраулар тагып, арбага тезелешеп утырып җырлап йөргәннәр. Аннары машина әрҗәсенә менеп, барган көйгә гармуннар уйнау, ялгыз яисә кара-каршы җырлашулар. Соңрак шул ук машина некрутларны Осланга, хәрбиләр кулына тапшырыр өчен алып киткән.

Менә ямьле, тын май иртәсендә дә машинага некрутлар утыра. Алар янына егетләр тезелешә. Тәгәрмәчләр җай гына бер көйгә тәгәри башлагач баян да телгә килә. Мәшһүр авыл көен сыздыра башлый. Ә машина әрҗәсендә җырчы бармы-юкмы—белгән юк. Купләрнең телләр дә көрмәкләнгән, җыр тезмәләре дә томанлы, ниндидер ятышмаган өзек-төтек сүзләре белән сыерлар мөгрәвеннән әлләни аерылмыйлар болар.

Һәм менә шул «артистлар» хорында Сабитның гаҗәеп көчле, йомшак аһәнле тавышы күтәрелеп китә. Бу яшь, ихлас, дөньяга ачык тавыш:

Бездә биек таулар бар ла,
Тау астында таллар бар:
Талда яфрак, миндә сагыну,
Сездә нинди хәлләр бар?

Моң һәм җыр иясе кисәк барысын да әсир итә. Берничә чуар йөрәк Сабитка кушылып җырламакчы була, әмма аларны шундук туктаталар. Бозма, җырласын!

Салкын чишмә буйларында
Атлар эчерсәң иде,
Туып-үскән илләреңдә
Гомер кичерсәң иде.

Урам буйлап некрутлар белән бергә үзәк өзгеч моң, татлы тетрәү тøяп килгән машинаны иңнәренә балта, пычкы салып эшкә юнәлгән ирләр, туктап, кәпәч эшләпәләрен селкеп озаталар. Чөгендер утарга барыр өчен аерым капка төпләренә җыйналышкан хатыннар, киленнәр яулык болгыйлар.

Китәм диден, читкә киттең,
Чын иде теләкләрең.
Инде киткәч, чит җирләрдә
Өзелер үзәкләрең...

Җырны тыңлап, машинадагыларга төртеп кызып-кызып сөйләшүчеләр, нәрсәдер раслаучылар, шикләнүчеләр бар. Ә ихаталары янында басып торган әби-бабайлар балбаллар сыман дәшми, тын кала. Әмма җыр тәэсиренә бирелеп болар да эчтән дога кылалар, «исән-сау йөреп кайтыгыз, оланнар!» дип изге теләкләр телиләр...

Килмәк урамнарын йөреп чыгып, машина колхоз идарәсе янына килеп туктаганда, Сабит та некрутлар йөрәгендә ташыган хисләрне иң югары ноктасына җиткереп җырлап бетереп килә иде инде:

Хуш авылым, сау бул, сәламнәр көт,
Таң җилләре искәндә,
Мин җырлармын сине сагынып,
Өзелеп искә төшкәндә...

Идарәдән түгәрәк корсак үстереп килгән, әмма һаман әле яшьләрчә җинел

хәрәкәтле рәис Тәуфыйк килеп чыкты. Машинадан төшкән некрутларның һәркайсына килеп, кулын кысты, ихластан сөйләде:

—Егетләр, служба жинел түгел. Беләм. Тик Килмәк авылы маркасын югары тотыгыз! Йөзгә кызыллык китермәгез! Һәркайсыгызга матур хезмәт итеп, авылга исән-сау кайтырга язсын, ярармы?

Һәм нәрсәдер югалткан-эзләгән кеше сыман егетләр төркемен күзәтеп торгач, сәер генә бер сорау биреп куйды рәис:

—Магнитофон да жырлаттыгыз бугай. Тик заманнан артта калам ахры. Нинди жырчы булды соң әле бу?..

Төркем Сабитны рәис каршына этеп чыгарды. Менә жырлаучы кем, янәсе. Тәуфыйк Сабитка текәлеп карап торды, егетнең жилкәсенә кагылып:

—Синме шулай авылны елатучы? Доярка Мөэминә малаемыни син?— Ходай безнең якларга да талантны бирер икән. Молодец, энем!

Килмәк халкы Сабитның колхоз, хөкүмәт өчен Тамбов урманнары кискәндә агач баскан Хәлиулла малае булуын искә төшерде. Бәетләр чыгарткан фажигале ир авылда гына түгел, тирә-юньдә данлыклы жырчы булган икән... Әби-чәбиләр Сабитны «моңлы бала» дип йөртә башладылар. Тик ни гажәп, бәйрәмнәр, кичәләр житеп, Сабитны концертларда жырларга димләсәләр, әллә оялды, әллә ихлас теләге булмады, сәхнәгә чыкмады Сабит. Бәлки яшерен генә жырлагандыр да ул. «Сәрвиназ»—Салих каршында дусның жырчы булып икенче кат ачылуы иде. Тик шуны аңламый тора, нишләп «Сәрвиназ»ны жырлый әле соң ул? Каян килгән аңа әллә нинди ят «Сәрвиназ»?.. Ник бер өйрәнгән, шәп сиптергән «Авыл көе» тезмәләрен жырламый яшьтәш...

Кил, иркәм, нур сыман
Балкып кил яныма.
Ягымлы жыр сыман
Рәхәт бир жаныма.

Күңелне рәхәт кытыклап, тәндә елдырам йөгерткән сүзләр Салихка да бик якын булып китте. Йөрәккә таныш хисләр бөркелеп чыкты алардан. Күңелне илерткән, тилерткән кызлар сагышы...

Син килсән, Сәрвиназ,
Күңелемдә жылы яз.
Шатлыгым, бәхетем зур,
Хәсрәтем, кайгым аз.

Шулчак Салихның миендә ут камчысы шартлады. «Сабит гашыйк, Сәрвигә гашыйк... Сәрвиназ—ул Сәрви! Сәрви-Сәрвиназ...» Сабит йөрәген жырга сала. Жырда алдаша белми Сабит...»

Сабит оста башкаручыларча тавышын иркен уйнатып, жырны матур төгәлләде. Житмәсә, кулын күкрәгенә куеп, беркавым башын да иеп торды. «Юк, өендә тик ятмый, остарган бу малай»...

«Бис! Бис!» дип кычкырдылар кызлар. Сәрви юл буенда жыйган чәчәкләрен алып Сабит каршына ук йөгерде:

—Сабит, син жырчымыни? Ник әйтмәдең? Ну, килештерәсең! Татарда да Сәрви исемле кызлар бармыни?

—Сәрвиназ!—дип елмаеп төзәтте Сабит. Соң инде, Сәрви булгач, Сәрвиназ булырга да күп калмый.

Чәчәк тоткан Сабит һәм аның янында елмаеп-балкып торган Сәрвигә

ымлап Улина Сабитка серле итеп пышылдады: «Карале, Салих, матур пар пулырлар иде полар, әйеме? Сәрви артыннан пезнең директор Сәләнтәй Митрофанович малае да йөри шул. Олег! Тәти егет!»

Салих тормышында еш кына шулай була, аның сөенече өстендә еш кына куркыныч яшен яшьнәүчән! Әле дә яшьләр хушлашып аерылырга торалар иде, искәрмәстән мазарлык тарафыннан каршыларына шәүлә булып карсак кына бер карт килеп инде. Хатыннарныкы кебек озын толымлы чәче, кәкрерәк борыны һәм көл сыман аксыл чырае белән ул шомлы әкият персонажына охшый иде. Менә ул тагын да якыная төште һәм таяк болгап нәзек тавышы белән өзеп-өзеп акырына башлады:

—Фахишәләр... зиначылар... оятсызлар... затсызлар. Мәетләр рухына дога укырга ирек бирмисез... Тәнрене пар дип пелмисез... ил өстенә каргыш өстисез... Син—Сәрви! Пеләм мин сине! Атаңа кызың Килмәк егетләре белән типтерә диям... Улина, әйтсәм, сине анаң асып куяр. Оятсызлар... затсызлар... У... у... Ә сезне, юньсез малайлар, пезнең кызларны аздырткан өчен, Элмәле егетләре тетмәгезне тетәрләр... Пелдегезме? У... у... тәмуг кисәүләре... кяферләр...

Элмәле кызлары, карт күренгәч тә, йөгереп диярлек үз авылларына юнәлде, Килмәк егетләре әлеге өрәкнең янауларына шомланып колак сала-сала килгән юлларына төште.

Сүзендә торган, Элмәле тәкъвасы Микуш пиччә[2], чынлап та авылларында зур гауга куптарган. Элмәледәгесен әйткән дә юк, хәзер инде үзләренә килеп тигәнен дә вагы-төяге белән хәтерләп бетерә алмый Салих. Тик иртәгесен кызларның төс-чырайлары бөтенләй качкан иде. Бусы хак. Туташлар төнбоек сыман йомылдылар. Хәтта бармак күрсәтсәң дә шаркылдап көлә торган Улина да кара болыт кебек булды. Китәбез, дигәч, әлеге кызлар-егетләр мәрәкәсенә яхшы ук төшенгән Әхтәм мастер да каршы килмәде, ризалык бирде. Инде уку башланырга да атна чамасы гына вакыт калган иде. «Рәхмәт, сенелләр, яхшы булыштыгыз. Инде укуга киткәнче әйбәтләп бер ял итегез!»—дип күңелле гөрелдәде ул. Исәп-хисап ясатып, кулларына тиешле акчаларын да тоттырды әле. Баш исән-сау котылды болардан дип сөенгәндер инде.

Ә кичен эштән киткәндә заводның кызын-егетен Элмәле чатында бишме-алтымы егет көтеп тора иде. Салмышлар булса кирәк. Кызарышканнар, күзләре ялтырый. Әчегән хәмер, сарымсак исе аңкып тора. Монысы сизелмәгән дә булыр иде, араларында килеп якага кул сузучылар да табылды. Бигрәк тә джинсы чалбар, чуар бизәкле майка киеп, муенына калын чылбырлы медальон аскан егет әтәчләнде.

—Ник пезнең кызлар белән йөрисез. Килмәктә сезгә татар кызлары петкәнмени?—диде ул бер Сабитка, бер Салихка усал текәлеп.

—И, ажа[3], бездә күптән колак тешләшмиләр. Сүзебез юк, телисез икән, син дә безнең кызлар белән йөре, алар тамгаланмаган,—диде аңа каршы Сабит ваемсыз төс белән.

—Сез пезнең тугайга килеп улап кирәмәтләрне куркыткансыз... Микуш пиччәнең догасын позгансыз,—дип төркемнән төкерекләрен чәчә-чәчә жикеренде озын буйлысы.

—Үз жирегезне этләр кебек тамгалап куйдыгызмыни?—дип Салих та тегеләрнең авызын тиз япты.

Инде төркемдәгеләр ярсып яный, акырыша һәм астыртын гына йодрыклар төйни башлаган иде, шулчак тамашаны күзәтеп торган Сәрви кинәт кычкырып җибәрде:

—Анкашкыр![4] Олег, адәм имгәге, Килмәк егетләренә кул сузасы булма!

[2] Ага, абзый.
[3] Дус мәгънәсендә.
[4] Кычкырма.

Кабыз матаенны, киттек!

Әлеге тәти егет төркемгә нәрсәдер кычкыруга, Элмәле егетләре һәм кызлары ничек эләкте шулай бишекле ике мотоциклга төялделәр дә, борылышка кереп күздән дә югалдылар. Тузаннар гына уйнап калды...

Салих, Элмәле чатында кызгылт ситса күлмәк кигән, кулына төенчек тоткан һәм дымсу көрән күзләрен текәп елмая төшкән аксыл чырайлы, бөдрәләнебрәк торган сары купшы толымлы чибәр Сәрви-Сәрвиназ шәүләсен калдырып, авылга таба атлады. Сусаган да, шактый ук ачыккан да иде кунак...

## 9

Салих дүшәмбе көн кичке сәгать бишләр тирәсендә, Наилә килен белән сөйләшенгәнчә, Осланга юл тотты. Үзе белән ул малаен да алырга ниятләгән иде. Ләкин Рәлифне юл бик ымсындырмады. Капка төбендә балыккамы, жиләккәме дип Рәлифне сабырсызланып көткән яшүсмерләрне күргәч, Салих инде улын артык кыстамады. Ярар, үзе теләгәнчә йөрсен... Рәлифнең ата нигезенә, жир-суга ияләшеп китүе, һәр эшкә ихлас күңел беркетүе, аннан мәгънә табуы аны чынлап сөендерә. Факиһә апасы да малайдан бик канәгать. «Тач та син бит бу, Салих энекәш», дип тора. Шулай дип беркөн Рәлифнең башын сыйпады-сыйпады да, тыела алмыйча чын-чынлап еларга ук керешә апасы.

—И балам, анасыз сабый—оядан адашкан бәбкә бит ул. Сызланганын беркем күрми, беркем ишетми. Назлаучы да юк... Ходай түземлекләр, сабырлыклар бирсен инде үзенә...

Әйе, ана кеше кыска гомерле булып чыкты шул. Рәлифне тапкач та, зәһәр телле, сукрануча, һәр нәрсәдән әр чыгарган хатынга өянәк чире ябеште. Чир дигәнең дә әллә нинди ил-көндә күренмәгән зәхмәт. Теле белән зәһәр чәчә-чәчә дә, эшләгән жиреннән, баскан урыныннан кисәк егылып китә иде Рәфыйга. Мизгел эчендә күзләре алмашына, чырае үзгәрә, аяк-куллары тартыша башлый. Аннары шул тартышка, шул газапка түзмәгән жан әллә нинди тән куыргыч тавыш, әрнү белән иңрәп жибәрә, тешләрен шакырдата. Әгәр шунда авызына кашык-фәлән тыгарга өлгермәсән, телен чәйнәп-өзеп йотарга да мөмкин кеше... Чир чир инде, берсе дә кешене аямый. Ләкин әлеге зәхмәтнең зиһенгә сыймаган ягы шунда: бераз торгач, күзен ача Рәфыйга, үз тирәсендәге адәмнәргә карап, сорап куя: «Ни булды, янәсе?» Һәм аннары берни булмагандай торып йөреп тә китә. Еласаң—ела, көлсәң—көл! Тормыш күген кара болыт басты. Яшен көткән кебек, ир хатынга гел куркып, шикләнеп карарга күнекте: менә йөзе белән зәңгәрләнеп зәһәр чәчәр, менә егылыр, менә авызыннан ак күбекләр ташыр сыман... "Кыз—кәнизәк кенә түгел... Хатын булып ирне көлдерә дә, бөлдерә дә икән... Ир тормышындагы кояш икән ул» дип уенда еш кабатлый хәзер Салих.

Әйтми булмый, авыруны кайсы гына табибларга күрсәтмәде дә, аңа нинди генә дәвалар кулланмады Салих. Тик берсеннән дә им-том, шифа гына табылмады. Ниһаять, аптыраган-йөдәгән иргә бер профессор әйтте: «Ходай чире бу. Жәзаның иң зурын бирим дисә, Ходай кешенең акылын алыр... Инде чирне гыйльми төстә аңлыйм дисәң, Ходай дигәнебез галижәнап табигать бит инде ул. Табигать көйсезлегеннән килә бу чир, баш мие көйсезлеге.»

Хатыны әлеге өянәктән үлеп киткәч тә, аннары да бик еш уйландырды бу зур табип сүзләре. Рәфыйганың Алла каршында нинди гөнаһысы булыр икән? Иргә хыянәт итмәде, азып-тузып йөрмәде... Салихның әнисенә бик якын сердәш булган ахирәтенең кызы, саф кеше баласы ласа ул. Буй тартып,

чибәр кыз кыяфәте алгач та, Рәфыйгага гел соклады, һәрчак мактады, кинаялап тә, ачык итеп тә улын шул кызга өйләнергә димләде ана. Дөрес, берчак, йөргәннәрен белеп, Килмәкнең күрәзәчесе Гашия карчык аулакта Салихның колагына салды-салуын: «Олан, анаң мактаган кыздан берүк ерак тор! Кашык чәйнәп үлә торган нәсел кызы бит бу. Кайчандыр нишләптер Алла каргаган бу нәселне. Тыштан ак, эчтән кара, үз-үзен ашый торган нәсел бу».

Әй, кыз назыннан егет җаны эрегән чакта нәсел-нәсәп хакында кем уйлансын соң? Кыз хатынга әйләнеп, зәһәр теле белән җан кыйный башлагач кына айныйсың икән ул!

Менә шулай: ата-анасы да бик теләгән, дине, рухыяте дә бик ятышкан кызга өйләнде өйләнүен Салих, тик хатыннан уңмады шул. Соңыннан, әлеге Гашия күрәзәчене искә төшереп, бик ачынды, үзенә бик сабак ясады тол ир! Яхшы бичә алыйм дисәң, чегәннәр ат тешләрен, ат казнасын капшаган кебек, кәләшнең дә иң элек нәсел-нәсәбен тикшерергә кирәк икән шул. Тыштан гына түгел, эчтән дә матурмы, итагатьле затлармы болар?

Сабак алуын алды ул, тик әлегә хатыны гына юк Салихның—өйләнми, һаман курка шул...

Осланга юл элек тә тигез, таштан иде. Асфальт та түшәлгәч, ул көзге кебек үк булган—ялтырый. Машинасының газ чәпәгенә еш-еш баса торгач, район үзәгенә дә якынлашты. Юлның сул ягында әрәмәлек, акланнар җәелеп китә дә Сөлчәгә килеп тоташа. Менә шунда бит инде район халкының Сабантуй бәйрәме үткәрелә.

Салих машинасы чирәмле әрәмәлек юлына борылды. Озын, шома колга, капчык сугышы өчен ясалган зурат, спорт ярышлары өчен төзелгән мәйданчыклар, җәйге эстрада корылмасы күзгә чалына барды. Мосафир машинасын туктатып, авызына папиросын элеп, Сабантуй үтә торган мәйданга аяк басты. Бәйрәмдә халык гөжләп тора биредә. Төрле авыллардан килгән дус-ишләр, туганнар очраша, сөйгән ярлар бер-берсен табыша монда.

Салих белән Сабит та Элмәле кызларын Сабантуйда, нәкъ менә шул җыр, бию барган җирдә очратты бит. Кайсы авылдан булгандыр, яшь кенә бер кыз бик килешле итеп өр-яңа җыр башкарып тора иде. Сабит аны отып калырга тырыша, авыз эченнән көйли. Сабитка карап, Салих та кызга сокланып тора...

—Кара син поларны, чибәр кыз күзлиләр!

Карасалар, артларына Улина белән Сәрви килеп баскан. Улина егетләрне үртәүдән шыркылдап көлә, Сәрви дә тыйнак кына елмайган. Беренче булып Сабит телгә килде:

—Авани херзәми! Күрмәгәнгә бер ел! Йә, карыйм әле үзегезне, туташлар.—Һәм ул артистланып кызларны әйләнеп чыкты.

—Үзгәрешләр сезнең файдага. «Бишле»!—Чынлап та, Сәрви тагын да сылуланып, чибәрләнеп киткән. Дымсу күзләрендә дә җиткән кызларга хас уйнак, серле чаткылар ишәйгән. Улинаның да борыны тартылып, йөзе түгәрәкләнеп, матурланып калган.

—Йә, Килмәктә тормышлар ничек, кирпичниклар? Аттестат алдыгызмы әле? Кайларга китәргә чамалыйсыз?—дип, Сәрви берьюлы әллә ничә сорау куйгач, сүз сүзгә бәйләнде. Байтак гәпләшеп тордылар.

—Пезне көтәләр. Китик!—диде, ниһаять, Улина һәм каядыр еракка карап кул болгады. Күрәмсең, Элмәле яшьләре шул тирәгә җыелышкан булгандыр.

Һәм менә шул мәлдә соңыннан терсәкне күпме тырышсаң да, тешләп булмаслык бер мәтәвекле хәл булып алды. Сабит Сәрвигә, Улинага ияреп

ят кавем тарафына китеп барды. Салих кына түгел, хәтта кызлар үзләре дә моны теләмәгән иделәр.

—Барма анда, Сабит. Хәерлеге түгел...—дип ихлас искәртте аны Салих.

Ләкин Сәрвине очратып, хисләр тоткынына әверелгән егетне сүзләр генә туктата алмады шул. Кызлар белән төркем эченә кереп югалгач, көнгә генә түгел, ярты айга җуйды аны Салих. Егетне унбиш тәүлеккә милиция кутузкасына ук ябып куйганнар... Әйе, ямьсез фараз дөрескә чыккан. Сәрви янәшәсендә күреп, тәти Олег һәм аның дүрт-биш яраны Сабитка бәйләнгәннәр. Сугыш киткән. Сабитның күз-башын бозганнар, әмма егеттән тегеләргә дә өлеш шәп чыккан: Олегның ике тешен бәреп төшергән, бер яранның теш казнасын имгәткән, икенче яранның күз төбен күгәрткән..

Милиция эш кузгаткан икән дә, ләкин Олег—Элмәле мәктәбенең директор малае бит, хөрмәтле Сәләнтәй Митрофановичның улы... Таныш-белешләрен эшкә җигеп, абруйлы ата улын һәм яраннарын шома гына йолып калган. Ә Сабит кем?.. "Доярка малае»... Килмәкнен Мөэминәсен кем белә? Кем аңа ышана? Хулиган булып унбиш тәүлек утыру гына аз, аңа бик ямьсез гаеп тә өстәлә: «районда милләтләр дуслыгын какшатучы... Экстремист...»

Сабит өлгергәнлек аттестатлары тапшыру кичәсендә була алмады, кутузкада иде. Әмма зинданнан котылгач та, эшләре гел кирегә тәгәрәде егетнең. Директор Мөстәкыйм Гомәрович тантаналы чыгарылыш кичәсендәге чыгышында ук үз-үзен тыя алмыйча кычкырган иде шул:

—Килмәк мәктәбе тарихында булмаган хәл: безнең укучы унбиш суткада утыра! Хулиганлык өчен генә түгел, милләтләр дуслыгы кебек яшәешебезнең изге принцибын пычраткан Сабит Бикмурзин... Сәяси, әхлакый яктан ышанычсыз кеше! Бу безнең педагоглар өчен юып бетерә алмаслык тап! Без кемне тәрбияләгәнбез, иптәшләр? Комсомол оешмасы нәрсә караган?

Ә директордан соң сүз алган райком вәкиленең—ул зур күзлекле, төксе чырайлы, җитди бер ханым иде—нотыгы аеруча куркыныч яңгырады:

—Идеологик яктан тотрыксыз Сабит Бикмурзин кебек яшьләргә совет вузларында урын юк. Аңа уңай характеристика да, юллама да бирелмәячәк. Ул үзенең гаебен хезмәт коллективлары тәрбиясендә намус белән эшләп кенә юа ала... Бөтен районда мондый экстремистларга каршы көрәшергә тиешбез, иптәшләр!

Әнисе янында фермада озак эшләргә туры килмәде район укучыларына кире мисал булып торган егеткә. Шул ук көздә, октябрь башларында. Сабит Бикмурзинны Совет Армиясе сафларына алдылар. Салих исә Уфада авыл хуҗалыгы институтына укырга кергән иде...

Тын, тымызык бер иртәне ачык машинада некрут егетләр янәшәсендә ихлас йөрәк җырларын җырлап, Килмәк урамнарын әче сагышка батырып моңланып киткән Сабит:

Кәккүк моңая кай якта?—
Саз буенда, аръякта;
Без бәхетле бала булсак,
Китмәс идек солдатка...

И моңлы бала! Үзең асыл булсаң да, нишләп шул чаклы сагышлы, әрнешле соң синең язмыш?..

«Оттымы, оттырдымы?..» Миендә чишмә кебек тибеп чыккан уйга Салих бер төрле генә җавап бирә ала хәзер. Чибәр чуаш кызы белән

бәйләнеп китсә, бәлки аңа нәкъ Сабит язмышын кичерергә туры килер иде. Оттырмаган, димәк...

Машинасына кереп утыргач, Салихның тәртәне кирегә борасы килеп китте, күнеле бәргәләнде. Чынлап та, ник ул Сәрви белән очраша соң? Салихка нәрсә бирә аның белән күрешү?.. Ул инде машинасын янә Килмәк юлына борырга җыена иде, кесә телефоны чылтырады. Эшеннәндер дип алса, Наилә килен икән: «Салих абый, түземсезләнеп көтәбез... Килеп җит инде!»—Шулай шул, вәгъдәләшкән җиргә бармаса, әллә нинди юраулар китәчәк. Барырга кирәк...

Осланга төшеп матур гына чәчәк бәйләме сатып алды, чәй өстәленә дип тегесен-монысын сайлап пакетына тутырды ул һәм, ниһаять, машина кирәкле капка төбендә килеп туктады. Каршыга Наилә килен йөгереп чыкты, Шәүкәт энекәше дә күренде. Күрешү, гәпләшү китте.

Менә алар йортка үтә, менә алар баскычтан күтәреләләр... Һәм шул чак ачык ишектән алларына җиңел зәңгәрсу күлмәктән саргылт бөдрә чәчле, аксыл чырайлы, тулы гәүдәле ханым килеп чыкты.

—Исәнме, Сәрви!

—Салих!

Күзләр очрашты. Кыз чагындагы кебек дымсу көрән, кешегә текәлеп, берчә көлеп, берчә житди карый торган салмак күзләр, тик алардан хәзер элек чалынмаган сагыш, ниндидер эчке яшертен моң түгелә кебек. Ә тавыш шул ук—яңгыравык, тантаналы:

—Салих... Мин сине шундыйдыр дип уйлаган да идем! Киң жилкәле, төз буйлы, тәвәккәл! Мыек та җибәргәнсең икән...

—Мыек та бар,—дип җупләде Салих.—Сез Сәрви туташ... Сәрви ханым, үзегез һич тә кирпеч заводында вагонетка эткән кызга охшамагансыз. Май заводы килешкән бугай...

Барысы да ихластан көлешеп алды. Аралашу да җиңелрәк булып китте. Гөрләшеп чәй эчеп куйдылар. Ашка кадәр бераз йөреп алыгыз, сөйләшегез дип Наилә кунакларны җимеш бакчасына алып чыкты. Монда һаман тәртип, ямь, чәчәкләр, җимешләр патшалыгы.

—Сезнең дә бакча бардыр, Сәрви?

—Бакча парлы кешеләрдә генә үсә лә ул...

—Тормышка Олегка чыккан идеңме? Директор малаеның исеме шулай иде бугай.

—Олег?.. Юк, өйләнешмәдек. Бер адәм имгәге лә ул. Атасы Чебоксарга барып аны университетка урнаштырган иде. Тик укыйм дип алдап кына йөргән. Эшләмәгән, эчкән, наркоман булган. Хәзер яман авыру эләктереп, тере мәеткә калган диләр.

—Алай... Сабит каршында гөнаһсы өчен Алла суккан, күрәмсең, үзен... Син белденме соң, Сәрви? Әнә теге чакта, Сабантуйда, Элмәле егетләрен кыйнады дип утырттылар бит Сабитны. Шул сәбәптән вузга да эләкмәде. Армия...

Сәрви дәшмәде. Башын аска иеп, кызарынып, уңайсызланып калды. Күрәмсең, Сабитның хәлләре үз вакытында ук аңа мәгълүм булгандыр.

—Сабит Армиядән кайттымы соң?—диде Сәрви ничектер куркып кына.

—Кайтты...

—Сабит хәзер кайда соң? Мин аның хакында чынлап берни белмим бит, Салих. Сорашырга да уңайсыз бит. Хатыны бардыр... Гайбәтләрдән кот очып беткән инде.

—Сәрви, Сабит авылда...

Мөлаем хатын күзләрен тутырып әңгәмәдәшенә карады. Алар гаҗәпләнү,

аптырау хисләре белән тулы иде:

—Авылда? Килмәктәме? Ничек? Мин бит аны берәр зур шәһәрдә яшидер, дип йөрдем. Шундый талант иясе иде бит ул. Бәхетен тапкан, гаиләсен корган кешедер дип белдем. Мин үзем дә бит, Салих, әллә ничә еллар читтә йөрдем...

Сәрви үзенең яшьлек тормышына кагылышлы Сабит хакында, аның фаҗигале язмышы хакында чынлап та берни белми бугай. Наилә дә әйтә алмагандыр. Бишек баласы гына булган түгелме соң ул без таралган чакта... Нишләргә соң? Ничек җиткерергә Сәрвигә Сабит хәлләрен?

—Сәрви, Сабитны күрәсең киләме соң?

—Сорыйсың тагын! Бер очрашып яшьлекне искә төшерер идек. Табын да әзер... "Сәрвиназ"ны җырлатыр идек...

—Әйдә соң...

Салих ни булса, шул булыр, дип тәвәккәлләп машинасын ачты һәм Сәрви ханымны утыртып Килмәккә юнәлде. Күренеп тора, юлдашы дулкынлана, күрешүгә әзерләнә бугай. Әмма хатын-кызларга хас сораулар биреп, Салихның эше, тормышы хакында кызыксына—үз-үзен тынычландырырга тырышадыр инде.

Менә җитез машина тиз арада олы юлны үтеп, агачлар, тирәкләргә күмелеп утырган зират янәшәсеннән бара башлады. Монда биш-алты ир тимер рәшәткә корып ята иде.

—Сабит шундамы?—дип беркадәр аптырап, каушап сорап куйды Сәрви.

Салих эндәшмәде.

Менә зират капкасы. Машина ишеген ачып Салих Сәрвигә җиргә төшәргә булышты.

—Салих, син нәрсә?! Ник монда алып киләсең? Каберлек түгелме соң бу? Салих...

Ир кул аша хатынның гәүдәсе авыраеп китүен, аяклары хәлсезләнүен тоеп, Сәрвине ныграк җитәкли төште.

—Нык бул! Һәм гафу ит, Сәрви! Мин сиңа дөресен әйтеп бетермәдем. Сүзләргә син үзең дә ышанмас идең. Син күрергә тиеш... Сабитның син бик якын кешесе идең бит. Сабит үзе дә сине көтәдер...

Ниһаять, каберлекләр тезмәсен үтеп, ак мәрмәр плитә каршына килеп бастылар. Зур коңгырт күзләре белән дөньяга ихлас елмаеп баккан хәрби киемле яшь кеше сурәте җәлеп итте. Астарак алтынсу хәрефләрдән уелган язу:

> Сабит Хәлиулла улы Бикмурзин
> интернациональ дуслык бурычын үтәгәндә
> батырларча һәлак булды.
> *8 V 1969—10 VIII 1987.*

—Исәнме, Сабит, дускай!—диде Салих һәм җиргә чүмәште. Балаларча сулкылдап елап Сәрви дә яшел чирәмгә тезләнде:

—Кичер безне, Элмәлеләрне, Сабит, кичерә күр!—Һәм эчтәге әрнү, сызлану ташкынын тотып-тыеп торалмады, кычкырып еларга керешге Сәрви.

«Җыласын, җиңеләеп китәр», дип уйлады Салих һәм хатынны ялгызын калдырып зират читенә юнәлде.

Сабитны җирләгәндә ул авылда, студент ялында иде. Әфганда һәлак булган десантчы өлкән сержант Сабит Бикмурзинның гәүдәсен цинк ящикта Килмәккә китергән татар капитаны авыл Советында булып, мәрхүм

хакында байтак сүзләр сөйләгән. Намуслы булган. Иптәшләренә карата һәрчак ныклы, ышанычлы терәк ролен үтәгән. Кеше артына качмаган... Сабит Бикмурзинның исән калу мөмкинлеге дә булган. Ләкин чолганышта калган иптәшен коткару өчен үзе ут эченә кергән...

Килгән капитан Мөэминә апаны авыл Советына чакыртып, аңа улының «Батырлык өчен» медален тапшырган. Шунда Мөэминә апа бер авыл активы булып утырган мәктәп директоры Мөстәкыйм Гомәровичка, бер хәрби капитанга карап әйткән икән: «Монда улыма милләтләр дуслыгына пычрак атучы, диделәр... Сез Әфганстанда улымны, интернациональ дуслыкны көйләү өчен шәһит киткән, дисез. Боларның кайсысы дөрес соң?.. Мин бит милләтләр тирәсен белмим. Мин Сабит улымны вөҗданлы итәргә, гадел итәргә тырыштым»...

Салихны исә капитанның: «Сабит Бикмурзинның исән калу мөмкинлеге булган»... дигән сүзләре тетрәндерде. Әйе, Сабантуйда да Сәрви белән җитәкләшеп китмәсә, мөгаен, аңа исән-имин калу әмәле ачылган булыр иде бит. Салих кебек хәзер институтта укып йөрер иде ул... Корбан үзенә вөҗданлыны, горурны сайлый шул. Корбан адәм имгәгенә, гомерне исәп-хисапка коручыга кагылмый...

Сабит рухы, аның турында уйлану Салих вөҗданында һаман әле уңайсыз бер кичереш тудыра иде.

Янәдән Сабит кабере янына атлаганда Салихның колагына таныш көй, моң чалынгандай тоелды. Хыялы шулай уйныймы соң?

Көн аяз, кидә яз
Чәчәккә күмелеп...

Юк, шик урынсыз икән. Авыз эченнән диярлек, шыпырт кына Сәрви-Сәрвиназ көйли иде моны. Ул инде күз яшьләре ташуын тыйган, беркадәр тынычланган кебек күренә... Ә Салих өчен иң мөһиме: Сәрви, әче булса да, Сабит хакындагы хакыйкатьне белде...

—Әйдә, Сәрви, кузгалыйк инде. Безне көтәләрдер,—диде Салих һәм ул үз кулында Сәрвинең кайнар, йомшак, яшьлектәге сыман җангa якын учын тоеп, алар капкага—хәяти тормыш тарафына—юнәлделәр.

Еракларга китеп җәелгән тук, эре башаклы алтынсу бодай басуы өстендә кичке июль кояшы җәйри иде...



Бикә Рәхимова

# БИК КАДЕРЛЕ ИЛ БИТ БУ!..

## Тергезик

**Учак...—**
**Төрки өчен моннан якын юлдаш**
**Һич булмаган озын юлларында...**
**Учак исен җилләр китермәде**
**Утсыз янган салкын елларымда.**

**Төтеннәре кайда таралгандыр,**
**Белер идем мин дә кадерләрен.**
**Балбалларны давыл аударганга,**
**Саклаучысыз учак каберләре...**

**Учакларга безнең ут сал диеп,**
**Җил-юлчыга йөзем куям тагын.**
**...Офыкларда таудай янган шәфәкъ**
**Оныттырмый төрки учак данын...**

## Аваз килә

**Казан яши бары татар өчен,**
**Башка өчен бары тик сәбәп.**
**Изүне дә кисеп тишү кирәк,**
**Уемына керсен дип сәдәф.**

**Казан—символ бары татар өчен,**
**Башка өчен җайлы "утырма".—**
**Кунак кызы гел чакыру көтә:**
**"Кич чыкмыйча, өйдә утырма"...**

**Кунаклары уйный әйлән-бәйлән,**
**Барсы бергә килеп, керешкән.**
**Ага сыйлар анда... Ике татар**
**Аулак өйгә килеп күрешкән...**

**Казан яши татар диеп, көеп,**
**Ышан, хаклык, чын да шулай бу.**
**Безгә язган язмыш—аваз килә:**
**Идел дулкыннары шаулавы...**

## Казанга 1000 ел

Мең генәме ул гүзәлгә?
Казан—халкым яшендә:
Вәйран булган мең каланың
Сыйдырган күз яшен дә.

Меңне меңгә тапкырласак,
Илаһи зур сан бит ул.
Күренгәнне күрмәүчеләр
Тик үзләре зан[1] бит ул.

Казан безгә Фәнәгүр дә,
Башта—Башту да икән.

Югалтуның ачылары
Безнең башларны игән...

Казан безгә—Сарай-Бату,
Ничәмә ничә Төмән.
Казаныбыз исән чакта,
Шәһәрсез калдык, димәм.

... Кайната, Казан кайната
Кайнарлы агымнарны.
Өстә булсын безнең агым—
Гел барлыйк тамырларны.

## Татар иле. Яшьле өмет...

Сандугачларны сайраткан,
Йөрәк майларын кайнаткан,
Бәлзәмнәр эретеп салган,
Бик кадерле ил бит бу!

Болгарны аякка куйган,
Җиде идел маяк булган,
Назлы җиле шифа койган,—
Хөрмәт күргән ил бит бу!

Кыпчагы мичәүдә юрткан,
Нугае татардан чыккан,
Ничәмә дошманны еккан,
Нинди гаярь ил бит бу!..

...Дилбегәсен читләр тоткан...
Нәселебез кемнәр йоткан?..
Хәстә-авырулар йоккан,
И, кадерсез ил бит бу...

"Ага күземнән яшьләрем,
Булды заман—мин яшьнәдем,
Кайтырмы алда ямьнәрем?.."—
Дип елаган ил бит бу...

## Тәмле...

Күкләремдә хәтфә болыт йөзә,
Күңел көтә яңгыр тамчысын.
Гөлләр көтә, керфекләре белән
Тартып алыр булып, талчыгып.

Яңгыр җиле исеп куйды әнә,
Сыгылып килде агач башлары.
Күктән Җиргә бәллүр баскыч төште:
Тып-тып атлап, яңгыр башланды.

Күкнең, Җирнең күрешкән сәгате:
Әзсез калмас изге мәхәббәт...
Аягымны сыйпап, тәмле ялар
Сусыл үлән—яшел мәрхәмәт.

## Төнге шигырь

Төн йолдызы гөлле юллар суза,
Ашкынулы күңел юл чыга.
Гөлләренә сулар сибәр өчен,
Әверәләм төнге юлчыга.

Тирән чумып, өскә калкасы:
Күк гөлләре тирән—биектә.
Киек-кошлар чумды офыкка,
Әверәләм мин дә киеккә.

[1] Зан—шикле.

* * *

Иртәләрем ирекле
Дога белән беркетәм.
Иртәнге нур тотарга
Бер тукталам, бер китәм.

Көндезләрен яп-якты,
Инде күпме нур акты.

Йөрәктә бөреләнгән
Көннең чәчәге атты.

Кичкә таба тылсымлы
Күләгәләр уены...
Төнгә илтеп җиткерим
Мәрхәмәтле уемны...

## Әнием

Яшәү сере—синең кул җылысы
Күзәнәгем саен саклана.
Маңгаемнан сыйпап аң күчердең,
Бөркет кебек зирәк саф ана.

Әткәемнең васыятен үтәп,
Биш сабыйны ялгыз бакканга,

Миң күкрәүне күкрәк белән үткәч,
Кызыл каның калган ак канга...

Сабырларның сабырлары идең,
Серен белгәч гомер итүнең.
Сабырсызлык заманасы килде,—
Көтеп торган синең китүең.

## Тигезлек билгесе

Халык дибез, милләт дибез,
Икесе ике сүз шул.
Милләт дисәк, безнең колак,
Безнең хис, безнең күз ул.

Урам тулы халык бара,
Милләтне син арала.
Кыен эшме? Әйе, кардәш,
Эчтә әрнү, әр кала.

Безнең колакка ят сүзләр,
Күзләре ят, үзләре.
Гомер буе рәнҗү күңлем
Милләттәшне эзләде.

Гомер буе милләт "төзим",
Беләм дә күк өлгесен...
Халык—тигез—Милләт диеп,
Эх, куярга билгесен!

## Булма юмарт

Хәлең авыр бүген,
Шигырькәем, дустым,
Үги калдың инде...
Кемнәр шулай кушты?

Татар дигән халкым
Читтән карап тора,
Син туңып торганда
Ятка бишмәт сыра.
Җиде ятка канын
Татар биреп тора.
Тулгагы да бирнә—
Татар тумый тора.
И татарым минем,
Булма алай юмарт,—
Ничек инде һаман
Үз нәселең юкарт?

Туның салып бирмә,
Алда салкын томан,
Ялангачланма, их,
Шәрә бүре сыман:
Төлке менеп алган
Кыйналган җилкәңә,
Әллә түзмәк булдың
Әйдәкләп илткәнгә?
Нәсел төбен алып,
Ничек бүләк ит, әт?
Үз кулларың белән,
Хурланмыйча, кит ләl..

Шигырькәем, күрдең,
Бер үгетлим... битлим...—
Сине милләттәшем
Күңеленә биклим...

## "Нибелунглар турында җыр"[1]

**Җыр түгел лә, елау бу,**
**Җанны кыеш, үтереш.**
**Гасырлар артка китеп...**
**Бүгенге белән көреш.**

**Гадәти бер көнчелек,**
**Кайнап яткан кан үче.**
**Кан йоткан Җир өстеннән**
**Берсе дә түгел өстен.**

**Кримхилда бик гүзәл,**
**Кызганыч, ул да бик җәл.**
**Брюнхилда—кыз-батыр,**
**Үз хәйләсенә батыр.**

**Ярый әле, Атилла**
**Сөйкемле сөяк икән,**
**Ачык язып, тарихның**
**Сәхифәсен гөл иткән,**
**Тактасын сөяп киткән.**

## Мәҗнүннәргә

**Мәҗнүннәргә дөнья кытлык кичми;**
**Ил тамырын ләкин алар кисми:**
**Ил тамыры киселә җилләрдә,**
**Мәҗнүннәрнең кадере беткәндә.**

**Олпатларның салкын акылыннан**
**Күңел тәрәзләре чәрдәкләнә...**
**Тәрәзләрдә Иблис гәүдәләнә,**
**Чәбәләнә дөнья, чәбәләнә.**

**Мәҗнүннәрнең хәлен төгәл тоеп,**
**Күзләренә якты йолдыз коеп,**
**Күңел тәрәзләрен якты уеп,**
**Фәрештәләр йөри канат куеп.**

**Ярый әле, йолдыз яңгырлары**
**Дерт иттерә, рәхмәт яугырлары...**
**Мәҗнүннәргә ява ягымлылык,**
**Агымсудай—килеп ягылырлык.**

**...Иелеп ал!**

* * *

**Коръән-Китап уку—күңелеңнән**
**Караңгыны куу—актыгын.**
**Бер кушуч дога битне юганда**
**Җиһан-Күктә туа яктылык.**

[1] Герман халыкларының борынгы эпосы. Бу зур күләмле әсәрдә безнең борынгы төрки батырыбыз илгизәр, илтөзәр Атилла турында да сөйләнелә. Төрки һуннар башлыгы Атилла хәзерге Аурупаның үзәгендә зур империя төзи, эпоста Атилланың унбер иле бар дип әйтелә. Ул бу әсәрдә бик ярдәмчел, кешелекле, сөйкемле итеп бирелгән.

***Редакциядән:***

**Бу айда журналыбызның күптәнге авторы, танылган шагыйрә, публицист Бикә Рәхимованың түгәрәк юбилее. Аны укучыларыбыз исеменнән ихлас котлап, сәламәтлек, яңа иҗат уңышлары телибез!**



Рифат
Җамал

# КҮҢЕЛГӘ КИЛМИ КЫШЛАР

* * *

**Йом күзләреңне**
**Хисләрең барла:**
**Яхшылык—анда,**
**Яманлык бармы?**

**Язмы—анда, көзме,**
**Әллә салкын кыш?**
**Йөзә Аккошлар,**
**Оча кара кош?**

**Сөюме—анда,**
**Әллә нәфрәт?**
**Гөлләр чәчәктә,**
**Коела яфрак?**

**Ач та күзләрең,**
**Кара алдыңа,**
**Ошамас, бәлки,**
**Күргән—җаныңа.**

**Сере кечкенә,**
**Син, дустым, аңла!**
**Күңелеңдә ни—**
**Шул синең алда!**

* * *

**Күңелем йомшакка**
**Мин аны яшердем.**
**Уйладым, сакលармын,**
**Күрәсең, яшь идем.**

**Күңелем яшердем**
**Усаллык артына,**
**Хисләрем күрсәтмим,**
**Һаман да тартынам.**

**Күңелем яшердем—**
**Усал сүз җитмәсен,**
**Күңеле керлеләр**
**Ат итеп җикмәсен.**

**Күңелем яшердем**
**Чыраем артына.**
**Чыраем түзә лә,**
**Тик күңел ярсына.**

**Күңелем яшердем—**
**Кыраулар алмасын,**
**Тик дуслар өзсеннәр**
**Күңелем алмасын!**

**Күңелем ачамын**
**Дусларга, якынга,**
**Тик алар өчен ул**
**Ак кына, пакъ кына!**

* * *

**"Ата сандугачлар гына**
**Сайрый"—диләр шагыйрьләр.**
**Шуңадырмы, күбесенчә**
**Шагыйрьләр бит чат ирләр.**

**Ә шулай да—безнең бәхет,—**
**Бар бит әле шагыйрәләр:**
**Шагыйрьләр акыл өйрәтә,**
**Шагыйрәләр—җан өрәләр.**

Рифат ЖАМАЛ (1951)—*шагыйрь; ветеринария фәннәре докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе. "Күңел сурәләре" һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

* * *

Берсе—болгар, берсе—кыпчак,
Кайсы Алтын Урдадан...
Әллә инде Татар диган
Милләт һич тә булмаган?!

Берсе—мишәр, берсе—типтәр,
Кайсылары—керәшен...
Әй, татарым, син кайда соң?..—
Төшләремә керәсең...
Төшләремә керәсең!!!

* * *

Язгы җилләр җанны тибрәтәләр,
Мәйданнарда ярсый шагыйрьләр.
Бар да өзгәләнә: "Милләт!"—диеп...
Тик нигәдер дәшми чал ирләр.

Нигә дәшми? Әйтер сүзе юкмы...
Күзләрендә күпме сагыш бар.
Буразналы куллар. Бу куллардан
Үткән икән күпме арышлар?!

Нигә дәшми? Алар хәтерендә
Башка җырлар шул ук авыздан.
Сүзләр башка, ләкин көе китми
Шушы хәтер диган явыздан.

Нигә дәшми? Чөнки сөйләүчеләр
Сулга каердылар кичәсен.
Бүген каералар уңга. Шуңа
Ышана алмый. Инде нишләсен?!

Мин дә дәшмим әле. Бер уй борчый—
Сөйләүчеләр бүген җитәрлек,
Көзге җилләр иссә, булыр микән
Көрәшчеләр, Себер китәрлек?!

* * *

*"Поездлар китеп тора,*
*Сөю китми, сабый күк*
*Могҗиза көтеп тора."*

М. Әгъләмов

Учаклар сүнә таңда.
Сөюләрем сүнми әле—
Син генә дәва җанга.

Чәчәкләр шиңә көзен,
Сөюләрем шиңми әле—
Син генә күңел көзгем.

Көньякка китә кошлар.
Сөюләрем китми әле—
Күңелгә килми кышлар.

Гомерләр үтеп бара.
Сөюләрем үтми әле—
Ябылмый әле яра.

* * *

Нәрсә көтә иртәгесен—
Кемнәр белә?
Билгесезлек җанны кыйный
Бәгырь телә.

Ә бүгенгә мин оҗмахта—
Кочагыңда,
Дөрләп янам синең яшьлек
Учагыңда.

Мин дә яшьмен. Һич картаймам
Синең янда.
Әйтерсеңдә мин туганмын
Әле яңа.

Шундый чагым—сине күреп
Һушым киткән...
Әллә яшәү мәгънәсе
Шушы микән?!

* * *

Уңышлар, җиңүләр... Борчылам,
Болытлар килер, дип, алмашка.
Кыйныйлар, сүгәләр... Өметем—
Сөюләр килер бер чал башка.

* * *

Яшен яшьни, күк күкри,
Яңгыр булып җир үкси...
Күз яшьләрең кипте инде.
Яшен булып бер үпче!

* * *

Илһам дигән нәрсә
Әй, нәзберек...
Син, җаныем, андый
Булма бер үк!

* * *

Бер үк бакчада үсәләр
Миләш белән алмагач.
Әллә миләш ачылана
Аны һичкем алмагач?

* * *

*"Бу дөньяны авыр, диләр,*
*Кем күтәреп караган...."*
Халык жыры

Күңел—зәгыйфь,
Иңнәр—зәгыйфь,
Авыр яфрак—җилкәдә...
Һич нинди җил ярдәм итмәс
Күтәрмәгән җилкәнгә.

* * *

Мин дөньяның күз күрке, дип
Мактана Адәм.
Сүзләреннән тып-тын гына
Көләдер Галәм.

Нур
Әхмәдиев

# МӨНИРСТАН

РОМАН

***

Вакыт башта көннәр, аннан атналар, айлар саный. Исәннәр казна йортыннан барыбер бер чыга. Мөниржанның да котылыр вакыты якынайганнан якыная бара. Ләкин өендә инде аны көтүче юк. Ул китеп, җиде-сигез айлар үтүгә, башта әтисе, тагын унбиш-егерме көннәрдән әнисе дә гүр иясе булып куйдылар. Хәзер кем янына кайта инде ул? Йортлары исән-сау тора микән? Аңа бирелгән һәр срок югалту белән бәйләнгән: беренчесендә Гайния, соңгысында—ата-анасы. Ул бит хәзер ятимнәрнең дә ятиме.

Төрмәдән котылган чакта, Мөниржан Исламов дигән гражданинның кулына шактый акча тоттырдылар. Көне-төне эшләп тә кәгазьдәге таяктан башканы күрмәгән авыл халкының төшенә дә керми торган сумма иде бу. Юлда юк-бар нәрсәгә әрәм-шәрәм итмәде ул аны, ашарына гына тотып, Азнакайга кайтып төште. Исәбе башта Әскәйгә тәпи-тәпи кайту иде, күчтәнәчләр алырга кибеткә керде. Күпме вакыт аерылып торганнан соң, ата-анаң булмаса да, ничек инде акчаң була торып буш кул белән кайтып керәсең: күрше-күлән, бала-чага бар дигәндәй... Менә шул чакта елкылдап торган велосипед күзенә чалынды. Туктале, нигә шуңа атланып кайтмаска?! Кайчандыр йөрергә өйрәнгән иде бит. Велосипед эчен тишмәс, кирәге чыгар. Ә акча дигән нәрсәнең бик яман гадәте бар: әтәч булып кычкырырга гына тора.

Авылда велосипед сугышка кадәр мәктәп директоры Якуповта гына бар иде. Яхшы кеше иде мәрхүм, мин директор дип борын чөеп йөрмәде. Ә бит директорның абруе югары иде. Менә шул Якупов Мөниржанны үз итте, ярдәм кирәк булса, башка берәүгә түгел, гел аңа гына эндәште. Үзе әз генә ярдәмне дә буш калдырмады: йә берәр тәмле нәрсә белән сыйлады, йә нидер бүләк итте. Ә бәрәңге утыртышканнан соң Мөҗәһит белән икесенә бәхетнең бөтенләй көтелмәгәне елмайды: директор абыйлары аларга велосипедта йөреп карарга рөхсәт бирде. Менә шул чакта Мөниржан йөрергә өйрәнеп калган иде. Мөҗәһиттән никтер булмады. Ике-өч тапкыр утырып карады да, мәтәлеп барып төшкәч, бүтән якын килмәде.

Утыз сигезенче елда ахыры, Якуповны, халык дошманы дип, кулга алдылар, аны кулга алганнан соң гаиләсе дә авылдан китте. Шул көннән бирле авыл халкының велосипедны күргәне юк. Андый затлы әйбер кайдан килсен туйганчы ипи дә ашый алмаган сала кешесенә.

*Ахыры. Башы 1нче санда.*

Сатып алган велосипедына Мөниржан Азнакайны чыгып бераз киткәч кенә утырды. Ул дулкынлана иде. Дулкынланырсын да, малай чакта велосипедка утырганда анын ике кулы да исән, аяклары гына педальгә житәр-житмәс иде. Хәзер аяклары бик житә, сынар кул белән йөртә алырмы?

Үргә түбәнрәк жирне сайлап, бисмилласын әйтте дә тәвәккәлләде Мөниржан. Юкка шикләнгән икән, берничә минуттан «ике тәгәрмәчле атына» ияләшеп тә житте.

Тәгәрмәч кыршаулары ялтырап торган велосипед зурларга ничек тәэсир иткәндер, әмма авыл малайларынын тәмам йокысын алды. Их, бер генә тотып карасан иде шунын рулен! Утырып йөрү турында хыялланмадылар да. Андый бәхет, эләксә дә, күрше малае Нәсимгә генә тия. Ә башкаларга велосипед артыннан күтәрелгән тузаны гына кала. Алар өчен бусы да ярап тора.

Баштагы көннәрдә велосипеднын үзен күреп шаккаткан малайларны Мөниржан абыйлары берзаман бөтенләй ушсыз калдырды. Ничек дисезме?

Мөниржан кичтән шактый гына төшергән иде. Башынын чатнавына уянып китте. Кибет ачылганны көч-хәл белән көтеп алып, башын төзәтеп чыкты. Бар иде әйбәт заманнар, күпмегә түләсән, шунын кадәресен салып бирәләр иде. Кайчан керсән дә, кабымлыкка мичкәсе белән килки балыгы тора. Өч тиенгә алсан, ярты авылына житәрлек тия. Акчан юк икән, сатучы алдында ышанычын бөтенләй жуймаган булсан, ул сина әҗәткә дә бирә. Кибет ябылса да, баш бәласе түгел, кибетченен өендә ким дигәндә өч-дүрт әржә запас аракы бар, төн уртасында да борып чыгармый.

Башын төзәткәч, Мөниржаннын күнеле күтәрелә төште һәм кинәт кенә гармун уйныйсы килеп китте. Ләкин өендә бик эссе иде. Ә ни өчен су коенмаска? Гармунны бит аны Зиннәт тугае буендагы ямь-яшел каз үләненә ятып та уйнарга була.

Велосипед кадәр велосипеды булган кеше монын ише көнне ничек инде жәяү йөрсен. Мөниржан да капка төбенә велосипедын алып чыкты һәм су коенырга китте. Зиннәт тугае авылнын түбән очында. Анда илтә торган юл авыл эченнән уза. Мөниржан урам буйлап велосипедта бара, үзе гармун уйный. Кара инде бу велосипедны: руленнан тотмасан да бара икән. Могжиза тек могжиза! Тамаша тек тамаша! Күргән малайларнын күзләре мангайларына менде. Күрмәгәннәргә алар сонышнан селәгәйләрен агыза-агыза сөйләде.

Өченче тапкырында Мөниржанны илле грамм спирт өчен утырттылар.

Жәйге иртәләрнен берсендә, әле Кызыл тау артыннаан кояшнын яна гына күтәрелеп килгән чагында, Мөниржан тавыкларына бодай сибеп йөри иде, берәүнен «Исәнмесез!» дигән сүзенә борылып караса, үз күзләренә үзе ышанмады: каршысында Хаммат басып тора иде. Кочаклашып күрештеләр. Сугыштан кайткан елда бергәләп аулагөйгә йөргәннәре икесенен дә хәтерендә иде. Хаммат нефтькә киткәннән бирле күрешкәннәре булмады. Хаммат кайтса, Мөниржан юк, Мөниржан кайтса, Хаммат юк. Сак белән Сок диярсен.

Хужа кунагын өйгә чакырды.

Өй эчен тәртипсез дип әйтмәсән дә, хатын-кыз кулы тимәгәнлеге сизелеп тора иде. Әйе, Мөниржан һаман ялгыз. Теге яки бу хатынны димләп карадылар, үзен-үзе кияүгә тәкъдим итүчеләр дә булмады түгел, ризалашмады, чөнки Гайниянен назлы карашын онытa, мәхәббәтен йөрәгеннән кем дә куып чыгаралмый иде.

Пенсия акчасына очын очка ялгап барган ялгыз ирнен өе арурак шартларда яшәп өйрәнгән кешегә шыксыз булып күренергә дә мөмкин. Ләкин төрмә казармаларын әле онытмаган Мөниржанга үз өе, «теге ннән»

кайткач, ожмах булып тоела.

Хаммат буш кул белән кермәгән икән. Дуслар көлешә-көлешә дә, бераз сагышланып та, узган көннәрне искә алып сөйләшеп утырдылар.

Мөниржан Хамматның хәзер Әлмәттә яшәвен, бораулау мастеры булып эшләвен ишетеп белә иде. Үзенә ниндидер орден да биргәннәр икән.

—Да, малай, син теге вакытта юкка минем белән китмәден. Нефтедә эш күп анда. Мине менә эшкә алу белән бораулау кадрлары мәктәбенә укырга җибәрделәр. Нефтьчеләр аны ШБК дип тә, «Бигәш академиясе» дип тә йөртә. Шунда укытып, бораулаучы ярдәмчесе ясадылар. Калганы үзеннән тора. Эшли-эшли бораулаучы да булдым. Сонрак мастерлар мәктәбендә укыттылар. Ике ел инде мастер булып эшлим. Тырышабыз, малай… Безнең нәселне беләсең бит, задурлык житәрлек!

Хаммат мавыгып та, горурланып та тормышын бәян итте. Сүзләрендә хәтта бераз мактану галәмәтләре дә чагылып алды. Нефтьтә «а»ны «б»дан аермаган Мөниржан күп нәрсәләрне аңламаса да, кызыксынып тынлап утырды. Сирәк-мирәк сораулар да бирде.

—Бораулауда коммерция тизлеге дигән нәрсә бар,—дип дәвам итте сүзен Хаммат.—Ул никадәр югары булса, эшең дә шулкадәр әйбәт дигән сүз. Ә ул күп очракта мастердан тора. Ягъни эшне ничек оештыруыннан. Ә эшне оештыру исә нәчәлстволың сиңа мөнәсәбәтенә бәйле. Тели икән нәчәлникләр, синнән Герой ясый, теләмәсәләр, утырасың шунда коры паекта.

—Авылда сөйләүләренә караганда, гел коры паекта гына утырмыйсың бугай. Орден алганыңны да ишеттем. Хакмы?

Хамматның болай да ачык йөзе бөтенләй балкып китте:

—Хәк же, хәк же! Хезмәт Кызыл Байрагы ордены бирделәр.

Орден кадәр орденны юкка гына бирмәгәннәрен Мөниржан аңлый иде.

—Ни өчен?—дип сорады ул, кызыксынуын тыя алмыйча.

—Безнең бригада бер станок-айга коммерция тизлеген…

Станок-ай дигәне дә, коммерция тизлеге дигәне һәм Хаммат авызыннан ычкынган күп кенә бүтән сүзләр нефть эшеннән ерак торган Мөниржан Исламовка берни дә аңлатмый иде. Ә кыза төшкән Хаммат ачыктан-ачык мактана башлады:

—Эшләр болайрак барса, Мөниржан дус, минем тиздән Герой булуым да бар. Син минем бораулау буенча СССРда рекорд куйганымны ишеткәнсеңдер ич?

Хамматның уңай җавап ишетәсе килгәнен белсә дә Мөниржан алдый алмады.

—Юк,—дип дөресен танырга мәжбүр булды.

—Кит аннан!—Гаҗәпләнүдән Хаммат кызарып чыкты.—Бөтен ил шаулады бит ул хакта. Язмаган гәжит калмады. Нужәли укымадың?

—Без укыган гәжитләрдә күбрәк бүтән нәрсәләр хакында язалар иде...

—Шулайдыр шул, гафу ит, онытып җибәргәнмен.—Кинәт боегып калган Мөниржанга карап, Хаммат уңайсызланып китте. Бу хәл аны һавада очкан жиреннән жиргә төшәргә мәжбүр итте.

Сүз артыннан сүз иярде. Сөйләшеп утыра торгач, Хаммат алып кергән шешәнең төбе күренде. Мөниржан кибеткә чыгып керергә дип кузгала башлаган иде, Хаммат туктатты:

—Йөрмә, үзем барам. Ничек дип җырлыйлар әле:

Акча бездә бер букча,
Ефәк безгә мунчала.
Яшь гомерләр ике килде,
Өч килсә дә ничава,—диләрме?

Хаммат жил-жил атлап чыгып китте.

«Яшь гомерләр ике килде...» Мөнирҗан анын берсен дә юньләп хәтерләми: өлгереп житкәч, сугыш утына ыргытылды, көч-хәл белән исән кайткан иде, төрмә шулпасы эчәргә булган икән. Берләнбер якты, жылы хатирә булып Гайния генә калган. Анын да, еллар узган саен, жылысы кими, яктысы тоныклана бара.

Ничек жырлады әле Хаммат? Ә, әйе, «Акча бездә бер букча» дип. Бәлки чыннан да шулайдыр. Авыл халкы: «Бурильщиклар акчаны капчыклап алалар икән»,—дип юкка сөйләмәс.

Хаммат каршысында Мөнирҗанның бөтенләй үк мескен булып күренәсе килми иде. Юып, электр плитәсенә пешерергә берничә йомырка куйды. Титибикәләренә рәхмәт, көн саен кытаклап торалар. Тавык кытакладымы, димәк, нindидер хикмәт бар дигән сүз.

Самавырынын капкачын күтәреп, суы барлыгына ышангач, анысын да көйрәтеп жибәрде. Сәгать унберенче киткән, әле бит анын иртәнгелеген дә ашаганы юк. Аракы дөньяны оныттырса да, карында улаган бүреләрне тыя алмый.

Хаммат озак тормады, кайтып та житте. Өстәлгә бер шешә аракы һәм ике балык консервысы утыртты.

—Гафу ит, кабымлыкка бүтән нәрсә юк икән кибеттә. Шәһәрдә колбасасы, кызыл, кара уылдыгыннан киштәләр сыгылып тора.

—Монда кайтарсалар да, аларны кем генә алып ашар икән. Ипилек тә рәтләре юк.

—Әйе шул. Хөкүмәт дурак түгел, белә ни эшләргә икәнен. Нефть кирәк булгач, кадерлиләр. Ә авыл элек ничек фәкыйрь булса, шулай булып калган. Авызын ачса, үпкәсе күренә. Мин бит хәзер авылга, сагындырса да, сирәк кайтам. Нефтьчеләрнен пачут зур, малай, зур. Кемнен акчасы бар, дөньяга шул хужа диюләре хак икән. Син менә үзен уйлап кара: башагын чак кына күтәреп торган арыш яки бодай басуы. Атна-ун көннән уракка төшәргә торалар. Игеннәрне урып алганны көтәсе иде дә бит, юк, шул басуга юл ачарга бульдозер кертеп жибәрәләр.

—Ник?

Мөнирҗан Хамматны арттыра дип уйлаган иде. Ничек инде шаулап торган басуга бульдозер кертергә мөмкин? Бу анын башына һич кенә дә сыймый иде.

—Никме? Чөнки илгә нефть кирәк. Кемнән генә сорасан да сина шулай җавап бирелер.

—Ә икмәк кирәк түгелме?

—Кирәк. Ләкин нефть барсына да галава ди партия.

—Анламыйм. Нефтьне галава дип, шау икмәкне харап итәргә ярыймы? Шуна кемнен кулы бара?

—Ә без түлибез! Бозылган һәр гектар жир өчен хөкүмәт колхозларга бик яхшы түли. Андый акча колхозның төшенә дә керми. Башлырак колхоз прсидәтелләре нефтьчеләрдән ул басудан жыеласы икмәк бәясеннән биш тапкыр артыграк акча каералар.

—Булмас!

—Икмәктер әгәр!—Алдында яткан икмәк телеменә Хаммат иреннәрен тидереп алды.—Бик беләсен килсә, кайбер колхоз предләре фәлән басуга буровой куйыйк әле, юл уздырыйк әле, дип арттан үзләре йөри. Чөнки юкны бар итеп акт төзергә өйрәнеп беттеләр. Тагын да хәйләкәррәкләре, түрәләр белән килешеп, башта акт төзетәләр, аннан игенен жыеп алалар. Басу бушагач кына буровой керә. Сарык та исән, бүре дә тук менә шул була инде.

—Анламыйм, ничек инде алай булырга мөмкин?

—Вәт менә шулай,—шешәнең икенчесе дә шактый бушаган, Хаммат тәмам кайнарланган иде.—Шул басуның уңышын башкаларныкына кушып, «авыл хуҗалыгын үстерүдәге югары казанышлары өчен» орден алучылар да бар.

—Хаммат дус, әллә бераз су кушасың инде? Мине колхоз атларына дип алып кайткан бер-ике йөк печән өчен дә утырттылар, ә син коточкыч нәрсәләр сөйлисең.

—И туган, әллә кайларда йөрсәң дә һаман сабый булып калгансың икән. Югарыраклар арасында чуалсаң, әлләниләр күрер идең. Вагоны-вагоны белән цемент, такта, торба югала, сүзе дә, эзе юк. Белмәсәм, сөйләмәс идем. Сине алдап утырырга мин бит бала-чага түгел,—диде Хаммат, тавышын баса төшеп.—Ярар, синең янга акыл сатарга да, лекция укырга да кермәдем. Үзенне бик күрәсем килгән иде, бигрәк тә гармун уйнаганыңны сагындым. Гармунын уйнарлыкмы? Их, малай, теге вакытларда матур гына яшәп калган идек. Ә Сәлимә, бичара, яп-яшь көе харап булган. Сиңа әйттемме, юкмы, аулагөйдә кунгалаганнан соң, мине бит Мөршидә үзенә чак өйләндерми калды. Ну ут хатын иде, сабакы! Әле хәзер дә кайчагында үзем хатын кочагында ятам, үзем шуны уйлыйм. Нечисно кәнишне! Ярый әле Мөршидә кияү тапкан, югыйсә күпме ир-атның башына житәр иде, каһәр!

—Хатының ниндирәк кеше соң?

Гайниясе исенә төшеп, Мөнирҗанның йөрәге кысылып куйды. Тәне җир куенында булса да, җаны оҗмах түрендәдер инде бәгырькәенең. Оҗмахка Гайния кебекләр дә кермәсә, тагын кем керер.

—Маржа. Ирина исемле.

—Әйбәтме соң?

—Ярый инде. Тик авылга кайтырга дисәң, теше-тырнагы белән карыша. Татар авылында мина ни калган, ди. Ә минем үлеп-үлеп үзебезнең авылны сагынган чакларым була. Хет шунда утыр да ела. Менә бу юлы да түзә алмаганга кайттым. Үзең беләсең, ешрак кайтырга авылда якын туганнарым юк.

—Кайчан кайткан идең?

—Кичә соңрак кына вахта машинасы китереп куйды.

—Кемдә кундың?

—Чулак Гыймади абзыйны хәтерлисеңдер бит. Аның хатыны Бибисара түти инәй ягыннан чыбык очы иде, урыны оҗмахта булсын. Шул Гыймади абзыйның бертуганының малае, безгә бит инде ераграк булса да, кода туры килә, менә шул Фәләх кодаларга кайткалыйм.

Гаҗәпләнсәң гаҗәпләнерлек хәлләр бар икән бу дөньяда. Иң бәхетле дигән кешенең дә күңелендә карурман ята. Анда чәчәкләр генә түгел, башкалар күзенә чалынмый торган әллә нинди урлар, убалар бар. Торып-торып исең китәрлек. Мөнирҗан Хамматны хәтта кызганып та куйды.

—Юньләп урысча сөйләшә дә белмәгән көе ничек итеп маржага өйләнәсе иттең? Татар кызлары беткән идеме?

—Юләр булганга!—Хаммат тегеләй-болай боргалап тормады, турыдан ярды.—Маржа бит ул, татар егетен күрсә, дөньясын оныта. Аңа бит синең телең кирәк түгел. Общагада берничә тапкыр янында кунып чыккан идем, күз яше белән килгән, балага уздым, ди.

—Шуннан?

—Шуннан кызгандым үзен. Өйләнәсе булды. Югыйсә парткомыгызга барам дип тә куркытты. Минем кандидатлык стажым яңа башланган гына чак. Ә ул, стерва, алдаган икән, бернинди дә йөге булмаган. Менә шулай, дустым. Ник алай иттең дигәч, яраттым, ташларсың дип курыктым, ди. Башта бәреп үтерәсе килгән иде дә, тора-бара ияләнәсең икән аны. Хәзер ике бала бар. Икесе дә малай. Күрәсең, бракодел түгел мин. Малайларның берсе Коля, икенчесе Сережа исемле.

Хаммат кинәт йодрыгы белән өстәлгә сугып куйды. Стаканнар

зеңгелдәште, ярый әле аумады.

—Бер сүз белән әйткәндә, авылыма, нәселемә, милләтемә хыянәт иттем мин, Мөнир дус! Миннән татар токымы калмаячак, маржаныкы йотачак. Терсәк якында тешләп кенә булмый.—Ул тынып калды да күзенә чыккан яшьләрен кульяулыгы белән сөртеп алды.—Әйдә, сүз әле берәр үзебезнен көйне. «Сарман»ны, юк, башта «Рәйхан»ны җырлыйбыз.

Аклы ситса күлмәгемнен
Якаларын кем уйган?
Ай...

Хаммат хисләнеп, сагышланып җырлады. Аның тавышы ярыйсы ук ягымлы иде. Мөнирҗанның тамагы бераз карлыгыбрак торса да, ана кушылмыйча түзмәде.

Алар һәрберсе үзенчә бәхетсез иде: Мөнирҗанны инде әйткән дә юк, ә менә тыштан караганда бик бәхетле булырга тиешле, даны да, акчасы да, гаиләсе дә булган Хамматнын да эчендә ут кайный, йөрәге күмерләнә икән бит. Аулакта утырган ике ир җыр артыннан җыр башлады. Иң соныннан Хаммат Мөнирҗанның «Герман көе»н уйнавын үтенде.

Без авылдан чыккан чакта,
Күтәрелде томаннар.
Дөнья хәлен белеп булмый,
Сау булыгыз, туганнар!

Хаммат, урыннан торып, Мөнирҗанга кулын гына биргән иде, соңрак түзмәде, кочаклап ук алды. Иреннәреннән пышылдап бер сүз чыкты:

—Рәхмәт!

Хамматның күзләреннән тәгәрәгән кайнар яше Мөнирҗанның җилкәсенә тамды.

Бораулау мастерының күңеле сизгәндерме, бу җыр аның туып-үскән авылы белән генә түгел, якты дөнья белән дә хушлашуы булган икән бит. Күрәсең, җанының кайсыдыр тамыры сизгәндер дә туган авылына бәхилләшергә алып кайткандыр. Сонрак, төрмәдә утырганда, сирәк килгән хатларның берсендә, буровойда авария булып, Хамматны торба бәреп үтерүе хакында язганнар иде. Гәүдәсен авылга алып кайтып, зурлап күмгәннәр. Бар иде кеше, юк инде кеше. Берәү дә үзенең кайчан, кайда ничек үләсен белми. Язмыш тактасын уку кемгә насыйп?

Адәм баласының хәтере кыска, тиз оныта. Күмгәндә купшы сүзләр сөйләнсә һәм хөрмәтнең зурысы күрсәтелсә дә, шуннан соң Хаммат каберенә аяк басучы булдымы икән? Хатыны, малайлары исәндер. Ир хакы, ата хакы дигән төшенчә булырга тиештер бит аларда. Хәер, Мөнирҗан үзен кемне дә булса гаепләргә хокуклы дип санамый. Башы төрмәдән бушамый, авылда чагында, дөрес, җәй көннәрендә бер-ике мәртәбә Гайния һәм ата-анасы каберен чистартып, чардуганнарын төзәтеп, тәртипкә китереп кайта кайтуын. Вакытның ничек тиз узуын кабер өсләренең яшел чирәм белән каплануыннан һәм исемнәр язылган ташларның саргаеп мүкләнүеннән дә белеп була икән.

Хамматны озаткач, табынын җыештырып куйды да ишек алдына чыкты Мөнирҗан. Калдык-постыкны сибүгә, тавык халкы аны шунда ук сырып алды. Ул кызыл әтәчнең эшем иясе булып йөрүләре! Хәрәм сараендагы кәнизәкләр янындагы төрек солтанымыни!

Бер уңайдан кетәклеккә дә күз төшерде. Титибикәләр бүген дә тырышкан:

алты күкәй салганнар. Рәхмәт төшкерләре. Күкәй бит ул үзе тәмле, үзе туклыклы, әзерләве дә мәшәкатьле түгел. Буйдак кешегә тагын ни кирәк.

Өенә кергәч, түшәгенә таянып, кичә килгән газетларга күз салды. Ашамыйча торса торыр, ләкин укымаса, җанына тынычлык тапмый Мөнирҗан. Укып ята торгач, йоклап та киткән.

Вакытлы-вакытсыз йокының ни хәере булсын. Төшләнеп, саташып бетте. Әүвәл Гайнияне, аны беренче тапкыр озата кайтканын күрде. «Галиябану»ны җырлады да бугай. Юк, җырлады түгел, икәүләп җырладылар. Соңрак, сугышка китәр алдыннан, саубуллашу киче җанланды. Егет кызны кочагына алмакчы була, кыз карыша; үбәргә тели—үптерми.

—Бер генә тапкыр!—дип инәлә Мөнирҗан. Кызның җавабы:

—Исән-сау кайт сугыштан, шунда үбәрсең...

Төш дәвам итә. Снаряд шартлый. Барысы да җәһәннәмгә оча. Мөнирҗан командир Ваня Корпухинны сугыш кырыннан сөйрәп бара. Тагын шартлау. Фәрештәләр, Мөнирҗанны иңнәренә алып, каядыр очалар. Каршы алган ак халатлыларның берсе Гайния икән. Ул Мөнирҗанны, җыелган халыктан тартынмыйча, суырып үбә. Мөнирҗанга шунда ук хәл кереп китә.

—Әйттем бит мин сиңа: үбүемне теләсәң, сугыштан исән кайт, дип! Минем иреннәремнең мең тылсымы бар, хәзер терелерсең.

Кыз аны янә үбә. Егет бөтенләй сау-сәламәт кешегә әверелә.

Вакыйга Ширәмәткә урман кискән көннәргә барып ялгана. Мөнирҗан ни өчен икәнен аңлый алмыйча калды: көрт баскан урман уртасында көтмәгәндә Сәлимә белән Гайния пәйда булды да әүмәкләшергә тотынды. Шунда колач җитмәс нарат шартлап сынды да кызлар өстенә ава башлады. Бу коточкыч хәлдән барысы да куркып, югалып калды. Кемдер кычкырган тавыштан аңына килеп, Мөнирҗан Гайнияне читкә алып чыгып өлгерде, Сәлимәне коткарырга соңга калды... Ап-ак кар өстенә кызыл кан тамчылары чәчрәде.

Тагын ниләр күрер, ничекләр саташыр иде, анысын белми, «драстуй» дигән тавышка уянып китте. Дөрес, ул әле уянганын аңларлык хәлдә түгел иде.. «Тагын саташам»,—дип уйлап алды Мөнирҗан. Ләкин ниндидер көч аны битенә салынып төшкән газетне алырга һәм күзләрен ачып дөньяга карарга мәҗбүр итте. Аның янында башына үзбәк түбәтәе кигән Фазыл басып тора иде.

—Драстуй!

«Бу ниткән бер бетмәгән төш булды соң? Фазылның әле бер генә тапкыр да төшкә кергәне юк иде ләбаса!» Мөнирҗан исән кулы белән ботын да чеметеп карады, ләкин каршысында басып торган Фазыл юкка чыкмады.

—Ник эндәшмисең? Әллә танымыйсыңмы?

Тукта, Фазыл төштә түгел, өндә дәшә түгелме соң! Күзләрен уып, Мөнирҗан торып утырды.

—Фазыл, әллә чынлап та син инде, шайтан алгыры!? Ышанасы да килми.

—Ачуланмасаң, кайттым әле.

Мөнирҗан ничек сикереп торганын һәм балачак дустын кочагына алганын сизми дә калды.

—Син бит бу, син!

—Мин шул, мин!

—Ә мин төш күреп ята идем. Сине дә төшемдә күрәм дип уйладым. Кайчан кайттың?

—Күптән түгел. Ике сәгатьләр чамасы элек. Бүген ниләр эшләргә уйлыйсың?

—Ни эшем булсын минем,—Мөнирҗан көлеп җибәрде.—Авылда чакта мин иркле кош кебек, ниндидер катлаулы планнар корып яшәмим. Гомернең күпчелек өлеше көн үтсенгә уза.

—Синең хәлләрдән бераз хәбәрдәр мин,—Фазыл авыр сулап куйды.—Кызганыч, Гайния китеп барган икән. Сәбәбе ачылмадымы?

—Юк шул...

—Гафу ит, авырткан жиренә кагылдым.

Мөниржан кулын селтәде:

—Ни эшлисең, язмыштыр. Син өйләнмәдеңме әле?

—Юк.

—Вакыт. Сазаган егет булып барасың.

—Шулаен ул шулай да, эшләр генә бармый унайга...Урта Азиядә, Ташкент якларын әйтәм, бу мәсьәлә катлаулырак шул. Анда законнар, йолалар димме, икенчерәк. Калым сорыйлар. Әйдә, иң яхшысы болай итик: хәзер бергәләп безгә барабыз. Сине дә, авылны да сагындым. Алып кайткан күчтәнәчләр белән чәй эчеп, сөйләшеп утырырбыз. Инәй карчык тавык чистартып калды. Әйдә!—диде Фазыл, ике төрле уйларга урын калдырмыйча.

Өрекләр, йөзем жимешләре белән чәй эчәргә утырганчы, Хөршит абыстайга күрсәтмичә генә, дуслар Фазыл алып кайткан шешәдән дә авыз иттеләр. Абыстай, аларның ни эшләгәнен белсә дә, дәшмәде. Ә тегеләре күрсәтеп эчәргә базмады. Фазылның әнисе булу бер хәл, авылның мөхтәрәм абыстае да бит әле ул.

Электр плитәсенә утырткан кәстрүлдә тавык пешә. Аның тәмле исе борын тишекләреннән кереп, ашказаны бизләрен үрти. Озак күрешми торган ике дусның күңел казанында исә хатирәләр кайный. Шушы вакыт эчендә икесе дә күпне күрде, күпне кичерде. Икесе ике жирдә булса да...

Күбрәк Фазыл сөйли. Хөршит абыстайга, ничә еллар күрмәгән улына карап, аның ниләр сөйләгәнен тыңлап утыру дөнья рәхәте. Бу көнне күрә алганына, шушы бәхетле көнгә кадәр яшәгәненә шөкранә кылып, куанычыннан күзенә чыккан яшьләрен тавыш-тынсыз гына яулык очы белән сөртә.

Фазылның Ташкент якларында булганын белә иде Мөниржан. Әмма анда ничек барып эләккән, ничек яшәгән—монысы караңгы иде. Хөршит абыстайдан сораштырганы булды, ана кеше әллә үзе дә белеп бетермәде, әллә белеп тә әйтмәде, Мөниржанга артык мәгълүмат бирмәде.

Фазыл сөйли:

—Бөгелмәдә поездга утырып кузгалдым. Уфага житкәнче, инәй биргән төенчекне урладылар. Ничек кирәк алай мен бәла белән Чимкент дигән стансага килеп життек. Без, дүрт егет, юлда чакта танышып, бер-беребездән аерылмаска сүз куешкан идек, эш сораштырырга керештек. Ярый әле ул тирәдә татарлар да житәрлек, үзбәк, казагы да безненчәне аңлый. Татарга тылмач кирәкми диләр иде, хак икән. Берәү безгә кирпеч заводына барып карарга киңәш итте. Бардык. Чыннан да анда эшчеләр житми, эш авырлыгына түзә алмыйча, кайсы кая китү ягын карый икән.

Без иң авыр эшкә дә риза. Чөнки сайланырлыгыбыз юк, эчтә бүре улый, кесәләрдә жил сызгыра. Без дигәнем—Мансур Баулы районыннан, Иркан—Ульян мишәре, Шәриф Башкортстаннан, Чишмәдән. Әйтәм ич, соңгы ике тәүлектә авызга сыңар валчык та кергәне юк...

Хөршит абыстай янә күзләрен сөртеп алды. Аның да туйганчы ашый алмаган чаклары күп булды, ләкин бу минутта ул үзен түгел, йөрәк парәсе Фазылын кызганып сыкрый. Аның бәгырь кисәге әнә бит нинди жәфалар күргән. Ярый әле үзен Ходай саклаган. Анасының догалары барып ирешкәндер. Аннан соң Фазыл үзе дә ачысын-төчесен күргән, авыр эштән курка торганнардан түгел.

—Паспорт сорадылармы соң?

—Паспорт аларга чуртыма да кирәк түгел. Ул якларга совет власте тиз

генә барып җитүенә бер дә ышанасы килми. Ә паспортны ахыр чиктә барыбер алдык без.

—Ничек?

—Анда барысын да акча хәл итә. Фәлән әкә төгән әкә белән сөйләшә, төгәне өченчесе белән. Һәм шул чылбыр дәвам итә. Өч айлап эшләгәч, бригадирыбыз Мирали әкә белән сөйләшкән идек, шул ярдәм итте. Безне бик хөрмәт итә иде, рәхмәт төшкере. Хөрмәт итмәслек тә түгел, тырыштык без, эшкә нык булдык. Мин бит милитсиядән качып киткән кеше, мине эзләгәннәрен беләм. Тегеләрне эзләүче юк, ләкин алар шулай ук колхоздан качып чыгып ычкынган.

Безгә мичтән чыккан кирпечләрне алып чыгып өяргә куштылар.

Эшләү тәртибе болай: кем күпме күтәрә ала, яңа «пешеп» чыккан кирпечләрне алып чыга да тиешенчә тезә. Ул кирпечләр кайнар, бияләй аша да пешерә. Бияләй дигәннән анысы артык озакка чыдамый, янып-көеп, ертылып бетә.

Ун көннәр чамасы без дә шулай эшләдек. Эш көне азагына җеп өзәрлек тә хәл калмый. Кайтасың да авасың. Берсендә шулай йокыга китә алмый ятканда, башка шундый уй килде: нигә соң әле без ул кирпечне конвейер рәвеше белән ташымыйбыз?

Иртән Мирали әкәгә әйткән идем, ул: «Хуп, мәйле!»—ди. Ягъни үзегезгә карагыз. Малайлар белән киңәштем, алар да каршы килмәде.

Болай эшләүнең отышлы икәне беренче көнне үк расланды. Күп күтәреп көчәнәсе, эч чыгарасы юк. Кирпечне бер-береңә тапшырганчы, кул пешеп өлгерми, әрле-бирле чабып йөрмәгәч, аяклар да ул кадәр арымый. Иң мөһиме, мичтән чыккан кирпеч өелеп ятмый. Мич янында торучыга гына кыен. Эссесенә һич түзәр хәл юк. Анысына да җаен таптык: егерме минут саен алмашып баса башладык.

Кулга акча да керә, пачут та бар. Бер тапкыр хәтта үзбәкләрнең туенда да булырга туры килде. Мирали әкәнең кышлактагы туганнарының берсе кызын бирә икән, үзе белән безне дә алды. Андагы кеше, андагы кеше! Әйтерсең, бөтен районнан җыйганнар. Нугайлар, татарлар дия-дия, безгә аерым хөрмәт күрсәттеләр. Түлке бер грамм эчемлек куймыйлар. Ә ризыклары!.. Сарыклар суела, пылаулар пешә, шашлык кыздырыла, алдан ләвәш өзелми, Әллә ничә көн кунак булып яттык. Уңайсыз иде, китәргә дә бик теләдек, җибәрмәделәр. Аларда йола шундый икән.

Эштән кайткач, общагада гына ятасы килми, егетләр белән чыгып йөреп керәбез. Ара-тирә вокзалга да сугылабыз. Бер керүдә дивардагы тактада милитсия эзли торган кешеләрнең сурәтләрен күрдем. Берсе Татарстанның Буа районыннан. Болай булгач озакламый чират миңа да җитмәс дип, кем әйтәлә? Куркудан котым ботыма җитте. Белмәссең, берзаманны минем сурәтне дә мир каршысына элеп куярлар. Арада сатлыклар булмас дисеңме, барып әләкләсәләр? Таш капчыкка керәсе килми бит.

—Син авылдан чыгып качып бик дөрес эшләгәнсең. Мин генә, исәр, сине тыңламыйча харап булдым. Шуннан?

—Шуннан шул. Түзмәдем, бергә килгән якташларга күңелемдәге шөбһәне чиштем. Киңәш-табыш итешкәч, миңа моннан китәргә кирәк дигән фикергә килдек. Бер-беребезгә ияләнеп беткәч кенә.

Китәргә, китәргә, китәргә! Тик кая?

Кая да булса китәргә өлгергәнче, башны Себер җибәрерлек вакыйга булды. Анысы болай…—Фазыл дөньясын онытып, башыннан кичкәннәрне кызып-кызып сөйли. Ара-тирә түбәтәенә дә сугып ала.

—Кирпеч заводыннан уңлап кешене еракта гы бер кышлакка мамык җыярга җибәрделәр. И-и, малай, мамыктан бәйләгән киемне киюе генә ансат, аны үстерү, җыю—каторга. Андагы хатын-кызларның ничек интеккәннәрен

күреп, йөрәккә кан сава иде. Өстән кояш кыздыра. Юк, кыздыра дию генә аз, яндыра, көйдерә! Ә яланаяклар—суда! Ярар, мин сөйлисе нәрсә башка. Мин бит үстерүдә катнашмадым, әйтәм ич, жыярга жибәрделәр. Жыеп алып чыгабыз да бер өемгә өябез. Тау каләрле булды. Атна эчендә без берничә шундый тау ясадык. Иртәгә кайтабыз дигән төндә, кирәк бит, мамык тавының берсе янды. Башкаларын чак саклап алып калдык. Бер яна башласа, ул күкерт кебек икән. Һич сүндереп кенә булмый.

Килде милитсия, китте сорау алулар. Ярый әле безнең бәхеттән китәсе булды. Кайттык. Тынычлык югалды. Мин бит тамгалы карга, тегеләй-болай була калса, ансат кына миңа ягачакларын беләм. Ак эт бәласен карага сылтау гадәте анда да бар. Өйгә кире сыпыртыр идем, монда да кулга алырга көтеп кенә торалар.

Беткән баш беткән дип Мирали әкә янына киңәшкә бардым, хәлне аңлаттым. Ул безне үз баласыдай күрә торган бик әйбәт үзбәк иде. Танышлары да күп. Әкәжан, мәйтәм, шулай-шулай, бер гаебем дә юк, нан тотып ант итәм: ярдәм итмәссеңме, хәсрәтемне бүлешер бүтән кешем юк. Ни киңәш бирерсең?

Аңлады хәлне әкә, артык сораулар белән интектермәде. Түбәтәен салып, башын кашып торды да Чимган таулары итәгенә урнашкан бер кышлакны әйтте. Андагы хужалык житәкчесе кардәше икән, шуның исеменә язу язып бирде...

Фазыл сөйләгән арада тавык шулпасы да өлгерде. Аны ашар алдыннан дуслар яшертен генә янәдән шешәдән тамак чылатты. Аш янында Фазыл сүзен дәвам итте.

—Эзләп киттем бу кышлакны. Мирали әкә өйрәткәнчә, башта поезд белән Ташкентка бардым. Ташкенттан Чырчык тарафына юл тоттым...

Фазыл ни өчен бу кадәр жентекләп сөйлидер. Ни Мөниржан, ни Хөршит абыстайның ул тирәләрдә йөргәне юк. Ә үзең күрмәгәнне күз алдына китерүе кыен.

—Тел белсәң югалмыйсың икән. Өченче тәүлек дигәндә барып кердем теге кышлакка. Тарлавыкта урнашкан икән. Башыңны күтәреп карасаң, өскә таулар аварга тора. Кышлакка бару да, аннан олы дөньяга чыгу да жәяүләп яки ишәк белән атка атланып кына. Бездәге сыман ат жигеп йөрерлек түгел. Соңыннан белдем: Гражданнар сугышы вакытында басмачлар оясы булган икән бу кышлак.

Тау арасында бик кызык: барасың, барасың, күз аткан нәрсәң күренеп тә тора, якында гынадыр, менә-менә килеп житәрсең кебек, ә ул жәһәннәмдә булып чыга. Берсеннән берсе биегрәк кыя астыннан атлаганда, ничә чакрым узганыңны һич кенә дә чамалап булмый.

Әйтәм ич, арып-талып булса да барып життем. Таптым кирәк кешене, бирдем теге язуны. Үзбәкчәне Чимкентта чакта бераз өйрәнгән идем, яртылаш үзбәкчә, яртылаш татарча пупалыйм. Хужа миннән шунда ук сорады:

—Ничә сыйныф укыдың?

—Жиде.

Моны ишеткәч, үзбәк агаеның чырае ачылып китте. Ләкин нигәдер аның ышанасы килми. Ул:

—Чынлап та жидеме?—дип сорады.

—Чынлап,—дим.—Түлке янымда дәкүминтем юк.

Үзбәк агае кулын гына селтәде:

—Безгә синең дәкүминтең түгел, эшли алуың кирәк.

Хисапчының ярдәмчесе үлгән дә, аның урынына дүрт гамәлне башкарырдай кеше таба алмыйлар икән. Кышлакта иң белемлесе дүрт классллы гына ди.

Кирпеч белән эшләгәндә башның әлләни кирәге юк: ал да ыргыт, ал да

ыргыт. Ә бит хисапчы булыр өчен баш кирәк.

—Белмим шул,—дим.—Эшләгән эшем түгел. Ат караганым бар, тирес түккәнем, сука сукалаганым, ашлык суктырганым бар...

Хуҗа:

-Андый эшкә минем миһманнарым болай да җитәрлек, мина хисапчы кирәк,—ди. Аның үз кырыгы кырык.—Карендәшем Мирали сиңа ярдәм итүемне сораган. Мирали әкәнен үтенечен аяк астына сала алмыйм, өйрәнерсен, грамытың җитәрлек.

Шулай итеп, һич уйламаган җирдән хисапчы булып киттем. Сигез айдан соң баш хисапчы Абдулла сырхаулады да мине аның урынына куйдылар.

Җиде класс укуның файдасы тиде. Хисапчы—үзбәкләр арасында бик абруйлы эш. Кышлак хуҗасының ихтирамлы карашын күргәч, андагы халык үземә «әкә, әкә» дип кенә тора.

—Барысы да әйбәт, тормышым көйләнгән иде, сагындырды. Яхшы булса да торган җир, сагындыра туган җир. Авылны, кешеләрне, инәйне сагындым. Аннан соң яшь тә бара, үзең беләсең. Минем үзбәк кызларына өйләнәсем килми. Яучыларга теләүчеләр бар-барын, әмма капчыктагы песи баласын аласым килми. Моннан берәрсенә өйләнеп, инәйне дә үзебез белән алып китәргә ният.

Хөршит абыстайдан яшереп эчкән аракы тәэсиреме, әллә сагынуы, күрешү шатлыгы телен чиштеме, Фазыл сөйли дә сөйли.

Дуслар ашыкмыйча гына гәпләшеп утырды. Аларга комачауламыйм дип Хөршит абыстай ишек алдына чыгып китте.

Әнисе юктан файдаланыпмы, әллә шул минутта гына исенә төштеме, Фазыл Мөнирҗаннан сорап куйды:

—Син Гөлфәния исемле кызны беләсеңме?

Мөнирҗан рәхәтләнеп көлде:

—Таптың сорар кеше! Клубка чыкмыйм, ул яшьтән узган... Ә болай яныма кызлар килеп йөрми. Кем кызы соң ул?

—Белмим.

—Ник сорыйсың алай булгач? Күзең төшмәгәндер бит? Кайда күрдең?

—Бөгелмәдән бергә кайттык. Хисапчылар курсына укырга җибәрделәр, ди. Бер кашык су белән йотарлык гүзәл, шайтан алгыры! Кай арада үсеп җиткәндер.

Мөнирҗан янә көлде:

—Харап булгансың икән, Фазыл. Йөрәгеңә утлы күмер төшергәннәр. Кем кызы икәнен ник сорамадың?

—Кыенсындым. Кара әле, мин китеп торган арада чибәр-чибәр кызлар җитлегеп куйган.

—Бездән сорап тормый, тормыш бара да бара, дустым.

—Мөнирҗан, әйдә бүген клубка чыгабыз. Чынлап әйтәм, сагындым. Үзебезнең авылның моңын, биюләрен сагындым. Үзбәк ягында яшәп карагач, сиңа шуны әйтәм: безнең татар кызлары бигрәк чибәр икән. Үзбәкләр үз кызларын да гүзәл ди, ну, малай, минем күңелне кузгатмый алар.

Мөнирҗан сүз озайтмады, бары көлемсерәп кенә куйды.

Кояшның алтынсу нурлары офык артына яшеренде. Җиргә кичке салкынча рәхәтлек инде. Көтү кайтканда урамда күтәрелгән тузан басылды. Клуб ягыннан кемдер тальян гармунын сызып җибәрде. Мөнирҗан аны шунда ук таныды: Җәләй малае Хатип бу. Гармунчылар күп булса да, гармун төрле кеше кулында төрлечә сайрый.

Гармун тавышы Фазыл күңелендә янган утны янә дөрләтте:

—Хәтерлисеңме, синең белән мунчада гармун яндырып көлен ашаган идек,—дип хатирәләргә бирелде ул.

—Хәтерләмичә соң! Бигрәк тиле булганбыз, әйеме.

—Әйтмә дә инде, Госман абзыйның алдаганына ышанып, бердигән гармунны харап итеп куйдык. Ләкин мин үкенмим: син барыбер гармунчы булдың. Киттекме! Инәй,—диде ул чолангдагы урынына ятарга өлгергән әнисенә,—мин клубтан урап кайтам әле.

—Бар, улым, бар, исән-сау гына йөри күрегез.

Хөршит абыстай бүген бәхетле иде. Кылган догалары Аллалаһыга барып ирешеп, әнә бит Фазылы кайтты. Өйләнергә дә нияте бар сыман. Бирсен Ходай, бирсен Ходай. Берәр акыллы кызга өйләнсен дә, Хөршиткә аларның балаларын багу бәхете язсын. Тик кире китү турында, аны да алып китү турында хыяллана бит бу бала. Юк инде, тагын ничә ел гомере калгандыр, чит-ят туфракларга китеп гүр иясе булырга язмасын. Горбәтлектә Урал якларында йөргәннәре дә бик житкән. Әскәйдән ары бүтән аяк атлап чыгасы юк. Аның үз алдына биргән анты бар.

Дуслар барып кергәндә, клубка егетләр, кызлар шактый жыйналып өлгергән иде. Фазыл шунысына игътибар итте: ул туган авылыннан качып киткәндә, клубка фронтовиклар хужа иде. Хәзер үзгәргән: яшь-жилкенчәк үсеп житкән, хәзер монда алар хужа, алар баш. Әнә бит клубны ничек дөбер-шатыр китерәләр.

Фазыл гына түгел, яшьләрнен кайберләрен Мөниржан да танып бетерми иде. Ләкин яшьләр, әдәп саклап, берәм-берәм килеп күреште.

Мөниржанның күнеленә рәхәт, ул бүген үзен кеше итеп сизә иде. Шуңа күрәдерме, кемдер килеп кыстаганны да көтеп тормады, клубның түренә узып, бушаган гармунны кулына алды. Көндезге эштә арып-талып эт булган яшьләр, күрәсең, шуны гына көтеп торганнар, уртага күмәк уенга чыгып басты. Арыган, сызлаган буыннарны язу өчен яшьлеккә дәртле бер көй дә житә.

Онытылып уйнады ул. Жырлы уеннарны бию алыштырды. Тукта, Фазыл кемнедер биергә чакырды. Бәрәч, кемнедер дигәне аларның күрше Гариф абзый кызы ич! Исеме кем соң әле? Әйе-әйе, Гөлфәния бит! Тукта-тукта, дусты сөйләгән кыз шул булып чыга түгелме! Тик Мөниржан күрше кызының Бөгелмәдә курсларда укыганын белми иде. Белмәве дә гажәп түгел. Төрмәдән «ялга» гына кайткан адәмгә кем хисап биреп торсын.

Гөлфәния белән Фазыл биеп туктагач, Мөниржан гармунын куеп, маңгаена бәреп чыккан тирен сөртеп алды һәм Фазыл янына китте. Ул арыган иде. Арырсың да, иртәнге якта Хаммат белән күрештеләр, соңыннан Фазыл кайтып төште.

Фазыл Гөлфәния янында басып тора иде. Мөниржан килгәч, күрше кызы оялып кына аның белән исәнләште, әллә озак биюдән, әллә дулкынланудан аның яшь, чибәр бите кызарып чыккан иде.

—Мин киттем!—диде Мөниржан Фазылга.

—Иртә бит әле, ник ашыгасың?

Мөниржан шаяртып жавап бирде:

—Сыер саварга йоклап калырмын дип куркам! Ярый, иртәгә күрешкәнгә кадәр!

Клубта уен дәвам итте. Яшьләрнең биюеннән күтәрелгән тузанга ишек төбендә тәмәке тартучыларның төтене кушылып, иренмәгән кешегә балта эләрлек булды.

Мөниржан койма буендагы сукмактан өенә табан атлый. Бар иде аның да бүгенге яшьләр шикелле уйнаган-көлгән чаклары, Гайния дип сызланган вакытлары.

Кинәт аңа бик ямансу булып китте. Гомерлек ялгызлыгын тою башына китереп сукты. Бу халәтеннән котылып тору өчен хәзер йөз, юк илле генә грамм булса да аракы эчәргә кирәк. Тик ул аракыны хәзер кайдан табасың? Бу вакытта бимазалаганны кибетче Ямал да өнәмәс.

Ул туктап уйланып торды һәм күзе ихтыярсыздан койма артында гына

торган медпунктка төште. Тукта, аракы гына эчәргә димәгән. Аңа бит спирт та ярый. Ә медпунктта спирт булмый калмас.

Медпункт, әлбәттә, бикледер. Һи, ишеге бикле булса, тәрәзәсе бар ич! Хәзер инде Мөниржанны уйлаган ниятеннән берни дә туктата алмый иде. Коточкыч ялгызлыктан һәм өметсезлектән аны бары тик спирт кына коткарачак. Котылып калу өчен булгач, медпункттан спирт алу хәтта җинаять тә түгел. Ул бит исән калу өчен кирәк. Төрмәдән кайткан булгач та, уларга димәгәндер бит.

Мөниржан бакча яктагы тәрәзәнең эшермәсен ачты, бәхетеннән, эшермә бикле түгел иде. Әмма ул таза ир-ат сыйсын өчен эшләнмәгән булып чыкты. Мөниржанның башы ничектер керде, күкрәге исә һич кенә дә сыярга уйламады. Аңа башын кире чыгарудан бүтән юл калмады. Ләкин кергәндә кергән баш, чыгара башлагач, һич кенә дә чыгарга теләмәде. Мөниржан үзенең бик ахмак хәлдә—әсирлектә калганлыгын сизде: ни керә, ни чыга алмый. Ни эшләргә? Озакламый клубтан халык таралыр, болай торып булмый, бер-бер карарга килергә кирәк.

Әй, беткән баш беткән, сыдырылса яңагы сыдырылсын, ничек тә башын тартып алырга!

Мөниржан кулы белән тәрәзә рамына таянып, башын ныграк тарта башлаган иде, сугышка кадәр үк салынган медпунктның, еллар узу белән шактый черергә өлгергән тәрәзә рамы өтерге белән тоташтырган нәзек җиреннән сынып, пыяласы челтерәп коелып төште. Башы ирекә чыкты һәм ул, гәүдәсен тотып кала алмыйча, гөрселдәп җиргә барып төште. Хәзер инде аңарда спирт кайгысы калмады, кызмача миенә никадәр ярамаган гамәл башкаруы барып житте һәм ул, кеше-кара күргәләгәнче дип, өенә сыпыртты. Кайткач белде, кулы бераз пыялага киселгән икән, аны чүпрәккә урады. Битенең сыдырылганына игътибар да итеп тормады.

Күрәсең булса, күркә талап үтерер дигәннәре хак икән. Мөниржан уянганда, авыл халкы медпунктның тәрәзәсе ватылуы хакында сөйләп арыган иде инде. Медсестра күптән түгел генә эшкә җибәрелгән Валя исемле яшь марҗа кызы иде, ватык тәрәзәне күргән сыер савучы хатыннар уяткач, беренче эше итеп Хәсьяновка хәбәр иткән иде. Ә колхоз рәисе шул минутта районга шалтыратты. Гаебен танырга, тәрәзәне куйдыртырга дип барган Мөниржанны тыңлап торучы да булмады. Озакламый килеп җиткән участок милиционеры Исламовны үзе белән районга алып китте.

Тикшерүне озакка сузмадылар: талау максаты белән җәмәгать милкенә зыян китергән өчен, суд аны чираттагы срокка хөкем итеп, «казна шулпасы» эчәргә озатты.

* * *

Фазылны исә язмыш Бөгелмәдән юкка гына Гөлфәния белән бергә кайтармаган икән: санаулы көннәр эчендә ике йөрәк арасында иң нечкә җепләр сузылды һәм капка төбендә сайрашып-чүкердәшеп каршы алган алсу таңнарның берсендә, ә кыз атна ялына кайта иде, Фазыл үзенең авылны ташлап китә алмасын аңлады, Гөлфәниягә ачыктан-ачык мәхәббәтен белдерде һәм кияүгә чыгарга кушты. Гөлфәния каршы түгел иде, ләкин бер шарт куйды: хисапчылар курсын тәмамламый торып, туй турында авыз да ачмаска. Курслар бетәргә күп түгел—ай ярымлап кына калган иде.

Өйдә яту таза-сәламәт егет эше түгел, Фазыл бригадирдан эш сорап барды. Бригадир өчен мондый кадр күктән төшкән бәхет, икенче көнне үк үзбәктән кайткан егетне печән хәзерләүгә җибәрде. Авылдашларының кайберләре Фазылның бу адымын аңлый алмады: ничек инде ул, паспортың була торып, башыңны шушы үләлмәгән колхозга кол итеп тыгарга мөмкин?

Аның паспорты булсамы, паспорты булсамы, абзагыз белер иде кая китәргә! Күрер идегез аннан аның кем икәнен!

Ләкин Ходай сөзгәк сыерга мөгез бирми интектерә.

Фазыл белән Гөлфәния арасындагы мөнәсәбәтне белүчеләр исә мыек астыннан елмайды: гыйшык уты диләр аны!

Печәннән соң уракка төштеләр. Сентябрь башларына Гөлфәния, укуын тәмамлап, колхозда хисапчы булып эшли башлады. Вәгъдәләр куешканча, инде туй ясарга да мөмкин иде, ләкин халыкта урак чорында ялкау гына өйләнә, дигән сүз бар. Көз—шул ук урак өсте, ашлыкны җыеп бетерергә, бәрәнге алырга кирәк. Туй ясар өчен иң унайлы вакыт Октябрь бәйрәме булып чыкты. Шулай итеп Хөршит абыстай күптән хыялланган теләгенә иреште: Фазылы башлы-күзле булды. Ходай боерса, орлыгы Бохарада түгел, оныклар да озак көттермәс. Бу инде Ана кеше хыяллана торган бәхетле тормышның нәкъ үзе. Аннан соң мәңгелек йортка күчсән дә үкенечле түгел.

Яңа елга чыккач, гыйнвар азакларында, колхозның отчет-сайлау җыелышы булды. Анда Мидхәт Хәсьяновны, район үзәгендә башка эшкә күчерелүе сәбәпле, рәислектән азат иттеләр һәм урынына авылның үз кешесен сайлап куйдылар. Бүтән үзгәрешләр дә булды. Элеккеге җиде бригаданы эреләндереп, дүрткә калдырдылар. Фазыл өчен иң гаҗәбе: көтмәгәндә аны беренче бригадага бригадир итеп билгеләделәр. «Мондыйн артык тәкыйгаҗәп дыңларый бар».

Бу яңалыклар Мөнирҗан утырган төрмә кысаларына тагын ярты елдан соң гына барып иреште.

Авылга Мөнирҗан бер мең тугыз йөз сиксән алтынчы елның февраль азакларында кайтып керде.

Поездан ана Ютазы стансасында да төшеп калырга була иде. Тик аннан Әскәйгә элэгүе күп тапкыр катлаулырак. Шуна күрә ул Бөгелмәдә төшүне кулай күрде. Вакыт чагыштырмача соң булса да, Азнакайга кайтучы автобуска утырырга өлгерде. Соңгы елларда Әскәйгә дә автобус йөрү җайга салынган иде салынуын, әмма соңгы автобус Мөнирҗанны көтеп тормаган, китеп барган.

Ни эшләргә? Вокзалда төн үткәрергә йә булмаса берәрсенә кереп куныл чыгаргамы? Әллә «унберенче трамвай» белән тәвәккәлләргәме? Белмәссен, юлга чыксан, берәр машина очрап куюы да бар.

Бәлки аңа Әскәйгә кайтып тормаска, хатирәләр яңартмаска кирәк булгандыр. Беткәнмени Рәсәйдә урын. Пенсиясе бар.

Абыйсы Гаяз сугышта хәбәрсез югалды. Ата-анасы күптән вафат, күрше авылдагы апасының алты бала, үз мәшәкате чиктән ашкан, һәркемнең дә үз тормышы бар. Дөресен әйткәндә, Әскәйгә бәйләп тотардай бер генә җеп тә калмаган. Читтә яңа тормыш башлап җибәрү җинелрәк булмас идеме икән? Бәхет эзләп татар гомер-гомергә читкә киткән. Хәтеренә күптән түгел укыган бер шигырь килде:

Кайда бармыйм, кайда йөрмим,<br>
Абынсам—татар икән.

Дөньяда татар хәтәрме?

Ялгышасыз,<br>
Татарларга<br>
Тигән җил хәтәр икән.

Әйе, татарның язмышы беркайчан да җиңел булмаган. Ул Донбасс,

Кузбасс шахталарында күмер чапкан, иксез-чиксез калын тайгаларда урман кискән, «халыклар атасы»ның планнарын тормышка ашырып, каналлар, ГЭСлар төзегән, завод-фабрикалар корган. Унтугызынчы гасыр азагында, егерменче гасыр башында «ач үлемнең куркусыннан ил елаган» бер вакытта авылы-авылы белән Төркиягә күчеп утырган. Октябрь түнтәрелешеннән соң горбәтлектә гомер уздырырга мәҗбүр булган милләттәшләре азмы? Ата-бабаларыбызның изге туфрагы, үзәге саналган Татарстанда татар дигән халыкның яртысы да яшәми. Шунысын берничек тә аңлый алмый Мөнирҗан: төрлечә алдап-йолдап, мал, акча белән кызыктырып, татарларны Ерак Көнчыгышка, салкын төньякка, бүтән җирләргә күчерү дәвам итә, ә Татарстанның үзенә комсомол путевкасы белән дә, путевкасыз да әллә кайлардан башка халыкларны дыңгычлап китереп тутыралар. Алар арасында әтрәк-әләм, адәм актыклары да җитәрлек.

Мөнирҗан үзенең кара акылы белән моның гадел түгеллеген, кем тарафыннандыр үз Ватанында татарны халык буларак сыекландыру, куян шулпасының шулпасына калдыру максатыннан эшләнгәнен аңлый, тик исбатлап бирергә генә хәленнән килми. Хәер, аның кебек ярты гомерен төрмәдә уздырган кешенең кайдан абруе булсын да, аны кем тыңласын ди. Татарстанның үз җитәкчеләре ни карый торгандыр... Ә бәлки ил буенча "кече" халыкларга карата алып барыла торган геноцид сәясәтенә каршы тору аларның да кодрәтеннән килмидер.

Шул ук вакытта кайберәүләр бу гигант төзелешләрнең, нефть чыгаруның төрле кыйтгаларга чәчелеп-сибелеп яшәгән татарларны киредән Татарстанга җыюда уңай роле булды дип тә исәплиләр. Уйласаң, бусында да бераз хаклык бар сыман. Бу дөньяны аңлар өчен каланчаң биек булуы кирәк. Әнә шул биек каланчаңнан карап күбрәк уйларга кирәк. Күбрәк уйласаң, шөрепләрең ычкына башлаганны сизми дә калырсың. Ул бит инде күптән әзер боерыкларга буйсынып яшәргә өйрәнгән. Төрмәдә бүтәнчә яши дә алмыйсың.

Өендә көтеп торган кешесе юклыгын белсә дә, Мөнирҗан кайтып кунарга ниятләде. Ул менә хәзер генә Әскәйне никадәрле юксынганын аңлады. Өйгә якынайган саен сагыну, җирсү хисе арта бара икән. Яшьрәк чагы булса, валлаһи, түзмәс, йөгереп кайтыр иде.

Көн тыныч, суык та түгел. Әлегә, әлхәмделиллаһ шөкер, аякларыннан зарланмый, күктә бәхет вәгъдә иткән йолдызларга карый-карый, авыл белән ике араны якынайта бирә. Ара-тирә Чатыр тавына күз сала. Төнге ай яктысында ул аеруча сихри, тылсымлы булып күренә. Адашудан куркасы юк: теге кайтуында ук юл күтәртелеп, таш түшәгәннәр иде. Аннан соң өч елга якын вакыт узды, хәзер менә асфальт та җәеп куйганнар, рәхмәт төшкерләре.

Төрмәдә чагында Мөнирҗанның авыл белән алыш-биреше өзелә. Ул хат язмый, ник хат язмый икән дип Әскәйнең үзендә дә өзгәләнүче калмаган. Туганнан туганнарының оныклары аны әллә белә, әллә юк. Татар тау халкы түгел, буыннар ераклашкан саен аның туганлыгы да кими бара. Берәүгә дә үпкәләп булмый: һәрберсенең үз тормышы, үз мәшәкате... Ярты гомерен төрмәдә уздырган адәм кемгә кирәк. Үзе соң, үзе шәҗәрәсен ничә буынга кадәр генә белә. Әле дөньяда бабасының исемен белмәүчеләр дә очрый.

Авылда хәзер аның бердәнбер сүз кушарлык кешеләреннән Фазыл гына калды. Әмма яшьлек дустының буш вакыты юк диярлек. Урта Азия якларыннан йөреп кайтканнан соң аны бригадир итеп куйганнар иде, колхозны совхозга әвереллдергәч, управляющий ясадылар—һаман шул камытны салганы юк. Хуҗалыкның тавык чүпләп бетерә алмаслык мәшәкате Фазыл җилкәсендә. Ничек чыдый торгандыр.

Уйларына чумып, Мөнирҗан атлавын белә. Тулган ай калыкты. Хәзер аның нурлары күңелен җылыта, яшьлеген искә төшереп, хисләр ташкынын кузгата. Их Гайния, Гайниябану! Син исән булсаң, Мөнирҗанның язмышы

бүтән юлдан китәр иде бит! Барын-югын ил белән бергә күреп, балалар белән чөкердәшеп, башкалар шикелле дөнья кичермәс иделәрме?

Күзенә чыккан яшьләрен исән кулы белән сөртеп алды. Ярый әле автобус белән кайтырга соңга калган. Бу минутта аның беркемне дә күрәсе, сөйләшәсе, серләрен бүлешәсе килми иде. Сирәк күрешкәндә, танышбелешнен телендә һаман бер үк сораулар бит: кайчан кайттың, кайда утырдың?

Капка төпләрендә аны коелары каршы алды. Бабасы Ризван теге гасырда ук казып, Карагаш кулыннан чыгарган таш белән эчләнгән кое бер гасырга якын инде үзгәрешсез. Бары тик, чересә, имән баганасын, сиртмәсен алыштыралар да тишелгәне урынына яна тимер чиләк эләләр. Сугышка кадәр дә, аннан соңгы елларда да тимер аеруча кадерле иде—Мөниржаннын әтисе ясаган агач чиләк кулландылар. Тимер чиләк илленче еллар урталарында гына эленде. Коены карап тору Исламовлар өстендә булса да, аннан кем генә файдаланмады. Авыл халкын әйткән дә юк, узгынчылар да, туктап, атларын эчереп, рәхмәт әйтеп китәләр иде.

Кая карама, нәрсәгә генә орынма, барысы да сагынып кайткан ир күнелендә җылы хатирәләр уята. Ләкин монда озак торып булмый, өйгә керергә кирәк.

Быел кар күп яуганга охшый. Авыл өйләрен көрт баскан. Мөниржанга, капкасын ачып керергә уйласа, озаклап кар көрәргә туры килер иде. Бу эшне башка көнгә калдырып, ул койма буенда озак ятудан тыгызланган кар өеме өстеннән эчке якка атлады.

Өенә кергәч, бала чактан ук күнеленә сенеп калган һәм газиз, кадерле булып әверелгән туган йорт исе борынына килеп бәрелде. Бу—йортны күпме генә юсаң да, җилләтсәң дә бетми торган борынгылык, кадимилек исе шул. Чемоданын идәнгә куеп, үзе сәкегә утырды. Йөрәгендә кайту, туган нигезенә аяк басу шатлыгыннан хисләре ташып торгангамы, утны кабызырга ашыкмады.

Хисләр ничек кенә бәргәләнмәсен, гомер буена болай утыра алмыйсың. Хәрәкәтсез торудан әрсез суык башта аның аягына, сонрак эчкә табарак та үрмәләде.

—Тәк…дип әйткән ди бер үрдәк,—дип бәхетле сөйләнә-сөйләнә, Мөниржан урынынан торды. Үз өендә катып утырырга ярамас, мичкә ягып җибәрергә кирәк.

Ул торып ут кабызды һәм абзарга чыкты. Урлап бетермәсәләр, анда утын булырга тиеш. Һи, алар авылында урлашуның гомергә булганы юк (колхозныкын кыстырып кайтуны санамаганда), утын әрдәнәләре ул ничек өйгән булса, шул көе торган.

Кочагына сыйдыра алган кадәр күтәреп, Мөниржан утын алып керде һәм ут уйнаган мич каршысына утырды.

Коры утын шартлый-шартлый яна. Янган саен өйгә җылылык һәм тансык төтен исе тарала. Өйнен җылына баруынын беренче билгесе шул булды— мич казнасы ярыгыннан чикерткә аваз салды. Өйгә кайту шатлыгыннан Мөниржаннын алгысыган күнеле тагын да ярсып китте. Бәлки бу чикерткә аны киткәнчегә кадәр үк хәтерли торган иске танышыдыр. Кызык, йорт чикерткәләре ничә ел гомер сөрә икән? Әнә козгыннар, ташбакаларны өчәр, дүртәр йөз ел яши диләр бит. Әлбәттә, чикерткә ише вак-төяк алай ук яшәмәс. Алар озын гомерле була калса, Җир шарын әллә кайчан басып китәрләр иде.

Хәзер менә үзе алып кайткан хәзинә белән тамак ялгап та алса. И юләр, ни эшләп монa кадәр чәй куймады икән ул. Ашаудан бигрәк аның эчәсе килә икән бит. Ике сәгатьтән артык тәпиләп кайтып, тамагы нык кибекте. Туктап, юлда кар кабарга да уйлаган иде, тыелып калды.

Плитәсе эшләсә, чәй кайнату артык кыен булмас булуын. Су алып

керергә генә кирәк. Чоланнан чиләк эзләп табып, кергән эзеннән ул коега чыкты. Коеның суы авылда иң тәмлеләрдән саналганга, малын кайдан туры килсә, шуннан эчерсә дә, күрше-тирә чәйгә суны Габделихсан коесыннан алып кайту ягын карый иде. Менә бит, Мөниржанның өйдә булмаганына ничәмә-ничә ел, ә кое тирәсендә эзләр бар. Димәк, килгәннәр, димәк, су алганнар. Югыйсә су күбесенең ихатасына торбалар буйлап артезиан коесыннан үзе килә.

Кое сиртмәсе чиләкне төшергәндә-менгергәндә ыңгырашып тавыш бирде. Бу аның «исән-сау кайтуың белән котлыйм» дип сәламләве булдымы, әллә «төнлә дә тынгы бирмисең», дип сукрануы идеме—ничек кенә булмасын, Мөниржанның тансыклаган күңеленә рәхәт бирде бу тавыш.

Ун-унбиш минутлар уздымы икән, электр плитәсенә утырткан чәйнектәге су кайнап чыкты. Өстәлне сөртеп, юлда чакта ук хәстәрләгән тәм-томын шунда тезде.

Чәйнең тәмлелеген әйт син, теленне йотарсың! Теләсә нинди суда чәй болай чыкмый да, тәмле дә булмый. Мөниржан үз коелары суына рәхмәт укып, тагын чәй агыза башлаган гына иде, өйалдында аяк тавышлары ишетеп, сагая калды. Кем йөрер икән бу вакытта?

Ишектән әүвәл бер йомарлам пар, аңа ияреп ир кеше керде. Урам аша күршеләре Гариф карт икән.

—Кем бар монда?

Урыныннан торып, Мөниржан күршесенең каршысына барды:

—Исәнме, Гариф абзый!

—Бәрәч, Мөниржан күрше, син бит бу! Исән-сау гына кайттыңмы? Көндезен бер дә күзгә-башка чалынмаган идең. Кайчан кайттың?

—Күптән түгел. Бер сәгатьләр чамасы элек кенә.

—Ту-ты. Ә мин урам як тәрәзәсе аша карыйм: сезнең өйдә ут күренә. Өстәвенә морҗасыннан төтен дә чыга. Туктале, мәйтәм, кем бар, кем шаяра икән, дим. Соңгы елларда Азнакайдан авылга җыен шыпана йөри башлады. Шулар түгелме икән дип, карарга керүем иде. Ярар, үзенне күргәч, күңелем тынычланды. Кайтып бик әйбәт иткәнсең.

Чыгарга җыенган картны Мөниржан туктатты:

—Ашыкма инде, күрше. Күрешү куанычыннан берәр чынаяк чәй эчик. Кайгыртып йөрүең өчен рәхмәт.

—Чәй дисеңме? Ярар, алайса, эчсәм эчим инде. Барыбер төнлә адәм рәтле йоклап булмый. Картаю бер дә әйбәт нәрсә түгел икән.

—Нинди картаю ди ул. Болай карап торуга егетләр кебек күренәсең әле.

—Карап торуга шулайдыр да, яшь барыбер үзенекен итә. Күзләр бирешә, күзләр...

—Өегездә ни хәлләр бар, Гариф абзый? Җиңги исән-саумы? Балалар ни хәлдә?

Алар арасында туганлык җепләре юк. Башка авылдан килен булып төшкәнгә күрә генә Гариф картның карчыгын ул җиңги дип йөртә иде.

—Бер көе. Балалар да Аллага шөкер. Авылда да искитәрлек яңалык юк. Газны син киткәнче керткәннәр идеме?

—Юк, сөйләнәләр генә иде әле.

—Алайса, өйләргә әнә шул газны керттеләр. Иллә дә рәхәт нәрсә икән. Шуны ни эшләп элегрәк уйламаганнардыр.Үзебезнең җир астыннан гына чыга бит югыйсә. Мичкә ни ягарга белмичә, халык күпме еллар иза чикте. Сиңа да керттерергә кирәк ул газ дигән нәмәстәкәйне. Бик рәхәт,—дип кабатлады күршесе.

Заманында Әскәйнең тирә-юнендә урман шаулаган, диләр. Әмма, Мөниржан үзен белгәндә, авылга иң якындагы Саклау урманына дүрт-

биш чакырым иде. Ара ераклыгы бер хәл, аннан авыл халкына һич кенә дә утын кисәргә рөхсәт ителмәде. Кайда ул кисү, корып ауган агачына да кагылдыртмадылар. Черегән төп, ботак-санак ишене алып кайтканынны күрсәләр дә, авыл советына чакыртып, жанынны алдылар. Печәнне болыннан чабып алып кайтканда, урман карауччы Саттар очраса, туктатып, арбанны тикшерде. Саттар тикшергәндә, ялгыш берәр агач яки куак үсентесе килеп чыксамы? Елый-елый штраф түләде халык.

Шуна күрә утынга тилмергән Әскәй халкы гомер-гомергә, язга чыгу белән, тирестән кирпеч сукты. Колхоз эшенә яраклы карт-коры белән кул астына керә башлаган бала-чага, кем капчык асып, кем уфалла арбасы тартып, көтү йөргән жирләрдән кышкылыкка кизәк жыеп алып кайтты. Мал ашаганнан калган салам да тирес белән түгелмәде—анысы да ягарга китте.

Соңгы елларда урманга, авыл кешеләренә караш үзгәрә төште. Сала халкы, әлбәттә, моннан файдаланып калырга ашыкты: хәллерәкләр, берсеннән берсе уздырып, йорт житкерде, каралты-курасын янартты, берничә елга житәрлек утын хәзерләмәгән хужалыклар да, калса—бармак белән генә санарлык калгандыр.

Мөниржанның хәзергә утыны бар иде. Кирәксә, жәйгә чыккач, тагын карар. Тик Гариф карт сүзендә дә хаклык бар—газ керттерергә кирәк. Газ уңайлы булмаса, карт-корысына кадәр чат ябышып ятмас иде шуна.

Әйе, газ кертергә кирәк. Тик кайдан башларга? Анын бит гомерендә дә мондый эш белән шөгыльләнгәне юк. Уйлап-уйлап та очына чыга алмагач, кулын селтәде: әйдә, жан биргәнгә, юнен бирер әле Ходай Тәгалә... Туган йортына кайту шатлыгы зур, юк-барны уйлап, куанычына күләгә төшерәсе килмәде.

Чынаяктагы чәен эчеп бетергәч, күршесе амин тотты да чыгып китте.

Мичкә яккан утын янып бетеп килә. Күмерләр тирән итеп сулыш алган кешене хәтерләтә: яктырып-балкып алалар да сүрәнләнеп калалар. Бөтенләй суынганчы томаларга кирәк булыр. Ләкин ашыгу да ярамый. Мичснә озак ягылмый торды, шаярырга кирәкми. Мичен иртә томалап, тәгәрәп үлүчеләр аз түгел. Ә Мөниржанның, каһәрле булса да, якты дөнья белән тиз генә хушлашасы килми. Бәлки калган гомерен кешечә уздырырга язгандыр...

Ул инде ятарга да жыенган иде, күнеленен нидер юксынуын сизде. Ни булыр икән? Тукта, ул бит кайткач гармунын кулына алмады. Турылыклы дусты, сердәше, үпкәләп, Мөниржан бармакларының телләреннән тизрәк йөгереп үтүен көтә торгандыр.

Тальянын киштәдән төшереп, төреп бәйләгән ашъяулыгын сүтте. И бу мизгелнең ләззәтлелеге! Гармунын кулына алып, сак кына тартып карады. Ул гыжылдап ыңгырашкан тавыш чыгарды. Озаграк уйнамый торсаң, шулай итә инде ул гармун. Бу бит Фазылның әтисе Фазлыйәхмәт мулла биргән гармун. Әллә үпкәләде инде! Күрекләре тузгач, күрше авылның сукыр остасыннан янарттырып алган иде. Бүтән төзәттергәне юк. Кырык елдан артык Мөниржанның шатлыгын да, кайгысын да, серләрен дә бүлешә. Тарткалый торгач, гармунның тавышы ачыла төште. Мөниржан тирән итеп сулу алды да жырлап жибәрде:

Эзләдем зәңгәр күкләрдән
Иң якты йолдызымны.
Нигә син мине көтмәден,
Гайниябану, сылуым, иркәм,
Калдырдың ялгызымны.

Бу сүзләрнең кайдан килгәнен белми ул. «Галиябану» жырында дисәң, анда юк. Ихтимал, колагына фәрештәләр пышылдагандыр. Дөньялыкта

кайбер дуслары ташласа да, Мөнирҗанның тугры калган фәрештәләре бардыр әле, барысы да качып бетмәгәндер. Яхшымы, яманмы, ул да адәм баласы бит. Хак Тәгалә аны да онытып бетермидер.

Сагынып караган кеше сагыну хисенең никадәр көчле икәнен белә. Тик сагынуны чакрымнар, килограммнар белән дә, вольтлар-ваттлар белән дә үлчәп булмый. Сагына һәм вәссәлам! Бетте-китте.

Ирекка чыгып, үз өенә кайтып кергән кичәге мәхбүс уйнады да уйнады. Борыны буйлап ике яктан тәгәрәгән күз яшьләренең битен өтеп-өтеп алуын да сизмичә уйнады. Ул бәхетле иде.

Көннәр бер-бер артлы уза торды. Аяз көннәрдә кояш Кызыл тау артыннан калкына да, Гатият тавы өстеннән тәгәрәп төшеп, Әскәй авылы өстенә бетмәс-төкәнмәс якты, җылы, миһербанлы нурларын сибеп әйләнә торгач, Чатыр тавы тарафына җитә. Аннан соң, гүя аны икмәк кебек телемләп кисәләр, кими барып, бөтенләй юкка чыга. Һәм җиргә башта эңгер-меңгер, соңрак яучы карчык адымнары белән әкрен генә караңгылык иңеп, дөньяга төн патшасы хуҗа булып кала..

Апрель урталары җитеп килә. Кайтуына айдан артык кына вакыт узса да авыл тормышына Мөнирҗан янә ияләнеп бетте. Әйтерсең, беркая да озаклап китеп тормаган.

Элеккеге шешәдәш дуслары коры законга карап тормыйлар, кайтуын юарга дип шешәсез дә, шешә күтәреп тә баштарак еш сугылалар иде, торабара суындылар. Ни өчендер эчкән кешенең эчмәгәнне дус-иптәш итәсе бик килми шул. Мөнирҗан үзенең ныклыгына хәйран калды: никадәр кыстасалар да эчмәде. Һәм эчмәс тә!

Тик аның үз теләге белән эчүдән туктаганына элеккеге ахириләренең берсенең дә ышанасы килмәде.

—Чирле икән, шуңа эчми,—дип нәтиҗә ясады Зиннәт.

—К...нә капсула куйдырткандыр,—Әхнәф шулай уйлады.

—Сихерләгәннәр, бозганнар абзыйны.—Бусы арада яшь, ләкин бик «өметле» сәрхүш Фәезнең фаразлавы иде.

Мөнирҗан кебек «сыналган, әйбәт сугышчан дус»ның үз сафларыннан төшеп калуына баштарак нык офтандылар алар. Офтанырлык та иде шул. Чөнки төрмәдә эшләп алган акчалары өстенә, сугыш инвалиды буларак, пенсиясе дә Аллага шөкер генә. Болай да юмарт күңелле Мөнирҗан, бераз кәгеп тә алса, бөтенләй ыштансызлана. Әшнәләренә шул гына кирәк тә. Сыйланалар-сыйланалар да, хуҗаның үз-үзен белештерми женләнә башлаганын сизүгә, шыпан-шыпан таешу ягын карыйлар. Хатыны юк, балачагасы юк, Мөнирҗан өйдә япа-ялгызы кала. Шунда ук ятып йокласа, адәм әүлиясе буласы да бит, юк, женнәр котыртамы, болай үзе котырамы—урамга чыга. Исенә элеккеге үпкә-рәнҗешләр төшә. Әгәр дә шул чакта ачуы килгән кеше очраса яки җайлы-җайсыз берәрсе сүз әйтсә, бетте, ни эшләгәнен белми. Ничә срокны ул шулай үзе «эзләп» алды. Авыл халкы кай арададыр аңа «Котырган» кушаматы да тагып өлгерде.

Кичтәнге табындашларның берәрсе, гадәттә, иртән баш төзәтергә керә. Акча барында Мөнирҗан жәлләми—кибет ерак түгел, керсәң, Бөгелмә "малайлары", мине ал да мине ал, дип күзеңә чекрәеп карап тора.

Бар чагында бүредәй, юк чагында шүредәй, ди халык. Мөнирҗанның кесәсендә берзаман җилләр исә башлый. Акча юк, ә эчәргә, баш төзәтергә кирәк. Авырткан башларны бергәләп эшләтә торгач, барыбер җаен тапмый калмыйлар: йә дуңгыз караучы Зиннәт берәр капчык фуражны аракыга алмаштыра, йә Әхнәф белән Фәез хатыннарының хушбуй, ислемай кебек нәрсәләренә «каз мае» сөртә.

Этләшә-этләшә эчә торгач, авылда тагын акча бирер көн җитә. Үз туган

көннәрен онытсалар онытхалар, шешәдәш дуслары, ә Мөнирҗанның туган көнен, төнлә уятып сорасаң да, исләрендә тоталар.

Элеккеге кайтуларында Габделихсан абзыйның «ресторан»га әверелеп, кайнап торган йорты бу юлы үз гадәтенә хыянәт итте.

Мөнирҗан Фазылга рәхмәт укып туя алмый. Беркөнне үтеп барышлый хәл белешергә сугылган иде, электр плитәсендә чәй кайнатканын күрде дә, Мөнирҗанны аптырашта калдырып, әйтте:

—Юк, бармый бу болай.

—Нәрсә бармый?

—Болай яшәп булмый. Газ кертергә кирәк.

Мөнирҗан аптырап калды:

—Кирәген кирәк тә бит. Үземнең дә шундыйрак ният бар иде. Тик кайдан башларга гына белмим.

Авылдашлары газ белән ашарга пешереп кенә калмыйча, өйләрен җылытуга да күчкәннәр. Рәхәтнең дә рәхәте, мактап туя алмыйлар. Бигрәк тә аның кебек чулак кешегә әйбәт булыр иде.

—Торба табарга кирәк,—диде Фазыл.

—Кайдан?

—Вәт сиңа, драстый! Кайдан тапсаң, шуннан! Без бит, Мөнир дус, нефть, кара алтын оясында яшибез. Ни кирәксә, халык шунда чаба.

—Акчам бар барын, ләкин мин беркемне дә белмим.

—Сиңа бит бик күп тә кирәк түгел, йортың кечкенә. Нечкәләрен моннан табарбыз, анысы бераз миндә дә бар. Җитмәгәненә җай чыгар, ә менә юанрак торбаларны Габделхәйдән сорарсың.

—Нинди Габделхәйдән?

—Үзебезнең авыл Мөкаррәматтәйне беләсең бит?

—Белмичә соң! Шуннан...

—Габделхәй шуның малае, нефть чыгару идарәсендә мастер булып эшли. Безнең авыл тирәләрендәге скважиналарга ул хуҗа. Газ керткәндә, ярты авыл торбаны аның аша юнәтте.

Мөнирҗан уйга калды:

—Анасын белү беләнмени! Ул Габделхәйне кайдан таба алам соң мин? Өйрәт!

—Ярар, җаен бер туры китереп, очраштырырмын. Чыннан да аның койрыгын тоту сиңа җиңел булмас. Ә без очрашкалап торабыз. Эш буенча.

Бу сөйләшүдән соң бер атна вакыт уздымы икән, Мөнирҗан мичкә ягып җибәргәнне генә көткән кебек, алар турына "КАВЗ" автобусы килеп туктады. Аннан ике кеше төште. Мөнирҗан аларның берсен—Фазылны гына таныды. Үзара сөйләшә-сөйләшә, бу икәү Мөнирҗанның иртән себереп куйган сукмагыннан капкага табан атладылар.

Мөнирҗан кунакларны каршы алырга чыкты. Кул биреп күрешкәндә, Фазыл янәшәсендәге ир белән таныштырды:

—Менә, Габделхәй энем, Мөнирҗан абыең шушы булыр.

Габделхәй елмайды:

—Син бигрәк инде, Фазыл абый, авылдашларны танымаска! Мин аның сабан туенда көрәшкәнен, Шакир абыйны сынар кулында күтәреп йөргәнен дә хәтерлим әле. Йә, булдымы, Мөнирҗан абый, шундый хәл? Әллә мин ялгышаммы?

—Булгандыр инде, энем, булгандыр. Яшь чакта дурак идек, картайгач та акыл кермәде, ә булганы утырмага китте.

—Мин өлкәннәрне таныйм, яшьләрне генә бик үк белеп бетереп булмый. Исән-сау гына кайттыңмы?

Сирәк очраша торган авылдашлар, әлбәттә, әүвәл хәл-әхвәл, тегесен-

монысын сораша. Мөнирҗан да Мөкәррәмәттәйнең хәлен белеште.

—Аллага шөкер, хәзергә үз аягында йөри. Безнең белән яши.

—Азнакайдамы?

—Шунда инде, шунда. Инәй баштарак бик ямансулаган иде, хәзер иялнә төште. Алай да җәен бер-ике айга авылга кайта, шунсыз түзә алмый. Үзем дә сагынам шул авылны. Югыйсә гел кайтып-киткәләп торам. Барыбер сагындыра.

Сүзгә Фазыл кушылды:

—Энекәш,—ул Габделхәйнең җиңеннән тартып, үзенә каратты,—сиңа зур рәхмәт, газ керткәндә, авылдашларыңа ярдәм итеп, күп игелекләр эшләдең. Хәзер Әскәйдә газ кермәгән ике генә йорт калды.

—Кемнәрнеке?

—Берсе Мөнирҗан абзыеңныкы, икенчесе Ибрай Зәкиясенеке. Зәкия карчыкка күптән кертә идек, үзе теләми. Шулай булгач, бер Мөнирҗан калып бара. Синең ярдәм кирәк.

Габделхәйдән торбаны ничегрәк сорарга белми торган Мөнирҗан Фазылга күңеленнән рәхмәт укыды һәм, ни әйтер икән дип, Габделхәйгә текәлде.

Нефтьче оста өйгә тагын бер мәртәбә күз йөртеп чыкты, үзе авыз эченнән генә нидер быдырдады. Чамасын тартты, ахрысы. Аннан соң әйтте:

—Өй зур түгел, монда өч-дүрт торба җитә. Аннан гына хөкүмәт бөлмәс, әлбәттә.

—Кайдан алырга икәнен генә әйт, машина җибәрербез.

—Кирәкми. Өч-дүрт торба өчен машина куарга... График буенча озакламый Карамалы белән ике арадагы скважинага җир асты ремонты керә. Малайларга әйтермен, тотылган торбаны юл уңаенда калдырып китәрләр.

—Ай, рәхмәт сиңа!—Куанычыннан Мөнирҗан елмаюын тыя алмады. Ул ничек итеп кесәсенә тыгылганын һәм акча сөйрәп чыгарганын сизми дә калды.

—Күпме түләргә?

Баштарак аптырап калган Габделхәй, хәлне аңлап, көлеп җибәрде:

—И Мөнирҗан абый, биргән торбалар өчен акча алсам—миллионер, куйган аракыларын эчсәм—күптән бер сәрхүш булган булыр идем. Коръән Кәримдә әйткән, бер-беренә ярдәм итеп яшәргә кирәк, дигән. Идарә кассасына түләтергә булыр иде дә, сиңа торба бирүләренә шикләнәм. Бездә бит шулай: законлы юл белән ала башласаң, мең киртә. Шуңа күрә халык бүтән юлны сайлый. Курыкма, һәр җирдә дә кем ничек таба, шулай җайлый торбаны. Кагыйдә-законнарга карап торса, Әскәй дә, районның бүтән авыллары да газсыз утырыр иде. Әйтәм ич, кайгырма, без моны промышленностьның авылга шефлык ярдәме итеп исәплибез. Торбасы булды ди, сварщикларың бармы?

Мөнирҗан җавап эзләп Фазылга текәлде.

—И-и, энекәш, язгы кыр эшләренә хәзерләнәбез бит. Сварщикларның берсе бүлнистә ята, икенчесе мастерскойдан китә алмый.

—Шуңа гына соравым иде: минем таныш бик әйбәт сварщигым бар. Ул ял көннәрендә генә эшли ала. Хакын үзегез сөйләшерсез.

—Бик яхшы булыр иде дә...

—Фазыл абый, тагын ниләр кирәген бергәләп уйлашырсыз әле.

—Ярар, анысыннан эш тормас.

—Газ плитәсе, АГВ да булса, куеп, берьюлы эшен бетерерләр иде...

Икенче көнне үк Мөнирҗан күршесе Мөдәррис машинасына утырып барып, кибеттән кирәк нәрсәләрне алып та кайтты.

Рәхмәт яугыры, Габделхәй сүзендә торды. Сөйләшкәннән соң ничә генә

көн узгандыр, алар турына гаять озын машина туктап, Мөниржаннарга торбалар калдырып киттеләр.

Ул әйткән сварщик та эшне озак тотмады—шимбә белән якшәмбедә килеп эшләгән иде, Мөниржанның АГВ торбасын мичкә ялгыйсы гына калды. Бу эшне ул үзе дә башкарып чыкты. Шулай итеп Фазылның җинел аягыннан атна-ун көн эчендә өе газлы булды да куйды.

Кояш көннән-көн елмаебрак карый. Шулай да кышның бирешәсе килми әле. Баштарак көндезләрен шаулап гөрләвекләр акса да, төнлә белән суык ун-унбиш градусларга кадәр җиткән чаклар булды. Ләкин яз язлыгын итте, ташулар ташып, кояш турырак караган тау кырлаларында ямь-яшел үләннәр борын төртте, яр буйларында алтын тәнкәләрне хәтерләткән сары чәчәкләр күренә башлады. Ниһаять, кошларның яз житүенә һәм үз якларына кайту шатлыгыннан чырык-чырык килүенә, берсен берсе уздырырга тырышып сайравына куанган агачлар кышкы йокыларыннан уянды, бөреләре тулышты. Язның дәртле адымнарын хәзер берни дә, хәтта кабат кыш ясарга омтылып караган карга һәм сыерчык бураннары да туктата алмый иде.

Мона кадәр өенә газ кертү белән мәшгуль булган Мөниржан кинәт кенә эшсез-шөгыльсез калды. Элекке кайтуларында салдымнан бушамагач, тик торганнан эч пошу дигән нәрсәне ул белмәде. Бик ансат түгел икән ул айнык баштан көне буена юкны бушка аудару.

Торып-торып, ниһаять ул бер карарга килде: пенсия бар дип тик ятмаска, хәле житәрдәй эшкә урнашырга кирәк. Моның өчен кемгә мөрәҗәгать итәргә? Сон, әлбәттә, тагын шул Фазылга! Бүтән кемгә булсын. Әскәйдә һәр кешенең гозере управляющийга, ягъни Фазылга барып төртелә. Авылда яшәсә дә, совхоз директоры ераграк, ул күбрәк район белән, түрәләр белән эш йөртә.

Фазылны күреп сөйләшер өчен анын өенә барып торасы юк. Ул бөтерчек кебек, җил-җил атлап, Мөниржаннар турыннан көнгә әллә ничә урый. Һәм бу урамнан гына түгел, көн саен ул булмаган урын авылда кала микән? Юктыр, юктыр. Ничек арымый, ничек аяклары чыдый шулкадәр йөгерүгә. Югыйсә яше дә гел юк түгел бит инде. Дөресрәге, нәкъ Мөниржан яшендә бит Фазыл да.

Алар икенче көнне үк очрашты. Күнеле сизгән кебек, иртәнге тугызларда урамга чыгып баскан гына иде, аскы урамнан ашыга-ашыга килүче Фазылны күреп, авызы ерылганын сизми дә калды. Мөниржанны күрүгә, Фазыл да адымнарын тизләтте.

Дуслар кул биреп күреште.

—Сәлам!

—Драстуй!

—Бик ашыгасынмы?

—Әйе шул. Иртәгә тракторларны тырмага чыгарырга иде исәп. Әллә берәр йомышын бармы?

Болай ук кистереп сорауны көтмәгән Мөниржан югалып калды һәм үзен шелтәләп куйды: кеше ут капкандай ашыгып йөргәндә, юк-бар йомышын белән башын катырмасаң. Авыл халкы моны ат дагалаганда бака ботын кыстыру, ди.

—Ярар инде. Бүтән вакытта әйтермен. Иркенрәк чагың булыр әле.

—Ай-һай, тырмага бер төшеп китсәк, тиз генә булыр микән ул иркен вакыт...Кыенсынма, әйт.

—Тик яту туйдырды. Берәр эш таба алмассынмы?

Фазылның борчулы йөзенә кояш чыкты:

—Эш дисенме? Күптән әйтәләр аны! Эш дисән, мин анын сиңа төшенә дә кереп карамаган шәбен табам.

Фазылның шатлануын күреп, Мөниржан сагая төште:

—Нинди эш инде ул?

—Әйтәм ич, бер дигән. Саф һава. Күктә тургай сайрый. Аяк астында гына йомраннар сызгыра. Сиңа карап суырлар дога кыла. Чикерткәләр җилкәнә кунып хәлеңне белешә. Оҗмах инде, оҗмах. Хур кызлары гына юк.

—Сузма инде, әйт!

—Көндез чыра яндырып эзләсәң дә, бүтән андый эшне таба алмассың.

—Мин белә торган эшме соң ул?

—Әйе инде. Югары оч көтүенә кеше кирәк.

—Көтүче булыргамы?—Юк, Мөнирҗан дустыннан мондый тәкъдимне көтмәгән иде.

—Көтүче шул. Ник, нәрсәсе начар? Ат бирәбез. Иптәшкә бирәр эт тә тапсаң. Менә мин дә көтүче бит. Әйе, бригадир, управляющий шул ук көтүче, тик эт көтүчесе. Ике дә уйламыйча, үзем китәр идем, валлаһи! Туйдым! Җибәрмиләр. Карале, көтүче булсаң, бөтен яктан да отасың бит, әй! Ашау мәсьәләң дә җиңелрәк хәл ителер, хезмәт хакың да ким-хур түгел. Уйла әле.

Мөнирҗан чыннан да уйга калды. Бер яктан караганда, Фазыл дөрес әйтә: табигать кочагы, саф һава, иң мөһиме—ялгыз. Эчәргә кыстап, авыл сәрхүшләре җаныңны җәфалап бетермәячәк. Тик... тик, булдыра алыр микән? Бер дә көтү көтеп караган кеше түгел бит ул. Икенче яктан караганда, көтүчелекккә кемнең махсус укыганы бар? Аннан соң аяклары чыдар микән, хәзер бит аңа унсигез яшь түгел.

Фазыл да аның икеләнүен сизеп алды:

—Куркасыңмы? Курыкма. Өйрәнгәч, бер нәрсәсе дә юк аның. Баштагы көннәрдә генә кыенрак булыр.

- Бер дә эшләп караган эшем түгел шул.

—Әйтәм ич, курыкма, дип. Чыбыркыңны хәзерли тор. Гафу, киттем. Лимит бетте. Уйла!

Фазыл белән саубуллашканнан соң, Мөнирҗанның күңеленнән тынычлыгы качты. Тәкъдим ителгән эш аны куркыта да, ымсындыра да иде.

Ишек алдына кергәч, баскычка утырып, ул бераз уйга калып торды. Ихатасында кайда нәрсә барын исенә төшерергә тырышты. Иярнең аларда гомергә булганы юк. Димәк ки эзләп интегергә дә кирәкми. Менә чыбыркыны эзләп карарга ярый. Элегрәк алар бар иде, хәтта берничә. Искереп, чыгарып ташламаган булсалар. Вакыт җан иясен картайта, әйберләрне туздыра—берәүне дә аямый.

Кайдан эзләргә икән ул чыбыркы дигәннәрен?

Тора-бара мәрхүм әтисенең чыбыркыларны келәткә кертеп куйганы исенә төште дә җәһәт адымнар белән шунда юнәлде. Кергән уңайга келәтнең ишеген киереп ачып, ябылмасын өчен аяк астында яткан ярты потлы гер белән терәтеп куйды. Ашыгуы белән кергән чакта башын бәргәнен дә сизми калды. Ярый әле бүреге бар иде. Аңламый, ник шулай кабалана торгандыр. Кызлар янына барырга җыенамыни. Көтү бит әле берничә көннән генә чыгачак.

Келәт... Тәрәзәләре юклыктан мәңге караңгы, караңгы булгач, мәңге серле-тылсымлы, шул ук вакытта бераз шомлы да бура. Аннан һәрвакыт ашлык, себерке һәм... тычкан исе килеп тора. Әтисе бу келәтнең сөяннән буралган һәм, алар өйләнешкән чакта, бирнәгә бирелгән булуы хакында сөйләгән иде. Әлеге нигезенә күчереп салган чакта ук ул бөтенләй яңа булмаган. Менә бит, урыны корыга күрәдер, үзенә, әйтерсең, вакыт җиле бөтенләй кагылмаган диярлек—хәзер дә шартлап тора, черегәнниткән җирләре күренми. Бары тик бүрәнәләрендә генә кортлар юллаган эзләр, вакыт узган саен, арта бара һәм болай да борынгы бураны тагын да кадимирәк итеп күрсәтә. Ул эзләр, ни сәбәпледер, әллә кайчан, бала

вакытларда ук, китапларда күрергә туры килгән кешенең баш мие сурәтен Мөниржанның күз алдына китереп бастырды.

Ишектән төшкән кояш яктысында Мөниржан идәндә уйнап йөргән тычкан баласына игътибар итте. Тик тычкан баласы адәми зат белән сак булырга кирәклеген исенә төшерде, ахыры, ана озак юанырга ирек бирмәде, ярыктан кереп шылды. Син күр дә мин күр! Ни өчен кергән иде соң әле ул монда? Ә-ә, чыбыркы карыйсы кеше иде бит ул. Мөниржан бер-ике адым алгарак атлаган иде, битенә үрмәкүч пәрәвезе сарылды. Күрәсең, үрмәкүчләр «әйдә, ярар» дип кенә үрмәгән, булсынга тырышкан, ничә еллаган бу ятьмәләр шундый куе, шундый тыгыз һәм ябышкак иде ки, Мөниржан анардан арына алмый интекте. Ирен тирәләренә сыланганы, жирәндереп, күнелен болгатты. Иртән кырынырга өлгермәгән иде, сакалмыек төртеп чыккан урыннарда ниндидер хәшәрәтләр селкенә, менә-менә тешләп алырлар кук тоелды. Бу исә күнелендә туган жирәнү хисен тагын да көчәйтә төште.

Эзләнүе юкка булмады—келәт канатыннан сустән үрелгән бер зур, бер кечкенә чыбыркы табып алды. Мона ул сабыйларча куанды, йөгереп чыгып, хәзер үк шартлатып карыйсы килде. Онытмагандыр әле ничек шартлатырга икәнен. Бала чакта алар малалайлар белән ярыша-ярыша чыбыркы шартлата иде бит.

Чыбыркы шартлата белү көтүче өчен гаять мөһим. Әйбәт шартлатсаң, малларың тынлар, шартлата белмәсәң, аякларына күбрәк чабарга туры килер.

Ул иртәрәк куанган булып чыкты. Киндер сүсеннән үрелгән чыбыркыларның икесе дә, беренче селтәнгән чакта ук өзелеп, коймага сыланды. Чөнки, озаграк кулланылмый торгач, аларны көя теткәләп бетергән иде. Әле ярый сынап карады, боларга ышанып чыгып, көлкегә калмады. Азгын сыерларны, авызы ашлыкка бер тисә, сумаладай ябышып кала торган сарыкларны көтүдә чыбыркысыз тыям димә. Малларың икмәккә керсә, эш харап, күрмәгәненне күрсәтерләр. Сталин заманнары узса да... Чыбыркы—кешелекнең үсеш тарихында зур бер алга китеш ул, уйлап карасаң. Чыбыркы кем кулында, ул аны ничегрәк тота—тормыш шулай бара. Көтүдә дә шулай, жәмгыятьтә дә.

Сораштыра торгач, чыбыркыны тапты ул—яшьтие Сибгат бирде. Бишенче класска хәтле жиде ел гыйлем кимереп тә, «а» белән «б»дан ары китә алмаганын күреп, ата-анасы Сибгаттән «пырафисыр» чыкмасына тәмам ышангач, «мәптек» белән араны тәмам өзеп, улларының кулына чыбыркы тоттырдылар. Язмыш тарафыннан бүләк ителгән чыбыркының гомере озын булды: олыгайгач кына аның кулыннан төште. Ана сугышның койрыгы гына эләгеп калды. Кайтуга тагын кышларын ул фермада мал карады, жәйләрен хужалык көтүен көтте—күзенә ак-кара күренмичә, койрык чәнчеп чабарга гына торган сыерларның, томана сарыкларның, башкисәр кәжәләрнең «генералиссимус»ы булды.

Кырык жиденче елда Сибгатне колхоз сыерларына «кадаклап» куйдылар. Эшкә дигәндә кечкенәдән үк үжәт иде, аның кулына күчкәч, колхоз сөтбикәләре сизелерлек юмартланды. Сыерның сөте телендә шул. Сибгат турында мактап район, өлкә газитләренә дә яздылар, бер мәртәбә хәтта Мәскәүгә ВДНХга (Бөтенсоюз халык хужалыгы казанышлары күргәзмәсе) да жибәрделәр.

Авылда туып-үскән кеше буларак, Мөниржан көтү көтүнен, Фазыл әйткәнчә, саф һавада тургай жырын тынлап йөрү генә түгел икәнлеген белә. Көн саен ничә чакрым юл узганын, белсә дә, көтүче үзе генә белә торгандыр. Сибгатнең дә, кырыкларны узуга, аяклары сызлый башлады, шуннан соң колхоз идарәсе аны кыр сакчысы, ягъни, Әскәй кешеләре теле белән әйткәндә,

пеләвәй итеп кучерде. Үз вазифасына намус белән карарга өйрәнгән Сибгат колхоз ашлыгын нык саклады, бер генә малдан да таптатмады. Ашлыкка керү җаен гына эзләгән бозауларны ул әллә кая кадәр бастыра, ярты көнгә булса да басуга юлны оныттыра иде., Эстәрледә йөзеп-чумып уйнарга төшәр алдыннан борчак, бодай ишедән авыз итәргә яраткан каз-үрдәк исә алгы аягының берсе аксак Мәрүсәгә атланган пеләвәйнең еракта шәүләсе күренүгә үк, котлары алынып, оча алмаганлыктан ава-түнә титаклап, каңгылдый-каңгылдый, кырдан таю ягын карады. Борчак, көнбагыш басуына менгән малайлар шулай ук аның очлы күзеннән качып кала алмады.

Кешенең шөгыле, аның гореф-гадәтенә, үз-үзен тотышына йогынты ясамый калмый. Сибгат тә, гомере буена мал-туар белән эшләгәнгә күрәдер, атка атлануга, алдында бер генә җан иясе булмауга да карамастан, «һайт!» дип кычкыра да «фьюит!» дип сызгырып куя. Галимнәр моны шартлы рефлекс барлыкка килү дип атый бугай.

Сибгат колхоз җитәкчеләренә дә, халыкка да ярады. Чөнки чыбыркысын яшендәй уйнаткан һәм Түбән очта шартлатканы Югары очта да ишетелә торган пеләвәй кош-кортка да, мал-туарга да сукмады, аларны тотып ябып, хуҗаларын кан елатмады. Ә бит Әскәй халкы пеләвәйләрнең төрлесен күрде. Кайберләре чирәмдә йөргән бозауларны да алып кайтып япты, бер ишесе малны гына түгел, кешеләрне дә кан чыкканчы ярды. Бигрәк тә колхозга Дәҗҗал кушаматлы Мидхәт Хәсьянов хуҗа вакытта пеләвәйләр ерткычлыклары белән кешеләрнең дә котын алып бетерде. Хәсьянов үзе дә чыбыркысын еш уйнатты. Әнсарны бит шул Дәҗҗал кыйнаганнан соң тотлыга торган булып калды, дип сөйлиләр. Көчлегә суд юк, замана көчлеләр кулында.

Моннан шактый еллар элек, сугыштан кайткач, Фазыл белән бергә ат караганнары Мөнирҗанның исенә төште. Онытылырлык кына булмады шул: атлар дия-дия, үзен утыртып куйганнарын сизми дә калды бит. Фазыл, качып китеп, дөрес эшләде. Хәзер әнә авылның иң абруйлы кешеләреннән берсе. Электән төрмә боткасын авыз иткәне булганга, тәмен белгәнгә күрә, бүтән татып карыйсы килмәде аның. Ә Мөнирҗан, юләр, беркатлы исәр, тыңламады Фазылның инәлеп әйтүен. Хәер, хәзер искә төшерүдән ни файда... Ходай Тәгалә насыйп иткән гомере күпме калгандыр, әнә шул калганын булса да адәм рәтле итеп, кешечә уздырырга кирәк.

Ат карауچының ярты гомере арба белән абзарда узса, калганы ат өстендә үтә. Ул чорда, селексән, бете дә коелмаган колхозда кайдан килеп чын ияр булсын—Мөнирҗан белән Фазылга капчыкның, як-ягына салам, уртасына куфайка куеп, иярне үзләренә ясарга туры килде. Элек яраганны ник хәзер ярамас икән. Күргәзмәгә куясы түгел ич.

Ике көннән ниятләгән ияре әзер булды.

Кояш көннән-көн ныграк кыздыра. Кешеләрнең язны сагынып-саргаеп көтүләрен аңлыймы, әллә үз графигы шундыймы, белмәссең.

Малларның инде күптән көтүгә чыгасы килгәндер. Әнә бит күршеләренең ишек алдында күшәп басып торган сыерлары сыртына кунган чәүкә, тырышыпмы-тырышып, ябага йолка. Сыерга, ихтимал, бик рәхәттер, күзен ачкан да эрегән кебек тик басып торуын белә.

Сарыклар янәшәсендә яшь бәрәннәр кайнаша. Алар йөгереп-уйнап йөриләр дә, мөгез чыгарга өлгермәгән маңгайлары белән әниләре корсагына төртә-төртә, имәргә керешәләр. Бу бәрәннәр әле көтүгә йөрүнең, сусыл үлән ашауның тәмен белми. Алар өчен бу ләззәт башланмаган.

Аръякларның маллары инде күптән тау кырлаларында, яр буйларында яшь үлән чемченә. Бигрәк тә Чәүкә урамында яшәүчеләргә рәхәт: капканны ачып чыгуга, таулар каршы ала. Сыер, сарыкларың әллә кая китәр дип тә куркасы юк—барысы да күз алдында.

Ниһаять, кешеләрнен дә, малларның да зарыгып көткән көне килеп житте. Мөниржанга иртәгә көтү чыгасын хәбәр иттеләр.

Көтсә дә, бу хәбәр анын тынычлыгын алды. Көннен калганын ничек уздырырга белми интекте. Ничә кат инде чыбыркысын, ияren тикшерде, киеп чыгасы галошларынын эченә салган кәгазьләрен ошатмыйча, кат-кат алмаштырды. Йокларга яткач та тиз генә йокы килмәде. Дулкынлана иде ул, әйтерсен, керләнеп тирескә катып беткән сыер-сарыкларны көтәргә түгел, кызлар янына яки тантаналы жыелышка барачак.

Миргали абзыйлар әтәче кычкырганда, ул инде аяк өстендә иде. Ашап-эчеп алгач, аты артыннан китте. Сугыштан соңгы елларда Фазыл белән ул эшләгән чакта атлар сыеша алмаган аранда хәзер унбиш-егермеләп ат тора. «Ат белән ир-атка кадер бетте,—диләр иде,—хак икән»,—дип уйлап куйды ул.

Ана Вәскәй исемле кысыр бия бирделәр. Узган ел бу очта көтүне кайдандыр килгән Василий-Васька исемле урыс көткән диләр. Кызык инде бу тормыш: элеккеге Туры биягә Вәскәй кушаматы ябышкан да калган. Вәскәй, ягъни, тутырып әйткәндә, Василий исемле бия була инде ул. Менә сиңа ишетмәсән ишет, колагын булса тишек. Көлеп үләрсен, валлаһи!

Әле ул атын алып кайтып, ихатасына керткәннән сон да шактый вакыт узды. Ниһаять, берәм-берәм капкалар ачыла башлады. Колаччынын күтәреп бүрек кигән агайлар, яулыкларын чөеп бәйләгән апалар, ыспай киенгән киленнәр капка төпләренә чыгып, бер-берсенә сәлам бирешә башлады. Мөниржан сәгать сукканын сизде һәм, атына атланып, урамга чыкты. Чыккан унайга чыбыркысын шартлатты. Сугышта һөжүмгә ташланырга бирелгән сигналдан ким булмады бу. Чыгарганны көтеп зарыккан маллар капкадан урамга атылды. Китте мөгрәү, китте мәәлдәшү...Маллар бер-берсе янына барып иснәшә-танышa. Кешеләр сыман, алар да озак күрешми торганнан сон, шул рәвешле хәл-әхвәл белешә торганнардыр.

Бисмилла әйтеп, Мөниржан малларны кузгатты. Урамнын бер очында өч-дүрт сыер, унбишләп сарыктан башланган көтү, капка саен ишәя барып, икенче очка житкәндә зур бер чирүне хәтерләтә иде.

Көтүнен баштагы көннәре авыррак. Салкын кыш буена тар абзарларда кысылып яткан маллар иректән тәмен белә. Ирекне тою аларны исертә, башын әйләндерә, шуна күрә алар арасында тәртипнен «т» дигәне дә калмый, койрык чәнчеп кайсы кая чабарга гына тора. Анархия! Махно атакай гына житми. Көтүченен хәленә кереп, ярый әле баштагы көннәрдә һәр йорттан диярлек кемдер ярдәмгә чыга. Күбесе малларын басуга озатып куя да кайтканда каршы ала, вакыты иркенрәкләр исә кырга ук чыгып, көтү белән бергә йөреп кайта. Көне дә матур булса, бергә-бергә анын ничек узганын сизми дә каласын.

Түземсезлек белән көтеп алган көтүнен беренче, икенче көне дә үтте. Атна-ун көн узуга, көтү Мөниржанга, Мөниржан көтүгә ияләшеп бетте. Вәскәй белән дә уртак телне тиз тапты. Ат гажәп акыллы булып чыкты. Узган елгы хуҗасы аны көтү көтәргә тәмам өйрәткән булган. Бәлки элегрәк тә белгәндер. Баштагы көннәрдә Мөниржан Вәскәйне, маллар тәмләп ашарга керешкәч, тышаулап жибәрә иде, соныннан, анын качарга нияте юклыгын анлагач, болай гына бушата торган булып китте. Атына ул күбрәк барганда-кайтканда һәм туплауга төшкәндә генә атлана, бүтән вакытта Вәскәй иректә йөри. Анын каравы, Мөниржан сызгырган тавышны ишетүгә, чаптырып килеп житә. Киноларда күрсәтелә торган индеецлар атыннан бер дә ким түгел.

Муйнакнын булуы шулай ук хезмәтен нык жиңеләйтә.

Әскәйдә көтүчегә кадер-хөрмәт гомер-гомергә зур. Көн саен ул чират буенча иртә-кич берәрсендә туктала. Бу гадәт кайчан кергәндер, әйтүе кыен. Әмма аерым хуҗалык вакытында ук халык көтүченен кадерен белгән.

Иртә-кич ашатучылар көндезлеге белән дә тәэмин итә. Көтүчене сыйлауда хуҗалар бер-берсен уздырырга тырыша: кемнең халык арасында ким-хур буласы килсен!

Мирсәгыйтьләрдә иртәнгелекне ашап утырганда, сүз иярә сүз чыгып, йорт хуҗасы сорады:

—Абзый, нигә син көтүгә эт ияртмисең?

Мөниржан ни дисен, дөресен әйтте:

—Бик ияртер идем дә, юк бит.

Мирсәгыйть бераз чигәсен кашып торгач:

—Бездә Казакъстаннан алып кайткан көчек бар,—диде.—Көтү көтә торган нәселдән, диделәр. Кирәксә алып тор. Әле яшь, ихатада тавык-чебеш куркытудан башканы белми. Синең янда йөреп, акыл кермәсме... Ошатмасаң, кире үземә бирерсең.

Менә шулай итеп ул Муйнаклы булды да куйды.

Муйнак чыннан да көтү көтәр өчен яратылган җан иясе булып чыкты. Беренче көннәрдә тик торган сарыкларга да өреп, аларны куркыта иде, атна да узмады, ул Мөниржанның чын ярдәмчесенә әверелде. Хәзер Мөниржан нәфселәрен тыялмый читкә каерыла башлаган малларга күрсәтеп:

—Муйнак, өс!—дип әйтергә өлгерми, эт шунда ук тегеләрне кагып килә.

Шулай итеп алар—Мөниржан, Вәскәй, Муйнак—өчесе бер гаилә кебек булып киттеләр.

Атланырга аты, ярдәмгә эте булса да, көтүче эше авыр хезмәт. Романтиканың «р» хәрефе дә юк анда. Җинел булса, акчасын да әйбәт түлиләр дип, аңа урнашу өчен чират торырлар иде. Кая ул чират тору, киресенчә, көтүче табу елдан-ел авырлаша бара. Әллә халык симерде, әллә бу һөнәрнең абруе бетеп бара. Шулай да, ничек кенә авыр булса да, көтүгә чыгу төрмәдә яту түгел. Монда син саф һавада, иң, мөһиме—үз-үзеңә хуҗа. Төрмә сакчылары, надзирательләрнең акыруыннан куркып яшәмисең. Мөниржан тәненә сихәт инүен, рухи яктан да көннән-көн сәламәтләнә баруын сизә. Ник элекке кайтуларында ук көтүгә чыкмады икән? Бәлки, төрмәгә кабат эләкмәс тә иде.

Малларның иртәнге якта бик ашыкмыйча нык кына ашап ала торган гадәте бар. Шул арада, иярен баш астына салып, Мөниржан яшел чирәмгә ята да китап йә журнал укый. Черем итүне туплауга төшкән вакытка калдыра. Тора-бара ул сарык сөте эчәргә дә хирысланып китте. Куе булганга микән, сарык сөтенең үзенчәлекле тәме бар. Закирларның язга чыккач кына бәрәнләгән сарыгы туплауда хәзер аны үзе эзләп килә. Сау, янәсе, сөт төште!

Көн артыннан көн узды. Май аен июнь, июньне июль алыштырды. Кайчандыр кап-кара җир яки ямь-яшел уҗым булган басуларда иген өлгереп килә. Аларның аксыл-яшькелт башаклары комсызланып кояш нуры эчә, башаклар тулыша һәм алтынсу-сары төскә керә, агара бара. Басуга якыная төшсәләр, сыерларның күзе яна башлый, аларга сарыклары да ияреругә генә тора. Кайвакыт малларны Муйнак кына тынлата алмый, Мөниржанның үзенә дә чабарга туры килә.

Бәла көтмәгәндә ишек шакыды.

Берсендә китап уку белән ныграк мавыгып киткән, башын күтәреп караса, өч-дүрт сыер басу кырына ук килеп җиткән. Мөниржан атына да атланып тормады, ашыгычлык белән чыбыркысын да алмыйча, шулар янына йөгерде. Килеп җитеп, кулы белән селтәнде. Ике сыер шунда ук кирегә борылды, ә Мәрданнарның кара сыеры, ачуланып, очлы мөгезләрен аңа юнәлтте, янәсе, буталып йөрмә монда.

Мәрдан сыерының мөгезләре яман, эләктерсә, эчәгеләренне айкар.

Быел, көтүгә чыккач кына да, ничә сыерны җәрәхәтләде. Мөнирҗан ике дә уйламыйча аның мөгезләрен кисеп ташлар иде дә, ярамый. Ярасамы!..

Сөнгедәй мөгез очларына эләкмәскә тырышып, Мөнирҗан артка чикте. Чиккән унайга нәрсәгәдер абынды һәм аркасы белән чирәмгә барып төште. Авыртудан акырып җибәргәнен сизми дә калды. Тиз генә сикереп тормакчы иде, кузгала алмый интекте. Авырту шулкадәр көчле иде ки, ул менә-менә аның җуяр дәрәҗәгә җитте.

Егылган көтүче, хәзер үк тормаса, шушында ятып калачагын аңлады. Шуна күрә соңгы көчен җыеп талпынды һәм үзенең кузгалуын, кузгалган чакта тәненнән нидер йолкынып-суырылып чыгуын тойды. Дүрт аякка күтәрелгәндә, егылган җиргә күзе төшкән иде, имәнеп китте: чирәмнән күренер-күренмәс кенә тырма тешләре чыгып тора иде. Кайсы хәерсезе ташлап калдыргандыр. Ярый әле яртылаш күмелергә өлгергән. Күрәсең, бер генә ел ятмагандыр. Бәхете бар икән, тырманың читенә егылган, уртасына туры килсә, калыр иде шунда кадакланып.

Кызулык белән башта сизмәгән иде, борынына кинәт кан исе килеп бәрелде, күлмәге белән сынар чалбар балагы, юешләнеп, тәненә сыланды. Кан исен тойган Мәрдан сыеры бераз сәерсенеп карап торды да, башкаларны да ияртеп, ямьсез акыра-акыра, көтүгә табан чабып китте. Андагы сыерлар да куркынды һәм, башларын борып мөгриләр тегеләр. Челләдә әлсерәгән сарыкларның гына дөньяда гаме юк: бер-берсенең корсагы астына башларын яшереп басканнар да тора бирәләр.

Мөнирҗан көтүгә табан атлады. Исәбе дөнья бетереп акырган сыерларны тынычландыру иде. Ләкин, ике-өч адым атлауга, хәле китте, әйләнә-тирәдәге һәммә нәрсә: таулар да, нефть скважиналарына сузылган электр баганалары белән еракта күренеп торган авыл да, көтүдәге сыер белән сарыклар да аның тирәсендә әйләнергә керешге. Әйләнә торгач, Әскәй белән Митрәй авыллары бергә кушылды. Җанының ничәнчедер тамыры куркыныч килгәнен хәбәр итте. Башында уйлар буталды: «Бетәм! Доктор!» Эчтән генә уйлаган сыман иде, тавышы ыңгырашу булып тышка бәреп чыкты. «Юләр, сине монда кем ишетсен дә, кем күрсен. Үлеп калсаң да, бүген генә табулары икеле...»

Көтүне туплауга төшерер вакыт та җитеп килә. Туплау ерак түгел анысы. Ләкин Мөнирҗанның бу сарык, сыер чирүен җинәрлек хәле юк. Туплауга көтү үзе дә төшәр, юлын беләләр. Бер кузгалсалар, туктатам, тыям димә. Аңа медпунктка кайтып, кан агуын туктатырга, яраларын бәйләтергә кирәк! Аннан соң кабат килер...

Кайдан кайтырга? Килгән юлдан кайтса, ничә тау менәргә, төшәргә кирәк. Хәле җитмәс. Иң яхшысы, таудан туп-туры кабат төшәргә дә инештәге сайлык аша олы юлга чыгарга...

—Вәскәй!

Исемен ишетүгә, ат башта колакларын шомрайтты, аннан соң хуҗасы янына юыртып килеп җитте. Мөнирҗан аңа шунда ук атланырга теләгән иде, егетләрчә сикереп менү түгел, өзәнгегә басып күтәрелергә дә хәле җитмәде. Җитәкләп, атын чокырдагы яр кебек урынга алып килергә мәҗбүр булды: бары тик шунда гына атлана алды. Атлануга, бердәнбер кулы белән Вәскәйнең ялына чатырдатып ябышты һәм үкчәләре белән атның корсагына төртте.

—На!

Вәскәй ике әйттермәде, ул хуҗасының хәлен аңлый иде бугай, җайдагы егылмаслык итеп йомшак кына юыртып китте.

Мөнирҗан күзләрен авырлык белән генә ача алды һәм, система астында ятуын күреп, курка калды: ә нигә куйганнар аны? Тукта, бу Әскәйме, әллә

Азнакаймы? Юк-юк, Әскәй түгел, үз авылларының медпунктын танымаска! Димәк, ул Азнакайда, больницада.

Кинәт, миен яндырып, башында бер уй пәйда булды: ә көтү кайда? Ашлыкка керсә, эш харап, икмәк таптаткан өчен баштан сыйпамаслар. Тагын да яманрагы—ә маллар күбенсә! Түләп бетерә алмассың. Уф, бар икән күрәселәре, болай да тамгалы чабата иде... Китәргә, тизрәк китәргә, маллары янына кайтырга кирәк. Әле сәгать ничә икән? Кемгә дәшәргә? Кемнән белешергә? Тапканнар система куяр вакытын, ачу китереп...

Башын борып, әйләнә-тирәне карарга теләде. Ләкин муены, карт бүренеке сыман, гәүдәсенә ябышып калган иде. Гәүдәсен хәрәкәтләндерергә теләде, анысы да гүя ташка әверелгән—селкенәсе килмәде. Язмышына буйсынып, Мөнирҗанның тик ятудан башка чарасы калмады.

Бу палатада үзенен ялгызы гына икәнлеген аңлаган иде инде. Яртылаш ачык ишек аша кешеләрнең әрлы-бирле йөргәне, сөйләшкәне, көлгәне, нинди дер арбалар тәгәрәткәне ишетелә. Керсен иде шундагыларның берсе, бирсен иде Мөнирҗанның күнелен бимазалаган сорауларга җавап.

Көтүдәге малларның ашлыкка керү ихтималы торган саен хафага ныграк сала. Көтмәгәндә, исенә Мәрдан сыеры килеп төште дә, Мөнирҗан куркып, бөрешеп куйды. Тәненә салкын тир тамчылары бәреп чыкты. Ул инде кычкырырга дип авызын да ачкан иде, ишектән ашыга-ашыга керүче ак халатлы кызны күреп, туктап калды. Шәфкать туташы, әлбәттә, Мөнирҗанның уй-фикерен, кичерешләрен белми. Ул хәтта аның ачылган күзләренә дә игътибар итеп тормады, системаны тикшерде. Барысы да әйбәт икәнлегенә ышангач кына, авыруның күзләренә карады һәм матур итеп елмайды.

—Айныдыгызмы, абый?

Айныдыгызмы? Бусы тагын ни дигән сүз? Мөнирҗанны корт чактымыни, сикереп торырдай булды.

—Әллә мин исерек идемме?—дип куркып сорады.

Шәфкать туташы көлеп җибәрде.

—Юк, абый,—диде ул ачыклык кертеп.—Мин наркоздан айныдыгызмы, дип сорамакчы идем.

Кызның сүзләре Мөнирҗанның уяна башлаган хәтерен селкетеп җибәрде:

—Наркоздан?

—Әйе, абый, наркоздан.

Мөнирҗан кызга дикъкать беләнрәк карады: тавышы радио дикторыныкы шикелле ягымлы бу тавыш иясе искиткеч гүзәл дә иде. Озынча йөз, сызылып киткән нәзек кара кашлар, кечкенә авызын уратып алган ымсындыргыч иреннәр хуҗасы теләсә кайсы егетне һушыннан яздырырлык. Заман шаукымына иярмичә, чәчләрен дә кистермәгән, үреп куйган һәм ак халаты өстеннән салынып төшкән ике калын толымы аны тагын да чибәррәк итеп күрсәтә. Тик менә...Тик менә карашы гына сагышлы. Нидән икән?

Баягы кырыс-тупас тавышы өчен Мөнирҗан уңайсызланып куйды. Гаебен йоларга теләп сорады:

—Гафу итегез, ә наркоз белән мине ни эшләттегез?

Шәфкать туташы ана гаҗәпсенеп карады:

—Безгә китергән чакта сез аңыгызны җуйган идегез. Рәүф Бариевич, хирург Хәмзинне әйтәм, бик ашыгыч операция ясады. Операцияне наркозсыз ясап булмый. Котлыйм, абый, исән калдыгыз. Доктор әйтте, тагын бер-ике сәгатькә соңга калынган булса, коткару икеле иде, диде.

—Ә миңа нәрсә булган?

—Үзегез хәтерләмисезме?

—Юк шул... Хәер, мин егылган идем. Ә монда ничек алып килгәннәрен

мин белмим.

—Хәзер врач керә, ул әйтер.

Шешәдәге сыеклык бетеп, соңгы тамчысы үтә күренмәле көпшә аша түбән төшә башлагач, Мөниржанның венасына керткән энәсен алып, кан чыкмасын өчен шәфкать туташы спиртка манчылган мамык куйды һәм, кулын терсәктән бөкләп, кысып тотарга кушты, шуннан соң система җайланмалары белән ишеккә табан атлады.

—Сестра!

—Тыңлыйм, абый...

—Минем бит көтү яланда калды. Хәзер сәгать ничә? Мина кайтырга, көтүне алып кайтырга кирәк!

Кыз көлеп җибәрде. Көлгән чагында күзләрендәге сагыш та юкка чыкты, йөзе тагын да яктыра төште.

—Ә сез монда ничәнче тәүлек ятуыгызны беләсезме?

Мөниржан аптырап китте:

—Ничек ничәнче тәүлек?

—Менә шулай. Өченче тәүлек!

—Өченче тәүлек? Булмас!—Болай да корып калган авызында теле әйләнүдән туктады.

—Булды шул, абый. Дөресен әйткәндә, доктор Хәмзин сезне теге дөньядан кире кайтарды. Азнакайдан китергәндә, сез яртылаш үлеп беткән идегез...

Артыгын әйтеп ташладым дигәндер, шәфкать туташы шып туктап калды.

—Азнакайда булмагач, кайда соң мин?

—Сез, абый, Әлмәт больницасында... Гафу итегез, мин чыгам, эшләрем бар.

Мөниржанны уйга салып, кыз чыгып китте.

Да!.. Өченче тәүлек ди бит...

Тәне тукмап ташланган кебек. Әллә өстеннән танк узганмы?

Юк, болай ятып булмый, доктордан сорарга да тизрәк кайтырга кирәк. Тик менә тәне нык авырта. Авыртсын. Җәрәхәт авырта-авырта төзәлә ул. Мөниржан аны гына белә. Сугышта ничек яраланган иде. Ходай саклагач, исән калды бит. Менә бу юлы да исән. Шәфкать туташы нәрсә диде әле: доктор, бер-ике сәгать соңга калып китерсәләр, коткарып кала алмый идек, дип әйтте диме?

Әйе! Ходай саклый аны. Тик нигә ялгыз башына сынау артыннан сынау бирep тора? Сөйгән бәндәсен авырлык биреп сыныймы? Ярый, сугышы бер Мөниржанга гына түгел, ил белән килде. Анда күргән җәфалары аз идеме, ник инде күпме газаплар күреп кавышкан Гайниясез калдырырга? Туарга житкән баласыннан мәхрүм итәргә? Төрмәдән дә чыгып өлгерми, кабат тыгып куялар. Бу бәла дигәне Мөниржанны сагалыймы, әллә Мөниржан бәлане үзе эзләп табамы? Язмыш бу кадәр үк каныкмаса, бүтән эше беткәнме? Баласы булса, атасы өчен оялып үләр иде.

Мөниржан тешен кысканын сизми дә калды. Юк, ул әле бөтенләй беткән кеше түгел! Врачларга рәхмәт, коткарганнар. Алар эшләрен эшләгән, калганы Мөниржанның үзеннән тора. Болай яту килешми, хәрәкәттә—бәрәкәт. Аягы, аркасы авырта авыртуын. Авыртса соң, ул бит бала-чага түгел, лаеш шулпасын эчкәне бар, ана гына түзәр. Госпитальдә түзде бит әле. Андагы хәле моннан күп тапкыр яманрак иде.

Белдгән язып, ул кыстырган мамыгын алды. Кан агуыннан туктаган иде.

Палатада сулыш алуы кыен: үзе бөркү, үзе тынчу. Югыйсә кече тәрәзә дә ачык. Ходай Тәгалә җиләс җилен ник кызгана икән. Күпме авыру аның

сыман бер йотым саф һавага зар-интизар булып ятадыр.

Эсседән, тәненең кызышуыннан аз гына булса да арынырга теләп, Мөниржан өстенә япкан ак җәймәне ачып ташлады һәм бер мәлгә, анадан тума шәрә ятуын күреп, үз күзләренә үзе ышанмыйча аптырап калды. Әйе, ул шәрә иде. Бары тик уң аягы бот төбеннән бәйләнгән дә күкрәге бинт белән уралган.

Алтмышка житеп килгәндә, хәер, алтмышка житкәндә генә микән, ир-атка да, хатын-кызга да гаурәт күрсәтеп яту килешми. Ярый әле кабат ябынып өлгерде, ишектән баягы чибәр шәфкать туташы белән доктор килеп керде.

Доктор озын буйлы, яше утыз биш-кырыклар тирәсендә. Борын астыннан җыйнак кына мыек җибәргән. Күзлек артыннан караучы күзләрендә арыганлык чаткылары сизелә. Күз төпләрендә җыерчык буразналары сузылган.

Докторның беренче соравы шул булды:

—Нихәл, Икс агай?

Мөниржан дәшмәде, чөнки сорауны аңлап бетермәгән иде.

Доктор кулын әүвәл авыруның маңгаена куйды.

—Температурасы бар.

Аның әйтеп бетергәнен көтмичә, шәфкать туташы шунда ук Мөниржанның култык астына градусник кыстырды.

—Доктор, ә нигә сез миңа Икс дип дәштегез?

Доктор көлеп җибәрде:

—Соң, абзый кеше, исемегезне белмәгәч, кем дип әйтергә соң? Больницага килә белгәнсез, кесәгезгә берәр документ кыстырырга башыгыз житмәгән. Үзегездән сорарлык хәлдә түгел идегез. Шуңа күрә авыру тарихыгызны да символик рәвештә генә тутырдык. Сез бит безгә күктән төшкән бүләк. Дөресен әйткәндә, бар белән юк арасында.—Аннан житди кыяфәткә кереп сорады.—Борылып ята аласызмы?

Мөниржан җавап биреп тормыйча гына борылырга кереште. Авырайган тәнен хәрәкәткә китерү җинел түгел икән. Аңа сөякләре генә түгел, һәр мускулына кадәр Җәмил тегермәне сыман ыңгыраша кебек тоелды. Ә ул, адәм мәсхәрәсе, кайтам диеп әтәчләнгән була. «Башта гәүдәңне селкетергә өйрән!» Ул эченнән генә үзен чын-чынлап әрләп ташлады.

Доктор:

—Ашыкмагыз, ашыкмагыз, менә шулай, менә шулай,—дия-дия аңа борылырга ярдәм итте.

Шәфкать туташы моңа кадәр сүзгә катышмыйча, үзенә кирәкне эшләп бара иде, түзмәде:

—Рәүф Бариевич, рөхсәт итегез!—дип, ярдәмгә ул да килеп кушылды.

Уртак тырышлык белән, ниһаять, Мөниржан капланып ятуга иреште. Әйләнгәндә тәне нык авыртса да, кычкырмады, тешен кысып түзде. Доктордан да бигрәк шушы чибәр шәфкать туташы алдында аның чебен тимәс чер итәр бер мәмкә булып күренәсе килмәде.

—Гөлзирәк, бар әйт, бәйләргә керсеннәр. Хәзер җәрәхәтен карыйбыз.

Аягын җентекләп күздән кичергәннән соң, врач сорады:

—Шулай да, исемегезне әйтегез әле. Монда сезгә шактый ятарга туры килер, һаман Икс дип дәшеп булмас.

—Мөниржан исемле мин... Исламов Мөниржан.

—Менә исемегезне дә белдек.—Докторның тавышында арыганлык сизелсә дә, күңеле күтәренке иде.—Хәзер менә шәрә ятсагыз да, күлмәк белән тугансыз икән,—дип шаяртты ул.

—Ник алай дисез?

—Шулай димичә! Аркагызга чак кына өстәнрәк кадаган булсалар,

нәкъ йөрәккә туры килер иде. Шуннан хур кызлары янында кәеф-сафа корып йөрер идегез. Сер булмаса әйтегез әле, нәрсә өчен сугыштыгыз? Кызлар өчендер инде, тагын нәрсә өчен булсын. Ир-ат башына хатын-кыз житә, дип әйтә иде минем бабай. Нәрсә белән каладылар? Лом тыгып чыгармаганнардыр бит? Мондый яраны беренче тапкыр күрәм.

—Кадамадылар мина. Сугышмадым да...

—Шаяртма, абзыкай! Мин тикшерүче түгел түгелен, шулай да беләсем килә: кайдан бу жәрәхәтләр? Каныгыз бит агып бетә язган иде.

Мөниржан үзе хәтерләгән кадәресен сөйләп бирергә тырышты. Ул сүзен төгәлләгәндә генә, Гөлзирәк тагын бер шәфкать туташын ияртеп килеп керде. Анысы өлкәнрәк яшьтә һәм кулына табак, медикаментлар тоткан иде.

—Башлыйкмы, Рәуф Бариевич?

—Башлагыз, Нәсимә апа.

Нәсимә дигәннәре кайчы белән бинтны кисте, ләкин алырга ашыкмады, ябышкан жирләрен чылата-чылата гына куптарды.

Капланып яткан Мөниржан ни эшләгәннәрен күрми. Күрсә дә, ни файда. Монда врач барысын да хәл итә, монда аның сүзе генә сүз.

Кулына кереш перчаткалар кигән Хәмзин Мөниржанның аягындагы жәрәхәт тирәләрен баскалап карады.

—Тәк-тәк, тәк... Һм. Водород перекисе белән эшкәртегез дә, калганын үзегез беләсез, бәйләп куегыз. Аягыгыздагы жәрәхәт артык куркыныч түгел, Мөниржан абый. Ә аркагызга хәзергә кагылмый торабыз. Берәр атнадан карарбыз, теккән жепләрен алыргамы, алмаскамы икәнен. Гөлзирәк, Нәсимә апа бәйләп бетергәч, авыру тарихын тутырырсың.

Авыру тарихын тутыргач, Гөлзирәк тә чыгып китте. Аңына килгәннән бирле тынгы бирмәгән уйлары белән Мөниржан япа-ялгыз калды. Аны башлыча ике нәрсә борчый иде: ул ничек итеп Әлмәт больницасына эләккән һәм көтүгә нәрсә булган.

Теле булса, соңыннан Вәскәй Мөниржанга ничек итеп больницага эләгүен сөйләр иде дә... Кызганыч, Аллаһы Тәгалә жанварларны, һәрхәлдә, кешеләр аңлый торган телдә сөйләшә торган итеп яратмаган.

Вәскәй, рәхмәт төшкере жан иясе, үзенә атланып утырган Мөниржанны башта олы юлга алып чыкты һәм асфальт юл читеннән авылга табан алып китте. Ләкин озак бара алмады, Әскәйгә житәргә ике чакрымнар калгач, хуҗасының кулы башта ялын ычкындырды, шуннан соң ук гәүдәсе дә сул якка янтаеп төште. Тагын да хәтәррәге, егылган ягының аягы өзәңгегә эләгеп, гәүдәсе асылынып калды. Баш белән жирдән сөйрәлеп баруның ни дәрәжәдә куркыныч икәнен чамалаган Вәскәй гажизләнеп туктап калды. Нидер эшләргә ул чарасыз иде.

Язмышына буйсынып шулай басып торганда, арттан килүче машина тавышын ишетеп, Вәскәй колакларын шомрайтты. Ләкин зур тизлектә килгән «Жигули», бераз гына акрыная төшсә дә, туктамыйча узып китте.

Ул күздән югалуга, ерактарак гүләгән тагын бер тавыш ишетелде. Бусы зур машина. Эчке тавыш атка әйтте—бу машинаны ул һичшиксез туктатырга тиеш. Югыйсә соң булуы бар.

Вәскәйнең озак уйлап торыр вакыты калмаган иде. Ул өстенә басып Мөниржанны имгәтүдән саклап, асфальт юлның уртасына чыкты. Торбалар төяп буровойдан кайтучы прицеплы машина ана табан якынайганнан якыная барды. Шофер баштарак атны гына күргән иде, кычкырта-кычкырта якыная төшүгә, нәрсәнеңдер сөйрәлүен дә шәйләп алды. Кеше түгелме соң? Ул болай да туктар, күрәләтә ат кадәр ат өстенә менмәс иде. Ат түгел, сарык кына таптатсаң да, ат бәясе түләтергә торалар.

Туктауга, шофер да, аның янәшәсендә утырган ир дә жиргә төшәрдән

алда атка карадылар. Вәскәй гажизлек газабы чыккан күзләрен туп-туры аларга текәгән дә кымшанмыйча басып тора. Ул, нәрсә карап торасыз, тизрәк булыгыз, ярдәм итегез, дип инәлә иде.

—Әнекәем!—дип кычкырганын сизми дә калды шофер кырында утырганы.—Канга баткан бит бу!

Ул кабина ишеген ачкан арада, «КамАЗ» шоферы җиргә сикереп төшеп өлгергән иде инде.

Шофер иң беренче эше итеп кулын Мөнирҗанның маңгаена тигереп карады. Җылы! Аннан янына килеп җиткән иптәшенә әмер бирде:

—Мин башын тотып торам, син аягын ычкындыр!

Аңын җуйган җайдакны ычкындырганда, икесе тиң канга буялып беттеләр.

—Нишләтәбез?

Бу көе бәлагә таручының кай җире җәрәхәтләнгәнен дә белерлек түгел иде. Шофер әйтте:

—Әйдә, башта кырыйга алып чыгыйк әле.

Юл читенең чирәмлерәк җиренә яткыргач, аларга җәрәхәт урынын карарга җай чыкты.

—Да... Каны һаман ага, туктатырга кирәк.

Ярый әле хәстәрле шофер икән: аптечкасында жгут бар иде, чалбарын бераз төшереп, бот төбеннән аны буып куйдылар.

—Моның күлмәк эче дә кан гына...

Машинада чиста чүпрәк тә табылды. Җәрәхәт турысына йод сөртелгән бинт куеп, күкрәгән чүпрәк белән урадылар.

Моны болай калдырып булмый иде. «КамАЗ»ның кабинасына да ничек туры килде шулай салып булмый, бөтен дөньясын буяп бетерү бер нәрсә, бәхетсезлеккә дучар булган бу абзыйны исән-сау Азнакайга илтеп җиткерергә дә кирәк.

Бәхетләреннән, туктаган бу «КамАЗ»ның кабинасында йокы бүлмәсе бар иде. Шунда башта чистарак саналган ике капчык, аның өстенә целлофан җәйделәр дә Мөнирҗанны сак кына кертеп яткырдылар. Аңсыз кешене күтәреп йөртү, йөртү генә түгел, биек кабинага кертеп урнаштыру аларның тәмам хәлен алды. Машина, шалтыр-шалтыр килгән торба тавышына игътибар итеп тормастан, бар булган тизлегендә Азнакайга очты.

Олы юлда комачаулаучы юк иде. Азнакай эченә кергәч, шофер, сигналын туктаусыз акыртып, юл билгеләренә дә карап тормастан, хастаханәгә ашыкты. Гөнаһ шомлыгына каршы, бераз баруга, ГАИ инспекторы басып тора иде. Бер кагыйдәне дә санламыйча, җиңел машиналар гына йөрергә тиешле урам буйлап ажгырып килгән «КамАЗ»ны күргәч, ул башта югалып калды, аннан соң исенә килеп, аклы-каралы таягын болгарга кереште. Алай да туктамагач, сыбызгысын сызгыртты һәм «УАЗ»ына утырып, куа китәргә уйлады. Руль артында ләх исерек утыруына ул аз гына да шикләнми иде. Ләкин машинасының двигателе тиз генә кабынам димәде. Ул кабызганчы, инспектор бу машинаны ясаган автозаводның атасын, анасын, әби-бабаларын кат-кат искә төшерергә өлгерде. Әллә шундый "җылы мөнәсәбәтне" аңлады, «УАЗ» көтмәгәндә кабынды, һәм инспектор инде күздән югалырга өлгергән торба машинасы артыннан куа китте. Тотсамы! Тотса, күрмәгәнен күрсәтәчәк әле ул аңа! Исерек дуңгыз! Алкаш! Сержант Шәймәрдәнов белән шаярырга ярамаганын гомер буена онытмас!

Биш минутлар уздымы икән, Шәймәрдәнов утларын яндырып, сигналын кычкыртып, һаман да тизлеген киметмичә бара торган «КамАЗ»ның эзенә төште. Машина инде үзәк хастаханәгә якынаеп килә иде.

Шәймәрдәнов утлары ярдәмендә ана туктарга кушып карады, мегафоннан кычкырды. Тәгәрмәчләренә атарга теләп, пистолетын да капшап алды.

Ләкин атарга куркыныч, кешеләр йөреп тора. Алдына чыгып туктатыр иде, юл тар, узып китәр мөмкинлек юк.

Хастаханә ишек алдына алар аллы-артлы барып керде. Шалтыр-шалтыр килгән «КамАЗ»га игътибар итми мөмкин түгел иде. Ул килеп туктауга, тәрәзәдән моны күреп торган ак халатлы ике кыз каршы чыкты. Машинадагылар аларга авыру алып килгәнлекләрен генә әйтеп өлгерде, Шәймәрдәнов, ачуыннан буыла язып, шоферның якасына барып ябышты.

—Ник туктамадың?

Ачуның күзе сукыр, ул әле һаман шоферның кан эчендә яткан кешенен кулларыннан тотканын күрми иде.

Шоферда инспектор кайгысымыни:

—Комачауламагыз әле, төшерешергә ярдәм итегез,—дип аның үзенә әмер бирде.

Шәймәрдәнов шунда гына аларның канга буялган кешене төшерергә маташканнарын искәреп алды. Аның башына килгән беренче уй: «Әһә, кеше бәрдергәннәр!»—булды.

Бу хакта шунда ук кычкырасы килсә дә, сержант вакытында тыелып калды: ничек кенә булса да, беренче чиратта кешегә ярдәм итәргә кирәк. Инспектор кабинаның сул ягыннан сикереп төшеп, Мөниржанны уң яктагы ишектән чыгаручыларга ярдәмгә ташланды.

Канга баткан гәүдәне бергәләп носилкага салып, эчкә алып кереп киттеләр.

Ләкин иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас дигән әйтем бар. Азнакайның үзәк хастаханәсендә эшләүче өч хирургның берсе чираттагы ялда, икенчесе үзе авыру—кичтән генә сукыр эчәгесенә операция ясаганнар, өченчесе ашыгыч рәвештә хатынының әнисен күмәргә Башкортстанга киткән булып чыкты. Тагын бер травматолог бар, анысы ярты сәгать элек кенә машина авариясендә нык зыян күргән берәүгә катлаулы операция ясый башлаган. Операциянең ничә сәгатькә сузыласын төгәл генә берәү дә әйтә алмый. Дежурдагы терапевт яраларны карагач, кинәш-табыш итеп алдылар да Әлмәт белән бәйләнешкә керделәр. Тагын ун минуттан, Мөниржанны алып, сиреналарын кычкырткан, әрҗәсе өстендәге утларын яндырган ашыгыч ярдәм машинасы Әлмәткә очты.

Азнакай—Әлмәт арасы тиз барганда 40-50 минутлык юл. Медперсонал көтеп тора иде. Тиешле процедураларны үтүгә, кем икәнлеге дә билгеле булмаган Икс агайны тагын берничә минуттан операция өстәленә кертеп тә салдылар. Хәмзинның оста кулы, шәфкать туташларының тырышлыгы Әскәй көтүчесенең гомерен әнә шулай саклап калды.

Мөниржанны озатканнан соң, инспектор Шәймәрдәнов «КамАЗ» шоферыннан анализлар алдыртып маташты. Ләкин көткән нәтиҗә чыкмагач, шоферның кулын кысып, акланды:

—Безнең эшебез шул, абзый кеше, бигайбә!

«КамАЗ»дагылар әнә шулай итеп кемнең гомерен саклап калганнарын да белмичә китеп барды.

Ул көнне көтүдәге малкайлар рәхәткә чыкты. Маллар бит туплауга төшү вакытын сизә. Аларның үзләрендә биологик сәгать бар.

Туплауда булырга тиешле вакыт узуга, көтү кабат тынычсызлана башлый. Тыючы булмаса, берсе анда, берсе монда тарткаланырга керешә. Бу юлы да башта әлсерәүдән туктаган сарыклар туплау тирәсендә үләнгә барып ябырылды. Сарык кадәр сарык үлән ашаганда, сыер карап торыр дисеңме? Карар сиңа, тот капчыгыңны! Туплауга алып төшкән сыерлар янә юлбашчы вазифасын үз өсләренә алды. Ләкин туплау бу тирәдә берәү генә булса, мал ашар ризык төрле җирдә. Әлбәттә, кибеп саргая башлаган жиз үләнгә караганда шаулап торган ашлык басуын кайсы мал өстенрәк

күрмәс икән.

Мөниржанны машина белән алып киткәнне сабыр гына карап торган Вәскәй башта Әскәйгә кайтмакчы булган иде, әмма, авылдан ераграк булу сәбәпле, мал аяк басмаган су буе тугаеның сусыл үләненә туры килеп, бу теләген тормышка ашыруны кичектереп торырга булды. Авыл качмас, әнә генә ул, ә җәй уртасында исе һушыңнан яздырырлык үләнле мондый тугайда сыйланып китмәсәң, гөнаһ булыр.

Көтүчесез калган маллар белән нәрсә булып бетәр иде, әйтүе кыен. Алар ярыйсы гына сыйлангач, мотоцикл белән кыр карарга чыккан баш агроном Хәсәннең, тәҗрибә кырында көтү йөргәнен күреп, чак кына йөрәге ярылмады. Тыныч кына үтеп китсәң, бөтен басуыңны эштән чыгарачак бу мур кыргырлары. Кемне дә булса ярдәмгә чакырырлык та түгел.

Көтүне ашлыктан куып чыгаргач, Хәсән Мөниржанны эзләп як-ягына карады, чокырлырак урыннарны урап килде. Көтүче бер җирдә дә юк иде. Үзе булмагач, аты да юк. Димәк... Бу вакытта кайда булыр дисең. Димәк, ычкынган. Тагын тәкатен тыя алмаган икән, бирән тәре! Менә хәзер син аның урынына көтү көт, ә ул рәхәтләнеп эчеп йөрсен. Ул Мөниржанның йә Әскәйдә, йә Митрәйдә сәрхушләнеп йөрүенә шулкадәр ышанган иде ки, башкача булу мөмкинлеге турында уйлап та карамады. Аңа ирексездән көннең калган өлешендә көтү көтәргә туры килде, чөнки малларны караучысыз калдыру турында уйлыйсы да юк иде. Болай да тәҗрибә басуының кирәген биргәннәр.

Ул көнне малларны кич белән агроном алып кайтканны күреп, авыл халкы гаҗәпкә калды. Төрмәдән кайткан араларында Мөниржанның ата сәрхуш булганлыгын онытып өлгермәгәннәр иде әле. Алар да, нәкъ Хәсән кебек үк, Мөниржанны эчкәндер дип уйлап, өсләренә зур гөнаһ алдылар.

Иртәгәсен көтү чыкмады. Югары оч халкы, көтә-көтә көтек булгач, Мөниржанның өенә барып карады, өе бикле иде. Фазылга кичекмәстән көтүне сигезенче класска күчкән ике малайга тапшырудан башка чара калмады.

Көтү куарга чыккан халык арасында хәвефле сүз таралды. Кичә ашлыкка кергән берничә сыер күбенгән булган, шуларның икесен коткарып кала алмаганнар. Аларның хуҗалары сәвиткә жалу итәләр икән. Ашлык таптаткан өчен, әле бит ашлыкның да ниндие иде, совхоз дирекциясе шулай ук чара күрми калмас. Кайтсын гына! Алай бер тамагына баш була алмагач, алынмыйлар аны көтүче кебек җаваплы эшкә!

Мөниржан атланып йөри торган атның булмавына берәүнең дә исе китмәде. Хуҗасы кайда, аты шунда булырга тиеш. Ике чабата—бер кием!

Икенче көнне, төш вакытлары җиткәндә, Вәскәй атлар абзарына үзе генә кайтып керде. Бахбай ирекнең кадерен белеп калды—авылга ашыкмады. Ләкин иректә йөрүе озаккарак сузылды бугай, нигәдер хуҗасы үзе дә күренми, сызгырмый да. Гаепле төс белән Вәскәй шуннан соң әкрен генә авылга табан атлый башлады. Аны күргәч, Мөниржаннан бигрәк Вәскәй юклыкка эче пошкан ат караучы Мөҗәһит куанып куйды. Баштарак ул, атның иярен салдырып, абзарга озатырга уйлаган иде, якынрак килгәч, ияр дә, атның сырты да канга буялганын күреп, йөрәге жу итеп китте. Кан буялган икән, тикмәгә түгел бу! Хәбәр яшен тизлеге белән авылга таралып, авыл җитәкчеләре Мөниржанны эзләү оештырдылар. Карамаган, айкамаган чокыр, куаклык калмады. Көтүче суга төшкән кебек юкка чыккан иде. Бәлки аңа һөҗүм итеп, малларын урларга теләгәннәрдер дә, үтереп берәр җиргә күмгәннәрдер. Эзенә төшә алмагач, район эчке эшләр бүлегенә хәбәр иттелде. Ләкин милициянең тырышып эзләве дә нәтиҗә бирмәде.

Маллары зыян күргәннәргә соңрак дәүләт страховка акчасы түләде, тапталган игенгә акт төзелеп, фәлән гектары гамәлдән чыгарылды.

Авылдашлары аның турында ни уйларга белми баш ваткан көннәрнең берсендә Мөниржанны гомуми палатага күчерделәр.

Хастаханәләрдәге палаталарның күбесе бер-берсенә игезәкләр кебек охшаш була. Аерма бары тик анда кемнәр ятуында гынадыр. Авыр хәлдәгеләр белән бергә эләксән, тешенне кысып булса да түзәргә кала. Ул мескен ни эшләсен, үзе сорап алган чир түгел.

Бу палатага күчергәндә, Мөниржан үз йомышына йөри ала башлаган иде инде. Дөрес, аның хәле юк, тәне авырта, ләкин бу инде астындагы «үрдәк»не кемдер килеп алып китүен көтеп яту түгел. Йомышына үзең йөри алу зур бәхет, күзенә чекрәеп карап торган Газраилны яныннан куу дигән сүз. Тик моны үз башыннан кичереп караганнар гына белә. Аны күчергән гомуми палата биш кешелек иде. Мөниржан палатадагылар белән юньле-рәтле танышырга да өлгерә алмый калды, икенче көнне янәшә койкадагы Николайны өенә кайтарып җибәрделәр. Аның белән саубуллашкач, Ризван дигәннәре:

—Уф, Поптан котылдык!—дип, шатлыгын уртаклашты. Николайның фамилиясе Попов икән, шуна күрә палатадагылар аны Поп дип кенә йөрткән.

Ризванны аңларга була, чөнки, үзе зыянсыз кеше булса да, "Поп" төннәрен гырлап бирәүгә дә йокы бирмәгән. Моны Николай барында бер генә кич кунарга өлгергән Мөниржан да сизеп өлгергән иде...

Мөниржан акрынлап савыга. Савыккан саен эчен хәвеф корты ныграк кимерә. Аның бит кайдалыгын Әскәйдә белүче юк. Көтү ни эшләп бетте икән? Валлаһи, кайткач, кеше күзенә ничек күренер. Шалтыратып әйтсән, әйбәт булыр иде дә бит, чит районга түгел, Әлмәтнең үзенә шалтыратулар да монда зур проблема, диләр.

Эче бик пошса да, Мөниржан кайтып та китә алмый, үзе турында авылга хәбәр дә итә алмый. Ни эшләргә белмәгәннән, палатадагыларга китергән гәҗит-журналларны караштыра, кулга төшкән кызыклырак китапларны укый, ара-тирә Игорь белән сөйләшеп китәләр. Шулай итеп көн артыннан көн уза.

Мөниржанны егерме көнләп тоттылар. Ул инде мондагы табипларга, шәфкать туташларына күнегеп беткән иде. Кесәсендә бер тиене дә булмагач, рәхмәтен сүз белән генә белдерергә мәҗбүр булды.

Кайтыр минут житкәч, Фазылга хат язып салмавына үкенде. Чөнки, янында документлары, акчасы булмау өстенә элек кигән күлмәге, чалбары да ертык-тишек, өстәвенә, канга баткан иде. Шул көенә аларны ничек киясең дә, ничек итеп кеше күзенә күренәсең.

Аптырап башын кашып тора иде, палатага Гөлзирәк килеп керде. Миннуллага укол ясыйсы бар икән.

Эшен бетереп чыгып китәм генә дигәндә, Гөлзирәкнең күзе Мөниржанның киемнәренә төште.

—И-и, Мөниржан абый, куй, боларны ничек киясең! Куй, булмаганны! Хәзер өйгә кайтып киләм, киелгән булса да, чистарак бирәр нәрсә табармын!

Мөниржан ни дә булса әйтергә өлгергәнче, шәфкать туташы жил-жил атлап чыгып та китте.

Хастаханәдә уздырган егерме көн эчендә Мөниржан мондагы медперсонал турында хагын да нахагын да ишетергә өлгергән иде инде. Наркоздан соң аңына килгәч, Гөлзирәкне беренче тапкыр күрүендә үк, бу чибәр шәфкать туташының күзләрендәге сагышка игътибар иткән иде. Гөлзирәк бит акылыннан язар хәлгә житкән булган. Хәтта хастаханәдә дә ятып чыккан. Ятарсын да әле өч ай гына элек кавышкан сөйгән ярыңны көтмәгәндә машина бәреп китсә. Иренең мотоциклы бер якка, үзе икенче якка егерме биш-утыз метрларга очкан, дип сөйлиләр. Кичке сменадан

соң хатыны янына ашкынып кайткан чагы булган. Ирен иртә белән генә тапканнар. Бәрдергән юньсез туктап та тормаган. Шунда ук ярдәм күрсәтелсә, белмәссең, бәлки исән дә калыр иде...

Мөниржаннын уйлары Гөлзирәктән Әскәйгә күчә. Аңа ни булыр? Сталин заманы түгел түгелен, тик барыбер баштан сыйпамаслар. Их, әйбәт кенә эшли, көтү көтүнең җаен алып бетергән иде бит.

—Абый, киеп карагыз әле!

Гөлзирәкнең тавышы аны тегендә-монда сикерешкән уйларыннан чынбарлыкка кайтарды. Ул шакмаклы күлмәк белән кара чалбар алып килгән булган. Кай арада өлгергәндер. Бик бәхетле булырга тиешле бу баланың канатларын язмыш ник шулкадәр иртә киселә икән?!.

Гөлзирәк чыгып торган арада, Мөниржан күлмәк белән чалбарны киеп куйды. Күлмәге тап-таман, нәкъ үзенә үлчәп теккән кебек, чалбарының балаклары исә озынрак иде, бераз кайтарып куярга туры килде.

—Йә, ничек?

Гөлзирәк ишектән керүгә үк, киемнәрнең Мөниржан абыйсына яраганын күрде һәм...авыр сулап куйды. Чит кеше өстендә Мансурының киемнәрен күрү аңа ирен, өч көннән дә тизрәк узган өч аен исенә төшерде. Шул ук вакытта ул авыр минутында ярдәмчесез калган абзыйга аз гына булса да булыша алуына чиксез шат иде.

«Кеше кешегә—бүре» дигән сүз бар. Әйе, төрле битлек ябынган әшәкелек, җирәнгеч кабахәтлек белән адым саен очрашып торасың. Мөниржан да моны башыннан аз кичермәде. Тик анын күңелендә, төрмә шулпаларын кат-кат эчсә дә, изгелеккә, игелеккә, яхшылыкның өстенлек итүенә ышаныч кимемәде. Шулай булырга тиеш тә. Югыйсә, Адәм галәйһис-сәлам белән анабыз Һаванын варислары күптән бер-берсен ашап бетерер, яктылыкка урын калмыйча, җирне караңгылык каплар һәм тормыш сүнәр иде.

Бәлки шулай булгалагандыр да. Әнә бит ничек язалар: имеш, җирдә әллә ничә тапкыр цивилизацияләр чәчәк аткан, юкка чыккан. Бу фаразлар чыннан да дөреслеккә туры килсә, моның өчен җитди сәбәпләр кирәк. Барысын да климатның кискен үзгәрүенә, космик һәлакәткә, чит планетадан килүчеләргә генә сылтап бетерә алмыйсың. Уйланмас җиреңнән уйланырсың, кодагый!

Гөлзирәктән мондый бүләкне кабул итүе уңайсыз иде. Мөниржаннын күңеле нечкәреп, бугазына төер тыгылды.

—Сеңлем, сине ничекләр генә бәхилләрмен икән. Янымда сукыр бер тиен дә юк бит...

Гөлзирәк:

—Кирәкми, абый, исән-сау йөр, бары тик шул гына,—диеп, аңа авыз ачарга да ирек бирмәде.

Кайтырга кузгалгач, Мөниржан башта автовокзалга сугылды. Ләкин автобуска аны утыртмадылар. Йөзен сакал-мыек баскан, акчасыз мондый пассажир кемгә хаҗәт! Акчасы булса, башкачарак сайрарлар иде. Акчасы юк шул, акчасы. Югыйсә, сугыш гарибе икәнлеген әйтеп, врачлар биргән кәгазьне дә күрсәтеп карады. Төкерәләр алар синең кәгазеңә, төкерәләр алар синең сугышта кан түгеп йөрүеңә! Аларның үз кырыгы кырык, үз туксаннары туксан!

Мөниржан, очраклы машиналарга утырып, ничек кирәк алай кич белән Әскәйгә кайтып җитте. Асфальт юлдан ихатасына бәрәңге бакчасы аша гына төште. Көтү кайтып, һәркем үз эше белән мәшгуль булганга күрәдерме, әллә инде юклыгына күнегеп беткәннәр идеме, анын кайтуына игътибар итүче булмады.

Иртәгәсен ул көтү китүен тәрәзә аша гына карап калды. Ул бит әле һаман да тәмам терелеп җитмәгән, тиз генә эшкә чыга алмаячак. Авыру

сәбәпле эштән азат ителү хакында бирелгән кәгазь белән аңа берничә көннән Азнакай табипларына барып күренергә туры киләчәк.

Көтүне ике малай куганын күреп, йөрәге сулкылдап куйды. Малайларның берсе җәяүле, икенчесе Вәскәйгә атланган. Анысы ара-тирә бик хәтәр генә чыбыркысын шартлатып ала.

Көтү күздән югалды. Мөниржан күңелендә ниндидер шом уяна барганын тойды. Аның юкка чыгуын авыл халкы ни дип юрады икән? Ахырда түзмәде, сагындырып өлгергән гармунын кулына алды. Бу минутта аның бүтән юанычы да, сердәше дә юк иде. Әй, гармун, Мөниржанга син, син житмисең икән бит! Өй эченә ишекләрне бәреп чыгасы килеп ярсыган моң агылды. Һәм бу моң төзәлеп бетмәгән җәрәхәтен күпмедер вакытка оныттырып торды, күңеленә кереп оялаган шомны куарга ярдәм итте.

Гармун сердәшен сердәш тә бит, тормышның матди ягын ул хәл итә алмый. Ә Мөниржанның Әлмәт больницасыннан чыкканнан бирле бер тәгам ризык капканы юк. Өендә эзләп караган иде дә, тапмады. Ничә ай буена кешеләрдә чираттан ашап йөреп, өйдә ни булсын. Акчасы бар барын, тик акчаның үзен ашап булмый. Шуңа күрә бердәнбер юл—ул да булса кибет ачылганны көтәргә кала. Ә ул бары тик иртә белән генә ачыла.

Мөниржан сәгатенә күз салды. Сигез тулып килә икән. Әһә, димәк, озакламыйча кибет ачылачак. Рәмзия эшкә төгәл йөри, сигез тулыр алдыннан кибетенең зәңгәр ишекләре киерелеп ачып куела. Рәхим ит: акчаңны түлә дә хәзинәдә барын алып кит, рәхәтен күр. Талонсыз аракы гына сорама.

Мөниржан ялгышмады. Озакламый урамнан җилкәсенә сумкасын аскан Рәмзия кибет ягына керт-керт атлап узып китте. Бигрәк матур атлый икән үзе, чукынчык. Әскәйнеке түгел, читтән, кайсыдыр авылдан килгән диделәр үзен. Өченче ел инде Түбән очтагы Ибрай Зәкиясендә фатирда тора икән.

Чулак кулының терсәгенә сумкасын асты да, җил-җил атлап, Мөниржан Рәмзия артыннан ук диярлек кибеткә юнәлде. Ләкин озакламый адымнарын акрынайтырга мәҗбүр булды: җәрәхәте авыртып аңа: "Ашыкма, абзый!"— дип искәртә башлады.

Рәмзия ишеген ачып кергән дә көзге каршында төзәтенеп тора. Хатын-кызның шул булыр инде аның: ике адым атласа, өченчесендә көзгегә күз салыр. Әлбәттә, иренен кызартмый калмас. Чамадан тыш кыланмасалар, ирен кызартулары, каш-керфекләренә сөрмә тартулары килешеп тора тагын үзләренә.

Гайния исенә төшеп, Мөниржанның күңеле сыкрап куйды. Урыны оҗмахта булсын мәрхүмәнең—бар яшәгән гомерендә бизәнүнең ни икәнен белмәде, чәчен ике толымга үрә иде дә яулык бәйләп куя иде. Болай да гүзәлләрнең гүзәле булган затка фәрештә булып күренергә шул да җитә иде. Хәер, заманасы да бүтән иде лә!

—Исәннәрмесез!

Рәмзия башта сумкасына бизәнү әйберләрен урнаштырды. Аннан соң гына елмайды һәм, борылып:

—Хәзергә исән идек әле,—дип чытлыкланып җавап кайтарды.

Мөниржанның йөрәге дерт итеп китте: әйтерсең, еракта калган еллар томаны аша аңа Гайния аваз салды. Кибеткә әйбер алырга килгән ир, ник килгәнен дә онытып, кибет хуҗасына карап катып калды. Ул арада Рәмзия дә халаты белән башлыгын киеп өлгерде, шуннан соң гына аңа дәште:

—Ни йомыш иде, абзый кеше?

Рәмзиянең шушы соравы аны күктән җиргә якынайтты.

—Өстәлгә куярлык ни-нәрсәләрегез бар?—Кибет киштәләре күргәзмә

экспонатлары куырдай такыр иде.

—Конфетлар, прәнник...

—Алары чәйгә. Итле ризыклар юкмы?

Рәмзиянең йөзенә елмаю чыкты:

—Сез, абзый кеше, әллә күктән төштегезме? Кайдан килеп авыл кибетендә ит булсын. Әле йомырка тапшыручысы да сирәк. Халыкның үзеннән артмый. Әнә балык консервылары бар. Аласызмы? Шешәнең агы да, кызылы да. Хет Бөгелмәнеке, хет Минзәләнеке—җаныгыз кайсысын тели, шунысын аласыз.

—Рәхмәт, шешәсе кирәкми. Берничә консервы, тагын печенье белән кәнфит бирегез. Әрсезлек булса да сорыйм инде: бәлки берәр дистә йомыркадан да өлеш чыгарырсыз. Бик ашыйсы килде, ә өйдә шымытыр.

—Хатыныгыз ник пешерми? Сезнең кебек абзыйны ач тотарга ярамаганны белмиме әллә? Ирләрнең мәхәббәте аларның ашказаны аша уза ди бит.—Вәт имансыз, чытлыклану да килешә икән үзенә.

—Исән булса пешерер иде...—Беренче тапкыр очрашып сөйләшкән шушы сатучы хатынга ачылып китүенә Мөниржан үзе дә аптырады. Кинәт аның җәрәхәте сулкылдарга керешге. Их!..

Каршысында торган бу ирдәге сәер үзгәрешне сатучы хатын да искәрде һәм гафу үтенергә тотынды:

—Авырткан җирегезгә кагылдым ахры, зинһар, гафу итегез. Сезне юньләп танып та бетермим сыман. Хәтерем ялгышмаса, сез кибеткә соңгы тапкыр яз көнендә кергән идегез...

Мөниржан янә гаҗәпләнде: чыннан да соңгы тапкыр ул бирегә көтү сезоны башланыр алдыннан сугылган иде. Көтүгә кергәч, кибет кайгысы да, аның хаҗәте дә калмады. Өй борынча ашау аның тормышын җиңеләйтте.

—Ну хәтер дә икән үзегездә!

Рәмзия чытлыкланып көлде. Аның челтерәп аккан чишмәне хәтерләткән яңгыравык көлүен кибет киштәләрендә тутыгып яткан сәнәк-көрәк ише тимер дә, кайчан кайтарылганын күптән оныткан, кайсысы инде бозылырга да өлгергән кильки консервылары да, бер почмакка өеп куелган чүпрәк товарлары да йотарга өлгерә алмый калды.

Рәмзиянең:

—Кайдан килсен инде ул безгә хәтер. Хатын-кыз хәтере—тишек иләк бит,—диюе аны янә бу мөлаем, чама белән генә чытлыклана белгән хатынга сокланып карарга мәҗбүр итте.

—Карагыз әле,—аның беренче әсәрләнүе узган һәм ул кыюлана төшкән иде,—бер авылда яшәгәч, авылдаш булабыз. Ә авылдашларның исемен белергә кирәк. Теге дөньяда очраша калсак, кем дип дәшәргә дә белмәсән, оятын кая куярсын...

—Теге дөньяга ашыкмыйк әле, бу дөньяда танышу мөмкинлеге булганда. Минем исемем Рәмзия.

—Сезнекен беләм мин. Ә сез Мөниржан абый, шулай бит...

—Шулай. Кайдан белдегез?

—Об этом говорит вся мәхәллә.—Кибетнең саргылт диварларына яктылык өстәп, көлү тагын кабатланды.

—Мәхәллә тагын ни сөйли? Башы төрмәдән чыкмый, көтүен ташлап качкан дип тә сөйлиме?

Рәмзия шунда ук җитдиләнде.

—Утырып кайтуыгыз хакында ишеткәнем бар барын. Ә көтү турында баштарак сүз куертканнар иде, тора-бара тынычландылар. Нәрсә булган иде соң?

Бу хатын әллә сихерләде инде, Мөниржан соңгы көннәрдә үз башыннан кичкәнне кыскача сөйләп бирде.

Шул чагында ишектә Түбән очта күршеләр булып яшәүче Ниса белән Хәния карчык күренде.

Алар башта Мөниржанга игътибар итмәде, чөнки ул ишеккә арты белән тора иде. Танып алгач, Ниса карчык гаҗәпләнеп сорады:

—Бәрәч, Мөниржан, син түгелме соң? Кайларга китеп югалдың? Хәзер көтүнең, син булмагач, рәте-чираты китте. Чынлап та кайларда йөрдең син шул гомер? Сина әйтәм, кайда йөрдең?

Ахирәтен Хәния кортка да куәтләде:

—Әйе-әйе, суга төшкән таш кебек гаип булдың!

Бу карчыкларга дөресен сөйли башласаң, кич житәр, анда да аңлата алмассың, ышанмаслар да. Әнисе Минсафаның замандашлары бит инде бу әби-апалар, бергә иген урдылар, ашлык суктылар, утауга йөрделәр, карлы су ерып, чана белән элеватордан чәчүлек орлык ташыдылар. Мөниржан боларга үзе шаһит—күрмәгәннәре калмады. Үзләре өчен дә, ирләр өчен дә җигелеп тарттылар. Аларның бу көнгә кадәр исән булулары—үзе бер могҗиза. Ат урынынына эшләп, гомерләре фәкыйрьлектә узган бәхетсез буынның соңгы моиканнары бит алар. Алар үзләренең бәхетсез икәнлекләрен белмәве белән бәхетле, илләр тыныч булып, Ходай Тәгаләнең ипи белән чәйдән аермаганына шөкрана кылып яши бирәләр. Җәмгыятен әйтер идең, үзгәрттеләр, үзгәрттеләр дә, үзгәртә торгач, түрдә тәсбих тартып утырасы әби-бабайларны янә дә эт типкесендә калдырдылар.

Мөниржан, ни әйтергә белмичә, карчыкларга карады. Ак яулыклар бәйләгән, картайсалар да, чырайларында инсафлы татар әбиләренә хас илаһи мөлаемлык сакланган бу әбиләрдән галибанә сөйкемлелек бөркелә иде. Аларга алдашу да ярамый, дөресен әйтү дә файдасыз. Шуңа күрә шаяртып җавап кайтармый чарасы калмады:

—И апа җаннарым, көтү көткән җиремнән кызлар урлады... Ябып тоттылар.

—Кит, әстәгъфирулла! Инәпләнитәннәрме әллә? Тилевәзирдән соңгы вакытларда гел шуларны күрсәтәләр,—диде Ниса.

—Алар алып китсә, тиз генә кайтармыйлар ди бит.—Хәниянең дә күп белүдә ахирәтеннән калышасы килмәде.

Йә чынлап торып ышана башларлар, бу корткаларны чит планетадан тизрәк җиргә төшерергә кирәк.

—Юк-юк, мине җирдәгеләр урлады, яшь егет дип уйладылар ахры.

—Булыр-булыр, хәзер хатын-кыз бик азды.

—Азмаска соң, хатын-кыз ун млиун кешегә артык ди бит Рәсәйдә.

—Артык булса да инде. Хатын-кызның кайчан ир-аттан кимрәк булганы бар? Сугыштан соң ничек иде, хәтерлисеңме? Ирләр яу кырында кырылды. Юк-юк, болай ук азгын түгел иде хатын-кыз!

—Ахырзаманның якынлашуы шулдыр, әйеме, ахирәт!

—Шулайдыр, шулайдыр. Йа раббым, үзең сакла!

Әбиләр тагын күпме сүз куертырлар иде, Мөниржанның ник килгәне исенә төште:

—Рәмзия, әйтегез әле, күпме акча түләргә?

Сатучы исәп-хисап ясаган арада, Ниса карчык Мөниржанның буш җиңеннән тартты:

—Әйт әле, ник өйләнмисең син? Гайния үлгәнгә дә бер гомер, син һаман буйдак. Ата каз сыман каңгырап яшисең...

—Ие-ие,—дип ялгап китте Хәниясе.—Әйтерең бармы, үз кадереңне үзең белмисең. Хатын белән адәм-рәтле яшәрмен дип куркасыңмы?

—И әбекәйләр, җанкисәкләрем, кем чыксын миңа.

—Чиләгенә күрә капкачы табыла аның. Яшь тә, карт та түгелсең. Әнә Рәмзияне алып кайт та, чөкердәшеп яшәрсез. Ничу анда җәһәннәм

очындагы Ибрай Зәкиясенең өендәге тузанын иснәп ятарга чәчәк кебек хатын башы белән!..

—Нисаттәй, синнән кияү сораганым юк ла!—исәп-хисап ясау белән мәшгуль Рәмзия бу сүзләрдән кызарып китте, ләкин сөйләшүгә кискен нокта куймады.

—Әй, син тик кенә тор! Ирсез хатын—кадерсез хатын. Туксан яшьләрдәге берәр егет сорап килсә, үзем, ике дә уйламый, кияүгә чыгар идем. Килмиләр генә, һе-һе-һе...

Күршесенең бу сүзләренә Хәния кулын селтәде:

—Кит, оятсыз, авызыңда тешең калмаган, тузга язмаганны сөйләп торасың! Йә кеше ышандырырсың.

—Ышанмагайлары тагын. Өйләнү, кияүгә чыгу—ата-бабалардан калган изге бер йола ул, ахирәт. Бу үләлмәгән кортка сүзенә карама, Мөниржан, өйлән!

Мөниржан Рәмзиягә күз кысты:

—Менә Рәмзия риза булса, бүген үк йортка килен төшерәм. Ни дисең, Рәмзия?

—Мондый намаз ияләре димләгәч, уйлап карамыйча да булмас.

Уен уен инде, ә вакыт уза, эчтәге бүреләр торган саен һөҗүмгә ныграк күчә баралар. Мөниржан, алган әйберләрен сумкасына тутыргач, тиешле акчасын түләп, чыгышка юнәлде. Кулы белән ишекне ачарга да үрелгән иде, Рәмзиянең:

—Мөниржан абый!—дип дәшүенә туктап калырга мәҗбүр булды.—Мөниржан абый,—дип кабатлады сүзен сатучы хатын,—үз вакытыгыз белән биредән тагын бер тапкыр урый алмассызмы икән?

—Ник?

—Иртәгә буш әрҗәләрне алырга киләчәкләр, шуларны тәртипкә китерергә кирәк иде. Ярдәм итмәссезме дигән идем.

—Белмим шул, кулдан килерме икән...

—Аның бер авырлыгы да юк. Тарала башлаганнарына кадак кына кагасы. Булдыра алмасагыз яки авырыксынсагыз бүтән берәрсенә әйтеп карармын.

—Мин бит баш тартмыйм.—Рәмзиянең йөзенә карау, тавышын ишетү Мөниржанга күптән татымаган бер рәхәтлек бирә. Дөресен әйткәндә, аның ашыйсы килүе дә басыла төшкән, бирдән инде китәсе дә килми башлаган иде. Тик менә, тик менә... җәрәхәте эшләргә ирек бирерме? Шулай да тәвәккәлләргә кирәк.—Коралларыгыз бармы соң?

—Аның өчен әлләниләр кирәкми, чүкеч белән кадак суыргычы җиткән. Алары бар.

—Алайса, хәзер үк башлыйм.

—Юк-юк, хәзер үк кирәкми. Иртәнге якта кеше күп була. Төштән соң, ярыймы?

—Ярый алайса, төштән соң килермен.

Кибеттән Мөниржан ашкынып кайтты. Бер кешегә күпме генә кирәк, озакламый тамак та ялгап өлгерде. Көтүгә чыкмагач, аның бүтән эше юк иде, түземсезлек белән төш җиткәнне көтә башлады.

Күктә кояш. Аккош каурыйларын хәтерләткән сыек болытлар чиксез зәңгәрлеккә аеруча ямь бирә. Кырда, бер-берсе белән узышып, тургайлар сайрый, иген кырларында бытбылдыклар кычкыра торгандыр. Басу-кырлар исенә төшүгә, ул авыл көтүен күз алдына китерде. Хәзер кай тирәләрдә йөриләр икән? Бу ике малайның көтүне суктырылган берәр иген басуына кертергә акыллары җитәрме? Малларны күбендереп кенә куймасалар ярар иде. Мал бит ул комагай, күпме ашаганын белми. Алдында булса, тәүлек

буе ашый, булмаса урлашу җаен карый.

Уйласаң, аның көтүдә бүген бер эше дә юк, ә җаны барыбер тыныч түгел. Бәхетсезлек килгәннән соң, ни булганын да, үзен алда ни көткәнен дә белми. Кесәсендә Әлмәт хастаханәсендә бирелгән белешмә бар барын.

Уйлары Рәмзиягә күчте. Ниндидер сөйкемле сөяге бар ул хатынның. Рәмзия исенә төшүгә, Мөнирҗан ирексездән өен күздән кичерде: пычрак яшәми ул. Аракы белән араны өзгәч, йортына өер-өер сәрхүшләр керми, таптаучы юк. Әмма дә ләкин хатын-кыз кулы тигән йортка кот куна, ул бөтенләй башка, төсе генә түгел, исенә кадәр икенче. Их, Гайния, дип көрсенде ул, беренче һәм бердәнбер мәхәббәтен исенә төшереп. Аның белән яшәгән санаулы көннәр һаман да сагындыра, югыйсә утыз елдан артык вакыт узган.

Менә хәзер дә ул күзенә бәреп чыккан тозлы сагышны кул аркасы белән сыпырып куйды. Ничекләр генә сагынсаң да, юксынудан башларыңны ташка орсаң да, Бәдертдин тавыннан тәгәрәп төшсәң дә, аны терелтеп, бәхетле көннәреңне кире кайтарып булмый югыйсә.

Рәмзия нәрсәсе белән Гайнияне хәтерләтә соң? Әһә, белде: елмайганда, бит очларында нәкъ Гайнияныкы төсле мәхәббәт уентыклары барлыкка килә икән бит!

Мөнирҗан, әйтерсең, кичен сөйгән кызы белән очрашырга барасы, кояшның төшкелектән авышуын түземсезлек белән көтте. Ул үзенең болай ашкынуына чиксез гаҗәпләнде, чөнки күптән, бик күптән, картлар әйтмешли, әлмисактан бирле, йөрәгендә мондый хиснең парә-парә китергәнен хәтерләми.

Вакытның тизлеге даими берәмлекләр белән үлчәгәндә барыбер. Ләкин син сонга калганда, ул бик тиз уза; көткән чакта исә, киресенчә, узмый интектерә. Минуты ай, сәгате ел, дип тиккә генә җырламаганнардыр.

Бүген вакыт галиҗәнапләре туктап калган иде. Югыйсә инештә сулар ага, фирүзә күктә болытлар сәяхәт итә, диварга элеп куелган сәгать бер хыянәтсез текелди бирә. Ниһаять, аның күкесе, оясыннан башын чыгарып, унике тапкыр аваз салды. Шушы вакыт аралыгы Мөнирҗанга гасырдан да озын тоелды. Әле бит унике тапкыр кычкырганнан соң да сәгатьтән артык көтәсе бар. Икенче китмичә торып, авылда кибет ачылмый.

Өр-яңадан кырынган Мөнирҗан тәрәзәдән күзен алмый—Рәмзия узганны көтә. Ниһаять, сатучы хатынның керт-керт басып үтеп киткәне күренде. Бәлки, хәзер үк чыгып, аны куып җитәргәдер? Юк, килешмәс. Рәмзия сүз әйтмәсә дә, кешеләр әлләни уйлар. Авыл бит ул мең күзле, мең колаклы, икене өч, өчне биш дип сөйләргә ярата.

Аның күңеле җырлый, ниндидер үзе дә аңламый торган билгесезлек өрфиясе белән өретелгән киләчәккә ашкына иде.

Тагын бер унбиш-егерме минутлап көтте дә, түземлеге төкәнде, сабыр канатлары сынды. Кулсыз җинен җилфердәтеп кенә кибеткә юнәлсә, кешеләр дөрес аңламас дип, кыршылып беткән сумкасын да беләгенә элде. Кеше сүзеннән ул юкка курыккан булып чыкты, чөнки юлда очраучы булмады, кибеттә дә Рәмзиядән гайре кеше юк иде.

Кибет хуҗасы аны елмаеп каршы алды:

—Килдегезме?

Мөнирҗан шаяртып җавап кайтарды:

—Кызлар чакырган җиргә бармаган егет егет буламыни ул!

—Бисмилла әйтеп башлыйк алайса!

—Күрсәтегез әйдә, кайда ни эшлисе?

Рәмзия аны складка алып кереп, тау кадәр өелгән аракы әрҗәләренә күрсәтте:

—Менә, Мөнирҗан абый, шушылар. Күрәсең, эш җитәрлек. Сез аларны тикшереп чыгыгыз инде. Арада төрлесе бардыр: бер-ике генә

кадак сугасылары да, ныграк төзәтәселәре дә. Гел тиясе юклары очраса да гаҗәпләнмәгез. Күпме өлгерә аласыз, шунысына рәхмәт—бар булганын иртәгә төяп җибәрербез. Калганы үз җае белән ремонтланыр. Хәзер мин сату залына чыгам, кирәк булсам, эндәшерсез. Менә чүкеч, менә кадак суыргычы, менә кадаклар—эшләгез генә.

Мөниржан аны сүзсез генә озатты да эшкә кереште. Җәрәхәтенә зыян китерүдән куркып, башта ул саграк кыланды. Тора-бара авыруы хакында бөтенләй онытты—аның кулы аша узган әрҗәләр артканнан арта барды. Рәмзия дөрес әйткән: аларның һәммәсен дә төзәтәсе юк, югыйсә эше болай ук тиз бармас иде.

Ара-тирә янына Рәмзия керә дә:

—Рәхмәт төшкере, ярдәмгә кеше эзләп күпме җәфаландым. Авылда шулай бит: кулыннан эш килердәе буш түгел, бушлары эшли башламас борын аракы буалар да, файдаларыннан зыяннары күбрәк була. Кайберләрен хатыннары җибәрми. Ирсез хатыннан шикләнүләредер, күрәсең. Чүкеч тотып әрҗә кадаклау хатын-кыз эше түгел инде ул,—дип рәхмәт укып чыгып китә.

Эш белән мавыгып, Мөниржан вакытның узганын сизми дә калган. Рәмзия:

—Мөниржан абый, бүгенгә җитеп торыр, кибетне ябам,—дигәч кенә туктады һәм үзенең арыганлыгын сизде, җәрәхәте дә сыкрый иде.

—Бик зур эшемне эшләдегез, сезне ничекләр бәхилләргә инде?—Рәмзия янчыгына үрелде.

Аның акча сузган кулын Мөниржан кире этәрде:

—Юк-юк, Рәмзия, мин бирегә акча өчен килмәдем, ярдәм итә алганыма шатмын. Өйдә бер эшем дә юк, каңгырап кына ятар идем. Чакыруың әйбәт булды әле.

Рәмзиянең дә сүзе сүз:

—Кешене бушка эшләтергә ярамый бит. Китап кушмый.

Мөниржанның күзләрендә шаян очкыннар уйнап алды:

—Яшьрәк чагым булса, суырып бер үп тә вәссәлам, дияр идем. Безнең яшьтә ни әйтергә дә белгән юк.

Рәмзия сүз эзләп кесәгә керә торганнардан түгел икән:

—Бер яшьлектә, бер картлыкта, диләрме әле? Аңа гына калса, үпкән-кочкан—җилгә очкан—гөнаһ саналмас.—Сатучы хатын, кызыл иреннәрен очлайтып, Мөниржанның бит очын җинелчә генә пәп итеп алды һәм шунда ук сумкасыннан кулъяулык чыгарып, иннек эзен сөртеп тә куйды.

—Берәрсе күрсә, йә әлләни уйлар...

Рәмзиядән аңкыган хушбуй исе, башка берни белән дә бутап булмый торган хатын-кыз исе кыргыйланып беткән Мөниржанның күңел офыгында еракта калган яшьлегенең яшене булып сызылып үтте. Менә-менә хәзер күк күкрәр кебек тоелды. Күптән, бик күптән аның тәненә хатын-кыз ирене кагылганы юк иде. Менә хәзер яңак очына тиеп кенә алды, башын әйләндерергә шул да җитте. Бу аның болай да әйбәт кәефен тагын да күтәреп җибәрде.

—Әллә кабатлыйсыңмы?

Рәмзия "сез" дип дәшсә дә, ул күптән "син"гә күчкән иде.

—Ошап киттемени? Тәмле әйбер күп булмый ул. Йә, ярар, әйдә миннән булсын изгелек...

Бу тәмле, татлы исерткеч мизгелнең озаккарак сузылуын теләп, Мөниржан күңелендә Рәмзияне кочагына кысып алырга дигән вәсвәсәле уй канат кагынган иде, кыюлыгы җитмәде. Ә Рәмзиянең үбүе бу юлы да яшен балкышыннан тизрәк булды. Ул аңына килгәндә, Рәмзия аның битен яулык белән сөртеп өлгергән иде.

—Гомер эчендә бер тапкыр кызлар үпте, анысының да эзе калмады. Кешегә сөйләсәм, ышанмаслар да инде.

—Ә сез кемгә сөйләп, кемне ышандырмакчы идегез?

—Син үзең соң кемнән куркып болай бик тиз сөртеп аласың?—Дөресен әйткәндә, ул бит Рәмзиянең Рәмзия икәнен һәм, кайдандыр килеп, кибеттә эшләвен, Ибрай Зәкиясендә фатирда торганын гына белә. Ничә яшьтә ул, кияүдәме, булып аерылганмы, балалары бармы—әнә шуның ише сораулар, нашатыр сипкәндәй, җанын бимазалый. Югыйсә иртәнге якта Рәмзия аның өчен гадәти бер сатучы гына иде ләбаса. Кинәт ул үзенә гаилә җылысы, җанын җылытыр, эчен бушатыр кеше җитмәвен сизде. Гомер узып бара, ә аның "әти" дип эндәшер, соң сулышында авызына бер кашык су салыр кешесе дә юк бит. Ник кенә туган соң ул? Хәзер инде ана бала турында хыяллану да көлке, ә җанына якын берәр хатын белән арканы аркага терәп, чөкердәшеп яшәү комачауламас иде. Ходай Тәгалә балаларын пар җенес итеп яралткач, бер уйласаң, ялгыз гомер кичерү яралтучыбыз алдында җинаятьтер дә. Эчү белән мавыгып, әлек бу хакта уйламаган, Гайния хәтере белән яшәде дә яшәде. "Үлгән артыннан үлеп булмый" дип, димләүчеләр дә булды, үзен-үзе хатынлыкка тәкъдим итүчеләр дә очрамады түгел. Срок артыннан срок алган, шешә артыннан шешә бушатып, эчүдән бушамаган адәмдә хатын кайгысы булдымы? Менә хәзер эчми, дөньялары яктырып китте, офыклары киңәйде, уйлары да бүтән төрле.

Мөнирҗан Рәмзиянең бер көлтә ачкыч белән кибетнең эчке һәм тышкы йозакларын бикләгәнен сабыр гына көтеп торды. Гайнияне хәтерләткәнгәме, бу хатын янында булу, аның ашыкмый- каударланмый гына хәрәкәтләнүен күзәтү, ни сәбәпледер, күңелендә рәхәт бер авырту уята, ул бу халәтнең озакка, бик озакка сузылуын теләи. Шул ук вакытта үзен: "Кара инде бу карт юләрне, унҗиде яшьлек кебек кыланмасаң!"—дип битәрләп алырга да онытмый.

Рәмзия ниләр уйлый торгандыр, анысы караңгы, Мөнирҗан исә көпә-көндез урамнан янәшә атлауларыннан да уңайсызлана, әйтерсең, авылның күзе аларда гына.

Кибеттән Мөнирҗаннарга кадәр кул сузымы кадәр генә ара—ике авыз сүз алышканчы, кайтып та җиттеләр һәм кое янында туктап калдылар.

—Менә, Рәмзия, минем гүрнәчәм шушы инде,—диде Мөнирҗан, борыңгылыгы йөзенә чыкса да, җиргә иңәргә өлгермәгән йортына күрсәтеп.

—Беләм, Мөнирҗан абый, беләм. Тагын әле мин сезнең коеның суы авылда иң тәмлесе икәнен дә беләм.

—Эчеп караганың бармы соң?

—Юк шул. Түбән очка кадәр биредән су ташымассың бит инде... Ә кунакка чакырып сыйлаучы булмады.

—Алайса, Рәмзия, мин сине бу судан чәй эчертми торып җибәрмим!—Мөнирҗан авызыннан бу сүзнең ычкынуына, үзенең кыюлыгына гаҗәпләнде. Ул инде, сатучы хатын хәзер үк китеп барса да, үпкәләмәс иде, ләкин Рәмзия:

—Ә нигә эчмәскә!—дип көлеп җибәрде.—Өйдә ирем, балаларым юк, каенанам көтеп тормый, кунакка чакыралар икән, ник кермәскә?! Эшләгәнегезгә акча да алмадыгыз, чәй куеп эчерсәм, бурычым бераз кимемәсме!

Ул Мөнирҗан ачкан капкадан кыю адымнар белән эчкә узды һәм, гаҗәпләнеп, туктап калды:

—Әнекәйгенәм лә! Ишек алды ямь-яшел,—Рәмзия соклануын яшерә алмады.—Зәкияттәйләрдә мондый яшеллек юк, маллары, кош-кортлары таптап бетерә.

—Мин бит мал-туар асрамыйм, ничек үссә, шулай тора бирә.

—Монда яланаяк йөрүләре рәхәттер!—Рәмзия туфлиләрен ишек төбенә салып куйды да шәрә тәпиләре белән уйдык-уйдык та, аралашып та үскән бәпкә һәм каз үләннәре, сарут өстеннән атлап китте. Меңъяфрак, сукыр кычытканнарны иелеп иснәде, койма буен баскан канлы үләнгә карап торгач, ак әрем өзеп алды.

—Ишек алды түгел, дару үләннәре питомнигы икән монда сезнең!—Ул хисләнгән иде һәм шул сәбәпле тагын да мөлаемланып, күркәмләнеп киткәндәй тоелды. Шунда аның күзе бакча ягында урман булып утырган бөтнеккә төште.

—Әрем белән чәй эчәләрме, белмим, ә бөтнекле чәйнең һәркемгә дә шифасы бар,—дип, кулындагы әремен ташлады һәм бөтнек янына атлады, өзәргә иелде. Ул иелүгә, күлмәк итәге күтәрелеп, ап-ак ботлары ачыла төште. Бу күренештән әле сәламәтлеге нығып җитмәгән Мөниржанның башы әйләнеп китте, тыны кысылды. Егылып китмәс өчен, ул бакча коймасына тотынды һәм күзләрен йомды. Ачканда, Рәмзия карлыган яфракларын өзә иде.

—Ярыйдыр бит?

—Куагы белән кертеп биримме әллә?

—Кирәкмәс, иртәгә ахырзаман түгелдер ич? Тамагым кипте,кереп чәй кайнатыйк.

Йорт эченә уздылар. Рәмзия керә-керешкә өйгә бәя бирде, ләкин берни дә әйтмәде.

—Чәйне ничек кайнатабыз?

—Мин үзем генә чакта газда кайната идем, теләсәң, электр самавыры бар...

—Бармы? Чәйнектәгесен эчеп туйган, булгач-булгач, самавыр кайнатыйк. Тәмлерәк тә булыр. Авылның иң тәмле суыннан куябыз бит.

Чиләкләрендә кичәге суы булуга карамастан, кунагын сыйлар өчен Мөниржан яңа тарткан су алып керергә булды. Гүя ул яшьлегенә кире кайтты: аяклары җиргә тисә тиде, тимәсә юк—коедан "ә" дигән арада бер чиләк су алып керде.

Самавыр кайнаган арада, өстәлгә Мөниржанның хәзинәдә булган нигъмәтләре янына Рәмзия дә сумкасыннан үзе белән алган тәм-томнарын өстәгәч, табынга хәйран гына ямь керде. Өй эченә рәхәт самимилек инде.

Чынаякларга чәйне Мөниржан үзе агызмакчы булган иде, Рәмзия:

—Куегыз инде, Мөниржан абый, хатын-кыз барында,—дип чәй ясарга керешге.

Чәй чыннан да бик тәмле идеме, әллә әдәп йөзеннәнме, Рәмзия аны мактап туялмады:

—Чәйнең тәме судан килә.

Ялгызың чәй эчүгә караганда бергә-бергә гөрләшеп утырулары күңеллерәк. Табын янында Мөниржан күптән кичермәгән рәхәт хисләр татыды. Кызганыч, бу рәхәтлек артык озакка сузылмас шул.

Сүзгә сүз иярә. Рәмзиянең дә күңелен бушатасы килдеме, Мөниржанның бәхетеннән, китәргә ашыкмады. Баштарак кулындагы сәгатенә күз салгалый иде, тора-бара аны да онытты.

Карап торышка уенчак, гел бәхет диңгезендә генә коенган кебек тоелган бу хатынга да язмыш аз күрсәтмәгән икән. Кияүгә чыгып, ун ел гына бергә яшәп калганнар, йөрәк өянәгеннән ире китеп барган. Улын ялгызы үстергән, бүтән кияүгә чыкмаган.

—Ә улың кайда?—дип сорады. Бу соравын биргәндә, кунагының авыр ярасына кагыласын уйламаган иде, Рәмзиянең чырае күләгәләнеп калуын күргәч, ярамаган сүз ычкындыруын аңлады.

—Әй, Мөнирҗан абый, хәрби училищега барам, офицер булам дигәч, каршы төшмәгән идем. Училищега да керде, тәмамлауга өйләнде дә. Маржага. Өйләнгәч тә кайтып атна-ун көн торганнар иде, менә өч ел инде бер хәбәре юк, хат та язмый, кайтмый да...

—Үзен... үзен хат язганың бармы?

—Нишләп булмасын. Баштагы частена язган идем, бүтән частька күчерелде, дигән җавап алдым. Нинди частька икәнен сорап язган хатымны бөтенләй җавапсыз калдырдылар. Хәзер менә белмим, әллә дөньяда юк, әллә маржа килен араны өздерде. Маржага өйләнүен башта ук өнәмәгән идем, бала-чага синең сүзенә карыймыни ул!..

Рәмзия күзенә бәреп чыккан яшьләрен кульяулыгы белән сөртеп алды.

—Сез, Мөнирҗан абый, гафу итегез инде бу исәр хатынны. Танышканга бер көн дә юк, берәүгә сөйләмәгән серләремне сезгә ачып салдым. Бераз җиңел булып китте.

—Зыян юк. Кирәкмәгән сорау биргәнгә, син үзең мине кичер. Белмәдем.

—Ялгызлык туйдырды. Бүген ничектер бушанасым килде. Әллә суыгыз бик килеште инде. Сез мине, мөгаен, тел бистәсе, бер җилбәзәк хатын дип уйлыйсыздыр...

—Юк-юк, икмәктер, андый уйның башыма кереп тә чыкканы юк. Киресенчә, синең монда булуыңны, табынымны бизәп утыруыңны күкләр тарафыннан җибәрелгән бер бүләк дип куанып утырам.

—Чынлапмы?

—Ант әгәр.

Икесе дә калган чәйләрен эчеп бетерде. Өйдә тынлык урнашты. Бераз шулай сүзсез утыргач, Рәмзия кыяр-кыймас сорау бирде:

—Киштәдәге әнә теге гармунда кем уйный иде?

—Тальянны әйтәсенме? Аз-маз мин үзем тарткалый идем.

—Хәзер дә уйнагыз әле!

Мөнирҗан аптырап калды. Дөресен генә әйткәндә, ул мондый сорау булыр дип көтмәгән иде.

—Онытылгандыр инде, күптән кулга алган юк.

—Белгән нәрсә тиз генә онытылмый ул. Ялындырмагыз, уйнагыз инде!

Рәмзия шулкадәр инәлеп сорады ки, ир-ат күңеле түгел, Антарктида бозы да эрер иде.

Мөнирҗан гармунының җәй буена җыйналган тузанын сөлге белән сөртте.

Өйрәнелгән гадәт буенча бармаклары гармун телләреннән йөгереп үтте. Телләр, хуҗаларын таныганлыкларын белдереп, куанычлы аваз чыгардылар да тынып калдылар.

—Ни уйнарга боерасыз?

—Күңелегез теләгәнне уйнагыз...

Күрек тартылган уңайга, бармаклар гармун телләре аша йөзә. Икеөч көйдән соң Мөнирҗан "Сибелә чәчем" көен уйный башлаган иде, көтмәгәндә Рәмзия җырга кушылды.

Сибелә чәчем, сибелә чәчем,
Сибелә чәчем, тарала.

Аның тавышы матур, ягымлы һәм күкрәгенең түреннән чишмә кебек ургылып чыга иде.

Йә утка сал, йә суга сал,
Йә кайгымнан арала.

Соңгы ике юлны тагын бер тапкыр кабатлаганнан соң, Рәмзия, үзен тыя алмыйча, дерелди башлады һәм күзләренә бәреп чыккан яшьләренә ирек бирде. Күрәсең, җырның көе дә, сүзләре дә сагышлы хатынның җанын актара иде.

—Их, Мөнирҗан абый, уйнап та куясыз икән! Сезгә артист кына буласы калган.

—Сәхнәдә түгел, яу кырында артистланырга туры килде шул безгә...

Тынычлана төшкәч, Рәмзия тагын бер-икене җырлады. Мөнирҗанның өендә моң йөзде, ярты гомеренә якынын казна йортында уздырган ирнең күңелендәге хисләр өермәгә әверелде. Түзмәде, җырга ул да кушылды.

...Рәмзия кайтып тормады. Иртәгәсен уртак түшәктә уянып киткәч, бер-берсеннән кыенсынып, күпмедер вакыт сүзсез яттылар. Ниһаять, Мөнирҗан Рәмзиягә:

—Мин сине көтеп яшәгәнмен икән!—дип пышылдарлык көч тапты.

—Күптән моның кадәр тәмле итеп йоклаганым юк иде. Рәхмәт.

—Рәмзия, китмә, кал!

—Миннән туймадыңмыни әле? Бик үтенеп сорагач, уйлап карыйсы булыр.

Бер-берсенең тән җылысын, җан җылысын тоеп янәшә ятуы икесенә дә рәхәт иде. Ләкин август кояшы һаман саен югарырак күтәрелә, тәрәзә аша күзләргә төшә, борынны кытыклый; әй инсаннар, торыгыз, көн башланды, сезне эш көтә, ди.

Торырга кирәк икәнен Мөнирҗан да белә, ләкин аның бу мизгелнең бүтән кабатлануына ышанычы юк, шуңа күрә ләззәтле-сәгадәтле минутларны мөмкин кадәр озаккарак сузасы килә. Дөресен әйткәндә, янәшәсендә Рәмзия атлы сөйкемле затның ятуына ул әле һаман да ышанып бетми—көтелмәгән төшнең дәвамыдыр кебек тоела. Әлеге халәтнең чынлыгына ышанырга теләгәндәй, ул иреннәре белән Рәмзиянең алкасына, колак яфракларына кагылды һәм хисләр чоңгылына очканын сизми дә калды: кояш кинәт берничәгә әверелде, борынгы йортның карала төшкән түшәмендә көпә-көндез йолдызлар бии башлады. Рәмзиягә дә, Мөнирҗанга да сулар өчен һава җитми. Алар тирән итеп сулыш алгач та, әле генә упкын белән кыя арасында уйнаган дөнья тынычланып калды. Мөнирҗан чытырдатып күзен йомды.

Ул шул хәлендә озак яткан, бәлки йоклап та киткән булыр иде, караватның ыңгырашканына күзен ачып карыйсы итте: Рәмзия киенә иде, Мөнирҗанның карашын тоеп, уңайсызлана калды; кулы белән шәрә күкрәкләрен каплап:

—Карамый тор, зинһар!—дип үтенде.

Ул моны шундый итеп әйтте, ымсындыргыч сыннан күзен аласы килмәсә дә, Мөнирҗан карашын читкә борырга мәҗбүр булды. Кызык инде бу дөнья, бигрәк тә аның хатын-кыз дигән заты: әле генә түшәк бүлеште, хәзер үзенә карарга да ярамый. Гайниясе дә шулай оялчан иде бит.

Гайния исенә төшүгә, йөрәге сызлап куйды: ул аңа хыянәт итте түгелме соң? Бәлки җиде кат күкләр аша хәләленең чит хатынны назлаганын ул карап, күзәтеп, рәнҗеп яткандыр. Ә бәлки рәнҗемәгәндер дә. Ник дисәң, Аллаһы Тәгалә адәм баласын дөньяга үзеннән соң дәвам калдырыр өчен яралткан. Ә Мөнирҗан? Моңа кадәр аның ике генә хатын-кыз белән якын мөнәсәбәткә кергәне булды: Сәлимә һәм Гайния. Рәмзия—өченчесе. Ләкин... ләкин шунысы бар: ул фронттан кайткач, үзен әгәр Гайния чит итмәгән булса, Сәлимә кочагына керер идеме әллә? Юк! Сәлимәнең үзеннән

көмәнле икәнен белгән булса, Мөниржанның йөрәге ни эшләр иде икән? Белмәве аның бәхетенәдер.

Гайния белән юклыкта, хәерчелектә булса да уздырган бәхетле көннәрен, ятарга өлгермәс борын торырга вакыт житкән төннәрен, күпме генә сагынсан, юксынсан да, хәзер кире кайтарып булмый. Узган гомер—аккан су. Үткән белән мәңгелек хәтер чоңгылында гына очраша ала. Гайниянең фажигале үлеменнән соң ул бит ни айнык көе, ни салган баштан бер генә хатын-кыз янына да якын бармады. Төрмәсе төрмә инде, әллә ирекккә чыккач, аны тансыклаган, назлы кочакларына алырга әзер торучылар булмагандыр дисенме? Жаны теләмәгәч, күнеле якын итмәгәч, хайвани ихтыяжны канәгатьләндерү өчен генә якынлык кылуны ул аңлап бетерми, вөжданы кабул итми. Югыйсә аның да яшь чаклары, гайрәтле чаклары бар иде. Хәер, әле дә гел үк төшеп калганнардан түгел икән. Тик менә тәнендәге жәрәхәте генә төзәлеп бетмәгән.

Рәмзия исә бөтенләй башка очрак. Ул—язмыш тарафыннан ана сонлап бирелгән бүләк. Тик... Язын төшкән кырау кебек, ай күрде, кояш алды гына булып чыкмасмы әлеге сөенеч? Ул шунысыннан курка. Юк, Гайния ана рәнжемәс. Хәзер инде ана бала турында хыялланырга язмаган, әмма һәркемгә тиешле бәхетнең бер кыйпылчыгы кагылуын күпсенмәсеннәр.

—Торасынмы, чәй кайнады!

Мондый да кадерле вә ягымлы тавышны ишетмәгәненә биш былтырдыр. Чыннан да ана дәшәләрме, әллә берәрсе белән бутыйлармы?

Каршысында елмаеп торган Рәмзияне күргәч, үзенең һаман да түшәктә йокы симертеп ятуын уйлап, хәтта кыенсынып та куйды. Ул бит мона кадәр үз көнен үзе күреп өйрәнгән кеше—жәйнең озын көннәрендә, көтүгә сонга калмас өчен, иртәнге сәгать өчтә сикереп тора иде. Ләкин бу юлы ашыкмады. Бераз арыганлык таралган тәненең түшәктән аерыласы килмәде.

Сәгать ничә икән сон? Мөниржан өстәмә йөк итеп иске йозак таккан герен вакытында тартып куйсаң йөрүен дәвам иткән күкеле сәгатькә карады: аның телләре алтыны күрсәтә иде. Шуны гына көткәндәй, ишектән башын чыгарып, күке алты тапкыр аваз салды.

Рәхәт итеп бер киерелгәч, Мөниржан сикереп торды. Әмма үзенең анадан тума икәнен күрү аны юрган астына кабат чумарга мәжбүр итте.

Оста кеше балтадан да аш пешерә. Ихтимал, Рәмзия шундый осталарның берседер. Үзенең көн саен утырып ашый торган өстәленә карагач, Мөниржанның күзләре биеште: булары аңкып торган тары боткасы һәм майда кыздырылган ипи телемнәре авызыннан сулар китерде.

Аның өстәлгә текәлеп карап торуын Рәмзия үзенчә аңлады:

—Ни тапсам, шуны пешердем, гаепләмәссен инде. Уятып сорарга кызгандым, бигрәк тәмле йоклый идең.

—Ә мин синең торганыңны сизмәгәнмен дә...

—Зыян юк. Кил әйдә, су салып торам, юынып ал.

Йа ходай, йа раббым, боларның барысы да өнме сон? Әллә, торып аягына басуына карамастан, төшләнә, саташа гынамы?

Табын янында Рәмзия пошаманга төште:

—Зәкияттәй күзенә ничек күренним? Нәрсә дип, кайда кундым дип әйтим?

—Юкка көяләнмә, Рәмзия,—дип Мөниржан аны юатырга ашыкты.—Беренчедән, синең балигъ булганыңа биш былтыр, үзенчә йөрергә хакың бар. Икенчедән, син аның килене түгел. Өченчедән, кунарга көн саен кайтам, дип килешү төземәгәнсеңдер бит?

—Төзүен төземәгән дә. Тик барыбер дөрес эшләмәдем. Ул бит борчыла торгандыр, эзли дә чыккандыр...

Рәмзия ашыга-ашыга савыт-сабаларны жыештырырга керeште.

Мөниржан шунысына игътибар итте: хатын-кыз кулы тигән савыт-саба бөтенләй икенче төрле шалтырый икән бит.

Ул үзе Рәмзиядән күзләрен алмый, үзенең исә күңелен шикләнү корты кимерә: менә хәзер ул китәчәк. Кире кайтырмы соң? Әллә ишекне бүтән ачмаска дип ябармы?

Рәмзия ниләр уйлый торгандыр, көзге каршысына басып төзәтенә иде. Бу йортның кадим заманнардан бирле хатын-кыз чырае күргәне юк. Ә ир-атка исә, каршысына басып кырынмаса, көзгенең хаҗәте юк, поты бер тиен.

Мөниржан менә хәзер Рәмзиягә бик мөһим сүз әйтергә тиешлеген аңлады. Тик ни дияргә? Күңелендә вулкан кебек кинәт уянган хисләрне ничек итеп аңа аңлатырга? " Син миңа ошыйсың, мин сине яратам!" яки "Мин синнән башка яши алмыйм" дияргәме? Унисигез-егерме яшьтә сүз эзләп кесәгә керүче сирәк. Алтмыштан узган ир ни эшләргә, ни дияргә тиеш? Мондый сүзләр сөйләп өйрәнмәгәч, мәхәббәт сүзләре әйтергә аның бит әле теле дә әйләнергә тиеш.

Барысы да көтелмәгәнчә килеп чыкты. Сүзләр эзләгән чакта, ул өенә ямь, нур өстәгән кибетче хатынны кочагына алганын сизми дә калды:

—Минем сине җибәрәсем килми!

Пышылдап кына әйткән сүзләр Рәмзиянең колак яфракларын пешергәндәй итте. Ул кызарып чыкты, ләкин үзен бик тиз кулга алды.

—Кал, дип тә әйткәнең юк!

—Менә хәзер әйтәм: кал! Үтенеп сорыйм: кал!

—Болай ашыгып кына хәл итеп ялгышмабызмы соң? Без бит синең белән дуамал яшьләр түгел, акыл белән уйларга, җиде кат үлчәп, бер кат кисәргә кирәк.

—Беләсеңме, Рәмзия, Гайниясез калганнан бирле, бер хатын-кызга да күзем төшкәне юк иде. Ә сине күрү белән ошаттым. Телисеңме, бүген үк сәвиткә барып язылышып кайтабыз! Әгәр инде дөньяның бер гарибе димәсәң...

—Ашыкмыйк. Ашыккан—ашка пешкән. Кочаклашып йоклау бер нәрсә, без бит әле бер-беребезне юньләп белмибез дә. Күрдем дә капландым булмасын иде. Ярый, кибетне ачканчы, мин Зәкияттәй янына кайтып килим әле. Ул әйбәт апа, ләкин милиция аша ил буйлап эзләтүе бар.

—Ник алай дисең? Шулай бик куркыныч җинаятьчемени син?—Мөниржанга кызык булып китте.

—Юк ла! Әлләниләр уйлама. Минем бит аңа әйтмичә кайтмый калганым юк иде. Борчыла торгандыр...

Мөниржанга:

—Үзең беләсеңдер,—диюдән бүтән чара калмады.

Кулыннан килсә, ул Рәмзияне беркая да: Зәкия карчык янына түгел, хәтта эшкә дә җибәрмәс иде.

Бәхетнең ни икәнен оныткан һәм бүтән аңа инде өметен өзгәндә генә, Рәмзиянең очравы, аралары якынаеп китүе, исенә төшерүгә битләрен яндыручы, йөрәген сикертүче бүгенге төн—йа Раббым, кызган, аны бәхетеннән аерма!

Күңеленнән шушы теләген тәкрарлап, Мөниржан Рәмзияне капкага кадәр озата чыкты:

—Мин сине көтәрмен, төшкелеккә монда кайт!

Җавап урынына Рәмзия дугаланып килгән кашларын сикертте һәм, Кызыл тау артыннан моннан ике сәгать элек күтәрелгән кояшка тиң елмаю калдырып, Түбән очка тырт-тырт атлап китеп барды.

Рәмзиясез калган йортка аның керәсе килмәде. Яраткан хатын-кызың булмаса, моңа кадәр яшәгән менә дигән йортың да шәме сүнгән кара мунчага охшап кала икән.

Кара мунча... Шунда беренче тапкыр Гайния белән мунчага барулары исенә төште. Никаһтан соң инде берничә төн уздырсалар да, бер-берсеннән оялып, адәм рәтле юынмыйча да кайтканнар иде алар. Бүген дә мунча керсән иде! Ә нигә кермәскә ди—урам аша күршеләре Гариф абзыйларның ак мунчалары менә дигән гүрнәчә—хан сараена алыштыргысыз: кызу салсаң, чыжлап тора, утырып юынырга да, чыгып хәл җыярга да урын җитәрлек. Күрше хакы—алла хакы диптер инде, яккан мунчаларына Мөнирҗанны дәшми калганнары юк диярлек. Авырып күпме больницада ятты, бит-кулны юу белән генә түгел, татарга мунча кирәк, ул мунчасыз тора алмый.

Бәлки кемдер ягып чакырганны көтәргәдер? Юк, булмый. Ул бит рәхәтләнеп суын ташып, җитәрлек кадәр утынын илтеп, мунчаны үзе дә яга ала. Мондый бөркү көндә эштән соң юынып чыгарга, шәт, Рәмзия дә каршы килмәс.

Башына мондый әйбәт фикер килүгә шатланып, ул Гариф картларга ашыкты. Бәхетенә күрә, өйләренә ук кереп торырга туры килмәде: Гариф карт белән Бәдриямал карчык, чөкердәшә-чөкердәшә, мунча себеркесе бәйлиләр иде.

Мөнирҗан йорт хуҗасы белән кул биреп, хуҗабикә белән баш иеп исәнләште.

—Себерке бәйлисез икән...

—Әйе шул, быел соңгарак калынды. Үзебез бара алмагач, малайның вакыт тапканын көтәргә туры килде. Кичә энгер-меңгердә кайтарып бушаткан иде, бәйләп бетерә алмадык, бүгенгә калды. Зыян юк, төн салкынча иде, кызышырга өлгермәде.

—Әйдәгез, мин дә бәйләшим.

—Кирәкми,—дип аның ярдәмен күршесе кире какты.—Карчык белән икебезгә вакыт уздырырга менә дигән шөгыль. Югыйсә эшсезлектән интегәбез. Күптән күренгәнең юк, авырып киттеңме әллә? Көтүне дә бүтәннәр көтте...

—Булды инде, булды, Гариф абзый, айга якын Әлмәттә больницада яттым. Мунча сагындырган, якмыйсызмы икән дип белешергә кергән идем.

Картлар сүзсез генә бер-берсенә карашып алдылар.

—Бүген генә ягу исәптә юк иде юклыгын... Кирәк булса, ягабыз аны. Ник якмаска! Мунча үзебездән дә артмас, карт сөяк җылы ярата. Шулай бит, карчык?

—Шулай, карт, шулай,—Бәдриямал карчык иренең сүзен җөпләп куйды.

—Алайса, күрше, мин хәзер утын алып киләм дә су кертәм.

—Утын дип кеше көлдермә, Мөнирҗан. Утын инде әллә кайчан кертелгән, су савытлары да тулы, шлангыдан гына агыздым. Бөтен нәрсәсе әзер, кабызасы гына калган. Җил юк. Хәзер төртеп җибәрәм, хәзер. Син тынычлап кына ят, мунча җитешкәч, үзем кереп әйтермен.

Мөнирҗан көннең җилсез булуына куанып куйды. Авыл халкы сак, уткүздән куркып, мунчаны җилсез көндә генә, анда да таң белән ягу хәстәрен күрә. Гариф абзый озак еллар янгын сүндерүче булып эшләде, бу мәсьәләдә бик тәкъва кеше.

Гариф карт кулындагы себеркесен кысып бәйләде дә җитез адымнар белән мунчасына табан юнәлде. Мөнирҗанга исә өенә чыгудан бүтән чара калмады.

Инде ни эшләргә? Ул үзенең Рәмзияне өзелеп сагынганын аңлады. Тик әле ул төш җитмичә торып кайтмас. Утырткан яшелчәсе, карыйсы кошкорты, мал-туары юк. Бу вакытны ничек уздырырга?

Коймага сөялеп, ул озак кына бакчасындагы шомырт агачына карап

торды. Эре-эре шомыртлар нык пешүдән шәмәхәләнә төшкән, тик тәлгәшләре пәрәвез белән капланган. "Ә минем тормыш тоташ пәрәвездән тора." Үзе өчен кинәт ясаган бу ачыш-чагыштыру аның йөрәген телеп үтте, күңеле үкенеч ачысы белән тулды. Күпме генә кешечә яшәде соң ул? Әчеп һәм төрмәдә уздырган гомерен яшәү дип әйтергә ярыймы? Соң булса да, ун булсын, Аллаһы боерса, калган көннәрен кешечә уздырыр. Ул бит хәзер бөтенләй башка кеше, аның бит хәзер Рәмзиясе бар...

Гариф абзыйларның мунчасыннан чыккан төтенне күрүгә, Мөнирҗанның уйлар өере тарала төште. Тагын берничә сәгатьтән яңа бәйләгән каен себеркесе белән чабыну ләззәтен тоеп, ул елмаеп куйды. Һәм план корды: Рәмзия белән чәчләре чәчкә бәйләнсә, мунча салырга! Мунчасыз татар—татар түгел. Ялан-ялан кеше мунчасына өметләнү килешми. Яшь булмасалар да, мунча салырлык кына рәтләре бардыр әле.

Башына килгән шушы уйдан канатланып, ул мунча салырга урын сайларга кереште. Бура бурап утыртып кую гына түгел, мунча өчен уңайлы урын табарга кирәк. Абзар-курага якын куярга ярамый, ут-күз чыгуы бар. Бәрәңге бакчасы артык ерак—су ташый башласаң, кәҗә маең чыгар. Иң яхшысы, төпләп ыргытырга кул җитмәүдән генә утырган ике төп карт карлыганны алып атарга да шул тирәне чамаларга кирәк. Барыбер адәм-рәтле җимеш биргәннәре юк. Рәмзия ни дияр тагын. Юк-юк, ул да ошатыр бу урынны. Ә ошатмаса? Ул чагында күз күрер.

Бүген көн кызу булырга охшаган. Кыйбла якта күк йөзе чип-чиста. Күктә Рерих, Куинджи картиналарын хәтерләткән җете зәңгәрлек. Мөнирҗан аларның кайбер картиналарын "Огонек" журналында күргән иде. Көнчыгышта да болытлар юк. Бары тик көнбатышта гына ике болыт, кояшны көтеп, офыкта саргая. Кояш анда тиз генә барып җитмәс, аларга озак саргаерга туры килер, чөнки әле төш тә җитмәгән, әле сәгать ун гына тулып килә. Рәмзия кайтырга да (әгәр кайтса) сәгатьтән артык вакыт бар. Син көткәндә вакыт бөтенләй акрын уза шул. Рәмзия ни эшли, хәле ничек икән? Ул бит төнлә дә адәм рәтле йокы күрмәде, өстәвенә иртә торды. Нинди табын хәзерләгән иде бит!

Ихатасында Мөнирҗан ары сугылды, бире сугылды, үзенә шөгыль тапмады. Тукта, ник әле ул кибеткә бармый? Кичә өлгерә алмый калган әрҗәләрне төзәтсә, файдасы да тияр, вакыт та узар. Рәмзия дә күз алдында гына булыр...

Катгый карарга килеп, ныклы адымнар белән ул кибеткә юнәлде. Чирәмлектә чемченгән оя-оя казлар, ризасызлыкларын каңгылдашып белдереп, аңа юл бирде. Кемнендер кикрикле ата казы, ысылдап, артыннан бара башлаган иде дә, Мөнирҗанның курыкмаганын күреп кире борылды. Язын алай итмәс иде, бәбкәләре зурая төшкәч, ата казларның да усаллыгы кими шул.

Кибет ачык. Анда берәү дә юк. Кулыңа эләккән нәрсәне ал да чыгып тай. Күрүче, белүче юк. Бу нинди гамьсезлек? Рәмзия шундый бер гамьсез, ачык авыз хатын микәнни? Юк, нәрсәдер бар монда...

Ул, Рәмзиягә дәшмәкче булып, авызын ачкан иде, кичә үзе әрҗәләр төзәткән склад ягыннан ниндидер тавыш ишетелгәндәй булды. Чыннан да анда кемнәрдер дөбер-шатыр килә иде.

Кинәт аның колагына Рәмзиянең үзәк өзгеч тавышы ишетелде:

—Ярдәм итегез!

Әлеге тавышны ишетүгә мәче җитезлеге белән тавыш килгән якка ташланды һәм, склад ишеген керүгә, үз күзләренә ышанмыйча, бер мәлгә туктап калды: ниндидер таныш булмаган ир Рәмзияне әрҗәләр арасына кыскан да кочаклап үбәргә маташа. Рәмзия җан-фәрманга карыша, ләкин аю кебек таза ир аның чыр-чу килүен, чәбәләнүен бар дип тә белми.

Арткы ишек ачык иде. Анда йөк машинасы торганны күргәч, бу оятсызның әрҗәләр төяп алып китәргә килгән шофер икәнен аңлады.

—Жибәр, кабахәт!

Күзенә ак-кара күренмәгән Мөниржан кулына эләккән беренче әрҗә белән Рәмзиягә кул сузучы адәм актыгына алып орды. Кемнеңдер үзенә һөҗүмен көтмәгән ир чайкалып китте һәм, аягында басып калалмыйча, эскертләп өеп куелган аракы әрҗәләренә барып сыланды. Әрҗәләр ишелде, алар белән бергә машина шоферы да жир идәнгә тәгәрәде. Нинди куркыныч янаганын төгәл генә аңлап бетермәсә дә, үз-үзен саклау инстинкты аны йөзтүбән капланып ятарга мәжбүр итте.

Мөниржанның күзен кан басты. Кулындагы әрҗә белән теге жирбитне дөмбәсләвен дәвам итте.

Ярый әле Рәмзия аңына килеп өлгерде:

—Мөниржан, тукта , үтерәсең бит!

Рәмзиянең бу сүзе аны айнытып жибәрде, чираттагы тапкыр сугарга күтәрелгән кулы кире төште. Килеп сарылган Рәмзияне кочагына алды. Жирдә әҗәлен көтеп яткан ир, унайлы форсатны чамалап, тизрәк чыгып сызу жаен карады. Күз ачып йомган арада, ул машинасын үкертеп китеп тә барды.

Мөниржанның жәрәхәтеннән киеме аша кан саркып чыкты.. Күрәсен булса, күркә талап үтерер диләр. Тәки терелеп бетәргә ирек бирмәделәр. Яраны аракы белән юып, Рәмзия чиста чүпрәк белән бәйләп куйды.

—Нишләп бәйләнде ул сиңа?—Мөниржан сорауны кабыргасы белән куйды.

Мескен хатын бу сорауга ни дип жавап бирсен? Ир-атларның хатын-кызга ни дип бәйләнгәнен Мөниржан үзе белмимени? Жир шарында көн саен, сәгать саен ничәмә-ничә хатын-кыз көчләнә, сексуаль маньяклар тарафыннан һәлак ителә. Бу хакта гәжит-журналлар яза, радио-телевидение хәбәр итеп тора.

Кибетне бикләп, алар кайтырга чыкты. Көннең матурлыгы тоныклана төшкән, иртәнге күнел тантанасы югалган иде. Өйгә кергәч, Рәмзия, иртән үзе жыештырган караватка капланып, үксеп еларга кереште. Бераздан башын күтәреп, яшьле күзләрен Мөниржанга төбәде:

—Ни өчен шулкадәр бәхетсез соң мин?!

Мөниржан дәшмичә калды. Ә нәрсә дип әйтсен ул? Үзенең аңа караганда да бәхетсезрәк икәнен әйтүдән Рәмзиянең хәлен жиңеләер дисеңме?

Сүзсез генә чәй эчтеләр дә, шешенгән күз кабакларын салкын су белән юып, Рәмзия кибетенә китте. Мөниржан аны озатырга чыкмады, ятып калды: жәрәхәте үтереп-үтереп сызлый иде. Маңгаена бәреп чыккан тир тамчыларын кул аркасы белән сөртеп, ул күзләрен йомды. Ләкин, никадәр генә тырышмасын, тиз генә йоклап китә алмады: тормыш мизгелләре, кинодагы кадрлар сыман, күз алдыннан узды. Тора-бара йокы барыбер үзенекен итте, Гариф карт кергәндә, ул, иреннәрен яртылаш ача төшеп, төшләр күрә иде инде. Шуңа күрә аның:

—Күрше, мунча өлгерде, барып иркенләп юынып кайт,—диюен чынга алмады, борылып ятты.

Гариф карт кабат эндәшергә өлгерә алмый калды, ишектән башта Рәмзия, аның артыннан ике милиционер килеп керде. Кергән унайга берсе карават янындагы картны кырыйга этәреп, Мөниржанның исән кулына ябышты:

—Тор!

Берни аңламаган Мөниржан аягына басты, бары шуннан соң гына йокылы күзләрен ачты һәм кулыннан тартучының кем икәнен абайлап алды: болар тикмәгә килмәгән. Ни булды икән?

—Гражданин Исламов син буласыңмы?
—Мин. Ә нәрсә?
—Сораулар бирмәскә! Тизрәк җыенуыңны бел! Безнең белән китәсең!
—Кая?
—Атаң башына!
—Ни өчен?
—Анысын баргач әйтерләр...
Берни аңламаган Гариф карт сүзгә катышты:
—Кая алып китәсез? Мин бит аңа мунчага әйтергә кергән идем...
Бу сүзне ишеткәч, ментлар шаркылдап көлде:
—Син бер дә борчылма, абзый кеше, мунчаны ул бүтән җирдә керәчәк. Бездә аның өчен махсус сауна әзерләнгән. Йөз дә ун градуслы... Ха-ха-ха!
Милиционерлар, барысы да чыгып беткәч, Мөнирҗанга ишекне бикләргә ирек бирделәр һәм, ашыктырып, капка төбендәге УАЗ машинасына табан алып киттеләр. Рәмзия Мөнирҗан янына омтылды, ләкин өлгерә алмады—кузгалып киткән машинаның әрсез тузаны аның яшьле күзләренә килеп сыланды.
Тукмалган шоферның ике кабыргасы сынган икән. Суд булды. Әмма судта Рәмзиянең Мөнирҗанны яклап сөйләгәннәрен игътибарга алмадылар—озакламый алтмыш яшьтән узган Мөнирҗан Исламовны сигезенче тапкырына казна ипие ашарга җибәрделәр. Аның бу бәлагә таруында үзен гаепле санаган Рәмзия шул хәлдән соң, йөрәге януына түзә алмыйча, Әскәйдән генә түгел, районнан ук күчеп китте.

* * *

Бәндәне ризык йөртә. Менә бит, җыяр ризыгы бетмәгәч, Мөнирҗан, казна йортыннан исән-сау кайтып, капка баганасына сөялде:
—Исәнме, туган йорт! Йорт ияләре, нигеземне саклаган өчен меңнән мең рәхмәт сезгә!
Ул бу юлы үзенең шактый бирешкәнен сизә. Бирешерсең дә, сигез тапкыр хөкем ителү ул сигез тапкыр сабан туена бару түгел. Ничек кенә әтәчләнмәсен, ничекләр генә сер бирмәскә тырышмасын, төрмә төрмә инде ул.
Өенә кергәч, Мөнирҗан тормышын кабат күз алдыннан кичерде. Хәтер учагындагы кузлар кабынды да сүнде, кабынды да сүнде. Никадәр генә тырышмасын, күршеләрендәге Миргали абзыйлардан калган йортта яшәүче Моратның кем икәнен исенә төшерә алмады. Югыйсә кайдадыр юллары кисешүе хак бит, хак.
Морат исә аны шунда ук таныды: ул надзиратель булып эшләгән Ташкент төрмәсендә утырды бит аның хәзерге күршесе. Күндәм, үзе сыңар кулы белән үзәкләрне өзәрдәй итеп гармун уйнаган мәхбүс ничек онытылсын! Йа раббым, син бит чиксез кодрәтле, ни өчен бу дөньяны шулкадәр кин дә, тар да итеп яраттың? Олыгая барган, җанының тынычлыкка сусаган көннәрендә Ташкентта, хәер, Ташкентта гына да түгел, бөтен Урта Азиядә татарларга килмешәк дип карый башладылар. Югыйсә Морат Үзбәкстанда туып-үсте. Һәм менә хәзер ул да килмешәк. Кайда гаделлек? Үзбәк түрәләренә ярар өчен чәче белән җир себерде, тырышты-тырмашты, надзиратель булып эшкә урнашты. Тиешле вакыты җиткәч, ялга чыгып, канәгать тормыш сөрә иде: менә дигән фатиры, бакчасы бар, пенсиясе дә Аллага шөкер генә иде. СССР таркалу тормышын челпәрәмә китерде. Акыллыраклар, болгавыр заманнар башлангач ук, йорт-җирләрен, дачаларын ат бәясенә сатып, тынычрак җирләргә күчеп китү җаен карадылар. Морат исә тормышның элеккеге эзенә төшүенә өметләнеп оттырды. Ул айныганда соң иде инде: күчеп китәргә теләүчеләрнең мал-мөлкәтенә эшнең асылына тиз төшенеп

алган һәм болганчык судан балык тотарга остарып киткән үзбәк агайлары шалкан бәясеннән артыгын бирми башлады.

Күченүне Морат, бәлки, тагын да сузган булыр иде, бер очрак аны ашыгырга мәҗбүр итте.

Беркөнне, тегесен-бусын алырга дип, ул Алай базарына чыкты. Көтмәгәндә-уйламаганда кемдер:

—Ах, падла, эләктенме!—дип бугазыннан эләктереп алмасынмы!

Таныды аны, таныды Морат: якасыннан алучы Ташкент төрмәсе түрәләренә күп мәшәкатьләр тудырган Ржавчина—Тутык кушаматлы зек иде. Пычак белән суеп кеше үтергән бу имансызны ни өчен Тутык дип атаганнардыр, анысы Моратка нәмәгълүм. Төрмәдә чакта да камерадашын суя язган Тутыкны карцерга утырту Морат өлешенә туры килде.

Морат эштән киткәндә, Тутык әле зонада калган иде, нинди хезмәтләре өчен чыгардылар икән?

Тутык белән очрашу ничек тәгалләнер иде, белмим, Моратның бәхетеннән, якында гына ике милиционер бар иде, шулар аралап өлгерде.

Әлеге күнелсез очрак Моратны пошаманга төшерде, төн йокыларын алды. Уйлап карасаң, Ташкент төрмәсендә утырып чыккан һәм анда эшләгән һәр надзирательне кан дошманы санап, Тутык кебек җайлы форсат көтеп йөргән элеккеге ристаннар шәһәрдә аз түгелдер. Коткарырга гелән-гелән милиционерлар очрап тормас, баш исән чакта бу тирәдән аякны еракрак олактыруың хәерле...

Күп мәшәкатьләр чигә торгач, гаиләсе белән ул, ниһаять, бер ай чамасы элек Әскәйгә килеп урнашты. Шушы нигездә гомеренең соңгы көннәренә кадәр яшәү иде нияте.

Аның ата-бабалары тумышлары белән Оренбург якларыннан иде. Ләкин кырык кат үлчәп, бер кат кисәргә өйрәнгән Морат күченеп кайту өчен Татарстанны сайлады. Моның житди ике сәбәбе бар иде: бердән, Татарстан башка күп кенә республика, өлкәләр белән чагыштырганда аягында ныграк басып торса, икенчедән, жан тартмаса, кан тарта, диләр бит—башкаласы борынгы Казан булган Татарстан Жир шары буйлап сибелгән һәммә татарның тарихи ВАТАНЫ бит ул.

Бәхетеңне кәҗә бер сөзсә, булмый икән ул. Мөниржан аны таныгандыр һәм хәзер ничек итеп аннан үч алу планын корып ятадыр—төнлә белән кереп суеп чыкса... Гәрчә Мөниржанга карата аның бер әшәкелек кылганы булмаса да. Исендә, кайсыдыр Советлар Союзы Герое белән уздырган бер очрашудан соң төрмә начальнигы аңа Мөниржанны эзләтеп таптырган иде. Юлларының бүтән вакытта кисешкәнен хәтерләмиме дә ул. Хәер, шул очрашудан соң Мөниржан төрмәдә озак тормады—иреккә чыгардылар.

Төрмәдә эшләү дәвамында Морат күз алдыннан үткән ристаннар, Чыңгыз хан чирүе санынча ук булмаса да, ун меңнәр белән үлчәнә торгандыр. Әйе-әйе, нәкъ менә күз алдыннан үткән дию дөрес, чөнки надзирательләр тоткыннар белән якыннан аралашмый. Дистанцияне сакламасаң, үзенә дә эләгәсен көт тә тор.

Морат Мөниржанны чулак бер гармунчы буларак кына белә. Ә чынлыкта кем ул: язмыш тарафыннан кыерсытылган бер мескенме, әллә Тутык кебек кеше җанын кыюны чебен үтерүгә дә санамаган явыз бәндәме? Әнә ич, чакырып, чәй эчәргә дә кермәде. Әй бу дөньяның кысанлыгы! Егерме елдан артык вакыт узганнан соң, аларны очраштыруның язмышка ник кирәге чыкты икән? Ул бит Әскәйгә тыныч тормыш эзләп кайтты. Әҗәлен биредә каршылау иде нияте, тормышка ашмас, ахрысы...

Иртәгәсен Морат хатыны белән юкка чыкты.

Мөниржанның көне йорттагы вак-төяк белән үтте: өч ел буена өй эчендә җыелган тузаннарны сөртте, идәнне юып чыгарды; бакчада, хуҗа юклыктан файдаланып котырып үскән тигәнәк, әрем, сукыр кычыткан, алабута ише азау яраган чүп үләннәрен йолкып ыргытты. Чүп үләннәрнең тамырлары тирәнгә киткән, көчле, аларны сыңар кул белән йолку уен эш түгел. Өстәвенә яшь чагы да түгел. Бер-ике сәгать эчендә, тәмам хәлдән тайса да, шактый "дошманының" башына җитте. Туган нигезгә аяк басу шатлыгы барысыннан да өстен, аңа күңелсезләнергә дә, юк-бар вәсвәсәле уйларга бирелергә дә юл куймый. Ул хәтта күршесенең күзгә-башка чалынмавына да игътибар итмәде.

Кайткан көнне Мөниржан беркая да чыгарга ниятләмәгән иде. Ирекне тою, туган нигезенә кайту шатлыгын бирәү белән дә бүлешәсе килмәде. Бу көнне ул хәтта гомерлек сердәшенә әверелгән гармунына да кагылмады—үзе белән алып кайткан ризыклардан тәгам җыйды да йокларга ятты.

Ул арыган, талчыккан иде. Шулай да яту белән йоклап китә алмады, әле Гайния, әле Рәмзия исенә төшеп, сагышлы да, татлы да минутларны күңеле аша кичерде. Авыр гер таккан керфекләре йомылып бетте дигәндә генә, түбәтәйле күршесе Морат күз алдына килеп басты, һәм ул дерт итеп китте, йокы дигәннең әсәре дә калмады. Таныды, таныды ул Моратны! Ташкент төрмәсендә Ваня Корпухин белән очрашкан көн ничек хәтердән бөтенләй җуелсын ди! Менә бит ничек ул дөнья: нинди хөрмәттә яшәсә дә, Герой-полковник күптән җир астында, ә эт типкесендә йөреп, төрмә кандалаларын симерткән Мөниржан һаман да исән. Исән генә дә түгел, ул бүген туган нигезенә кайтты, яңадан тугандай булды. Шушы минутта аннан да бәхетлерәк җан иясе бөтен дөньясында юктыр.

Аларга күрше булып яшәргә язган икән, иртәгә Морат янына керергә, сөйләшеп утырырга кирәк. Күрше хакы—Алла хакы. Аннан килеп Морат төрмәдә дә кансыз кыланмады кебек, ә надзирательләр арасында җәлладка тиңнәре дә аз түгел иде.

Йокыга соң киткәнгәдер, Мөниржан иртәнге сигезләр тулганда гына уянды. "Йокыны симертеп тә куйдың, Исламов!"—Аның чыраена канәгать елмаю җәелде. Хәер, ашыгыр җире дә юк ләбаса. Шулай да, озакка сузмыйча, Морат янына сугылып чыгарга кирәк. Төштән соң Фазылны күрәсе булыр, нишләп яталар икән. Әле үзен һаман да эшеннән алмаганнар, дип ишеткән иде.

Юынып, чәйләп алганнан соң, ул Моратларга керергә ниятләде. Ут күршеләренең ишек келәсендә йозак күргәч, исе китмәде: йә кибеткә мазар киткәннәрдер, йә берәрсенә йомышка кергәннәрдер. Әллә соң абзар-кура тирәсендә генәме?

—Күрше!—Мөниржанның тавышы карлыгып чыкты. Тамагын кырып, ул көчлерәк тавыш белән:

—Берәр кеше бармы?—дип кабатлады.

Җавап кайтаручы булмагач, аның чыгып китүдән гайре чарасы калмады.

Өйдән бер кузгалгач, Фазылны да күреп кайтыйм дигән иде, анда да юлы уңмады: Фазыл басуда, ә Гөлфәниясе кош-кортка җим куеп йөри иде.

Яшьлек дусты аның янына икенче көнне үзе кереп чыкты. Бер "Бөгелмә малае" да алып кергән иде Фазыл. "Дарузаттан" дип әйтеп караса да, Мөниржан:

—Минем норма әллә кайчан артыгы белән тулды инде,—дип катгый рәвештә баш тарткач, өстәлдә кукраеп утырган шешә ачылмыйча калды. Сәгатькә якын авыл хәлләрен сөйләшеп утырдылар да аерылыштылар—Фазылның печәнчеләр янына барасы бар иде.

Чыгып китәр алдыннан гына Фазыл:

—Әй, дус, иң кирәген әйтергә онытып чыгып барам икән. Безнен авылда Рәмзия исемле бер кибетче хатын эшләгән иде бит, хәтерлисеңме икән? Түбән очтагы Ибрай Зәкиясендә торган иде. Шул синен төрмә адресыңны сорап язган иде. Бирдем инде, ачуланма, яме,—дип ушын алды.—Әллә сон арагызда бер-бер нәрсә булдымы?—Фазыл шаяртып кашын сикертте дә, җавап көтеп тормыйча, чыгып китте.

Аның бу сүзләре Мөнирҗанны уйга салды: кызык, Рәмзиягә ул адрес нигә кирәк булды икән? Барыбер хат язмады.

Бу сорау күнелендә җылы хатирәләр уятты һәм ми күзәнәкләренә тынгы бирмәс табышмак булып кереп урнашты.

Кайтуына ун-унбиш көнләп вакыт узды. Кичке сәгать бишләр тулып килә иде, көтмәгәндә-уйламаганда ишек шакыдылар. Кем булыр икән? Авыл кешесе бик шакып өйрәнмәгән бит ул, килә дә керә.

Ишектән күренүгә, авылдан аерылып торган өч ел эчендә шактый буй җибәреп өлгергән кызны ул шунда ук танып алды: почтальон Гамира кызы Лилия кергән иде.

—Кер, сеңлем, әйдүк түрдән уз!

—Юк, узып тормыйм.—Кызның житди йөзенә эшем иясе кыяфәте чыккан иде.—Менә, абый, сезгә хат бар.—Ул кулындагы конвертын тоттырды да, Мөнирҗан телгә килеп ни дә булса әйтергә өлгергәнче, атылып чыгып та китте.

Хат... Кемнән икән? Кайсы бәндәсе дөньяда Мөнирҗан атлы җан иясе барлыгын онытмаган? Уйлап карасаң, аның бит хәзер хат алышыр кешесе дә калмаган. Зонада чакта соңгы хатны Фазылдан биш былтыр элек алган иде.

Бәлки, органнардандыр? Юк, алардан түгел, аларның хатын ул мөһереннән таный, исеннән сизә.

Конвертта хатның кемгә икәне генә күрсәтелгән, җибәрүчесе билгесез иде. Түземсезләнеп, шул ук вакытта шикләнә-шикләнә, дулкынланудан калтыранган бармаклары белән конвертны ачты ул, һәм, беренче юлларын укуга ук, йөрәге кысылып куйды—хат Рәмзиядән иде. Мәңгегә югалттым дип исәпләгән Рәмзиядән. Мөнирҗан хатны сүзен сүзгә, хәрефен хәрефкә аерып укыды.

"Исәнме, Мөнирҗан! Бәлки мина "абый" дияргә кирәктер. Ләкин өч ел элек булган хәлдән соң, син минем якын кешемә әверелдең, шуңа күрә "абый" дип әйтергә телем әйләнми.

Минем хатымны алгач, гаҗәпләнәсеңне сизеп торам. Бәлки, ачуың килеп, хатны ертып ташлау теләгең дә уяныр. Берүк, ертып атарга ашыкма, укып бетерергә түземлегең житсен.

Сине хөкем иткәч, мин Әскәйдә озак тормадым, күчеп киттем. Ник дисәң, чарасызлыктан канатларым салынды, чөнки сине коткарып кала алмадым. Бусы беренчедән. Икенчедән, күпмедер вакыттан соң, мин үземнең йөккә узганымны аңладым. Әлбәттә, аннан котылып була иде, тик мин бу адымга бармадым, чөнки ул синең балаң иде. Аннан соң улымнан һаман да хәбәр юк, картайган көнебездә миңа да, сиңа да юаныч, терәк булыр дип уйладым. Беркемнең дә юклыгын беләм бит мин. Ирсез бала табуны мактамыйлар, Әскәй халкына тел кашырга сәбәп бирмәс өчен, күчеп китүдән дә яхшысы булмас, дигән фикергә килдем. Хәзер менә Бөгелмә районының бер авылында яшим, фермада эшлим."

Тукта, бу Рәмзия авырга уздым, дигән бит. Әлеге яңалык Мөнирҗанны хатның калган өлешен ашыга-кабалана укырга мәҗбүр итте.

"Мөнирҗан, син мине каһәрләгәнсеңдер, чөнки минем аркада яна срок алдың, күпме мәсхәрә, кимсетелүләр күргәнсеңдер, кичергәнсеңдер. Мин

юньсезне гафу ит. Ни өчен юньсезме? Юньсез булмасам, мин Әскәйдән күчеп китмәскә, кеше сүзеннән курыкмаска, өендәге учакны сүндермичә саклап, кайтуынны көтәргә тиеш идем. Син бит, никаһлы ирем булмасаң да, кызым-нарасыем Чулпанның әтисе...”

Мөниржанның кинәт башы әйләнеп китте, сулышы ешайды. Баш әйләнмәслек тә түгел шул: аның кызы, Чулпаны бар! Чынмы бу, әллә саташа гынамы?

“Баштарак хат язарга кыюлыгым житмәде. Шунысы да бар, икебез уздырган бердәнбер төн миңа нинди генә хокук бирә иде соң! Без бит юньләп сөйләшергә, аңлашырга да өлгерә алмый калдык.

Адресыңны кайдан, кемнән генә сорарга да белми гаҗизләндем. Рәхмәт Фазыл абыйга, ниһаять, аның аша адресыңны таптым. Үзең дә инде бер хат язмадың. Язган булсаң, күкнең чите кителеп төшмәс иде әле. Фазыл абый биргән адрес белән язган хатыма “досрочно освобожден” дигән җавап алдым. Бу хатымны да авылга кайтканыңны белеп түгел, бәлки кайткансыңдыр дигән өмет белән генә язам. Иреккә чыккач, барыбер Әскәйгә кайтмый калмассың дип уйладым. Ходай Тәгалә бу хатымны сиңа ирештерерме, юкмы, белмим. Ләкин минем бүтән чарам, бүтән өметем юк.

Мөниржан!

Әгәр дә хатым барып житсә һәм син мине гафу итсәң, теге вакыттагы хисләреңнең бер генә чаткысы сакланып калган булса да кызыбыз Чулпан хакына, зинһар өчен, хәбәр сал, килеп житәрмен, шунда барысы турында да сөйләшербез. Рәмзия.”

Хатны укыган чакта, Мөниржан әледән-әле күзен каплаган яшьләрен сөртте, аның тыны куырылды, сулышы буылды. Хәтта берара кызы туганын хәбәр итмәгән өчен Рәмзиягә үпкәләп тә алды. Ләкин аек акылы үпкәсенең урынсыз икәнен әйтте. Юк, үпкәләргә аның һич кенә дә хакы юк. Алла боерып, күрешә-кавыша калсалар, моннан соң ул Рәмзияне уч төбендә генә йөртәчәк. Рәмзия хәзер аның өчен кайчандыр түшәк бүлешкән бер хатын гына түгел, ул—кызының әнисе, ул—изге зат!

Озак уйлап тормаска, хәзер үк почтага барырга, чакырып телеграмма сугарга кирәк.

Мөниржан ашыкты, кабаланды, шул сәбәпле аягына галошларын ялгыштырып киде. Бер салды, кабат бутады. Өченче тапкырында гына дөрес кия алды.

Почтада чират юк иде, озак тоткарланмады. “Кичекмәстән килүегезне көтәм. Мөниржан,”—дип телеграмма сукты да чыгарга ашыкты.

Кайтышлый кибеткә сугылды, арадан иң матур күренгән курчакны сатып алды. Хәер, әлләни сайланырга туры килмәде: курчаклар нибарысы өчәү генә иде.

Кайта-кайтышка ук болай да чиста ишек алдын кабат җыештырды, өен тәртипкә китерде. Аның күңеле җырлый, аяклары җиргә тими иде. Тиздән Рәмзия киләчәк, үзе генә дә түгел, Чулпанны да алып килер ул. Хәзер Мөниржан да әти. Ул Чулпанны ничекләр кочасын, алдына алып сикертәсен күз алдына китерә дә елмаеп куя.

Мөниржан әлләни эш тә кырмады, тик тә тормады. Чалбарын үтүкләп куйды, пинжәгенә булган орден-медальләрен жентекләп беркетте. Аларны киеп, башына эшләпә дә элгәч, күпне күргән көзге каршысына килеп басты һәм канәгать калды—көзгедән менә дигән кияү егете карап тора иде. Аңа бит сынатырга ярамый, ул бит иртәгә Рәмзия һәм кызы Чулпан белән күрешәчәк!

Ә иртәгә килмәсәләр?

Нишләп бу хакта алданрак уйламаган икән? Хәзер авылда машиналы кешеләр аз түгел, әгәр сораса, берәрсе Рәмзияләрне бүген үк алып килергә

дә риза булыр иде. И-и, тишекбаш, тавык мие ашаган нәрсә! Егерме биш-утыз чакрымнарда гына бит анын газизләре.

Ярар, бүген сон инде, иртәгә өчен сөйләшеп куярга да тан белән юлга кузгалырга кирәк.

Башына мондый әйбәт фикер килгәненә куанып, Мөниржан күршесенә кереп китте. Гозерен анлаткан иде, Әнәс эһ тә итмичә риза булды. Тик тан белән түгел, фермада бер катка эшне төгәлләгәч барырбыз, диде.

Ярар сон, төгәлләгәч икән төгәлләгәч! Ике-өч сәгатьтән генә дөньянын асты өскә килмәс әле.

Кич белән ашадымы икән, оныткانмы—хәтерләми. Хәзер анарда нинди ашау кайгысы булсын ди, иртәгәдән ул бит янача—семья белән яши башлаячак.

Иртәгә мәшәкать, ыгы-зыгы күп булачак. Утны сүндерергә дә йокларга ятарга кирәк.

Шунда анын күкеле сәгатькә күзе төште. Герләрне күтәрәсе бар икән, югыйсә туктап калыр. Күкесе кычкырудан туктаса да, сәгатьнен тек-тек килеп йөрүе өйгә үзгә бер ямь бирә.

Мөниржан сәгатькә табан бер генә адым ясап өлгерде. Күкрәгендә туган көчле авыртудан аяклары сыгылды, һәм ул гөрселдәп идәнгә ауды.

—Ah!

Анын гырылдап чыккан тавышыннан куркып, мона кадәр почмакта гамьсез сайраган чикерткә койрыгын кысты: чыркылдамый башлады.

Мөниржаннын гырылдавы янә кабатланды:

—А-а!..

Төн уртасында үз өендә йөрәк өянәге аяктан еккан ялгыз ирнен хәлен кем белсен дә, кем ярдәмгә килсен. Анын үлем алдындагы шомлы гырылдавы иске йорт диварларында йотылып калды.

Әүвәл, тан атуын белдереп, әтәчләр аваз салды:

—Кикрикүк! Кешеләр, уяныгыз!

Башлап янгыраган шушы тавышка бер-бер артлы Әскәйнен бүтән әтәчләре дә кушылды. Бу инде авылнын йокыдан уянуын, бер үк вакытта тыныч та, ыгы-зыгылы да яна көн тууын белдерә иде.

Әтәчләрнен ансамбле тынып озак та үтмәде, йокысыннан айнырга өлгермәгәннәрне сискәндереп, көтүче чыбыркысын шартлатты. Капкалар ачып ябылды, урам хәрәкәткә килде. Кемнендер "Беларусь" тракторы узып китте.

Техник прогресс никадәр генә үсмәсен, авылнын иртәнге тормышына үзгәреш аз керде. Югарыда санап үткән күренешләр кечкенә генә аермалыклар белән йөз еллар буена кабатланып килә.

"Москвич"ынын тузаннарын инештә әле генә юган Әнәс кичтән сөйләшкән вакытта күршеләре капкасы төбенә килеп туктады. Мөниржан абыйсы күренмәгәч, сигналын кычкыртты. Алай да чыкмагач, башта ишек алдына, сонынннан өйгә керде.

—Мөниржан абый, син кайда?

Җавап кайтаручы булмады. Шунда Әнәс Мөниржаннын идәндә яткан гәүдәсен күрде. Күнеле беләнниндидер хәвеф барлыгын, төзәтә алмаслык хәлгә таруын сизде. Шулай да өмет бөтенләй үк ташлап бетермәде: элек андый гадәте бар иде, бәлки исереп аугандыр гына...

—Мөниржан абый дим, барабызмы?

Җавап та, берниндн хәрәкәт тә булмагач, Әнәс анын кулын тотып карады—кул сап-салкын иде. "Үлгән!"

Мондый очракта ни эшлиләр? Фельдшерны дәшәргәме, әллә авыл советына хәбәр итәргәме? Аз гына уйлап торганнан сон, авыл советына

барырга булды: тәне суынып өлгергән адәмгә медик чакыртудан ни файда. Хәер, силсәвиттә беләләрдер әле...

Медицина экспертизасы Мөниржан Исламовның йөрәк инфарктыннан үлгәнлеген раслады. Тикшерү мәшәкатьләре кичкә кадәр сузылды, шул сәбәпле бу көнне күмәргә сонга калдылар. Чөнки мәетне урнаштыру турында шәригатьнең үз кануннары бар. Дингә каршы көрәшнең иң хәтәр елларында да бу канун бозылмады диярлек.

Мөниржанның телеграммасын алган Рәмзия, кызы Чулпанны җитәкләп, көндезге автобус белән Әскәйгә килеп житте. Күптән түгел генә авыл кибетендә эшләп киткәнлектән, автобуста аны танучылар шактый иде. Кешеләр, бигрәк тә хатын-кызлар, аның тормышы, хәзер ни эшләп йөрүе белән кызыксынмый каламы соң! Юл буена сорауларга җавап бирә-бирә туеп бетте. Кунакка киләм, диде. Кибеткә сатучы кирәк, кермисеңме, дигән сорауга исә шаяртып җавап кайтарды:

—Бик кыстасагыз, уйлап карармын...

Ә нигә уйлап карамаска? Сату эшенең җаваплылыгы зур булса да, сәгать иртәнге өчтән-дүрттән торып, ашыга-кабалана фермага чабу түгел инде. Өстәвенә таныш, өйрәнгән эш. Әскәйдән китми калса, кибеттә сатуын һаман да дәвам итәр иде. Әйе, итәр иде, ник итмәсен.

Кызыксынган халыктан аерылып, Рәмзия Мөниржаннарның капкасын ачты. Көтә-көтә арып беткәндер инде, хәл җыярга өйгә кергән чагыдыр. Менә хәзер кызык итсеннәр әле үзен.

—Кызым, бар, өйгә кер дә: "Әтием, без килдек!"—дип әйт.

Кызчыкның өйгә кергәнне көтәргә түземлеге җитмәде, баскычка аяк басу белән аваз салды:

—Әтием, без тилдек!

Чулпан ябык ишекне ничек ачарга белмичә аптырап калды, әнисенә карады:

—Асылмый...

—Хәзер, кызым, хәзер ачабыз аны. Аһ, бу әтиеңне, килегез дип чакырды, үзе каршы чыгып та алмый.

Кызын җитәкләп, Рәмзия эчкә узды.

—Мөниржан!

Ул шунда ук юкка дәшүен аңлады: өй эчендә бер җан иясе дә юк иде. Күзе диварга элеп куйган пинжәккә төште.

—Кызым, кара әле, әтиеңнең күпме орден-медальләре бар.

Чулпан шунда ук медальләр белән уйнарга кереште.Аларның бер-берсенә бәрелеп чыңлавы сабый күңеленә шатлык өсти иде.

Тукта, сәгать ник йөрми? Ә-ә, тукмаклары идәнгә тәрәлгән икән бит. Гаҗәп, Мөниржан, үзе өйдә чакта, аларны күтәрергә онытмый, шуларны күтәрүдән һәм сәгатьнең күңелле текелдәвеннән тәм таба иде. Димәк, димәк, ул өйдә түгел. Ә кайда булуы мөмкин?

Рәмзия сәгатьнең телләренә карады: ун тулып, егерме минут киткән. Алар кайчан туктаган соң—төнге ундамы, әллә ике-өч сәгать элек кенәме?

Ашкынып килгән хатынның сизгер күңеленә шом керде: Мөниржанга ни булды икән? Кемнән сорарга, кемнән белергә?

Кызын ияртеп, ул урамга чыкты. Тик урамда да җан иясе күренмәде. Көпә-көндез авылда кеше табам димә: халык йә эштә, йә өендә. Көтү кайтыр алдыннан гына авыл бер җанланып ала да, яшьләр клубка чыга башлаганчы, тынып тора.

Кая барырга белми аптырап торганда, зират тыкрыгыннан туп тибә-тибә ике малай килеп чыкты. Бала-чаганың белмәгәне юк, ни әйтерләр икән.

Ул ялгышмады.

—Егетләр, Мөниржан абыегызның кайда икәнен белмисезме?—дигән

соравына башта бераз сәерсенеп тордылар: олы башың белән, янәсе, шуны да белмисең. Аннан калкурагы әйтте:

—Үлгән ул,апа. Аны Азнакайга ярырга алып киттеләр.

Малай әйткән сүзнең мәгънәсе Рәмзиянең аңына шунда ук барып җитмәде әле.

—Ускәнем, ни диден? Зинһар, шаяртма, мин бит чынлап сорыйм...

Малай күзләрен челт-челт йома-йома җавап бирде:

—Мин дә чынлап әйтәм, апа. Әти шулай диде.

Рәмзиянең аяк астында җир убылды. Мөнирҗан юк, Чулпанның бер тапкыр да күрергә өлгермәгән әтисе үлгән! Сәгать менә ни өчен туктап калган икән.

Күрешү өмет итеп ничә чакрымнан килгән, әле генә кояш кебек балкыган хатынны яшен суктымыни—күз аллары караңгыланып, башы әйләнеп китте. Бер кулына Чулпанны житәкләгән көе Мөнирҗаннарның ыңгырашып ачылган капкасыннан көч-хәл белән кереп, баскычка утырды да күз яшьләренә буылды. Ул аларны тыярга тырышмады да, энҗе яшьләр тәгәри бирде. Соңарып кына килә язган бәхетне Ходай Тәгалә ник аңардан кызганды икән? Кечкенә генә бәхетне...

Бу халәтендә күпме утырыр иде, Чулпанның:

—Әни, минем асыйсым килә,—дию кузгалырга мәҗбүр итте.

Күчтәнәчкә алып килгән ризыклар белән тамак ялгагач, Рәмзия ике юл чатында калды: хәзер үк кайтып китәргәме, әллә иртәгәне көтәргәме? Калса, кызының әтисен соңгы юлга озатыр иде, иртәгә, ихтимал, аны күмәрләр. Татарда мәетне озак яткыруны хуп күрмиләр. Тик аннан ни өчен килгәнен, биредә ни эшләп йөргәнен сораячаклар. Чулпанның әтисе кем икәнлеге белән кызыксынучылары да табылыр. Аларына ни дип җавап бирергә? Дөресен сөйләү җиңел түгел, алдашырга күңеле тартмый, Мөнирҗанның рухы рәнҗер сыман. Әтисен күмү тормыш әлифбасын яңа үзләштерә башлаган нәни кызына ничек тәэсир итәр?

Ахырда ул Зәкия әбиләрдә кунып, Мөнирҗанны күмгәч кенә китәргә булды.

Ирләр зиратка киткәч, Рәмзия Зәкия әби янына кайтты, ләкин ул анда озак юанмады, утырып чәй эчтеләр дә автобус тукталышына юнәлделәр. Тик аларга тукталышка ук барып җитәргә туры килмәде, узып баручы җиңел машиналарның берсе утыртып алып китте.

Сәгать дүртләр тирәсендә йөк машинасы белән Морат кайтып төште. Бар булган әйберләрен шофер белән ашык-пошык төяделәр дә, син күр дә, мин күр—китеп тә бардылар. Морат берничә сәгать кенә элек күршесен җирләгәнне белмичә дә калды. Аның бар курыкканы Мөнирҗан күзенә чалыну иде.

Әскәйдә хуҗасыз тагын бер йорт барлыкка килде. Ә тормыш дәвам итте.

*1998—2007 еллар.*
*Казан—Әлмәт.*

*Тәмам.*



Рифкать
Имаев

# НӘРСӘ БУЛГАН БУ ҖИЛЛӘРГӘ?..

## Өч серем бар

**Өч серем бар сезгә, дуслар,
бер кемгә дә чишмәгән:
уйчанлыгым—инештән бит,
шаянлыгым—чишмәдән;
сабырлыгым—шул авылдан;
кайнарлыгым—шәһәрдән;
картлардан мин акыл алдым;
тәвәккәллек—яшьләрдән;
халкым миңа йөрәк бирде;
көч-куәтем—илемнән.
Белмәгәннәр белеп торсын:
Иделдән мин, Иделдән.**

## Кагылды

**Сөйләнсә дә өстәгеләр:
"Бу,—дип,—безгә кагылмый".—
Көнбатыштан көнчыгышка
Болыт юкка агылмый.**

**Бу элекке заман түгел,
Хәзер капка ябылмый...
Булмады шул бу юлы да
Үткәннәрне сагынмый.**

**Сезгә, бәлки, җил дә тимәс,
Безгә менә кагылды:
Астагыларның күбесе
Инде кайгы ябынды.**

---

Рифкать ИМАЕВ (1948)—*шагыйрь; "Гомер агышлары", "Алма балланган вакыт" исемле китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Түбән Кама шәһәрендә яши.*

Бу кризис дигәннәре
Ачты салды ялганны—
Түләргә кирәк икән бит
Әҗәткә дип алганны.

Алдадылар "кагылмый", дип—
Шактый каты кагылды...
Әйбәт кенә барган җирдән
Ил яңадан абынды.

## Алма сатканда

Алмагачлар балкыган чак
Бакчаларда ал булып.
Тулган алма эчләренә
Кояш нуры бал булып.

Алма сата авылдашлар.
Җиткән алма сәгате.
Сакларга иде ничек тә
Шушы матур гадәтне.

Тезелгәннәр юл читенә
Алма битле апалар,
Туктап калган юлчыларга
Мактап алма саталар.

Бер алмага карый юлчы,
Бер апамның йөзенә.
Апам әллә алма булып
Күренә инде күзенә?

## Су буе

Яр астының яшь таллары
Карый ярдан—үрелеп:
Туган якның матурлыгы
Бетмидер шул күренеп...

Җәй кояшы төшеп бара,
Арган, ахры, кыздырып.
Сандугачлар җыр сузалар
Берсен-берсе уздырып.

Яр астының үз аһәңе,
Кабатламый беркемне.
Чөкердәшеп кайтып бара
Казларның бер төркеме.

Су керермен дигән идем
Тирләп төшкән килешкә,
Кыймый торам куркытырга—
Балык уйный инештә.

Таллар суга кармак салган:
Әллә балык каптыра?
...Шушы инеш искә төшсә,
Һәрчак күңел яктыра.

## Еллар безне...

Елатмагыз чәчне тартып,
Елатмагыз, кирәкми!—
Нәрсә булган бу җилләргә?—
Көн-төн яфрак сирәкли.

Елый каен, елый тирәк,
Чәчләр җиргә сибелгән.
Кем эше бу диясе юк—
Җилләр чыкты чигеннән.

Басты дөнья мәшәкате,
Кайчак күрми кителә.
Айный кеше сап-салкын яшь
Тамгач кына битенә.

Салкын җилгә барсы да бер,
Каен ни дә, тирәк ни...
Әйтерсең, без сары яфрак,
Еллар безне сирәкли...

## Картлыкның бәхетлесе

Бабай—чиккән түбәтәйдән,
Әби яулык ябынган:
Кайтып килә "пар күгәрчен"
Күрше авыл ягыннан.

Узган атна башларында
Бәби тапкан кызлары.
Колак салсаң, аңлашыла:
Шул турыда сүзләре.

Дөньяда иң матур бала—
Аларның оныклары.
"Туган икән, үсәр,—диләр,—
Сәламәт булсын бары".

Зәңгәр күктә тургай җыры,
Юллары—яшел сукмак.
Хозурланып тирә-якка,
Алалар туктап-туктап.

Бабай—яшел түбәтәйдән,
Әби—ак-ак яулыктан:
Яшәсеннәр куанышып,
Аерма тик саулыктан...

Җирдә җәй, җанны иркәли
Болынның яшел төсе.
Шундый буладыр, күрәсең,
Картлыкның бәхетлесе.



Гөлзадә
Әхтәмова

# КИҢ ИЛДӘ

Киң Иделгә карап уйга калам:
Халкым җыр чыгарган—язларда,
Иделләрдәй тирән кайгыларын
Агызмакчы булып бозларда.

Киң Иделнең яры ишелгәндә
Тотынып калган нечкә талларга.
Ничә үлеп, ничә туу кирәк
Татар күңелләрен аңларга?

Атамалар калган елга саен,
Исемебез яши күлләрдә.
Күпме шәһәр нигезе әрни әле
Тарих туфрагына күмгәндә.

"Этил суы ака торыр" диеп,
Борынгылар дөрес уйлаган.
Җәйрәп ята монда татар рухы
Һәм Иделгә берни булмаган.

Тик без генә бераз кимеп киттек,
Ватан монда, Ватан китмәгән!
Шушы җирдә үскән милләттәшләр
Соңгы сүзен әле әйтмәгән.

Киң Иделләр буйлап еллар ага,
Төрле чагы була холкының...
Җәйрәп ята монда татар җире
Моңлы җыры булып халкымның.

Гөлзадә ӘХТӘМОВА—*шагыйрә, һәвәскәр тарихчы; берничә китап авторы. Алабугада яши.*

***

Күзләрнең сарандыр кояшы.
Кемнең бар, кемнең юк юлдашы.
Шулай да бүген йә иртәгә
Мәхәббәт ашыкмый китәргә:
Яшидер, яши ул күңелдә
Хисләре саекмас Иделдәй.

Күзләрнең көннәре болытлы,
Үзгәрә, гел чуар холыклы:
Яңгыры коядыр чиләкләп,
Җилләре аладыр чәбәкләп.
Тик була гаҗәеп шәп чагы—
Җып-җылы әбиләр чуагы.

Күзләрнең буладыр үз яме,
Һәр җиләк-җимешнең үз тәме.
Гомернең өстендә каймаклар—
Янында йөгергән оныклар.
Сокланып караудан аларга
Йөрәктә мәхәббәт яңара.

Күзләрнең сарандыр кояшы.
Арттадыр гомернең юл башы.
Һич яшел түгелдер яфраклар,
Кышларны көтәдер туфраклар.
Шулай да шатлык бар күңелдә
Яшәүнең мәгънәсен күрүдә.

## Кимеп бара

Кимеп бара кунак булган өйләр,
Кимеп бара дуслар, туганнар.
Кимеп бара инде бу дөньяда
Сине сагынып көтеп торганнар:

Сулар ташып, кызу мунча ягып,
Бәлеш пешереп куйган җиңгиләр...
Хәтерләргә менеп кунаклады
Шаян сүзле тапкыр җизниләр.

Кимеп бара инде колач җәеп,
Безне каршы алган абыйлар,
Ишекләре һәрчак ачык булган
Ак яулыклы күрше әбиләр.

И, гомерләр узу шулдыр инде!..
Һәр заманның була үз яме.
Моңсулана бара өстәл яны,
Талымлана бара аш тәме.

Әкрен-әкрен генә югалтулар
Керәп бара инде гадәткә.
Авыр кайгыларны, әрнеп-сыкрап,
Кабул итә күңел, әлбәттә.

## Тузганаккай

Оныттыңмы сары чәчәк чакларыңны?
Утырасың бүген ап-ак бүрек киеп.
Тузганаккай, ничек чыдый торгансыңдыр,
Җилләр исә, сиңа төрле яктан өреп...

Чәчәк кебек чагым минем дә бар иде,
Чәчләремә төште бүген ап-ак кырау.
Тормыш җиле мена-мена өзәр диеп
Юл өстендә утырам бит мин дә шулай.

Чәчәккә тиң гүзәллекне онытмыйдыр,
Хәтерлидер кебек берәү һаман әле.
Сары ялкын эчендә мин ялгыз чәчәк,
Яшьлек хыялында шуңа калам әле.

Тузганаккай, очыйк, дисең, икәүләшеп,
Бергә-бергә очу, бәлки, булыр җиңел...
Язмыш җиле кай якларга очыртса да,
Өмет калсын, ансыз җаным риза түгел.

## Бер күрешеп алыйк әле

Йолдызларга очып китте бар хыяллар,
Адаштырды язмышларны урау юллар.—
Фани дөньяларда вакыт табыйк әле,
Исән чакта бер күрешеп калыйк әле.

Сагындырды да соң инде синең күзләр,
И җыелды, күп җыелды сөйләр сүзләр.
Синең дә бит әйтер сүзең бардыр әле,
Чакыр әле мине, иркәм, чакыр әле.

Су буенда көтә безне биек таллар,
Үсеп кенә калган иде бездән алар.
Шул талларга учыбызны куйыйк әле,
Үткәннәрне бераз искә алыйк әле.

Тыкрыкларда борын төрткән яшел үлән
Күтәрелеп китәр безне күрү белән...
Синнән миңа башка берни кирәк түгел,
Бер очрашу гына сорый моңсу күңел.

Гомер көзе көн дә коя яфракларын,
Сизәсеңдер ни көткәнен, яшьлек ярым.
Соң булса да, йөрәкләрне тыңлыйк әле,
Исән чакта бер күрешеп калыйк әле.

Мөхәммәт
Мәһдиев

# БЕР МОҢ

## I

Бу хикәяне язарга мин күптән хыялланып йөри идем. Язар өчен башта шартлар эзләдем. Үземнең шәһәрдәге гадәти квартирамда, гадәти өстәл янында утырып берничә тапкыр тотынып карадым—хикәянең исемен таба алмадым. Исеме табылмаган хикәя—хикәя түгел. Бу хакыйкатьне язучы гына түгел, укучы да белә. Хикәя шулай тумыйча калды. Аннан соң мин җәйге ял вакытында үзем укыган, яшәгән урыннарга кайтып йөрдем. Без укыган мәктәп бинасының инде эзе дә калмаган, аны сүткәннәр, ул урынны сөргәннәр, хәзер инде ул урын иген басуы да, юл да түгел, анда хәтта әрем дә үсми, анда бозау да арканламыйлар, ул урынны тракторлар йөк машиналары ермачлап бетергән һәм анда, бу дөньяда бер нәрсәнең дә мәңгелек түгеллегенә куелган һәйкәл кебек, ДТ-54 тракторының кызгылт-кола ватык кабинасы җиргә кереп каткан да вәссәлам!

Шулай итеп, ул урыннарда истәлек яңартып, картлар теле белән әйткәндә, яшьлек эзләре буйлап йөрүләр берни дә бирмәде һәм хикәяне яза башлар өчен бердәнбер чара—замандашым Мөхәммәтханны эзләп табып, күрешеп сөйләшү генә калды, соңгысы исә иң уңай чара, чөнки Мөхәммәтханның туган авылын ук белмәсәм дә, чама белән ягын, төбәген белә идем. Утыз ике ел күрешмәгән булсак та, мин беләм: Мөхәммәтхан әйбәт, ипле, нык яшидер, әгәр берәр явыз авыру килеп чыгып аны бәреп екмаса, әлбәттә, эшлидер, эшендә ул мактаулыдыр, кешеләр арасында аның абруе зурдыр; аның үз хуҗалыгы да тәртиптәдер; һичшиксез, аның ишек алдында рәшәткәле бакча бардыр, ул бакчада яшелчә, җиләк-җимеш, гөлләр үсәдер, ул бакчаның рәшәткә башларына кибәргә дип сөт чүлмәкләре элengәндер, ә бер урында Мөхәммәтхан каккан чөйгә аның хатыны марляга төреп саркырга эремчек элеп куйгандыр, ишек алдының бер почмагында цемент эретмәсеннән җиргә батырып тагарак ясалгандыр, аннан йорт кошлары су эчеп китәләрдер, чолан ишегенең яңагына электр кыңгыравының төймәсе куелгандыр. Мөхәммәтханның уллары яки кызлары үсеп җитеп, кайсы институтта, кайсы колхоздадыр, өйләнгәне-кияүгә чыкканы бардыр, аерым яшәгәннәре ике көннең берендә аның янына кирәк-ярак сорап киләләрдер, ә ул саргылт кашлары астыннан тыйнак кына елмаеп, аларның бер генә йомышын да кире какмыйдыр. Аның хатыны бик эшлекле генә, юантык кынадыр һәм ул хатын, мөгаен, Мөхәммәтханны юашка санап, «бу семьяның тоткасы—мин» дип ышанып яшидер һәм вакыт-вакыт иренә җитәкчеләрчә юнәлеш биреп торадыр...

Аннан, Мөхәммәтхан ял көннәренә туры китереп үзенең шәһәрдәге улына яки кызына барып кайтадыр, кышын ул зәңгәр драплы, каракүль якалы пөхтә пальтосы өстеннән соры плащ киеп, ул плащның путасын артка тарттырып

бәйләп куядыр һәм, ат жиктереп, берәр малайдан үзен станциягә илттерәдер. Анын күн сумкасында шәһәрдәге улына яки кызына күчтәнәчкә берәр каз, ике литрлы банка белән каймак буладыр... Ә җәй көне ул шәһәрдән идән буявы, яхшы өтерге фәлән-төгән күтәреп кайтадыр, станциядән җәяү кайтканда әрсезләмәс өчен чалбар балагын оекбаш эченә җыеп кыстырадыр...

Барырсын, күрешерсен һәм мин белеп торам—егет белән кыз шикелле без бер-беребезне кочаклап алырбыз, дөнья мәшәкатеннән инде бераз коргаксыган арка-сөякләребезгә дын-дын китереп бәргәләп, үзебезнен, сагыну хисләребезне белдерербез һәм шактый вакыт бер-беребезне карап сөйләшә алмыйча торгач, Мөхәммәтхан өенә керергә чакырыр, бик пөхтә итеп җыелган чолан яки өйгә кергәндә тыз-быз йөргән хатынына ул мине тәкъдим итәр:

—Менә,—дияр,—утыз ел... Юк, алай гына түгел... Утыз ике ел күрешмәгән сабакташым килде. Менә, дияр,—таныш бул: бу—минем тормыш иптәшем (Хәнифә, Наилә, Сәлиха һ. б.) була. Ә монысы—бергә яшәдек, хәзер—язучы, теге өченче ел укыдык бит әле китабын,—шуны язучы, сабакташ...

Ә мина кыен булыр—чөнки табигать мине семья-көнкүрешкә кагылышлы мәсьәләләрне алдан сизүдән мәрхүм иткән дә, шунын бәрабәренә бик вак, кирәксез мәсьәләләрне сизү сәләте белән бүләкләгән. Менә анын хатыны бүген ду-чат килеп күмәч изәргә, кичен сепаратны көйләп сөт аертырга, аннан мунча идәннәрен юып алырга уйлап куйгандыр, иртәгә кичкә кияү белән кызны чакырып алмакчы булганнардыр—нәкъ шул вакытта бер дә кирәксезгә «сабакташ» исемле берәү килеп чыга, синен планнарынны сүттерә, шулай да әлеге тормыш иптәшне елмайган булып сина карап-карап ала...

“Әйдә, өйгә узыгыз”,—дип өй ишеген ача, үзе эченнән уйлап куя: утыз-ике ел синсез яшәгән идек әле, каян килеп чыктын аяк арасына кыл сыймаган вакытта... Аракы өмет итеп кермәдеме икән? Куна калса нихәл итәрсен?—Әйдә, узыгыз, әнә түрдән утырыгыз...

Шул вакытта Мөхәммәтхан хатынына карап алса һәм хатыны шул вакыт: унынчыны бетергән кызга пальто аласы идек бит, тагын дүрт сум унике тиен китәмени инде, ну шушы эшсез гулять итеп йөрүчеләрне...—дип минем турыда начар уйлап куйса...

Юк, мин андый «көнкүреш гаебен» күтәрә алмаячакмын. Һәм мин ул очрашудан сон хикәя дә яза алмаячакмын. Бәлки, алай булмас та, бәлки, Мөхәммәтхан, хатыны, мин рәхәтләнеп сөйләшеп бер чәй эчәрбез, гөрләшербез, серләшербез, әмма кичке якта көтү кайта башлагач анын хатыны сәгатькә карап алыр, ыгы-зыгы килер һәм мин үземне бу йортта артык кеше итеп сизәрмен. Юк, хикәя язу өчен очрашу мәҗбүри түгел. Мин шулай уйладым да зәнгәр урманнар артына, Мөхәммәтхан яшәргә тиеш булган монсу, юаш рәшә сөременә күмелгән якка—Мишә суы буена тезелеп утырган авылларга бармадым, машинаны шәһәргә таба борырга куштым. Зәнгәр-күксел урманнар мина рәнҗегәндәй, горизонтта күккә сенеп тоташ буяуга әйләнделәр, әйтерсен, алар мина рәнҗиләр һәм «Әй, син, туганкай, нигә безнен белән исәнләшмичә китеп барасын, бу дөньяда беребез дә мәнгелек түгел», дип сагыш катыш каш җыералар иде...

Бу сәяхәтемдә мин, шулай итеп, хикәяне башлау өчен ачкыч тапмадым һәм, ахрысы, бу турыда яза алмам дип өметсезлеккә биреллем.

Ләкин мин ул хикәянен исемен таптым, һич тә көтмәгәндә, һич тә уйламаганда. Хәер, бу турыда мин ахырдан әйтергә булдым. Чөнки минем хикәямдә сөйләнәчәк хәлләр—хикәянен төп максаты, ә инде аны язу әмәлләрен, язу газапларын сөйләү белән укучынын вакытын алу минем тарафтан намуссызлык булыр иде; мин белеп торам, берәүләр мине озын кереш сүз өчен дә тиргәрләр, нәрсәгә безгә бу, вакыйга бир, диярләр. Укучыга ана вакыйга

бир, төп герой көрәшсен, җинсен, ахырдан бүләк алсын, туй ясасын, лауреат булсын—менә укучы нинди хикәягә иялӘнде...

Ә Мөхәммәтхан турындагы хикәядә—укучылар кашларын җыерырлар—бернинди вакыйга юк. Чын. Анда бер Мөхәммәтхан гына бар. Ул берни дә башкармады, бернинди һәлакәткә очрамады, бернинди батырлык эшләмәде, ул безнең барыбыз кебек укучы гына иде. Әйе, сугыш вакыты урта мәктәбенең унынчы классы малае иде...

## II

Кырык бишенче елның мул, калын карлы кышы апрель урталарына кадәр нык кына торды да, бер төнне кинәт көпшәкләнде: иртән, тулай торактан чыгып, без мәктәпкә барганда дөньяны яз исе аңкыткан иде. Белмим, каян чыккандыр ул ис, төн эчендә эрегән карга җебеп калган иске такта түбәләрдәнме, бернichә сәгать эчендә бүртенергә өлгергән (әллә без элек күрмәгәнбезме?) карт топольләрдәнме, багана башларында моңаеп, мескенләнеп калган көпшәк кар бүрекләрдәнме, әллә Вятка ягына ук тоташып киткән күгәрчен тамагы төсле юкә урманыннанмы—без моны белмәдек һәм аңлый да алмадык. Әмма шул көнне без дәрестән кайтканда, көнбатыштан тыгыз, җылы җил исә, ул җил үпкәгә бәреп керә һәм безнең сугыш еллары газабы белән сыекланган куәтсез каныбызны куалый, йөрәкне сафландыра иде. Шул җилгә сәерләнеп, исерешеп акшары каралган шыксыз тулай торакка таба кайтканда, без күк гөмбәзендә сихри моң ишеттек: биектән-биектән, зур кайчы булып тезелеп, кыйгылдашып, кыр казлары килә иде, аларның тавышы, әллә ниткән газаматле, мәгънәле аһәң булып, сугыш хәсрәте белән кителгәләп, сыгалап беткән безнең күңелләргә кагылды, шау итеп сөйләшеп кайткан җирдән барыбыз берьюлы тын калдык. Шатлыклы һәм ни өчендер газаплы ләззәт иде бу тавышларны ишетү, һәм мин игътибар иттем: иптәш малайларымның барсының да күзендә дым иде, юк, елаклар дип минем иптәшләремне гаепләргә ашыкмасыннар, алар, әһ тә итмичә җәен колхозда авыр эш башкарып, көздән язга кадәр синуслар, косинуслар, ассимиляция, диссимиляция законнары, Владимир Ильич Ленинның «Апрель тезислары», Авраам Линкольн, Георг Вашингтон биографияләре һәм перфект, плюсквамперфект, партиципцвайлар өйрәнеп йөрүче тырыш егет-малайлар иде.

Әмма, кыр казлары оча, безнең якларга килә иде—бу инде бик яхшы, бик мөлаем күренеш, бу инде бер дә шиксез, яз килде, дигән сүз иде, кыр казлары килү—фашизмның менә-менә шушы көннәрдә дөмегәчәге, сугышның менә-менә тәмамланачагы дигән сүз иде. Тик ул сугыш корбансыз гына булсын иде, әйтик, безнең танклар алга таба бара, фашистлар, кул күтәреп, юл өстенә чыгалар, аларны колоннага тезәләр дә тылга озаталар, мәсәлән, Теләче-Саба якларына юл төзергә, кар сулары тотарга җибәрәләр, җир йөзендә бер генә, бер генә кеше дә үлми, снарядлар шартламый, чөнки безнең җиңәчәк болай да билгеле бит инде, кан коярга җитәр, җитәр инде!

Кыр казлары, ахрысы, шулай сөйли иде...

Шулай, яз башланды, икенчеме, өченчеме көндә урман артыннан йомшак, әмма дәһшәтле гөрелте дә ишетелде, бөтен дөнья көпшәкләнде, төнлә юкә урманы берөзлексез шаулады, юл катысына ат аягы бата башлады, абзар артына чыгарган ябык, янбаш сөякләренә көянтә-чиләк элерлек йөнтәс сыерларның аркасына чәукәләр утырып укра чүпләделәр, баскыч төпләрендә үгез эчәрлек су җыелды.

Менә-менә язгы каникул игълан итәргә тиешләр иде. Мәктәп директорының бик кызык бер гадәтен без инде белә идек, укулар ел саен бер айга соңга калып башланганлыктан, һәр елның кышында ул безгә «быел язгы каникуллар булмый,

дип әйтә килә һәм аннан кинәт кенә, линейкага жыеп, безне шатландыра иде: каникул! Бу язны да без шундый кинәт киләчәк бер мизгелне көтеп яши идек.

Безнең мәктәп әйләнә-тирәдә зур уку йортларыннан санала һәм укучылар хәтта күрше районнан да килеп йөриләр иде. Мөхәммәтхан, мәсәлән, бөтенләй ерактан—егерме биш-утыз чакрымнан килеп йөри иде. Белмим, аның бу тирәдә берәр туган-тумачасы булгандырмы, әллә безнең мәктәптәге педагогларның яхшы, мактаулы исемнәре бөтен республикага таралган булганмы, һәрхәлдә Мөхәммәтхан, аркасына пөхтә капчыгын асып, безнең авыл аркылы ял көнне кичтән уза иде, ә безнең барасы юл ун гына чакрым булганлыктан, без дүшәмбе иртән генә китә идек. Мөхәммәтханның капчыгында тире оек эченә тыгылган бер чирек сөт, суган, тунмай белән пешереп төелгән бәрәңгедән куш йодрык зурлыгында алты йомарлам һәм алабута оны кушып пешергән чынаяк тәлинкәсе зурлыгында нәкъ алты юка таба күмәче була иде—моның белән инде ачыкмаска була! Һәр атна өендә ул мунча кереп, кием-салымына әнисеннән тулы ремонт ясатып килә иде, хәер, ремонт та әллә нәрсә кирәкми, чөнки Мөхәммәтхан шулкадәр пөхтә егет иде ки, аның чалбарының бер тез башы сидрәгәндә, икенчесе дә сидри һәм, ялга кайткач, әнисе ана нәкъ бер зурлыкта бер төстә ямаулар салып жибәрә иде, әйтерсең, ул ямаулар—фасон өчен...

Каникулны бездән бигрәк Мөхәммәтхан көтә иде, чөнки аларның өендә алты бала, иң олысы—Мөхәммәтхан, ул да укуда булгач, йортта эш жыелып тора, абзар түбәләрен кәрәргә, абзарны су басмасын өчен арт якта тирән канаулар казырга, өй астына су төшмәсен өчен ишек алдындагы бозны чабарга, гөрләвекләргә юл алдырырга иде—аларны кем эшләсен? Әтиләре сугыш башланганнан бирле бер тапкыр да яраланмады, кеше аталары кебек кайтып күренеп китә алмады, Мәскәү яныннан башлап, укчы полкта, жәяүләп, Польша аркылы узып, Берлинга якынлашып килә иде.

Безнең мәктәптә бик күркәм бер йола бар иде. Белмим, аны укытучылар уйлап тапканмы, әллә ул гадәт барлык мәктәпләрдә дә булганмы, һәрхәлдә, атнаның соңгы кичендә, ашханә бинасында концерт була иде, бу концерт чираттан бара, мәктәп зур булганлыктан, аның чираты елына икедән дә артмый иде. Язның нәкъ әнә шул беренче көннәрендә, кыр казлары килгән, каникул көткән, сугыш бетә дип өметләнеп, канатланып йөргән көннәрдә, концерт чираты—Мөхәммәтханнар классында, ягъни унынчы «б» классында иде. Мөхәммәтхан өч ел буе концертларда катнашып килде, аны, ни өчендер, әллә тавышы моңлы, әллә үзе тыйнак булганга, өчпочмаклап тезелгән хорның башына (авыл сәхнәсендә хордан башка концерт булганы бармыни?) чыгарып бастыралар һәм ул, гадәт буенча, салмак, ипле тавыш белән башлап жырлый иде.

Берсекөнгә унынчы «б» концерты һәм, әгәр каникул була калса, шуны игълан итәр кич иде. Әлбәттә, бу кичәне һәркем үзенчә дулкынланып көтте, һәркем көтте. Аннан, ул концертларның шул ягы да күңелгә бик якын иде: концерт башланыр алдыннан, пәрдә караңгылыгына чыгып, директор Совинформбюро яңалыклары белән таныштыра иде. Соңгы атналарда бу информацияләрдә гомердә күз күрмәгән шәһәрләр, колак ишетмәгән исемнәр телгә алына, ишетелә башлады. Мәсәлән, бер информациядә директор «безнең гаскәрләр зур, авыр сугышлардан соң Венгриянең Сөхерешфәхер шәһәрен азат иттеләр» дип сөйләде. Башка шәһәр булса, әлбәттә, без бу хәбәрне кул чабып каршы алыр идек, әмма бу шәһәрнең исеме безгә житди булып яңгырамады, чөнки, өч елдан бирле икелегә-өчлегә укып, мәктәпне иза чиктергән Сөхрәшева Фәхерниса дигән бер кыз бар иде, барысы да шуңа карап көлделәр дә көлделәр. Дөрес, ул кыз мәктәптә иң матур кыз иде, аның кашлары, аның керфекләре, иреннәре, каратутлы битләре, аяк-муеннары теләсә кайсы рәссамның игътибарын жәлеп

итәрлек иде, әмма ул вакытта без әле матурлыкның нәрсә икәнен алай аңламый идек һәм без, концерт көне дип утын күмере белән чистарткан тешләребезне ачып, Фәхернисага карап көлдек тә көлдек.

Мөхәммәтханнар концерт бирәсе көнне дә без берәр хикмәтле немец, мадъяр шәһәре турында ишетергә, ә иң зурысы—тагын өч-дүрт көннән сугыш бетә!—дигән хәбәрне ишетергә өметләнә идек.

Әмма без көткәнчә булмады. Әллә узучы юлчы кереп кунганмы—ә безнең мәктәп урнашкан авыл аркылы Мари якларына пыяла заводына йөрүчеләр байтак иде, ул заводтан лампа куыгы, стакан, пыяла, аш тәлинкәсе, пыяла аш кашыгы кебек нәрсәләр алып кайтып була иде—һәрхәлдә, Мөхәммәтханнар авылыннан пыялага баручыларның берсеннән мәктәп балаларына авыр хәбәр ишетелеп калган: 2 апрель көнне, сугышчан бурычын үтәгән вакытта, Мөхәммәтханның әтисе батырларча һәлак булган.

Мәктәп телсез калды.

Безнең арада сугыш чыккан елның беренче айларында ук әтисез калганнар, әтиләре хәбәрсез югалганнар, әтиләре авыр ярадан савыга алмыйча үлеп киткән һәм әллә нинди, әллә ниткән сәбәпләр белән ярым ятим калганнар күпчелек иде. Бу хәл, ничектер, бөтенләй гадәти, шулай килеп чыгуы табигый булган бер хәлсыман кабул ителә иде, ә менә кырык бишенче елның апрелендә алты бала калдырып үлгән солдат безнең күнелләрне тетрәтте. Тулай торакта да, мәктәптә Мөхәммәтханның әтисе үлгәнгә һәркем үзен гаепле сыман сизә, Мөхәммәтханга мөмкин кадәр игътибарлы булырга тырыша, шаян сүз әйтүдән үзен-үзе тыеп тора иде. Мөхәммәтхан да дәшмичә генә дәресләрен карады, аның күз aslары зәңгәрләнеп юкарган, күз кабаклары шешмәкләнеп салынган һәм керфек төпләре бераз гына кызаргансыман иде. Кичке алтыда ул дәшми-нитми генә концертка әзерләнә башлады, мич каршына килеп, калай кашыгы белән утын күмере төйде, аннан теш чистартырга чыгып китте, бераздан караватастындагы агач сандыгыннан юка күн чүәкләр алды, кесәсеннән каурый артлы урталай ватылган түгәрәк көзге чыгарып, мендәренә сөяп куйды.

Безнең эш рәхәт—бүген без залда гына утырачакбыз, унынчы «б»лар исә мәш килделәр.

Нәкъ сәгать җидедә зәңгәр шакмаклы чаршау алдына директор чыгып басты. Зал шып булды.

Директор озак көттермәде, гадәт буенча, «тавыш бетте» дигәнне аңлаткан ишарә ясап, сул кулын уч ягы белән безгә таба күтәрде һәм шундук сөйли дә башлады.

—Хөрмәтле укучылар, укытучы иптәшләр һәм залда утырган мәктәп хезмәткәрләре,—дип дәште ул залга, аның тавышы калтырый иде,—Совинформбюроның соңгы мәгълүматын сезгә җиткерүем белән мин бик бәхетле. Кичә, 16 апрельдә Советлар Союзы Маршаллары Жуков һәм Рокоссовский командалык иткән беренче һәм икенче Белорус фронтлары гаскәрләре һәм Советлар Союзы Маршалы Конев командалык иткән беренче Украин фронты гаскәрләре Берлин операциясен башладылар...

Шул урында директорның тавышы калтыранып алды һәм зал алкышларга күмелде. Күпмегә кадәр кул чапкан булыр идек, бәлки таңгача, әмма директорның сул кулы яңадан күтәрелде (хәер, аның кулы шул берәү генә иде, кырык өченче елда ул, госпитальдән кайтып төшеп, әнә шул сыңар кулына мәктәпне кабул итеп алган иде). Директор дәвам итте:

—Дошманның Одер һәм Нейсе елгаларының көнбатыш ярындагы ныклы оборона ныгытмаларын җимереп, безнең гаскәрләр көчле хәлиткеч һөҗүмгә күчтеләр. Сугышның җиңүле рәвештә бетәчәгенә санаулы гына көннәр калды, туганкайлар...

Аның тавышы тагын калтыранды һәм ул ашыгыч рәвештә кесәсеннән

кулъяулыгын чыгарды. Әмма үзен тиз кулга алды. Безнен учлар алкышлардан ут булып кызган иде инде, кул тагын күтәрелде.

—Ә хәзер район мәгариф бүлегеннән алынган телефонограмманы укырга рөхсәт итегез...

Адәм баласы берьюлы килгән ул кадәр шатлыкка ничек чыдыйдыр, ләкин без чыдадык. Берсекөннән язгы каникул башлана! Шатлыкның чиге-чамасы булмады. Тик вакыт-вакыт Мөхәммәтхан искә төшеп кенә йөрәк киселгәләп, бәгырь өзгәләнеп ала иде.

Унынчы «б» концертының хорында Мөхәммәтхан күренмәде. Жырскетчлар гел сугыш турында булды, гансләрдан, фрицлардан туйганчы көлдек, фашистларга кечкенә сәхнәдән нәләт, нәфрәт яуды. Арада ике кыз башкарган жыр аеруча ошады. Фашист солдатына дәшеп, алар жырны авылча, халыкча тәмамладылар:

Бабаң утырмага килсен,
Әбиенә сәлам әйт.
Үкчәңне күтәр, хәшәрәт,
Юк итәрбез кабәхәт.
Тралә-лә-ләм,
Тралә-лә-ләм,
Үкчәңне күтәр, хәшәрәт,
Юк итәрбез, кабәхәт.

Бу жырның монарчы ишетелгәне юк иде, ахрысы унынчы «б» кызлары моны классташлары Мөхәммәтханның әтисен үтерүләренә ачынып, нәфрәтләнеп үзләре чыгарган иде—бу жырны тыңлаганда, йөзләр житдиләнде, сулышлар кысылды. Мөхәммәтхан үзе сәхнәдә күренмәде. Жырдан соң декламацияләр, ничәмә-ничә төрле биюләр булды, концерт вакыт буенча инде бетәргә тиеш иде һәм алып баручы шунда гына ялгыз жыр белән Мөхәммәтхан чыгачагын әйтте. Зал бер мәлгә тын калды. Өченче көн генә әтисенең үлгән хәбәре килгән Мөхәммәтхан ни дип, ничек жырлар икән? Өч ел буе аның бер генә мәртәбә дә сәхнәгә ялгыз чыкканы юк иде.

Башта сәхнәгә үзенең тальянын күтәреп, урындык тотып, тугызынчы «а» дан Яңа Мичән малае Ярхәметдин чыгып утырды. Бераз гына көттереп, кыска аяклары белән унайсыз эре атлап, Мөхәммәтхан да чыгып басты; Ярхәметдингә карап алды да, алга табарак атлады, бер аягын алгарак шудырып, сәхнәнең ныклыгын тикшереп карагандай итте дә, кулларын артка салды, түшәмгәрәк, залның артына таба караш юнәлтте. Залда булган бөтен бала, бөтен укытучы аның кара кайгысы турында беләләр, ишеткәннәр иде, шуңа күрә берәүләр башларын аска иде, икенчеләре читкә борылдылар—кыскасы, Мөхәммәтханның күзенә туры карап утырырга берәү дә жөрьәт итмәде. Хәер, Мөхәммәтхан да залга карамый, әйткәнемчә, зал артына түшәмгә табарак карый иде. Берничә авыр секунд узды. Шул берничә авыр секунд эчендә, ахрысы, һәркем баш ватты: ник болай? Нигә бу малайның әтисен үтергәннәр? Ни хаклары бар? Сугыш бетә бит! Мин ышанып әйтә алам: әгәр шул көнне газетада, мәсәлән: «Берлин өчен сугышларда күп солдатлар батырларча һәлак булдылар»,—дип язылган булса, моны, сугыш вакытының гадәти бер трагедиясе дип, һәркем үзенчә кабул итәр һәм бер авыр сулау белән бу хәбәрне сеңдерер, уздырыр иде. Әмма бит монда конкрет шәхес—Мөхәммәтхан әтисен үтергәннәр! Менә фашистлар гаепле, анысы факт, ләкин тагын кем дә булса безнең арадан берсе гаепле түгелме? Аның әтисен коткарыр өчен барысын да эшләп бетердекме? Бетердекме?

Авыр уйларны тальян бүлдерде. Ярхәметдин аккорд бирә икән, һәм залда монарчы беркем дә ишетмәгән, тоймаган, йөрәк өзгеч көй-моң таралды. Башта озын гына аккорд белән ул моңны сипкелле, тулы яңаклы, математик башлы, мәктәпнең шахмат чемпионы сүзсез Ярхәметдин таратты. Бөтендөнья

халкының—оккупация астында җыкланган тугандаш украин, белорус, молдаван, литва, кырым, латвия халыкларының ачы хәсрәте, фашистлар коллыгында газап чиккән поляк, французларның канлы яшьләре, балаларын сугышка озаткан аналарның тирән сагышы, бөтендөнья ятимнәренең сыктау авазлары шушы тәбәнәк буйлы, классташлары арасында тарихны бик яхшы белгән бер кыз тарафыннан «Пипин короткий» (Каролинглар династиясенең беренче короле) дигән кушамат алган Яна Мичән малае Ярхәметдиннең кып-кыска дүрт бармагына җыелган да беткән, имеш.

Ләкин Ярхәметдин алай зурлап уйлап тормый иде булса кирәк, ул тәгәрәтеп-тәгәрәтеп, уйналачак көйнең төп казыкларын утыртып, шулар тирәсеннән бер әр кат әйләнеп чыкты да, вак соры күзләрен желтерәтеп, Мөхәммәтханга карады. Тегесе исә аның карашын сул колагы, сул яңак сөяге белән генә элеп алды да, алга таба атлаган сыман бер хәрәкәт ясады һәм, аксыл-саргылт башларын күтәрә төшеп, авызын ачты. Ачты... һәм моңарчы бу залда беркем дә ишетмәгән бер көйнең, бер монның нинди дер бер урынын тотып алды да, җырның сүзен әйткәнче, тамак белән, дөресрәге, йөрәк белән гөлдер-гөлдер китереп, чирек секундлык кереш ясады һәм, карашын бөтенләй түшәмгә юнәлдереп, залга дулкын-дулкын итеп моң салды. Җырның сүзләрен ул үзенчә тетеп-тетеп куя, ул кисәкләрне тоташ моң белән, көй белән төрә дә аннары гына безнең арага тарата иде бугай, кыскасы, сәхнәдә Мөхәммәтхан түгел, ә сугыш хәсрәтен үзенә туплаган анабыз Җир шулай, тәбәнәк аяклы бер егет-малай сурәтенә кереп, кисәк-кисәк, көшел-көшел итеп хәсрәтен бушата иде һәм Мөхәммәтхан, саргылт куе кашларын җыера-җыера, чын йөрәктән бик озын, бик озын бер көйгә җырлады:

Эн-кәй-ем мин-не тапкачтын

(шул арада Ярхәметдин әллә нинди әйләнешләр-чолганышлар ясап ала, әйтерсең, секунд эчендә Берлин-Сөхерешфәхер якларыннан үзенең Яна Мичәненә әйләнеп кайта иде).

Ак би-ләүгә бил-әг-гән шул,
Ак би-ләүгә бил-әг-гәннн...

Кемдер, авыр сулап, башын аска ия, аһ, ул безнең барыбыз да гашыйк булган алгебра укытучысы, озын-озын ике кара толымлы гүзәл кыз Гыйффәт апа икән. Әмма Мөхәммәтхан залны ишетми, ул инде икенче, сихри дөньяда иде.

Җырның икенче яртысын, Ярхәметдиннең тәгәрәвек аккомпанементыннан соң, ул тирән сулыш кушып алып китте, һәм шуңа күрә кайбер иҗекнең алдына ул «һы» «һа» кисәкчәләре кушып җибәрә башлады. Аның гәүдәсе бераз гына чайкала, ияге чак кына калтырый иде булса кирәк.

Һа-акъ би-ләү-ләр-гә би-ләг-гән,
Бәх-те бул-сын дим-мәг-гән...—

Мөхәммәтхан икенче җырын башлаганда, залда күзе яшьләнмәгән бер генә кеше дә булмагандыр дип уйлыйм. Икенче җырны башлар алдыннан, Ярхәметдин дә әллә нинди еракларга, тыкрыкларга кереп бетте. Мөхәммәтхан исә элеккечә җырлый бирде.

Һап-пакъ, иде-дем, кар күк идем,
Сус-сыз жирдә ләй кар-ралд-дым шул.
Сус-сыз жирд-дәй кар-ралд-дым.
Монл-лый бал-лай түг-гел ид-дем,
Хәс-серәт бел-ләң монланд-дым...

Ярхәметдин, сипкелле яңагын тальянга терәп, хыял дөньясына чумды, әллә кайларга алып китеп, уратып бетерде, Мөхәммәтхан исә, гәүдәсен салмак кына чайкалдырып, тизлеген акрынайтып, җырның соңгы юлларын кабатлады:

Моңл-лый бал-ла түг-гел ид-дем,
Хәс-сер әт бел-лән моңланд-дым...

Күпмедер вакыт аңышмыйча, кул чабарга да онытып тордык. Мөхәммәтхан, кыска, юаш, саргылт чәчле башын халыкка кырт кына иеп, сәхнәдән инде кереп тә киткән иде. Ярхәметдин әле көйне түгәрәкләп җиренә җиткерергә, нокта куярга азаплана иде. Күпмедер вакыт узгач, ниһаять, кул чаба башладык. Ул арада стеналарга эленгән керосин лампаларының филтәләрен күтәрә төштеләр, зал яктырып китте, концерт тәмам икән.

Ул концерттан арылып, тулай торакка кайтканны ачык хәтерлим. Башка вакытларда, концерттан чыккач, тулай торакка каләрге араны, уйнап-көлеп, ду-чат килеп, шаярышып кайта идек. Ул көнне алай булмады. Чыктык, чокырлы-чакырлы, баткак карлы юлдан тулай торакка таба атладык. Безнең тулай тораклар Казанка елгасының буена урнашкан иде, ә ул тирәдә Казанканың башланган урыны, урман эче, ул тирәдә Казанкага урман эченнән вак-төяк бик күп елгачыклар кушыла иде. Баксаң, без концертка әзерләнеп йөргән арада, ул елгачыклар бөтенесе дә юл алган, һәрберсе, чурлап аваз салып, Казанка елгасының мәһабәт салмак шавына кушылганнар иде.

Дөньяны җылы яз баскан, караңгы төн көпшәкләнгән, куәтсезләнеп калган, озакка сузылган кыш мең, миллион чурлау авазы белән тарала, бетә, юкка чыга. Табигать, адәм балаларына яхшылык эшләгәненә куангандай, безнең ябагалы тай муеныдай йон баскан битләребезгә җылы ягымлы җил булып килеп бәрелә, атлаган саен, аяк баскан саен, җанга җир якыная, өметләр тулылана иде—мондый төн бер генә булыр!

Без инде тулай торакка якынлаша идек—тулай торак ике елга кушылдыгы өстендәге калкулыкта, биек-биек нарат урманы итәгендә урнашкан, шунда җилсез-нисез йомшак бер төндә без нарат урманының шавын ишеттек. Шул шауны эзләп соңыннан, ун, егерме, утыз ел үткәч, мин бик күп урманнарга кердем, Себер тайгаларында, Һиндстанда, Сәрәндиб атавының джунглиларында йөрдем, ләкин ул шауны бер генә җирдә дә, башкача беркайда да ишетә алмадым.

Нарат урманы шаулый иде! Наратлар төбенә басып, шыксыз тулай торакка керәсе килмичә, без озак тордык, Мөхәммәтхан безнең янга килмәде, читтәрәк йөренгәләп торды. Безнең беркайчан да шул вакыттагыча сүзсез, телсез калганыбыз юк иде—ул төнне калдык! Ә наратлар шаулады, җил юк иде, әмма наратлар шаулады. Бу шаудан без бер мәгънә тотып алгандай, аңлагандай булдык: җир шары күкрәк киереп бер сулыш алырга әзерләнә, күпмедер вакытка булыр, әмма җир шары үзенең күкрәгенә снарядлар, бомбалар төшертмичә туктап ял итәргә әзерләнә, военкомат, почта бүлекләре «батырларча үлде» дигән авыр хәбәрне кабул итүдән, таратудан туктап торалар, караңгы төндә постта торган солдаттан башка барлык, барлык кешеләргә тәмле төшләр күрә-күрә тынычлап йокларга мөмкинлек бирелә, йоклагыз кешеләр, ял итегез, ә без, наратлар, сезгә, бөтен халыклар өчен уртак телдә бишек җыры җырлыйбыз, йоклагыз, йоклагыз... Шифалы бу җил, ахрысы, Көнбатыштан, хәлиткеч сугышлар барган, соңгы каннар коелган яктан исә иде...

*1976*



Әлфия
Ситдыйкова

# ЭЗЛӘП ТАПКАН БӘХЕТ КАДЕРЛЕРӘК...

## Тукта, мизгел!

**Тукта, мизгел! Син—гүзәллек!
Җанга салыйм сихри көчең.
Җиргә килеп яшәвем дә
Яшен булып яшьнәр өчен.**

**Тукта, мизгел! Кабатланмас
Моңнарыңа иим башым.
Бетмәс кодрәт яши синдә,—
Кузгатырлык гасыр ташын...**

**Куркам, куркам! Син—коточкыч!
Алма җанын мәхәббәтнең.
Әле бары бүген татыйм
Сөю дигән көй ләззәтен.**

**Туктатыгыз! Тукта, вакыт!
Яшәешнең күзенә бак.
Битарафлар күңеленә
Мәңге сүнмәс бер учак як.**

**Киртәләр юк! Күрәсеңме,
Ирек кошы канат җәйгән.
Ерак бабамнарның тавышы
Ишетелә ерак җәйдән.**

**Тукта, мизгел! Яз күзенә
Тутырып бер кара әле...
Кешелекнең киләчәккә
Кыю атлап барган мәле.**

Әлфия СИТДЫЙКОВА—*шагыйрә; "Назга сусау", "Йөрәк сүзе йөрәккә" һ.б. китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы. Чаллыда яши.*

***

Көтә-көтә көтек булдым инде,
Ике күзем бетте күгәреп.
Яшим гомеремнең һәр мизгелен
Заман җилләрендә җилгәреп.

Үрәм-сүтәм озын толымнарын
Тормышбикә диган гүзәлнең...
Халкым азат, хөр күңелле булса
Сынатмыйча мин дә түзәрмен.

***

Җаннар кабат-кабат яралана,
Үткәннәрне искә төшереп.
Ялгышларсыз гасыр түгел, ел да
Яшәмәгән әле кешелек.

Хаталардан сабак алсак та, без
Абынабыз, алга барганда.
Күңелебез сабый хәлдә кала,
Ышанабыз төче ялганга.

Вакыт кына дәва була диләр
Узган гомер салган ярага...
Ирек, хөрлек дәгъва итеп, әнә
Яңа җаннар җирдә ярала.

***

Белмәгәнмен кайда туасымны,
Кайчан туасымны, кем булып.
Тамырлардан ага гасырлардан,
Бабамнардан күчкән моң—тулып.

Җанны эзләп, ерак кайтавазлы
Бабамнарның токым авазы
Миңа күчкән. Миндә тармакланыр
Нәсел агачының дәвамы.

Күзәнәкләр тулган моң-сагышка,
Ил язмышы аңга бәйләнгән.
Мин—бер тамчы, Тарих аргамагы
Чорга бүләк иткән әйрәннән.

Ирек кошы очкан гасыр күге,
Киң даланың ефәк кылганы
Мин туганчы билгеләгән гүя,
Мин инанган якты кыйбланы.

Без күрәбез, мизгел әйләнгәнне,
Күз йомганчы эзле тарихка.
Шул тарихның моңы күчкән җанга,
Яшәү көче биреп тамырга.

...Белмәгәнмен кайда туасымны,
Кайчан туасымны, кем булып.
Тамырлардан ага, гасырлардан,
Бабамнардан калган моң—тулып.

***

Йомшак итеп чәчтән сыйпадың да,
Өздерепләр күзгә карадың.
Бер сыйпавың белән сызлауларын
Киметтең бит йөрәк ярамның.

Җиңелрәк булып китте шулчак
Тормыш иңгә салган йөкләрем.
Бер дәшү дә җитә кайчакларда
Ачар өчен күңел бикләрен.

Таң сызылды... Яңа өмет туды,
Җанга кунды былбыл тавышы.
Ак томанга төреп суга салдым
Гомерем буе җыйган сагышны.

***

Уч төбедәй йөрәгемә
Меңләп яра салып язмыш,
Вакытыннан алда мине
Үтермәкче булды, ялгыш.

Шулчак килеп якты Сөю
Йөрәгемне алды кулга.
Яраларны бәйләде дә
Әйтте: "Хәзер мине тыңла!

Сөеп яшә бу дөньяны,
Кешеләрне, халык гамен.
Шигъри телдә сөйлә илгә
Үзең күргән тормыш ямен!"

Буйсынмыйча калалмадым.
Төзәлде бар яраларым.
Рәхмәт, Сөю! Шул сүз белән
Үлемнәрдән араладың.

Яшим сөеп кешелекнең
Үткәнен һәм киләчәген.
Чөнки беләм, йөрәгемдә
Сүнмәячәк ут-чәчәгең.

***

Ком тауларын или-или кемдер
Эзләп ала алтын бөртеген.
Ә кемгәдер үзе килә табыш,
Селкетмәгән килеш керфеген...

Юк, көнләшмим андыйлардан һич тә,
Җиңел килгән җиңел югала.
Адәм заты яшәү дәверендә
Төрле сынау белән сынала.

Эзләп тапкан бәхет кадерлерәк—
Исбатланган хаклык күптәннән.
Алтынга тиң табышларны барлап,
Күтәреләм—калкып тирәннән.

*Укучыларыбыз игътибарына бу санда тәкъдим ителә торган төрек галиме һәм әдибе Ф. Күпрелезадәнең "Габдулла Тукаев" исемле мәкаләсе безнең фәнни-әдәби хезмәтләрдә еш искә алынса да, матбугатта басылганы юк иде әле. "Төрек йорты"нда—"Төрекләр файдасына эшли. Унбиш көндә бер чыга" шигаре белән ачылып, Йосыф Акчура кебек зыялыларыбыз исеме белән бәйле мәгълүм журналда 1913 елда басылган бу мәкалә бөек шагыйрь турында—вафаты уңаеннан чит илләрдә дөнья күргән һәм аның иҗатының зурлыгын ачкан беренче мәкаләләрдән. Автор татар әдәбиятын—үзе язганча, Шимал төрекләре дөньясын яхшы белүен күрсәтә; фикерләрендә замандашлары М. Бигиев, Г. Исхакый, З. Вәлиди, С. Сүнчәләйләрнең язганнарына таяна. Татар шигыре үсеше турында әйткәннәрендә бәхәсле урыннарга да юлыгабыз; Г. Ибраһимовның "Татар шагыйрьләре"ндәге (әле ул чакта бу китап басылмаган да...) кебек Г. Тукай иҗатын, лирикасын "саф сәнгать" җәһәтеннән карап, аңламау очраклары да юк түгел. Шул ук вакытта гомумтөрки мәдәни дөнья белән бәйләнешле бик кызыклы күзәтүләре дә бар.*

*Бүгенге укучы өчен бу мәкалә, һичшиксез, әһәмиятле тарихи-әдәби бер ядкарь булыр дип уйлыйбыз.*

Күпрелезадә

# ГАБДУЛЛА ТУКАЕВ

Ошбу ел барча төрекләргә хәвеф-хәтәре белән килде, кайгы-хәсрәт китерде... Күп гасырлардан бирле саф каннарыбыз белән юылган мокатдәс җирләребезне югалту гына җитмәгәндәй, милләтнең бөек затлары да берәм-берәм арабыздан китеп барды. Хәлбуки, ятим мәгънәвиятебезнең караңгы көнендә, безгә юаныч һәм сәгадәт юлларын күрсәтердәй йолдызлар бик еш туып тормый! Босфор буйлары Вәфикъ Паша, Әхмәд Мидхәт кебекләрне бирүдә никадәр саран булса, Идел буен да Габделкаюм, Тукаевка тиңнәрне мәйданга китерүдә аннан юмартрак дип булмый. Бу кытлыктан котылып, киләчәккә олы кешеләр әзерләп бирергә теләсәк, башта хәзерге бөекләребезнең матәмен тотарга өйрәник.

Иксез-чиксез ак кар дингезенә охшаган салкын Идел буйларында гомер кичергән ыругдашларыбыз, күренә ки, олы шәхесләрен безгә караганда җылырак һәм самимирәк кайгырталар. Бөек шагыйрьләре Габдулла Тукаевка карата Шимал төрек матбугаты, андагы төрек фикер вә каләм ияләре, бигрәк тә яшь егет-кызлар күрсәткән мәхәббәт һәм баглылык Волга буенда милли вөҗданның Истанбулга караганда куәтлерәк икәнен аңлатты. Газеталар, рисаләләр атналар, айлар дәвамында Тукаев, аның тормышы һәм әсәрләре турында язып торды; идарәханәләргә һәр яктан меңәрләгән тәгъзия телеграммалары килде; шагыйрьнең басылган әсәрләре сатылып бетте; хәтта Тукаевка багышлап кайбер хәйрия чаралары да үткәрелде... Милли вөҗдан барлыгын моннан да ачык итеп күрсәтә торган башка нәрсә юк. Күңелләрендә миллилек тойгылары кузгалган меңләгән кешедән оешкан матәм

процессиясе милли шагыйрьләренең җәсәденә чәчәкләр, рухына фатихалар бүләк иткәндә, инде төрекләрнең дә мәдәният һәм кешелек юлына аяк басуын исбат итте.

Бөек Ислам фикер ияләреннән Муса әфәнде Бигиев Тукаевның вафаты уңаеннан нәшер иткән мәкаләсендә Шимал төрекләренең соңгы егерме биш еллык үсеш-тәрәккыятен ике җанлы мисалда күрсәтеп бирә:

Русиядәге төрекләрнең беренче уяну хәбәрчеләреннән булган остаз Шиһабеддин Мәрҗани моннан егерме биш ел элек сиксән яшендә вафат булган чакта, беркем дә бу вакыйгага әһәмият бирмәгән, җеназа мәрасиме үтә дә гади булган, хәтта кайбер җаһил мөдәррисләр: "Динсез шигыйнең җеназасына бармагыз!"—дип коткы салган иде. Муса әфәнде бу хатирәне җан ачысы белән сөйли һәм шушы соңгы вакыйгалар белән чагыштырганнан соң: "Шагыйрь үлде, ләкин милләт тереллде!"—дип, шатлыклы аваз сала. Шул ук вакытта, мөхтәрәм галимнең бу хосуста Шимал төрекләренә юнәлтелгән авыр бер шелтәсе дә булып, анысы да бик хаклы: "Быел Ислам дөньясы өстенә хәвеф-хәтәр ябырылган, милләтнең намусы вә гыйззәте тапталган хәлдә, моңа бер дә пошынмыйча, гап-гади бер кешегә матәм тоту, әгәр тәкълидтән булса, мәгънәсез; әгәр җитди булса—милләтнең башка мәсьәләләргә карата ваемсыз һәм гамьсез булуын күрсәтү җәһәтеннән—фаҗигадер. Өстәвенә, яшь шагыйрь исән чакта аны бар дип тә белмәгән, авыр яшәү шартларын күрергә теләмәгән бәндәләрнең, ул вафат булгач, кайгырган кыяфәт чыгаруга ни хаклары бар?" Менә шундый авыр ике сорау. Беренчесе, безнең Рум илендәге фаҗигабезгә кагылышлы булганга, бәгырьне бигрәк тә телгәли... Төрекләр моңарчы бер-берсенең кайгыларына да, шатлыкларына да гамьсез калдылар, бер-берен уйламадылар, белмәделәр, аңламадылар. Инде моннан соң туганлык җепләрен барласалар һәм мәдәният хәятында бергә атласалар ни булган!? Авыр чакта милләтләр дә, кешеләр кебек үк, юануга мохтаҗ; мондый вакытта хәтта бергәләп күз яшьләре түгү дә ике арада куәтле һәм онытылмас туганлык җепләре суза ала!

Шимал төрекләренең бөек шагыйре, 25-26 яшендә караңгы бер хастаханә куышында юксыллык һәм яшәү авырлыгыннан җан тәслим кылгач, Идел буйларыннан Кара диңгез ярларынача гомуми бер матәм фөрьяды купты. Милли шагыйрьләренең яп-яшь килеш үлеп китүе, әле яңа гына туып килгән Шимал төрек әдәбияты өчен гаҗәп зур югалту иде; шуңа күрә кирәк матбугат һәм каләм әһелләренең, кирәк яшь буынның бу фаҗига каршында тирән өметсезлек һәм матәмгә бирелүе, аларның бөек шагыйрьләрен, үлеменнән соң булса да, тәкъдир итү биеклегенә менүен күрсәтте.

Тукаевның вафаты Истанбул фикер һәм әдәбият галәмендә үтә ваемсыз каршыланды; халыкка һәм зыялыларга Төрек миллияте нигезләрен җиткерү юлында хезмәт куйган "Төрек Йорды" белән "Төрек Учагын" санамаганда, матбугатта һәм каләм әһелләре арасында бу мөһим вакыйгага илтифат итүче булмады диярлек. Көндәлек гәзитәләр бер-ике юллык тәгъзияләр белән чикләнде. Бары "Тасвире әфкяр" белән "Ислам дөньясы" гына Тукаевка берничә багана аердылар. Моның сәбәбен җентекләп тикшереп торуга хаҗәт юк дип саныйм; укучы һәм мөхәррирләрнең милли вөҗданнан мәхрүм булуы, аларның Төрек галәмендә барган вакыйгаларны лаеклы рәвештә күзәтеп баруына киртә тәшкил итә. Муса әфәнденең Шимал төрекләренә адреслаган гаепләвен без монда Җәнүб төрекләренә дә юнәлтә алабыз. Әмма ләкин Төреклекнең ни икәнен аңламаган күпчелек янәшәсендә яшь, энергияле, миллиятпәрвәр яңа бер буын җитлегеп килүен күрмәмешкә салынып булмый. Соңгылары Төреклек галәмендә барган һәр вакыйганы бөтен вөҗданнары белән күзәтеп бара башладылар. "Йорт" бу нөсхәсен шушы агымның бер галәмәте буларак чыгарган кебек, мин дә бу юлларны шуларның бер вәкиле сыйфатында язам.

Тукаевның гомер юлы һәм әсәрләре хакында җитди күзәтүләр язар өчен, таныргга тиешмен, һич кенә дә сәлахиятем юк. Шимал төрекләренең фикри һәм әдәби хәрәкәтләрен әле яңа гына күзәтә башлаган кебек, Шимал шивәсе белән танышуыбыз да күптән түгел. Шуңа күрә, никадәр бу мөһим мәсьәләнең лаеклы каләм тарафыннан язылуын теләсәм дә, кайбер сәбәпләр бу авыр вазыйфаны минем

җилкәгә аударып калдырды.

Габдулла Тукаевның 25-26 еллык гомере башыннан ахырынача хәсрәт сәхнәләреннән гыйбарәт дип әйтергә була. Ата мәхәббәте, ана шәфкате, гаилә тәрбиясе кебек һәр баланың рухына җылы өргән, кешедә иң татлы хатирәләр калдырган сәгадәтләр мескен шагыйрьгә бөтенләй таныш түгел. Үги аталар, чит-ят гаиләләрдә, үзен сөеп иркәләрдәй, күз яшьләрен шәфкатьле куллары белән сөртердәй рухлардан мәхрүм булып үскәнгә, Тукаевның йөрәгендә шәхси сөюләргә карата бушлык хасил булып, әлеге бушлыкны ул милләт мәхәббәте белән тутырган. Тормышта шәхси сәгадәтләр булмавын бик ачы сурәттә татыган шагыйрьдә нарциссизм, эгоизм галәмәтләре чалымланмыйча, фәкать вә фәкать милләт кайгысына гына урын булуы гаять табигыйдер.

Тукаев "Исемдә калганнар" дип аталган 38-40 битлек бер чәчмә әсәрендә гомеренең тәүге елларын гади, садә тел белән күнелгә үткәзерлек итеп хикәяли.

Бу әсәрнең икенче кисәге язылып чыкмаганга күрә, кызганыч, шагыйрьнең соңгы еллары хакында системага салынган мәгълүматка ия түгелбез. Шулай да, көндәлек газеталарда, төрле рисаләләрдә әлеге елларга караган бик күп хатирәләр нәшер ителгәнгә, алардан бу хосуста файдалану мөмкин булды.

Габдулла Тукаев милади 1886 нчы елда Казан тирәсендәге Кушлавыч авылында туган. Атасы—Мөхәммәдгалим мулла углы Мөхәммәдгариф мулла, 14-15 яшьләрдә үк Кашгар мәдрәсәсенә киткән, анда сабагын тәмамлагач, туган авылына кайтып, мулла булган гап-гади бер адәм.

Гариф мулла, беренче хатыны үлгәннән соң, Өчиле авылының Зиннәтулла кызы Мәмдүдәне хәләл җефетлеккә алып, ошбу никахтан Габдулла Тукаев дөньяга килгән. Кара бәхет шагыйрьне туганнан бирле озата килгән: биш айлык чагында атасы вафат булган. Ул вакытта Гариф мулланың ата-анасы инде күптән мәрхүм булганга, Мәмдүдә ятим бала белән япа-ялгыз торып калган. Тик бераздан ул Сасна авылы имамына кияүгә баргач, Габдулланың ятимлегенә үксезлек тә өстәлгән: ул Шәрифә исемле бер ярлы карчык карамагында калган. Габдулла карчык йортында ялгыз башы михнәт чиккән бер вакытта, никахына якынча бер ел узуга, анасы аны үзе янына алдырган.

Бәхетсез сабый анасының шәфкать канатлары астында озак юана алмаган: Саснага килүенә күп тә үтмәстән, анасы вафат булгач, үги атасы аны Өчилегә, үлгән анасының гаиләсенә илтеп тапшырган. Ләкин болай да ишле булган бу гаиләдә Габдулланы кем кайгыртсын? Бу йортта үткән ялгыз, үги көннәрдән шагыйрь күнелендә бер генә хатирә, Сажидә апа исемле кечкенә кызның хатирәсе генә сакланып калган.

Бу гаилә фәкыйрьлек һәм мескенлектән иза чиккәнгә, Габдулланы Казанга барган бер кешегә биреп җибәрергә мәҗбүр булганнар. Ул кеше баланы Казанга китереп, Печән базарында Мөхәммәдвәли исемле кешегә асрамага биреп калдырган. Шагыйрь бу кеше белән хатыны Газизәне азмы-күпме мәхәббәт илә искә алып, хатирәләрендә аларны "әти, әни" дип атый. Әмма бу чорга караган хатирәләре билгесезлек пәрдәсе артында калганга, шагыйрь кирәк бу вакыйганы, кирәк Мөхәммәдвәли белән Газизәнең хасталангач: "Без үлсәк, бу бала нишләр?" дигән фикергә бирелеп, үзен кабат Өчилегә озатуларын, соңыннан андагыларның уллыкка бала бирәбез дип тирә-як авылларга хәбәр таратуларын һәрвакыт билгесез үткән заман формалары белән хикәяли. Дөрестән дә, "Исемдә калганнарны" укыган кеше, моннан соңгы вакыйгаларның шагыйрь хәтерендә бик ачык саклануын язу стиленнән үк чамалый ала.

Тукаев Өчиледә озак тормаган, шул тирәдәге Кырлай авылының Сәгъди исемле хәлле генә, галиҗәнап бер адәм аны балалыкка алган. Сәгъдинең Сажидә һәм Сабира исемле ике кызы, яхшы күнелле бер хатыны булган. Тукаев аларда үткәргән гомере, бигрәк тә Сәгъдинең киң күнеллелеге турында хатирәләрендә ихтирам һәм мәхәббәт белән искә ала. Өчиледәге фәкыйрь тормыштан котылып, әзме-күпме рәхәткә төшү бәхетсез балага аеруча зур куаныч китергән. Ләкин сәгадәтле мизгелләр кочагында озак назланырга ирек бирмәгән кара бәхете аны бу юлы да куып тоткан: иртән изрәп йоклаган чагында колагына: "Сабира апаң үлде, син һаман йоклап ятасың.

Тор!"—дигән дәһшәтле фөрьяд килеп бәрелгән. Ә берничә көн үтүгә, үги анасының иренә дәшеп, бу кайгыны "үги бала шомлыгы"на кайтарып калдырырга тырышуын Габдулла үзе ишетеп торган. Киң күнелле Сәгъди абзый андый нәрсәләргә артык әһәмият бирмәсә дә, Габдулла шул көннән бирле хатынның гаепләү объектына әверелеп калган.

Шул кышны Габдулланы мәктәпкә биргәннәр. Авыл имамы Фәтхерахман хәзрәт хатыны кызлар белән бергә Габдуллага да сабак бирә башлаган. Зирәк бала шул кышта ук әлифба һәм иман шартын зиһененә алган. Киләсе елнын җәе Габдулланың тормышында, бәлки, иң бәхетле чор булгандыр. Шагыйрь хатирәләрендә бу чәчәкле фасылны сокланып, бөтен гүзәллекләрен күрсәтеп тасвир кыла. Бу җәйдә Сәгъди абзыйның Садретдин исемле баласы туган. Укулар башлангач, Габдулланы ирләр мәктәбенә биргәннәр, анда ул "Кисекбаш" китабын укыган, тырыш һәм зирәк булуы сәбәпле, ялкаурак шәкертләргә сабак та бирә башлаган. Габдулла Сәгъди абзыйларда ике еллап торган; ул вакыт эчендә Сабирадан кала Сажидә дә үлеп киткән, Сәгъди абзыйның аягы аксаган. Үги анасы бу хәсрәтләрне, бер гаепсезгә, үксез баладан күргән...

Көз житкәч, көннәрдән бер көнне Габдулла "Рисаләи Газизә" укып утырганда, өйгә Бәдретдин исемле бер Кушлавыч кешесе килеп кергән. Сәгъди белән хатыны өйдә туры килмәгәнгә, Габдулланы алар артыннан йөгерткән. Дәррәү өйгә кайтып кергән ир белән хатынга билгесез кунак: "Мин Кушлавычтан булам. Бу сабый—авылыбыз мулласының мәхдүме. Без аны кайчаннан бирле эзләп тә, таба алмый йөри идек. Жаек шәһәрендә аның иргә барган апасы тора, сорыйлар, баланы шунда илтеп тапшырмакчымын,"—дигән. Өч ел дәвамында карап үстергән баланы биреп җибәрү Сәгъдигә дә, хатынына да җиңел булмаган, баштарак ризалашмыйча торганнар, ләкин Бәдретдин төрлечә яный башлагач, бирергә мәҗбүр булганнар. Габдуллага карап: "Безне онытма! Безне онытма!"—дип хушлашканнар. Инде кич житеп, караңгы төшә башлаган...

Юлда Өчиле аркылы үтеп, Кушлавычка, Бәдринең өенә килеп туктаганнар. Аның Гайшә исемле житез генә хатыны, Камалетдин исемле ундүрт яшьлек улы һәм Кәшифә исемле уникедәге кызы булган. Авылның шактый көр тормышлы кешеләреннән булган Бәдринең өендә яшәгәндә Габдулла кулына эләккән "Фәвакиһел жөләса" китабын укыган, кышын мәктәпкә сабакка йөргән. Габдулла кирәк белеме, кирәк әдәп-әхлагы белән мулла улы булуын һәркайда исбат иткән. Хәтта берсендә авылның байларыннан булган Садыйк исемле кешенең, исерек булганга, сәламенә җавап кайтармаган. Сәбәбен сораганнарга: "Исереккә сәлам бирмә, ул бирсә дә син алма!" бәйтен укыган. Ниһаять, кыш житкәч, аны Казанга алып китеп, аннан унсигез көндә Жаек каласына илтеп житкергәннәр.

Хатирәләренең беренче кисәге шушы урында өзелгәнгә, моннан соңгы шәхси тормышынданиләр булганын яхшылап белмибез. Шуна күрә, шәкертлек еллары һәм иҗат тормышы турында сөйләү белән генә чикләнергә мәҗбүрбез.

Тукаев Жаек каласына килгәннән алып, 1906 нчы азакларына кадәр "Мәдрәсәи Мотыйгия"дә укыган. Хөррият вә тәрәккыяткә мөкиббәнлегендә, милләтпәрвәрлегендә, кыскасы, шагыйрьнең фикер җәһәтеннән үсү һәм камилләшүендә бу мәдрәсәнең тәэсире искиткеч зур булган. Мотыйгулла әфәнде исемле, Мисырда укып кайткан, яңа фикерле бер мөдәррис карамагында булган бу мәхәлләгә рус, төрек һәм гарәп гәзитәләре килеп торган, шәкертләр, бигрәк тә Габдулла әфәнде аларны зур кызыксыну белән күзәтеп барган. 1902-1903 уку елында мәдрәсәгә Истанбулда укыган зирәк, хөр фикерле бер шәкерт килгән. Аның тәэсирендә Тукаев төрек роман һәм шигырьләрен, руслардан Пушкин белән Лермонтовның әсәрләрен зур кызыксыну һәм ләззәтләнү кичереп укый башлаган. Мотыйгия мәдрәсәсендә биш-алты айлап кына торып киткән ул шәкертне Тукаев һәрдаим хөрмәт вә мәхәббәт илә искә ала.

1905 нче елда, Шимал төрек әдәбиятының иң бәрәкәтле дәверен башлап җибәргән, казый Ризаэддин бин Фәхреддиннең "Сәлимә"се таралган 1895 нче ел хәрәкәте җимешләрен биргән бер дәвердә, "Фикер" гәзитәсендә "Мужик йокысы" исемле урысчадан тәрҗемә бер шигырь астында "Жаек шәһәрендә Мәдрәсәи

Мотыйгия таләбәсеннән Габдулла бин Мөхәммәдгариф Тукаев" имзасы пәйда була. Үзенчәлекле, кабатланмас бер шагыйрьнең иҗат җимеше булган бу нәрсәләр, әкренләп башка йөзләгән әсәрләр арасыннан аерылып, биеккә күтәрелә, "Габдулла Тукаев" исеме ихтирам белән телгә алына башлый. "Нур"да, "Әл гасрел җәдид"тә дәвамлы басылып килгән әсәрләре яшь шагыйрьгә олы дан китерә, бик күп гәзитә вә рисаләләрдә аның шигырьләре күренә башлый. Казанда басылган шигырь мәҗмугаларын һәркем, бигрәк тә яшьләр ябырылып укыйлар. "Мөхәммәдия", "Әнвәрел гашыйкыйн" кебек әсәрләр йогынтысында шигырьләрен башта Госманлы шивәсендә язган Тукаев, әкренләп халык шивәсенә якыная, телен гарәп һәм фарсы сүзләреннән тазарта, шулай итеп кин катлау укучыга мөрәҗәгать итү мөмкинлегенә ирешә.

Тукаев тамак туйдыру хакына бик яшьли мәгыйшәт мәйданына аяк баса: башта Уральскидә, сонга таба Казанда төрле гәзитәләрдә эшләргә, авыр хезмәтләр башкарырга мәҗбүр була. Гәзитәчелек эше тамакны бик чамалы туйдырса да, азгынлык һәм фәкыйрьлек, тәртипсез тормышка илтүче факторларның ин олыларыннан санала. Организмын кимергән куркыныч авыру озак вакытлы ял һәм дәвалану таләп иткән хәлдә, фәкыйрьлек вә юксыллык аны хастаханә түшәкләренә егылганчы эшләргә мәҗбүр итә... Тукаевның үзен нинди язмыш көткәнен белгән килеш, караңгы һәм өметсез хастаханә почмакларында үлем көтеп ятуы һәм үзеннән һәр минут саен ерагая барганын күргән тормыш-яшәешкә нәфрәт тулы үпкәләр яудыруы—никадәр фаҗигале күренеш!

Шимал төрекләренең бөек шагыйре, Клячкин хастаханәсенең бер хөҗрәсендә, икенче апрель көнне күзләрен фани дөньяга йомды... Бу кайгылы хәбәр шәһәр буйлап җәелүгә үк гыйлем һәм фикер әһелләреннән ун кешелек төркем оештырылды. Бу төркем рәттән ике көн җыелып, апрельнең дүртесендә үткәреләчәк җеназа мәрасимен карарлаштырды һәм һәр тарафка хәбәрләр җибәрелде. Бөек милли шагыйрьнең җеназасын үткәрү милләт өстендәге бурыч булганга, мәрхүмнән калган 500 сумлап акчага кагылмыйча, халык ярдәме белән кирәкле сумма җыелды. Ул көнне мәрхүм вафат булган бүлмәдә яшь шәкертләр Коръән укыды, халык сөекле шагыйрьләрен соңгы тапкыр күрергә дип агылды.

Иртәгесе көн Шимал төрекләренең милли тарихында мөһим бер көн булды. Иртән чыккан гәзитәләр кара кысалар эчендә бөек шагыйрьнең вафаты хәбәрен кайгылы сүзләр белән язып чыкты, гәзитә идарәләре һәм китап нәшриятлары җеназа мәрасиме мөнәсәбәте белән ул көнне ябык торды. Мәетнең гәүдәсе өйлә намазыннан соң сәгать бердә хастаханәдән чыгарылырга тиеш булганга, халык сәгать унда бу тирәгә җыелыша башлады. Ниһаять, сәгать бердә мәетне Коръән аятьләре укып һәм тәһлилләр әйтеп, хастаханәдән алып чыктылар. Шагыйрь гәзитә һәм нәшриятлар, клублар, шәкертләр, артистлар бүләк иткән ак чәчәк бәйләмнәре арасында сүзсез һәм хәрәкәтсез ята. Йөзе сулган. Чәчәк бәйләмнәре өстенә бик күп нәрсәләр, хәтта шагыйрьнең үз шигырьләреннән кайбер өзекләр язылган.

Җеназа намазы кылынып, мәетнең гәүдәсе меңләгән кешелек мәһабәт җәмәгать тарафыннан мәңгелек капкасына китерелгәннән һәм Коръән аятьләре укылганнан соң, табут өстендәге чәчәкләр кабер өстенә куелды. Ниһаять, Габдулла Гыйсмәти, Фәхрелислам Агиев, Шәехгаттар Иманаев, Гыйльметдин Шәрәф әфәнделәр тарафыннан мәрхүмнең бөеклеге, милләтенә кылган хезмәтләре хакында нотыклар тотылды, догалар укылды. Мәрасимгә катнашкан яшь кызлар, хатыннар, картлар, шәкертләр һәм мөгаллимнәр олуг шагыйрьләренең рухына фатихалар багышлаган чакта, барлык күнелләр аркылы бу вакытсыз югалтудан туган гомуми бер сагыш һәм хәсрәт ташкыны кичә иде...

Шимал төрек әдипләреннән Гаяз Исхакый әфәнде бер чыгышында, төньяктагы ыругдашларыбызның яшь һәм куәтле әдәбияты турында сүз йөрткәндә, чәчмә әсәрләрдә төп өч сыйфат барлыгы турында әйткән иде: ДЕМОКРАТЛЫК (ХАЛЫКЧАНЛЫК), ТАРТЫШУ, МӘСЛӘККӘ ХЕЗМӘТ. Мина калса, бу сыйфатлар Шимал төрекләренең тезмә әсәрләренә дә хас. Габдулла Тукаевның барлык шигырьләрендә, нигездә, шушы өч сыйфат шунда ук күзгә бәрелә. Ул шигырьләрен "Мияубикә"дә, "Энҗе бөртекләре"ндә булганча, йә балалар өчен яза;

йә булмаса гади халыкка хөррият, кешелек, хатын-кызлар иреге, милләтпәрвәрлек төшенчәләрен сендерү өчен иҗат итә; ә кайчак, "Печән базары"нда, "Осуле кадимче"дә күренгәнчә, җаһил һәм фанатик муллалар, милләткә файдасы тимәгән байларны фаш итү максатын алга куя. Әйтергә кирәк, Габдулла Тукаевның өстен һәм кимчелекле яклары ни булса, бөтен Шимал төрек әдәбияты өчен уртак булган өстенлек һәм кимчелекләр дә нәкъ шулар.

Габдулла Тукаевның фикер үсешендә, әсәрләренең асылы һәм өслүбендә башлыча ике тәэсир күзгә чалына: беренчедән, иске мәдрәсә ысулыннан ядкарь булып калган "Мөхәммәдия"ләр, "Әнвәрел гашыйкыйн"нар тәэсире; икенчедән, рус демократик әдәбиятының, Пушкин һәм Лермонтовларның йогынтысы. Тәэсирләрнең беренче күбрәк тел һәм бәянда, икенчесе фикер һәм уй сөрешендә күренә. Шагыйрь кулланган вәзенләр, бигрәк тә тәүге әсәрләренең өслүбе, Идел буеның классик китабы булган "Әнвәрел гашыйкыйн"га бик якын:

*Шигырә чук иттем һәвәс кальбем илә, җанымлә бән,*
*Чөнки иттем ифтиракъ җанымлә, җананымлә бән.*
*У гүзәл гыйшкында әшгар сыйләмәге халисән,*
*Кәндемә мөнис идендем кальбе гирьянымлә бән.*
*Улды яр агъярә яр һәм улды кальбем тарумар,*
*Иштә, яздым шигъреме күздән акан канымлә бән.*

Телнең гаруз вәзенәнә иярүдәге гаҗизлеге һәм шуның нәтиҗәсе буларак ималәләр, зөхафларның күплеге әдәбиятыбызның Гашыйк Пашадан соңгы дәверен хәтерләтә. Ләкин Тукаев Госманлы шивәсендә шигырь язуын озак дәвам итмәде, рус әдәбияты тәэсирендә Шимал төрек фикер ияләренең барысында да диярлек булган халыкчанлык, гади халыкка йөз тоту, аның телен куллану теләге Тукаевта да баш калкытты. Үзе үк "Бер татар шагыйренең сүзләре" исемле шигырендә язганча, ул Пушкин белән Лермонтовтан үрнәк алып, халык телен куллана, милләткә хитаб кыла башлый. Беренче җыентыгына кергән "Шагыйрь вә Хатиф", "Гыйшык бу йа!", "Күңел", "Әй каләм!", "Ифтиракъ соңында", "Дәрдмәнд дәгелмием?", "Тәрбияи әтфалә", "Пушкинә", "Японияны мөселман итәчәк голәмә нәрәдә?" кебек әсәрләр шушы сәбәптән башка җыентыкларда сирәгрәк очрыйлар.

Иҗат мәйданына аяк басканда ук "Бөтен уеның иртә-кич милләте хакында булуын, милләт һәм миллиятен җиһаннарга да алмашмаячагын, милли шагыйрь булырга ниятләгәнен" әйтеп килгән Тукаев, шул вакытта ук инде рус гавам әдәбиятына, мужикны падишаһ дип белгән адәмнәрнең фикерләренә мөкиббәнлеген күрсәткән иде. Үз гомерендә һич шәфкать вә наз күрмәгәнгә, шәхси ләззәтләр барлыгын таныйрга теләмәгән бу галиҗәнап шагыйрь "Ләззәт вә тат нәрәдә?" дип исемләнгән тезмә әсәрендә чын халык шагыйре булуын бөтен ачыклыгы белән исбат итә: ләззәт һәм сәгадәтне бик күп гүзәл нәрсәләрдә, гыйшык вә кавышуда, абелхәят (тереклек суы) эчүдә, чикләнмәгән иректә, бер кавемгә баш булуда, хөкемдарлыкта, өйләнүдә, гаскәр башларының канлы җиңүләрендә эзләгәннән соң, ниһаять, аны милләткә хезмәт итүдә таба. Тормышта һичнинди шәхси бәхет эзләмичә, фәкать милләт кайгылары өчен кайгырган бу яшь шагыйрь эгоизмнан шулкадәр ерак тора ки, сәнгать таләпләренә иярүне уйлап та бирми, һәм үзенә яшәү максаты итеп алган милләткә хезмәттән гайре берни дә аның зиһенен мәшгуль кылмый. Аның гавам теле куллануы фәкать шушы милләткә хезмәт идеясенә бәйле.

Тукаев милләтенең үсеш-алгарышын кайгыртканга, ошбу максатка киртә булган теләсә кайсы нәрсәгә һөҗүмнән, осуле кадимчеләргә каршы аяусыз көрәштән, җаһил муллаларны мыскыллау һәм рисвай кылудан чирканмады. "Мәчетләрне базарга әйләндереп, гавамга гамәл саткан, ахирәтне дөньяга алмаштырып сәүдә кылган, иске яһүди кыйссаларын халыкка дин дип тәкъдим иткән, чын фидакарьләрне бар кеше алдында динсез дип тамгалаган" җаһил сафсатачыларга "Житәр, инсаф кылыгыз, кирәк инсаф, оятсызлар!" хитабын ыргыту; читлек артында, капчык эчендә кешелектән чыккан мәхлукларга охшаган хатыннарга хөррият таләп итү яшь шагыйрь өчен зур бер мәдәни батырлык дигән сүз. Болай хәрәкәт кылган

кеше фанатикларның кимсетү-тешләүләренә, динсезлектә гаепләүләренә түзеп торырга мәҗбүр. Әмма Тукаев милләте өчен теләсә нинди авырлыкка түзәргә әзер торган куәтле һәм фидакарь шәхес иде. "И каләм!" исемле шигырендә "Аурупаны гарешләргә кадәр күтәреп, безне ник җир төбенә төшерден? Милләтнең бу хәле язылганмы тәкъдир китабына, аның бөтен гомере шулай рисвайлыкта үтәрме?"сорауларын куйганнан соң:

*Бакма һич кәс хәтеренә, милләтең дәрдена бак,*
*Бәддога, явыз догая һәр заман асма колак.*
*И каләм, синдән килер һәп бәхтемез, икъбалемез,*
*Бәкләнер дүрт күз илә лотфыңда истикъбалемез.*
*Кәчмәсен карангылыкта маһемез һәм салемез,*
*Гафилез без, җаһилез! Вай хәлемез, вай хәлемез!*
*Һәр тараф мөслимләре бер-бер итәрләр аh у ваh.*
*Нә сәбәпле кәлде безә бөйлә бер бәхте сияh.*
*Әйлә ярдәм безгә һәр дәм, әй каләм, кыл мәрхәмәт,*
*Рәфгъ улынсын җөмлә хәсрәт, фәкъp вә хәкъp, мәсканәт.*

эндәше белән каләм ияләренең никадәр какшамас һәм асыл мәсләк тотарга тиешлекләрен искәртә.

Нәкъ шулай ук, "Мөхәрриргә" шигырендә дә, тирә-якта купкан тавыш-гаугаларга, каршы әйтелгән сүзләргә әһәмият бирмәскә, фәкать киләчәк турында гына уйларга кирәк дигән фикер уздыра. "Әй мөхәррир! Сиңа динсез дисәләр, кайгырма! Сиңа агу биргәнгә, син бал бир! Дошманың җаһилләр булу белән горурланырга кирәк, син гыйлем әһелләренең үзенне дус күргәннәрен бел, шул җитә. Хаклык яклы булганнар һәркайчан каһәрләнер, ләкин милләт киләчәктә хаклыкның кайда икәнен аңлар. Сине җаһилләр мактасын дисәң, бар мәчеткә, монафикълык кыл, гамәл сат; шул чакта сиңа беркем дә дәһри димәс". Хакыйкатьтә, дөрес һәм хөр булган ошбу фикерләү рәвешенең, бер үк вакытта гаять галиҗәнап булуын да әйтергә кирәк... Чын милләт хадимнәре эгоизмнан никадәр өстен торалар! Без иң бөек һәм фидакарь дип санаган милләт хадимнәренең шәхси мәнфәгатьләр дигәндә милләткә, аның проблемаларына никадәр гамьсез караганнарын еш күргәнгә, бу асыл төрек шагыйре күрсәткән бөеклек каршында хәйранлык катыш хөрмәт белән иеләбез. Тукаев, Күл Тәгин ташларына чокып язылган, фидакарьлек һәм милләтпәрвәрлек принципларына искиткеч дәрәҗәдә тугрылыгы белән хакыйкый бер төрек баласы икәнлеге күрсәтә!

Тукаев милләтенә яна рух, яңа тормыш өрү өчен көрәшкән чакта очраган һөҗүмнәргә сүзсез генә сабыр итү белән чикләнми, аның яшь һәм куәтле рухы муллаларның җаһиллеге, акылсызлыгын фаш итәр, диндарлыгына тап төшерергә тырышучылардан көләрлек дәрәҗәдә киндер. Бу кинлек аның үз рухыннан түгел, милләтнең яшь һәм таза рухыннан күтәрелә. "Мулланың шикаяте", "Яңа Кисекбаш", "Осуле кадимче"—җаһиллек вә фанатизмга каршы үткен һәм тәэсирле сатира. Элекке заманда үзенең ихтирам ителүен, кая гына барса да сый-хөрмәт күрүен, халык надан булганда, болганчык суда балык тотуын искә төшереп зар елаган мулла—җиһандагы бар гыйлем "Кисекбаш" һәм "Әнвәрел гашикыйн"га сыеп беткән дип инанган чалмалы җаһилләр сыйныфының парлак бер вәкиле. Гаяз әфәнде проза турында сөйләгәндә: "Тормыш-яшәешебезнең якты көзгесе булган әдәбиятыбызда иске-яңа бәрелешенең бөтен этаплары күренә; анда хатын-кыз мәсьәләсе мәйданга чыга, хатын-кызларның хокукларын бетерү һәм саклау тарафдарлары бәрелешә. Анда мәктәп-мәдрәсәләр мәсьәләсе ачыла, кадимче-җәдитче гаугалары күренә, анда хорафат сакчылары белән позитив фән яклылар көрәшә... Кыскасы, проза башыннан ахырынача низаг һәм тартышудан гыйбарәт,"—дигән иде. Тукаев әсәрләре Гаяз әфәнденең әлеге бәяләмәсеннән читтә кала алмый. Сәнгатьнең иҗтимагый файда китерергә тиешлегенә рус һәм алман романтиклары белән бертигез дәрәҗәдә инанган яшь шагыйрь, кайсы темага гына язса да, мотлак рәвештә берәр гамәли файда эзли. Шуна күрә, аның шигырьләрендә баштан ахыргача көрәш, тартыш, хәрәкәт һәм хәят

бар. Тукаевта хисси, шәхси, гыйшык турында язылган шигырьләр юк дәрәҗәсендә сирәк һәм әһәмиятсездер. Асылда, аңа кыйммәт биргән иң төп нәрсә нәкъ менә шушы гайре шәхсилеге, әсәрләренең гавам яшәешенә яхшы һәм тугры көзге булуы, бер сүз белән әйткәндә, гамәли файдасыдыр. Саф сәнгать ноктасыннан карасак, Тукайның урыны күпкә, бик күпкә түбән тәгәрәргә мөмкин!

Шигырьләрен язганда, Шимал төрекләренең барча фикер һәм каләм ияләре кебек үк, сәнгать турында уйлап та бакмаган Тукаев, матди җисеменең зәгыйфьлегенә дә карамастан, гомер юлында очраган кайгы-хәсрәтләр каршында һич кенә дә өметсез түгел. Милләте өстенә яуган бәла-каза вә афәтләрне күтәрә алмыйча, өметсезлеккә бирелеп, дөньяда хаклык юк дигән; хаксыз дөньяда яшәгәнче, Хак Тәгалә хозурына кайтуны өстен күргән бу шагыйрь, пессимизмның яңа аякка басып килгән бер милләт өчен ни дәрәҗәдә агулы бер азык иканен белгәнгә күрә, әсәрләрендә һәрдаим ышаныч, яшәү дәрте, өмет төшенчәләрен алга сөрә. Мәсәлән бер рус шагыйреннән тәрҗемә иткән "Кемнән ярдәм көтәргә" шигырендә кешенең ярдәмне бары үз-үзеннән генә көтәргә тиешлеген әйтә; "Өмид" шигырендә "Чыкчы и фикрем кояшы, китсен өстеңнән болыт!" дип фәрьяд кыла; "Шәкерт яхуд бер тәсадеф"ендә "Аллаһның шәкертләр ризыгын гарантияләвен" шәрык кешесенә хас эчкерсез инанганлык белән әйтсә дә, яшьләрнең милләт өчен бердәнбер өмет икәнлеген, киләчәкнең якты булачагын, тырышканнарның исемнәре алтын белән язылачагын бәян итә. Чөнки бу өметне шагыйрь үз рухыннан түгел, югарыда әйтелгәнчә, милләтнең яшь, гайрәтле рухыннан ала. Көлә-көлә, җырлый-җырлый үлү, Газраилне күргәндә дә башлаган җырыңны өзмичә "Без китәбез, сез каласыз!" дип әйтү, фәкать шул вакытта гына мөмкин.

Габдулла Тукаев әсәрләрендә Русиядә бик тә модада булган социализм һәм анархизм чалымнары бик очрамый. Ул акчасын милләт файдасына сарыф итәргә теләмәгәннәргә каты бәрелсә дә, чаманы югалтмый... "Фикер" матбагасын сатып алып, "гәзитә чыгарачакбыз" дип Тукаевны шактый гына алдап йөргән мәшһүр бай Мортаза Гобәйдуллинга каратып язган шигыре бу җәһәттән бик мәгънәле. Шулай да, мохтаҗлыгын күп кичергәнгәдер инде, алтынга каршы тирән нәфрәтен яшерә алмый. "Алтынга каршы" дип аталган бер шигырендә "Әй Раббым! Бар җиһанны гиздем, моннан да олы бәла, моннан да зарарлы шайтан күрмәдем, җиһан халкы аңа кол булган, хакыйкатьне күрмиләр. Зөһедлек, тәкъвалык, дөреслек, дин, Коръән, Зәбур, Тәурат, Инҗил—барсы да алтын... Әй Аллаһым, җир йөзеннән бу каһәр төшкере мәгъдәнне юк ит!"—дип ялвара.

Яшь шагыйрь Пушкин һәм Лермонтовка, бигрәк тә Пушкинга карата үтә ихтирамлы. Шиллердан, Шекспирдан, Госманлы әдәбиятыннан кайбер икътибаслары булса да, иң күп ияргәне—рус әдәбияты һәм, хосусан, Пушкин. Шигырьләренең беренче җилдендәге "Пушкин" исемле шигырь нәкъ шуны күрсәтеп тора:

*Назыйрсез шагыйрь улдың, афәрин, Пушкин Александр,*
*Бәнем дә дәрд вә шәукым сәнең дәрдеңлә йәксандыр.*
*Сәнең әшгареңә бәнчә агач-таш билә ракъсандыр,*
*Агач ракъс итмәмәк шагыйрь улан инсана нокъсандыр.*
*Ничүн ракъс итмәсен, шигъreң мисале шәмсе рахшандыр,*
*Нә шагыйрьдер у кем шигырь аңа Мәүләдән ихсандыр.*
*Касавәт килүр кальбә сәнең шигъреӊ мөнафиһа,*
*Ничүн кем шәмсә каршы парлайур дөнья вә мафиһа.*
*Кыйраәт әйләдем, әзбәрләдем бән җөмлә асарең,*
*Кереп гөлзарыңа бән дә тәнавел итдем әсмареӊ.*
*Сәнең бакчаңда гиздем, йөредем, әйләдем тайран,*
*Күрүбән гандәлибаның тамаша әйләдем сәйран.*
*Кәлүр рәүнакъ колүбә сүзләреңдән җанә сайкалләр,*
*Дикелмәс бөйлә улмадыкча һичбер намә һәйкәлләр.*
*Мәрамым, матлубым анчак сәнең мәнзум вә мәнсурың,*
*Бәнем шәэнемме тәфтиш мәзһәбең, дине мәнсубың.*
*Әвәт, дәрд мөдәррәр йәксан вәләкин бәндә юк дәрман,*
*Вирер дәрманы да шаять Җәнабы мән ләһүл фәрман.*

Чамадан тыш хиссилектән, хыял байлыгыннан мәхрүм булган Габдулла Тукаевның шигырьләрендә темалар, югарыда әйтелгәнчә, нинди дә булса берәр гамәли файдага ия; күңелнең самими һәм максатсыз дулкынланулары, табигать гүзәллекләре аның әсәрләрендә һичнинди урын тапмаган. Шагыйрьнең иң мөһим, сәнгатьлелек ягыннан иң камил әсәре милли бер легенданың, урман париләреннән булган “Шүрәле”нең тезмә хикәясеңдер. Тәнкыйтьче Әхмәтзәки әфәнде тикшерүләренә караганда, бу легенда халыкның элеккеге мәҗүсилек чорыннан калган бер хикәя икән. Шүрәле урманнарда кешеләрне алдап, озын һәм очлы тырнаклары белән кытыклап үтерә икән. Бервакыт берәү бу паридән акыллырак булып, аның озын, хәтәр бармакларын кыстырган. Тукаев халык арасында “Былтыр кысты” исеме белән билгеле булган менә шул хикәяне гади һәм табигый бер рәвештә, бераз гына сәнгатьчәләп шигырьгә әйләндергән. Йөз утыз юлдан торган бу хикәя биш кисәккә бүленеп, бигрәк тә беренче кисәкләрдә табигать гүзәллеге һәм урман манзаралары— шагыйрь Сүнчәләй белдергәнчә—Шимал төрек шивәсенең бөтен куәте белән тасвирланган. Ак, кызыл, сары, яшел төстәге чәчәкләре, матур тавышлы кошлары, өркеп качарга гына торган киек-җәнлекләре белән руханилашкан бу чиксез урман, Шимал төрекләренең караңгы язмышына карап һәрдаим сыктаган шагыйрьдә борынгы Төрек рухын кузгатып җибәргән булса кирәк, аны тасвирлаганда ул: “Зур бу урман: читләре күренмидер диңгез кеби. Бинһая, бихисаптыр, гаскәре Чыңгыз кеби!”—горурлануын яшерми. Гомумән алганда, салкын һәм гайре шәхси позиция тоткан Тукаевның “Шүрәле”дә яхшы гына сурәтләү куәсе белән азмы-күпме лиризм күрсәткән булуын нинди факторларга сылтарга, анысын тәгаен белмим. Һәрхәлдә, сәнгать әсәре булу җәһәтеннән Тукаев моннан да камилрәк нәрсә иҗат итмәгән булса кирәк. Мөгаллим Әхмәдзәки әфәнде бу әсәр хакында “Мәктәп” мәҗмугасында бастырган бик мөһим бер мәкаләсендә, мөгаллим Катановның тикшеренүләренә нигезләнеп, Идел буе төрекләрендә, русларда, фин-угырларда бу типтагы легендалар булуын билгеләп үткәннән соң, аның шәкел вә өслүбе хакында озын-озак итеп сөйли. Су париләре, урман париләре, диңгез париләре бөтен борынгы кавемнәрдәге кебек, төрекләрдә дә бар. Хәтта мин үзем Фатих Солтан Мөхәммәд дәверенә кадәр яшәгән Госманлы шагыйрьләрендә бу иске карашларны чагылдырган нәрсәләргә бик күп юлыктым. Тукаев бу легенданы берни дә өстәмичә, ничек бар шулай тасвир итеп, бик мәгъкуль эш кылган, шулай итеп ул үзенә яңа һәм бай бер илһам чыганагы тапкан. Әмма аның бу хосуста да рус сәнгатьчеләренә ияргәнлеге күренеп тора.


تورك يوردى

عبدالله توقايف

*Габдулла Тукай турындагы әлеге мәкаләнең “Төрек йорды” журналында басылган бите.*

Шимал төрекләренең бөтен язучылары, шагыйрьләре кебек, фәкать халык, гавам, авыл кешеләрен генә кайгырткан, шуңа күрә югары сәнгатькә якын килмәгән Габдулла Тукаев хакында әйтелгән тәнкыйтьләрне, бу яшь әдәбиятка тулаем юнәлтергә мөмкин. Яшь шагыйрьдәге өстенлек һәм кимчелекләр Шимал төрекләренең бөтен каләм әһелләрендә теге яки бу дәрәҗәдә хас. Беренчедән, халык теле нигез итеп алынганга, Муса әфәнде Бигиев “Халык назарына берничә мәсьәлә”дә бик хаклы рәвештә билгеләп үткәнчә, тел ягы дөрес һәм саф булып бетә алмый. Якын арада мөстәкыйль бер мәкаләдә бу мәсьәләне аерым алып тикшерү ниятем булганга, монда шуны гына әйтәсем килә: төрле төбәкләрдә яшәгән төрекләрнең үз шиваләрен әдәби тел итәргә маташулары, демократлыкка туры килсә дә, киләчәк өчен зарарлы: бу анархия гомуми, уртак, бай бер гыйлми вә әдәби телнең барлыкка килүенә олы киртә булачак. Аннан соң, Шимал төрекләренең яшь

әдәбияты әлегә артык яшь булганга күрә, примитив һәм башлангыч формада гына, анда югары сәнгатькә ихтыяҗ тумаган әле. Ләкин тел вә әдәбият камилләшә барган саен, үсеш кануннары таләп иткәнчә, анда да хакыйкый сәнгатьияләре, өслүбчеләр, кыскасы гамәли файдадан бигрәк сәнгатьнең үзе турында уйлый торган адәмнәр житешәчәк. Асылда, сәнгать турында уйлау гамәли файдадан бөтенләй баш тарту дигән сүз түгел, алман һәм рус романтиклары бу хосуста матур үрнәк була ала.

Шимал төрекләренең әдәбиятында назым (поэзия) бигрәк примитив хәлдә яшәп килә. Бу шул дәрәҗәдә ачык ки, хәтта мин мәсәлән Тукаевны укыганда, вәзеннең аһәңе, телнең вәзенгә салынмавы җәһәтеннән үземне Гашыйк Паша "Мәгърифәтнамә"сен укыгандай хис иттем. Моңа бер чара табу җәһәтеннән, Идел буендагы мәсләктәшләремә кечкенә генә бер киңәшемне җиткерәсем килә: без гаруз вәзене белән инде алты йөз еллап эш итсәк тә, аны чын мәгънәсендә үзебезгә җайлаштыра алмадык. Шимал төрекләре телебезгә ят булган вәзенне кулланып азапланганчы, милли җырларының табигый вәзене булган иҗек үлчәмен куллансалар, әлбәттә, мәгъкуль эш кылган булырлар. Бу эш демократлык (халыкчанлык) фикеренә муафыйк булган кебек, сәнгать вә аһәң ягыннан да файдалы. Ималә (вәзенне саклау өчен иҗектәге авазларны махсус рәвештә сузу) вә зөхафлар белән тулы дүрт фәгыйләтен вәзене унберле яки уналтылы иҗек үлчәменә караганда аһәңсезрәк, хәтта колакны тырныйдыр!

Гомумән алганда, боларның барысы да зарури нәрсәләр, һәр яшь әдәбият үтәргә мәҗбүр булган көчеш этапларына хас житешсезлекләр. Бу этапларны яшь, куәтле һәм җанлы сурәттә үткәргән, Тукаев кебек олуг һәм фидакарь шәхесләр житештергән әдәбият, һәрхәлдә, бик ныклы нигезгә корылган дигән сүз. Төньяктагы ыругдашларыбызның киләчәктә бик көчле мәдәниятькә ия булачагын күрсәткән бу сөенеч галәмәтләре, өметсез һәм кайгылы кальбләребезне иң караңгы көннәребездә дә дәртләндерә һәм, барлык авырлыкларга да карамастан, сүнмәгән гайрәтебезне куәтләндерә. Бөек милли шагыйрьләре Габдулла Тукаевны югалту ачысы мөнәсәбәте белән язган шушы кимчелекле, ләкин эчкерсез юлларны камиллеккә ирештерү өчен, ай-йолдызлы байрак астында гомер сөргән төрек кардәшләрегезнең, бу олы югалту уңаеннан, Идел буендагы туганнарының кайгысына уртак булу теләкләрен җиткерәм.

*13 май, 1329 (1913)*

**Имза (Мөхәммәд Фуад)**

*Татарчага Наил Вахитов тәрҗемә итте.*

# ТУКАЙНЫ ПИТЕР ДӘ ОНЫТМЫЙ

Петербург—биниһая зур Рәчәй империясенең ике гасырлык башкаласы—ил һәм андагы халыклар, кешеләр тормышында гаять мөһим роль уйный. Мәгълүм ки, күп нәрсәләр пайтәхеттә хәл ителә, сәясәт шунда билгеләнә. Шуна күрә Тукай язмышы да, аның туган халкы—татар тереклеге дә шактый дәрәҗәдә мәмләкәт башкаласына бәйле. Шагыйрь Петербургта чыккан күп кенә гәҗит-журналлар, китаплар белән танышып бара, андагы сәяси, иҗтимагый, мәдәни вакыйгалардан да хәбәрдар була.

Болардан тыш Тукай 27 еллык гомереннән 13 көнен Рәчәй башкаласында уздыра. Аның биредә Уфадан Мәскәү аркылы поезд белән 1912 елның 20 нче апрелендә килеп төшүе мәгълүм. Шагыйрь "Мәкаләи махсуса" язмасында (1912) үзенең Петербургта булуы, тәэсир-кичерешләре хакында кызыклы гына факт-мәгълүматлар бирә (Әсәрләр: 4 томда.—IV том, 1977. 189-211 б.). Шулай ук Кәбир Бәкер, Кәрим Сәгыйд һ.б.ларның истәлекләрендә дә Тукайның пайтәхеттәге көннәре гәүдәләнеш тапкан (Тукай Петербургта.—С. Петербург, 1998.—54 б.). Бу язмалардан күренгәнчә, шагыйрь Рәчәй башкаласына берничә чакыру ала. Аларны күренекле рухани, галим, педагог Муса Бигиев (1875—1949) оештырып җибәрә. Чакыруның сәбәбен ике төрле аңлату бар: а) "Хәбәр" (яисә "Сүз") исемле гәҗит чыгару, шуна Тукайны баш мөхәррир итү; б) Шагыйрьне дәвалау, укучылар белән очраштыру, Финляндиягә санаторийга җибәрү. Боларның соңгысы чынбарлыкка ныграк туры килә.

Тукай үзенең кайчан киләсен, мөгаен, алдан хәбәр итмәгәндер. Аны беркем дә каршы алмый. Вокзалдан ул извозчик белән туп-туры Муса Бигиев яшәгән Сергеевский урамына (81 йорт. Хәзерге Чайковский) юнәлә. 4-5 бүлмәле фатирда—5 бала, ата-ана, өстәвенә хуҗаларның ике туганнан туганы. Барлыгы—9 кеше. Тукайны хуҗа үзенең эш кабинетына урнаштыра.

Бу хакта шагыйрь болай яза: "Муса әфәнденең үзе ята торган караватында мин авырып, йөткереп, гадәт буенча папирус тартып ятам". Тукай уңайсызлык кичерә. 4-5 көннән соң "Нур"ның баш мөхәррире Сафа Баязитов (1887—1937 дән соң), дусты Кәбир Бәкер ярдәмендә "Казанская" кунак йортындагы аерым номерга күчә. (Ул Казанский собор артында гына).

Петербургның язгы юеш һавасы авыру Тукайның хәлен тагын да авырайтып җибәрә. Булачак юрист, сәясәтче, журналист, ул вакытта Петербург университеты студенты Шакир Мөхәммәдъяров (1883—1967) тырышлыгы белән шагыйрьне университетның "бик яхшы докторы" Польнега күрсәтәләр. Табиб авыруны бик игътибар һәм ихтирам белән карый. Тукайны юату сүзләре әйтә, аңа кымызга барырга киңәш итә. Доктор исә Шакир Мөхәммәдьяровка болай ди: "Туберкулезның соңгы дәвере, бер үпкәсе... череп беткән, икенче үпкәсенең дә яртысы гына калган. Тын ала торган әгъзаларының дүрттән бере генә тын алып тора". (Шуннан соң да әле Тукай елга якын яши. Үзе бер могҗиза!)

Шагыйрь, хәле авыр булуга да карамастан, гомумән, кешеләргә сер бирмәскә тырыша: сөйләшә, шаярта, тәнкыйтьли, ... йөри. Петербургта да ул татар зыялылары, студентлар, журналистлар белән очраша. Сафа Баязитов фатирларында (6 нчы Рождественская—хәзерге Советская урамы; Мойка, 22 йорт) була. Берничә мәртәбә "Нур" гәҗите редакциясенә бара (Петроград ягы, Большой проспект, 45). Биредә журналистлар белән әңгәмә кора, гәҗит чыгаруда да булыша. Муса Бигиев белән дә аралашып тора. Финляндиядәге милләттәшләребез Тукайны үзләрендә санаторийга урнаштырырга ниятлиләр. Әмма юеш һавадан иза чиккән шагыйрь, кымыз вакыты житте дип, Петербургтан китеп бара. Аны вокзалда 25-30 лап кеше, шул исәптән Сафа Баязитов, Лотфый Исхаков һ.б. озатып кала. Кәбир Бәкер шагыйрь белән Мәскәүгә кадәр бара һәм Тукайны Рязанский вокзалдан Уфага утыртып җибәрә. Шуннан шагыйрь Троицк тарафларына—кымызга юнәлә.

Тукай язмаларында Рәчәй пайтәхетенә каршылыклы мөнәсәбәт күзгә ташлана. Әйткәнебезчә, шәһәрнең юеш, дымлы һавасы шагыйрьне изә. "Петербургның

суыгы,—ди ул,—гыйнвар суыгы, сыросте-сырость иде. Шунлыктан... урамга чыгу мина газап иде". Невский проспект аны "гаҗәпләндерә дә, куркыта да". Аны юкка гына шагыйрь "Байлар урамы ул! Шомалар урамы ул!"—дими. Шуның белән бергә Тукай Питерның чиста, тигез урамнарына, биек, матур йортларына, мәдәни истәлекләренә соклана, аны "Сәйфелмөлек кыйссасы"ндагы "пәриләр шәһәре" белән дә чагыштыра. [Минем бу калада күп мәртәбәләр булганым бар. Андагы затлы сарайларны, искитмәле бина-корылмаларны карап йөргәндә, минем күнелгә һәрчак бер уй килә: болар бит бөтен Рәчәй хисабына, шул исәптән минем халкым хезмәтенә корылган. Нинди контраст, гаделсезлек: монда байлык, зиннәт, илдә коточкыч фәкыйрьлек, артталык!]

***

Бөек шагыйрьнең Петербургта булуына, якты дөньядан китүенә дә инде 90 елдан артык вакыт узып китте. Әмма Төньяк башкала, иң беренче чиратта, анда яшәүче милләттәшләребез Тукайны онытмый, аны искә төшереп тора. Гаяз Исхакый Питердә нәшер кылган "Ил" гәҗитендә бөек шагыйрьне зурлап, сөеп язылган мәкаләләр, шигырьләр басыла. Октябрь алды һәм аннан соңгы елларда бу калада Тукайны искә алу кичәләренең уздырылуы мәгълүм. Төньяк башкалада гомер кичереп, инде мәрхүм булган Габдрахман Таһирҗанов, Энҗе Сәгыйдова, Әнәс Халидов, Дәниф Шайхразиев һәм кайбер башка зыялыларыбызның шагыйрь әсәрләрен яттан сөйләүләрен минем үземә дә берничә мәртәбә ишетергә туры килде.

Тукайга Петербургта ярдәм итүчеләрнең берсе—Кәрим (Габделкәрим) Садыйк (1888—1939). Ул журналист, педагог, күп кенә татар зыялыларының якын дусты. Бу мөхтәрәм затның кызы Энҗе ханым Сәгыйдова (1921—1997) озак еллар буе Ленинград-Петербургтагы Салтыков-Щедрин исемендәге мәшһүр китапханәнең милли әдәбиятлар бүлеген җитәкләде, татар әдәбиятын, шул исәптән Тукай иҗатын укучыларга җиткерүдә дә гаять зур эш башкарды. Аның Тукайны өйрәнүгә багышланган бай эчтәлекле хезмәтләре дә бар.

Узган гасыр азакларыннан башлап Тукай белән кызыксыну тагын да көчәйде. Шагыйрь яшәгән кунак йортына истәлек тактасы куелды. Очрашуларда, кичәләрдә Тукай шигырьләре укыла, аның сүзләренә язылган җырлар башкарыла. Мәгълүм ки, Петербург шәһәре һәм Ленинград өлкәсе татар җәмгыятьләре тарафыннан татар һәм урыс телләрендә инде менә берничә ел буена "Нур" (баш мөхәррире—Әлфинур Гафурова) һәм "Нур—Петербург" (баш мөхәррире Ринат Мәһдиев) гәҗитләре чыгып килә. Аларда иҗтимагый, милли-мәдәни тормышка кагылышлы материаллар белән бергә, Тукай шигырьләре, бөек шагыйрьгә мөнәсәбәтле язмалар да даими басылып тора.

2006 елда, шагыйрьнең тууына 120 ел тулу уңае белән, Санкт-Петербург милли-мәдәни тормышында мөһим бер вакыйга булды: шәһәрнең Петроград тарафындагы бер скверында бөек Тукайга һәйкәл ачылды [Ул Зверинская урамы һәм Кронверский проспектлары чатында. "Татар тыкрыгы" да янәшәдә. Җәмигъ мәчет тә ерак түгел. Элек бу тирәләр «Татар бистәсе» дип йөртелгән]. Бу Төньяк башкалада матур бер башлангычның тууына китерде: инде менә өченче ел Тукай көннәрендә шәһәр һәм өлкәнең татар җәмәгатьчелеге һәйкәл янына җыела. Узган елның 27 апрелендә үткән бу чарада безгә дә катнашу насыйп булды. Аны төп оештыручы—Татарстанның Санкт-Петербург шәһәрендәге һәм Ленинград өлкәсендәге вәкиллеге. Шигъри митингта Татарстан вәкиллеге җитәкчесе Шамил әфәнде Әхмәтшин, шәһәр хакимиятенең тышкы элемтәләр бүлеге башлыгы урынбасары, каланың Җәмигъ мәчете имамы Җәгъфәр әфәнде Панчаев, без фәкыйрегез һәм башкалар чыгыш ясады, шагыйрьнең бөеклеге, иҗатының бүгенге көнгә дә аваздаш булуы ассызыкланды. Күп кенә мөхтәрәм затлар, зыялылар катнашкан бу чарада шагыйрьнең шигырьләре сөйләнде, җырлары башкарылды, җирле әдипләр дә үз әсәрләрен укыдылар. Тукай һәйкәленә күпсанлы чәчәкләр куелды. Шигъри бәйгене М. Горький исемендәге Мәдәният сарае директорының урынбасары, фән кандидаты Әнҗәп Гыйбадуллин алып барды. Ахырда очрашу-аралашулар булды. Мин Казаннан алып барган китапларны, гәҗит-журналларны кызыксынучыларга бүләк иттем.

Тукайны искә алу төрле формаларда башка урыннарда да узган. «Изге юл» исемендәге татар җәмгыяте җитәкчесе Гыйниятулла әфәнде Кутуев, мәсәлән, Ленинград өлкәсендәге Тосно шәһәрендә бөек шагыйрьгә багышлап бик матур

кичә, «Тукай укулары»н уздыруы хакында сөйләде.

Шигъри митингта мин Тукай һәйкәле авторларынын берсе Әхнәф әфәнде Зыякәев белән дә очраштым. Чыгышы белән ул Нефтекамск каласыннан икән. Ленинградтагы Репин исемендәге сәнгать Академиясен тәгәлләгән, бирелә кала. Профессиональ рәссам, скульптор. Билгеле шәхес. Ул ижат иткән Тукай һәйкәле шактый мәгънәле, күркәм чыккан. Шагыйрь бер кулы белән тамагын тоткан (тыны бетә, сулыш авыр алу), икенче кулында—китап. Ин мөһиме—Тукайнын күз карашы, йөзе. Аларда бу шәхеснен бөек рухы, көчле омтылышы гәүдәләнә.

Санкт-Петербургта милләтебез тормышына, Татарстанга кагылышлы кызыклы гына китаплар язылып, басылып тора. Узган ел гына жирле шагыйрә Вилия Хәлиуллина-Живаеванын татар һәм урыс телләрендә «Голос сердца» («Йөрәк авазы») исемле шигырьләр жыентыгы (252 б.) дөнья күргән. Анда аерым шәхесләргә, шул исәптән Тукай һәйкәле авторы Әхнәф Зыякәевкә багышланган шигъри юллар да бар. Моннан берничә ел элек Лилия Насибуллина «Голос неба» исемле фәлсәфи поэмасын бастырган. Ш. Әхмәтшин һәм Ш. Насыйровлар язган «Татары на службе отечеству» китабында *(С.—Петербург, 2005. 159 с.)* милләттәшләребезнең Россия хәрбидингез флотындагы эшчәнлекләре тарихи планда яктыртыла. Питерда туып-үскән, укыган һәм хәзер дә шунда яшәүче Рәхим Теляшев үзенең күп санлы мәкалә-хезмәтләре («Золотая Орда: полемические заметки», «От индейцев и гуннов до Золотой Орды», «Татарская община Санкт-Петербурга...» һ.б.) белән укучыларга яхшы таныш. Анын 2005 елда дөнья күргән «Татары в Великой Отечественной войне и блокаде Ленинграда (К 60-летию Великой победы и 1000-летию Казани)» китабы (575 б.) гаять кызыклы фактмәгълүматларга, иллюстрацияләргә бай. Анда күп кенә татар генераллары, адмираллары хакында очерклар да бар. Санкт-Петербургнын нигезләнүенә 300 ел, Казаннын меңъеллыгына багышлап Төньяк башкалада зур форматлы «Два города—две судьбы. Ике шәһәр—ике язмыш» исемле искиткеч китап басылып чыккан. Рус һәм татар телләрендә язылган бу китапта ике шәһәр тарихына, аларнын үзара мөнәсәбәтләренә, мәдәнияткә мөнәсәбәтле язмалар урын алган. Зәвык белән эшләнгән бу басмада күптөрле рәсем-сурәтләр, иллюстрацияләр урын алган. Кызганыч, бу зиннәтле китапны мин Питерга баргач кына күрдем. Аны миңа Татарстан вәкиллеге бүләк итте. Рәхмәт үзләренә!). Соңгы елларда, гомумән, Төньяк башкалада татарлар турында, аларнын тарихына, әдәбиятына, мәдәниятенә кагылышлы башка төрле басмалар да нәшер ителеп тора.



*Хатыйп Миңнегулов һәйкәл авторы Әхнәф Зыякәев (уңда) белән. Петербург. 2008 ел.*

Санкт-Петербург төбәге татарларында теге яки бу дәрәҗәдә милли аң бар. Һәм ул үсә, көчәя бара. Төрле, кызыклы чаралар уздырыла, милли гамәлләр башкарыла. Әмма аларны иң борчыган мәсьәлә—тел проблемасы. Үзара күбрәк урысча сөйләшкәннәрен, сөйләмнәрендә урыс сүзләрен катнаштыруларын алар үзләре дә аңлый. Димәк, бу авыр мәсьәләнен унай якка хәл ителүенә өмет бар.

**Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,**
*филология фәннәре докторы, КДУ профессоры.*
*Май 2008 ел.*

# ГЫЙБРӘТЛӘР АЛАСЫ БАР...

Бер тапкыр да күрмәгән, иҗатын юньле-башлы белмәгән көе, танылган рус язучысы Роман Солнцев турында сүз әйтергә дип кулыма каләм алмаган булыр идем. Әгәр ул 70 яше тулганчы барыбызга да уртак Ходай каршысына китеп өлгермәсә... Әгәр арабыздагы бер очраклы "кыска ялганыш" ("короткое замыкание") турында, әлеге юбилее якынлашкан көннәрдә искә төшереп, "Казан утлары"нда эшләүче дусларның берсенә сөйләмәсәм... Әгәр дә каләмдәшем: "син моны яз әле, исемен үзем куярмын: гыйбрәтле кыйсса бит",—димәсә...



Ринат Суфиев булып туган, Роман Солнцев булып иҗтиһад иткән бу талантлы шәхеснең иҗаты белән бер мин генә түгел, тагын байтак милләттәшләребез тирәнтен таныш түгелләр. Гәрчә заманында аның "Көймә ватылса—утын" ("Лодка пойдет на дрова") дигән әсәрен Рәис ага Даутов туган телебезгә тәрҗемә итеп бастырды, матбугатта шул хакта уңай фикерләр әйтелде. Кыскасы, бу язучыны ихластан "үзебезнеке" дип тану-таныту омтылышы булган иде.

Башка халыкка туфрак булган кан-кардәшләребезне үз итеп җиткерә алмауны мин шәхсән дөрес аңлыйм. Әмма "болай да бай" булганга, Солнцевлар гына түгел, Акмулласы, Мәҗит Гафурие да кирәкми, татарга без бик җиткән дип, бүксә киерүне генә кабул итә алмыйм. Бүгенге "бөек"ләргә кояшны алар капламый лабаса! Зирәк халыклар, бабасы—эфиоп, хатыны—яһүд, ә үзе татардан "азган" дип, галимен дә, язучысын да, амбразура авызын каплаган каһарманын да читкә тибәрми,—әлбәттә, кавеменең, иленең дәрәҗәсен күтәрә торганнарын.

Ярый, бусы—сүз җаеннан гына әйтелгәне.

Англиядә эшләүче татар язучысы Равил Бохараев Тукайның 100 еллыгы алдыннан интернет аша хәбәр салды (аның белән "виртуаль" аралашкалап, сирәк булса да күрешеп яшибез). "Миңа Красноярскидан Роман Солнцев шигырь язып җибәргән. Тукай юбилее якынлашканда, күрәсең, ул Ринат Суфиев булып уянган",—дип язган Равил. Шунда ук Р.Солнцевның кыска гына хатын да теркәгән. Мәсьәләнең асылына кагылганлыктан, аны төп нөсхә телендә китерү дөрес булыр:

*Дорогой Равиль! Посмотри эти простенькие стихи. Не сможешь ли перевести их на татарский, если они достойны, на твой взгляд, встать в ряду многих других стихов в честь нашего великого Тукая? Если получится, я был бы счастлив,—отдай их или перешли в Казань, в ТАТАРСКУЮ газету (зур хәрефтән үзе язган). На торжество 26 апреля прилететь не смогу—прямых самолетов нет, а наша бабушка больна, сидим с Галей по очереди дома...*

Равил, юбилейга бер-ике генә көн калуын искәреп: "Билгеле, бик соң инде... шулай да, бу шигырьне күршегездә генә булган "Мәдәни җомга" гәзитенә бирсәң, бәлки әле берәрсе тәрҗемә итеп өлгерер",—дип өстәгән. Югыйсә, ул язда үзенең мәшәкатьләре баштан ашкан... Барыбер каләмдәшен кайгырта: бәйрәмгә бер кучтәнәч, Роман дуска юаныч булыр иде, ди.

Инде шигырь текстына күз салыйк:

## Улица Тукая

**Нет самолетов до Казани!
Да как же мне теперь успеть?
Лишь с неба птичьими глазами
на гордый город посмотреть.
Увидеть, как встают мечети,
церквушки из зеленой мглы.
С утра сегодня даже дети
стихи читают Габдуллы.**

**Сегодня старики, студенты
учителя, рабочий люд
идут с цветами к монументу,
стихи твердят, стихи поют...
Нет самолетов до Казани!
Но и в Сибири есть Тукай!
О нем татары рассказали,
и нежно пел о нем курай.**

**Что за поэзия такая,
что веет сквозь века светло?
Я жил на улице Тукая—
и мне, мальчишке, повезло.
Читал его стихи, мечтая
прославить камские края.
Теперь на улице Тукая
живут сестра и мать моя.
Да все мы—истина святая—
кто жаждет родине служить,
живет на улице Тукая
или хотя б мечтает жить!
Она же—Пушкина и Блока,
Джалиля улица... на ней
Дердменд метался одиноко
и пел Такташ, как соловей.**

**Есть много всяких разных улиц—
во славу денег и войны,
но только эта протянулась
во всю длину моей страны.
Шумя лесами на раздолье,
поставив храмы на крови,
напоминает нам, что воля
рубля не стоит без любви!**

**Без совести—и жизни нету.
А без труда—нет ничего...**

**Поклон великому поэту
с сибирской улицы его!**

"Мәдәни җомга" егетләре, шигырьне укып та тормастан, безнен ул сан күптән әзер инде, дип котылдылар. Аларга үпкәләп булмый, чыннан да бик соң исенә төшкән шул Солнцевның... "Ватаным Татарстан" газитенә сүз катып карарга туры килде. Монарчы да анын әдәбият-сәнгатькә житди мөнәсәбәте белән танылган абруйлы басма иканлеге мәгълүм иде. Рәхмәт Асия ханым Юнысовага: юбилей санын без дә тапшырдык тапшыруын, шулай да, татарчага "аударттырып" хәзер үк китерсән, 28 апрельгә куеп булыр, диде (һәм сүзендә торды). Шундый чакта тиз генә "аударырга" әзер торучысын табып булмый бит. Кыскасы, Красноярдан Лондон аша урап Казанга кайтып ирешкән әманәт минем жилкәгә кучте дә куйды (югыйсә миндә дә Солнцев кайгысы мыни инде?). Үземнен кайчандыр шигырь язып караганымны искә төшерергә туры килде. Билгеле, саф тәржемә үк түгел, шигырьне озатып йөрүче хаттагы рухны гына азмы-күпме чагылдырырга омтылган экспромт-"инша" булып чыкты.

*Роман Солнцев*
*(Ренат Суфиев)*

## Тукай урамы

**Кайда яшәсә дә халкым,
Туган телгә сыена.
Тукай урамы сузыла
Бөтен илем буена.
Очып кына кайтыр идем,—
Казанга юллар ябык.
Ничек кенә кайтыйм икән,
Нинди әмәлләр табып?!
Миңа юл күрсәтер иде
Сөембикә-манара,
Биектән, кош күзе белән
Карар идем**

Калама...
Бу—минем Рухым кальгасы,
Таныйм әллә кайдан ук.
Шигырь телендә сәламлим
Бүген Ирек мәйданын.

Бүген Казан урамнары
Тукай белән уяна.
Бүген Пушкин урамыннан
Тукай дәшә дөньяга.
Тар хәятым читлегеннән
"И Туган телем" чыга.
Анда язгы бөреләр дә
Саф татарча ачыла.

...Ничек кайтыйм арагызга?
Себер урманнарыннан
Адашмый чыгар идем лә
Казан урамнарына,—
Юлым ябык, ара ерак,
Чарам юк. Үткәнемә
Хәтер генә тоташтыра
Өзелгән җепләремне...
Мин дә бит татар малае,
Мин—Тукай урамыннан.
Әле дә сеңелем белән
Әнием тора монда.
Тукайлы сабый чагым—ул
Төшемдә йә уемда.
Тукай урамында яшәп
Калдым гомер буена.
Бу—Шигърият урамы ла,
Бу—Туган тел урамы.
Гөрләвекләр саф татарча
Челтерәп ага торганы!

Очып кына кайтыр идем...
Искән җилдән көнләшәм:
Исә ул Казан ягына,
Ә мин аңа эндәшәм:
"Кабул ит тә шигыремне,
Илт бәйрәм табынына:
Ул минем горурлыгым да,
Илемне сагыну да.
Әйт: улың яши Себердә
Тукай урамы булып".
...Язгы күбәләк терелә
Саф татарча кагынып.

Май башында Равил Бохарай миңа Солнцев-Суфиевтан алган тагын бер хатны җибәрде:

*Равиль, салям! Конечно, я рад, что Мударис перевел мое стихотворение. Если не трудно, пусть перешлет его моей маме, а я летом буду у нее. Сам сейчас улечу на Север... Адрес же мамы такой: Татарстан, Нижнекамск, ул. ТУКАЯ, <...> Ахметовой Салихе Мадьяровне (монда да "Тукай" сүзен зур хәрефтән үзе язган).*

Бүтән мәгълүматым юклыктан, "мечтая прославить камские края" дигәненә игътибар итмәстән, Р.Солнцевның әнисе белән сеңлесе (бәлки апасы?) Казанның Тукай урамында яшидер, дип уйлаган идем. 28 апрель гәзитен күрсәтелгән адрес буенча Түбән Камага җибәрдем. Каршы җавап килмәде, әмма барып ирешкәндер, дип уйлыйм. Улының шигырен үз телендә укыгач, Салиха апаның күңелен нинди кичерешләр биләде икән?

Лондон аша килеп ирешкән әлеге хатында Р.Солнцев, үз дәрәҗәсен белеп кенә, таныш түгел тәрҗемәчегә рәхмәтен дә сиздергән иде:

*А вообще пришлет пусть мне что хочет—для журнала. Могу ему и я книжку свою какую-нибудь переслать, если сообщишь мне его адрес. Мой адрес: 660036 Красноярск-36, а/я 8636, Роману Харисовичу Солнцеву.*

Билгеле, "почта әрҗәсе" белән элемтәгә керүне мин кирәксенмәдем. Р.Солнцевтан автографлы китап алу яки аның шактый популяр рус әдәби журналында баш редактор икәнлегеннән файдалану ихтыяҗым юк иде. Бары тик аның әтисе дә, минеке кебек үк, Харис исемле булганына гына игътибар иттем.

Шул җәйне ул, хатында ниятләгәнчә, Түбән Камага, Тукай урамына кайткандыр, әнисенең бәхиллеген алып киткәндер дип ышанасы килә...

Чөнки Красноярскидагы 8636 санлы әрҗәдән хатларны укырга хәзер Роман Харисович юк, ул үзе дә, хәтта "юллар ачык" булса да, быелгы Шигырь бәйрәменә кайта алмас инде...

**Мөдәррис ВӘЛИЕВ**

***

Мөхтәрәм Мөдәррис Вәлиевнең журналыбызга тәкъдим иткән бу язмасы мине дә битараф калдырмады, хатирәләр яңартуга сәбәп булды. Язмада безгә мәгълүм булган конкрет шәхесләрнең конкрет бер гамәлләре турында сүз барса да, уйлана китсәң, фикер мантыйгы проблемалы аерым бер зур темага этәрә: ул – бер милләт баласы булып туып та, икенче бер милләт телендә иҗат иткән (яки мәҗбүр булган) каләмдәшләр темасы. Алар бездә байтак. Шуларның берсе – Ренат Суфиев (Роман Солнцев). Ходай гомер һәм мөмкинлек бирсә, татар булып рус телендә иҗат иткән замандаш язучылар, аларның "йолдызлы сәгатьләре" һәм фаҗигалары турында иркенләбрәк язарга ниятем дә бар. Роман Солнцев – 60 нчы еллардан бирле аралашып, хатлашып яшәгән ватандашым. Архивымда аның байтак хатлары саклана. Форсаттан файдаланып, 70 еллык юбилеен да истә тотып, аның соңгы хатларының берсен укучыларга тәкъдим итәм. Минемчә, үкенү дә, үпкәләү дә, сагыну-ностальгия дә, әрну дә җитәрлек ул хатта.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**
*1 март 2009 ел*

*Дорогой Равиль, здравствуй!*

*Вот миновал год, как мы красиво отпраздновали твой юбилей и говорили о том, что и мне тоже пора бы - хотя бы книгами - вернуться на Родину...*

*Вот миновало два с половиной года, как я получил письмо от какого-то референта Шаймиева, что бабай говорил, что надо бы Солнцева издать в Казани... но увы, все тут же забылось... А еще лет пять назад Мухамадиев обещал, обнимал, клялся... И я начинаю понимать, что в наше время все заняты только своими личными делами. Что некогда отдавать дорогое время на других людей. Да еще и бумагой делиться, деньгами... издательств мало, а писателей много... а еще есть пословица: с глаз долой - из сердца вон.*

*И если я печатаю в журнале десятки поэтов и прозаиков из Татарстана, пишущих на русском и просто русских, то делаю это из неистребимой ностальгии по Родине и еще, наверное, из неистребимой глупости. Ты издаешь журнал при поддержке государства, бюджета - это совсем другое, нежели я, - мне приходится на доброе дело выпрашивать деньги у бизнесменов... зато, правда, через интернет наш журнал читает сейчас полмира... Но я ведь устаю.*

*Устаю от этой гонки, от чужих пустых обещаний. Может быть, когда умру, в Казани и в самом деле издадут тоненькую книжку Р. Солнцева... а может быть, и нет... И я уже сегодня хочу сказать, дорогой друг, что освобождаю всех, кто мне что-то обещал, от их обещаний. Такая, видно, нынче жизнь волчья. Всегда можно оправдаться тяготами этой жизни. Так что забудь и ты, Равиль, что обещал с кем-то поговорить, кого-то уговорить. Если за год не нашел пяти минут, чтобы встретиться с Валеевой, то и дальше не найдешь. Поклон твоей чудесной жене! Обнимаю. Всего тебе доброго!*

*Ренат.*
*15 февраля 2005*

***P.S.** В «Новом мире» выйдет нынче еще один рассказ, связанный с Татарстаном, - «Тулуп». Его, наверное, и в газете «Республика Татарстан» напечатает Ольга Стрельникова - почитаешь?*

Тәфкил
Вафин

# МӘКРУҺЛАР

## Татар "декабристкалары"

Алда әйтелгәнчә, 1867 елның апрель аенда Казан губернасыннан берничә этап мәкруһлар Турухан краена озатыла. Аларның төп өлеше Зөя һәм Тәтеш өязеннән. Зөя төрмәсендә ябылып ятканнарның хатыннары күп мәртәбә төрмә капкасы янына килүнең файдасы була, алар бер-берсе белән танышалар. Шул капка янында алар ирләрен Себергә җибәргән очракта хәләл җефетләре артыннан китәргә сүз куешалар. Шундый теләктә торучы хатын-кызлар шактый була.

Татар "декабристкалары"на берниндн дә шартлар тудырылмаган, әлбәттә. Баржаларга түләп барган өчен түләргә берничә тиеннән башка акчалары да, кыйммәтле әйберләре дә булмый. Бөтен байлыклары таяк башына эленгән төенчектән гыйбарәт.

Бурлаклар сөйрәгән баржа Пермь шәһәре янына килеп туктагач, татар хатыннары баржадан төшеп бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр җәяүләп Тобол шәһәренә таба атлыйлар. Үзләре белән алган киемнәре тузып, ертылып бетә. Себер татарлары яшәгән берничә авыл аша узганда тегеләр, әлбәттә, ярдәм күрсәтәләр, кием-салым, ямаулыкка үзләре тукыган киндер кисәкләре, чабата бирәләр.

Татарстан Милли архивы документларын карап утырганда, гаризалар табылды. Берсе— берничә имзалы документ: "Прошение крестьянок о сопровождении арестованных мужей и на совместное поселение в Сибирь".

Димәк, татар хатын-кызларын тиктомалдан гына чыгарып җибәрмәгәннәр, башта алардан гариза яздырганнар. Бу гаризалар декабристкаларныкыннан аерылып тора. Тегеләр дворянлык өстенлекләрен саклап калуны сораса, татар хатын-кызларыныкы юлда барганда Себер татарлары белән бәйләнешкә кермәскә, коткы-фәлән таратмаска дигән йөкләмәдән гыйбарәт.

Безнең әбиебез Миңлегөл ул вакытта 35 яшендә була.Дүрт балалы Мөхәммәтсабитның икенче хатыны, әти-әнисе үгетләвенә, абыйлары каршылыгына карамастан, авырлы килеш, ирләре Турухан краена озатылган хатыннарга кушылып, Себер тарафына кузгала. Башкалар белән арестантлар баржасында Пермьгә килеп җитә. Аннан —Тоболга. Тоболдан Көнчыгыш Себернең Турухан краенда урнашкан Енисей бистәсенә таба арып-талып атлый бирәләр. Алар арасында Мөхәммәтсабит бабамның фикердәшләре Әбраретдин, Габделхәбир, Хәкимуллаларның хәләлләре дә була (исемнәре миңа мәгълүм түгел). Алар өчесе булдыралган кадәр Мөхәммәтсабит бабабызның 6-7 айлык авыры булган яшь хәләл җефетенә булышлык күрсәтеп, аңа актык тәгамнәрен ашатып, юл буе үгет-нәсихәт, рухи көч биреп баралар. Ниһаять, зур газаплар кичеп, билгеләнгән урынга килеп җитәләр.

Сабит бабалар бишәүләп атна-ун көн алдарак килеп житкән була. Алар шунда ук эшкә керешәләр. Иң әүвәл бергәләшеп вакытлыча яшәп торыр өчен өй корыштыралар. Хатыннары килгәч, берничә бүлмәдә биш гаилә сыеша. Мулла Тажетдин Мөхәммәдъяров кына берүзе яши (ул хатынына Салтыганнан чыгарга рөхсәт бирми). Бу хәл 1867 елның августында була.

---

*Ахыры. Башы 2008 елның 11нче санында.*

Бәхетләренә каршы, килеп урнашкан Енисей бистәсендә алар элегрәк көн күрә башлаган милләттәшләрен очраталар һәм шуннан сон берникадәр тынычланалар. Асраугa сыерлар алып, печән әзерләп, сөтен савалар. Алдан килешү буенча, туган бозаулары да үзләренә була.

Енисей елгасында боз октябрь айларында ката. Енисей елгасынын чишмәдәй саф та, салкын да суында мәрасин балыгы, чегә балыгы, омуль мыжлап тора. Кыш салкын булса да, елганың яр буйларында боз калын булмый, чөнки күздән калын кар каплап китә. Сабит бабаларыбыз, жирле халыктан күреп, балык тоту эшен дә тиз генә үзләштерәләр.

Шул 1867 ел октябренен бер төнендә Минлегөлне тулгак тота башлый. Әнисе карынында меңләгән чакрым юл үткән бала, ниһаять, якты дөньяны күрә, аваз сала. Анарга Хәкимулла дип исем бирәләр. Исем кушуны Тажетдин мулла сөенеп башкара. Мөселманнар саны тагын бер кешегә артты дип бергәләп шатланышалар.

Ирләр урманда эшли. Агачларны бер урынга егып, урманда ук бура бурыйлар. Мулла Тажетдин Мөхәммәдъяров андый эшкә катнашмый. Ул Себердә калуны күз алдына да китерә алмый. Күп вакытын язу өстендә утыра. Төрле түрәләргә, хәтта, император исеменә дә хат арты хат жибәрә. Ләкин жавап кына ала алмый.

Бер еллап вакыт эчендә, 1868 ел кышына кергәнче, нарат бүрәнәләрдән, авырлык белән булса да, тагын дүрт өйне яшәрлек итеп өлгертеп куялар. Кызыл балчыктан кирпеч сугып, мич тә чыгаралар.

## Яңа этаплар

1868 елнын җәендә хакимият Турухан краена сөреләчәк чираттагы этапны әзерли башлый. Ул Тәтеш өязе мәкруһларыннан туплана. Шул максаттан кулга алынганнар арасында Мөхәммәтша Вәлиев тә була. Мөхәммәтша үзе Тәтеш өязе Чирмешән авылыныкы булса да, хатыны Янгилденеке —Мөхәммәтсабит бабамнын туганнан туган сеңелесе, исеме Гөлжамал.

Мөхәммәтша жизнине сөргенгә алып китү белән халык телендә Мөхәммәтша бәете яңгырый башлый:

*...Мөхәммәтша Себер китте Тәтеш диган каладин.*
*Дин хәсрәтен күрер өчен туган икән анадин.*
*Без ызбадан чыкканда өстәл тулы аш калды.*
*Гөлҗамалның, балаларның күзе тулы яшь калды...*

Сөреләчәк мәкруһларнын берсе Фәтхулла Габдулловка төрмәгә хатыны менә мондый хат керттерә:

*"Сезки хәләл жефетем Фәтхуллага без хәләл хатынынннан —Гарфижамалдан куптин-куп сәламнәремне язам. Фәтхулла, жаным, үтенеп сорыйм синнән, Гайфулла кебек үзенне чукындырып хурлыкка кала күрмә. Бөтен авыл халкы сина кяфер дип әйтер. Битенә төкерерләр. Әгәр син урыс буласын икән, ул вакытта бу якты дөньяда чыннан да ни өчен яшәргә? Бу якты дөньяда яшәүнең кызыгы калмый. Әгәр дә сине Себергә жибәрәләр икән, мин дә синнән калмыйм, синең белән бергә барам. Артыңнан калмыйм. Аллаһы Тәгаләнең кодрәте зур, ташламас.*
*Ичмасам кызыбыз авыл халкы каршысында хур булмас.*
*Минем хатыным бар дип әйт.*
*Өмет баглыйм сиңа, Фәтхуллам".*

Кулга алынучыларның тагын берсе— Янгилде авылы крестьяны "Сергей Герасимов". Гаебе— "подстрекатель к отпадению от православия крещенных татар" булу.

Зөя өязе исправнигынын губернаторга рапортында тагын болай диелгән: "Крестьянина Сергея Герасимова я вынужден был арестовать при полицейском управлении, дабы этим показать крещенным татарам, что за подобные заявления и противозаконные действия лица удаляются из места жительства без суда и следствия" (ТРМА.— ф 1.— Тасв. 3.— Сахл. бер. 228.— Б. 146).

Кем соң ул Сергей Герасимов? Ул Әмәйгел әбиемнең әтисе Вәлиулла. Ярлы булу сәбәпле, солдатка алына, 28 ел патшага хезмәт итә. Кайткач, әбинең әнисе Ләйлигә өйләнә. "Георгий тәресе" белән бүләкләнгән була. Күкрәгенә такмыйча, аны кесәсендә генә йөртә.

Зөя өязендә, хәер, бөтен Казан губернасында да, зур киртәләр булуга карамастан, "чукынмаган" саналганнар христиан диненнән Мөхәммәд диненә яңадан кайтырга омтылалар һәм мәкруһ булалар.

Мөхәммәтсабит баба кебекләр, урыс түрәләре әйткәнчә, "главные виновники к отпадению крещенных татар из православия"ләрне Себергә олактырган саен мәкруһлар саны кимеми, арта гына бара. Зөя өязе исправнигы моны 1867 елның 20 сентябрендә Казан губернаторына җибәргән рапортында да күрсәтеп китә "... число отпавших видимо возрасло и наконец дошло до огромной цифры..." (Шунда ук.—Б. 137.)

Актив мәкруһлар, "подстрекательләр" Себергә сөрелгәч, калган мәкруһлар яңадан православиегә кушылыр дигән өмет акланмый, киресенчә, яңадан йөзләрчә кеше иманга кайта. Мисал өчен, 1850 елның 15 октябрендә халык санын алу мәгълүматларына карасак, 122 хатын-кыз һәм 102 ир-ат яшәгән Чүкри-Аланда бер генә татар исемле яисә атасы татар исемле зат та теркәлмәгән. Чөнки аларны 1834 елда ук метрика кенәгәләренә "керәшен татарлары" итеп язганнар. 1858 елдагы ревиз кенәгәсендә исә бер генә урыс исемле кеше дә калмаган, "Ислам дәфтәренә" авылы белән кайтканнар. Шыгай авылында да шундый хәл кабатлана. "Ислам дәфтәренә" теркәлә алмаганнары үзләренең мәкруһ булуларын аңлатканнар.

Рәсәй хакимияте, чиркәү руханилары белән бергәләп, мәкруһларның әйдәрләрен Турухан краена сөрә тора, алар урынына исә яңалары үсеп чыга. Мондый хәл Зөя өязендә генә түгел Цивильск, Тәтеш, Буа, Чабаксар өязләрендә дә гомуми төс ала. Яшьләр хакимияткә каршы торырлык көч табалар. Күрше авыллар гореф-гадәтләрне, динне бергәләп яклый башлыйлар...

Ислам дине белән көрәш Себердә дә туктап тормый. 1620 елда Тубыл шәһәрендә махсус епархия төзелә, аңа христиан динендә булмаган Себер халыкларын христианлаштыру бурычы йөкләнә. Петр Iнең эчке сәясәтенә бәйле рәвештә, чукындыру сәясәте XVIII гасырның беренче чирегендә аеруча активлаша.

1714 елның 16 декабрендә Себер митрополиты Федор Лещинскийга җиткерелгән фәрманында патша аңа Себер татарларын христиан диненә күчерергә, ә аларның "нәҗес гыйбадәтханәләрен" яндырырга дип әмер бирә. Бу әмерне тормышка ашыру өчен Ф. Лешинский махсус экспедиция оештыра, ул 1718-20 елларда Тура елгасы буенда яшәгән татарларны чукындыра, күп мәчетләрне җимерә-яндыра. Христиан динен кабул итмәгән татарларны зинданга ябып, ашсыз-сусыз тоталар. Халык телендә хәтта ут белән җәзалаулар турындагы мәгълүматлар да сакланып калган.

Миссионерлар мин бәян иткән чорда да йоклап ятмый. Ф. Лещинский варислары Енисей бистәсенә дә килә. Ләкин мондагы "переселенецлар"ның нинди халык икәнен белгәч, эзләре суына...

1871 елның кышында бистә татарлары өч бурадан торган мәчет өлгертәләр. Тагын ике-өч елдан бу мәчет манаралы була. Ислам җәмгыяте дә төзиләр.

Енисей бистәсенә Мөхәммәтсабитның кече улы, 17 яшьлек Мөхәммәтвафа (әтиемнең әтисе) барып чыга, бу хәл 1884 елда булырга тиеш.

Әмәйгел әбием сөйләгәннәрне хәтерлим: "Улым, Вафа бабаң, әтисе Сабит кебек, бик үткен иде. Берничә мең чакрым җирне барып әтисен табар дип беркемнең дә башына килерлек түгел. Ул әнә тәвәккәлләгән, әтисенең капкасын шакыган. Әтисе башта аны танымаган, әлбәттә. Сөргенгә чыгып киткәндә бу улына өч кенә яшь була бит. Әтисе янында озак яшәмәгән ул. Сабит бабай Себердә калырга тәкъдим итеп ялынып та караган юкса. Мал-мөлкәтен мирас итеп аңа калдырырга вәгъдә иткән. Вафа улы риза булмаган, мин Янгилдегә, туган авылыма кайтып китәм, дигән.

Шулай итеп, Мөхәммәтвафа бабай кайтып китә. Китмәс тә иде, авылда үзеннән өч кенә яшькә кечерәк, яратып йөргән кызы була шул аның Әмәйгел исемле.

Мөхәммәтсабит бабайны авылдашлары онытмыйлар, сагынып сөйлиләр. Аның турыда берничә бәет тә чыгарылган була. Кызганычка каршы, аларны Әмәйгел

әбидән отып та алмаганмын, кәгазьгә дә төшермәгәнмен. Бәләкәй идем шул.

Мөхәммәтсабит баба Себердә гомеренен 36 елын сарыф итә. Хәкимулла улынын да яше 30дан уза, кызлары да үсеп житәләр, оныклары да туа. Гасыр башына анын хужалыгында өч сыер, ике ат була, умарта да тота.

Әтинең бертуганы Хәбирә апа әйтүенчә, Мөхәммәтсабит баба "абый туган елны вафат була". "Абый" дигәне әтием Гайфетдиннен олы абыйсы Гыйльфан була инде. Гыйльфан абый 1903 елда туган. Мөхәммәтсабит бабабызны Енисей бистәсенен мөселман зиратына жирлиләр.

***

Мин үземне бәхетле саныйм, Ходайга мен шөкер, алтмыш ел буе эзләгән Мөхәммәтсабит дәү бабамны тапТЫМ!..

Хәзер Красноярск краенда кырыклап татар авылы бар. Биредә 50 мен чамасы милләттәшебез яши. Аларнын күпчелеге— 1860-70 елларда көчләп чукындырылып та, янадан Мөхәммәд диненә кайтулары өчен сөрелгән татарларнын дәвамы.

## Автор турында мәгълүмат

*Тәфкил Гайфетдин улы Вафин Апас районының Янгилде авылында туа. Сигезьеллык мәктәп тәмамлагач, МТСта үлчәүче һәм тракторчы була. Төньяк флотта хезмәт итә. Аннары ул— паровоз һәм тепловоз машинисты, район авыл хужалыгы идарәсе башлыгы урынбасары, райком инструкторы, колхоз рәисе, крахмал заводы директоры, район ягулык сату конторы директоры... Эштән аерылмыйча гына ике техникум һәм авыл хужалыгы институты тәмамлый.*

*—Тарих укытучылары безгә татарларның "явызлыклары" турында сөйләделәр. Урысларның Куликово сугышында "татарларны тар-мар иткәннәрен" сөйләп биреп "бишле" алгач баш түшәмгә тия язганнар истә,— ди Тәфкил ага.— Кенәзләрнең "батырлыклары"н да шәп беләбез, горурланабыз, алар турында опералар тыңлыйбыз. Ә менә үз тарихыбыздан хәбәрдар түгелбез.*

*Журнал укучы бу автор белән таныш инде. "Тормыш язган хикәяләр" сериясе аның "Әмәйгел әби"се белән башланып киткән иде (2006, № 4). "Мәкруһлар"ы татар тарихын шәбрәк аңларга һәм тоярга ярдәм итә. Шунысын да әйтик: Тәфкил Вафин үз өендә (1970 елдан алып Лаешта яши) гаилә музее ачкан бердәнбер татар кешесе булса кирәк.*

Михаэль
Фридерих

# КОЗГЫН КӨНЧЫГЫШКА ОЧА...

Оренбургта басылып, Русиянең мөселманнар яши торган барлык төбәкләрендә, хәтта янәшәдәге Кытайның Көнчыгыш Төркестанында да тарала торган «Шура» журналының 1911 ел апрелендә чираттагы саны дөнья күрә. Башка әсәрләр белән бергә биредә «Козгын» дигән шигырь дә бар.

*Козгын козгынга очадыр,*
*Козгын козгынга әйтә:*
*- Козгын! Карным бик ачадыр,*
*Кайда җим бар?— дип әйтә.*

*Козгын козгынга җавабән*
*Әйтәдер: - Мин җим табамын:*
*Яшел тугайда ятыр*
*Алдап үтерелгән батыр.*

*Кемдер егетне үтергән,*
*Алган йөгерек атыны—*
*Белде бизәнеп утырган*
*Өендә яшь хатыны.*

Бу сүзләрнең авторы үз исемен атамаган—журналда бары тик исеменең беренче хәрефен «Д»-ны кую белән канәгатьләнгән. Ләкин шунда ук әлеге шигырьнең тәрҗемә булуын да искә алырга онытмаган. Дөрес, оригиналның шигырь исеме дә, аның авторы да әйтелми калган.

Классик рус әдәбиятын яхшы белгән татар зыялыларының бер өлешенә, күрәсең, бу искәрмәләр җитәрлек тә булгандыр. Күпчелек өчен исә татар каләме белән язылган шигырьне Пушкин исеме белән бәйләү сер булып калган. Искә төшерик: Пушкинның исем куелмаган бу шигыре 1829 елда иҗат ителгән. Татарчага тәрҗемәсеннән ул күләме белән дә аерылып тора—биредә без дүрт юлга күбрәк укый алабыз.

*Ворон к ворону летит,*
*Ворон ворону кричит:*
*«Ворон, где б нам отобедать?*
*Как бы нам о том проведать?»*

*Ворон ворону в ответ:*
*«Знаю, будет нам обед;*
*В чистом поле, под ракитой*
*Богатырь лежит убитый.*

*Кем убит и отчего,*
*Знает сокол лишь его,*
*Да кобылка вороная,*
*Да хозяйка молодая».*

*Сокол в рощу улетел,*
*На кобылку недруг сел,*
*А хозяйка ждет милого,*
*Не убитого, живого.*


Ләкин бу шигырь дә рус шагыйренең оригинал әсәре түгел икән. Бу ике козгын Пушкинның ана телендә "сөйләшә" башлаганчы, инде шактый озак вакыт "очып барганнар" һәм ул очыш Шотландия тауларында башланган булган. Инглизчә белмәгән Пушкин, бу шигырьне 1826 елда французча Вальтер Скотт (1771-1852)

*Михаэль ФРИДЕРИХ – әдәбият галиме, фән докторы; мәкалә язылган вакытта Бамберг университеты хезмәткәре. Көнчыгыш әдәбиятына һәм тарихына багышланган фәнни хезмәтләр, шул исәптән Г.Тукай турындагы монография авторы.*

тарафыннан язылган Шотландия балладалары жыентыгыннан укып алган һәм аны «шотландская песня» дип атаган. Шул шигырьдәге биш строфадан Пушкин үз тәрҗемәсе өчен өчесен сайлап алган, шигырьнең исемен ("The Two Corbies") төшереп калдырган.

Әгәр дә без оригиналның татарчага һәм русчага тәрҗемәләренә күз салсак, шуны күрербез: Пушкин төп текстка бик якын тора, шулай да ул эчтәлекне саклап калу өчен бер строфага күбрәк куллана. Аның татар "тәрҗемәчесе" исә эчтәлекне кыскарта һәм шуның белән шотланд халык жыры күләмен саклый (дүртәр юллы өч строфа). Шотланд һәм рус вариантларында өч жан иясе—лачын яки эт, ат, яшь хатын— егетне кем үтергәнен белеп торсалар, татар шигырендә бу юк. Мондый кыскартуларга «Д» дип исемләнгән шагыйрьне нинди сәбәпләр этәргәнен ачыклау шактый кыен булса да, нәтиҗәсе ачык: татар версиясе вәзгыятьне төгәлрәк һәм ачыграк итеп тасвирлый, нокта куя.

Шундый осталык һәм зәвык белән ике козгын турындагы шотланд халык жырын татарчага тәрҗемә иткән «Д» кем соң ул? 1911 елның апрелендә бу шигырь дөнья күргәндә, әлбәттә, «Д» татар укучысы өчен бөтенләй билгесез шәхес булмаган. Укучыларның күбесе аның Дәрдемәнд икәнен шунда ук аңлаган. Аның шигырьләре, күп санлы һәм зур күләмдә булмасалар да, 1906 елдан башлап татар газета-журналларында даими басылып килгәннәр бит. Ләкин шул псевдоним артында кем торганын, унынчы еллар башына кадәр күпчелек әле белмәгән.



*Дәрдемәнд*

Ә чынлыкта әлеге юллар авторы Закир Рәмиев (1859—1921), бик танылган һәм билгеле кеше булган—үзе яшәгән Оренбургта гына түгел, аннан еракта да. Уфада, Казанда, Мәскәүдә, Уральскида, Санкт-Петербургта, Бакуда, Тифлиста, Себердә, Ташкентта, Бохарада, хәтта Кашгар һәм Торфанда яшәүче төрки-мөселман зыялыларының абсолют күпчелеге Закир әфәнденең күпкырлы эшчәнлеген белгәннәр һәм югары бәяләгәннәр. Ул—Оренбург шәһәр Думасы әгъзасы, беренче Дәүләт Думасы депутаты, икенчесендә һәм өченчесендә депутатлыкка кандидат, прогрессив татар мәктәпләренә ярдәм күрсәтүче, шөһрәтле «Вакыт» әдәби нәшриятының хуҗасы, әйдәп баручы татар басмаларыннан Оренбургта чыккан «Вакыт» газетасын (февраль 1906 ел—гыйнвар 1918 ел) һәм «Шура» журналын (гыйнвар 1908 ел—декабрь 1917 ел) чыгаручы, тәрбия, мәгариф, мәдәният үсешенә финанс ярдәме күрсәтүче меценат. Чөнки ул Уралдагы алтын прискаларының хуҗасы.

Әйе, Дәрдемәнд ул—Закир Рәмиев. Үзенең шундый үзгә хәлдә булганлыгын ул бик яхшы аңлаган—аның матди байлыгы аңа шигъри ирек биргән.[1] Шагыйрь Дәрдемәнд буларак, Закир Рәмиев башка замандаш шагыйрьләре кебек (мисал өчен, иң күренеклеләрен генә алыйк: Габдулла Тукай, Сәгыйть Рәмиев, Мәҗит Гафури, Нәҗип Думави, Зариф Бәшири) яшәү өчен төрле эшләргә алынырга мәҗбүр булмаган. Шулай ук әлеге авторлар кебек ул гонорар китерә торган күпсанлы мәкаләләр, репортажлар яки шигырьләр дә язмаган. Алар үзләре исән чакта ук аерым

---

[1] Биредә, Исмәгыйль Рәми тарафыннан чыгарылган «Дәрдмәнд әсәрләре» жыентыгындагы Фатыйх Кәриминең кереш сүзен искә төшереп булa. Ф.Кәрими, чыганакларны атамыйча, Дәрдемәнднең үз фикерен китерә: теләгәнеңне әйтәсең килсә, син матди яктан бәйсез, ирекле булырга тиешсең, фәкыйрь һәм бәйле булсаң теләгәнеңә ирешү мөмкин түгел (Дәрдмәнд әсәрләре / Төзүчесе һәм чыгаручысы И.Рәми. – Казан, 1929. – 10 б.)

шигырь китапларын да күреп калганнар. Шагыйрь Дәрдемәндкә исә үз лирикасы эчтәлеген дә, стилен дә замана зәвыгына яраклашып чарларга туры килмәгән. Һәм Дәрдемәнд мондый ирektән тулысынча файдалана алган: аның лирик иҗаты дулкынланып торган, вакыт-вакыт күбек белән капланган XX йөз башы татар әдәби диңгезендә үзенчәлекле бер кыя булып калкып тора.

Чыннан да, Дәрдемәнд XX йөз башында кулларына каләм алган һәм үз фикерләре, уй-хисләре, тойгылары һәм өндәүләре белән киң җәмәгатьчелеккә дәшәргә батырчылык иткән барлык татар замандашларыннан бар яктан да аерылып торган шәхес. Билгеле, Дәрдемәнд күп язмаган, көн тәртибендә торган актуаль мәсьәләләр һәм лозунглар аның иҗатында яңгыраш тапмаган, күпсанлы татар зыялылары кебек ул вакытлы матбугат битләрендә мәгариф, дин, милләт мәсьәләләренә багышланган дискуссияләрдә катнашмаган. Башка телләр йогынтысыннан азат булган татар телен дә якламаган, тыныч кына үз ана телендә иҗат иткән. Нигезсез рәвештә кыска вакытлы уңышлар һәм тәрәккыят эйфориясенә дә бирелмәгән, шулай ук җәмгыятьтә «җинелүләр» нәтиҗәсендә тора-бара формалашкан шундый ук нигезсез торгынлык һәм пессимизм хисләре дә аны басып китмәгән. Аның лирик иҗаты эчтәлеге һәм стиле белән, Галимҗан Ибраһимов әйтмешли, бер чуеннан коелган шикелле.

Дәрдемәнд исән чакта, шулай ук узган гасырның 20-30 елларында да, татар тәнкыйтьчеләрен бер нәрсә кызыктырган да, ялгыштырган да—ул да булса, Дәрдемәнд лирикасының тоны, яңгырашы. Аларның күпчелеге, минемчә, ялгышып, Дәрдемәнд иҗатының төп хисләре дип көчсезлекне, моңсулыкны һәм өметсезлекне атаганнар. Тәнкыйтьчеләр фикеренчә, шагыйрь «тормыш дигән нәрсәнең мәгънәсезлегенә», «дөньянын фанилегенә» инанып иҗат иткән, аның шундый карашлары шигырьләрендә дә чагылыш тапкан.[2] Дәрдемәнд лирикасының мондый «үзенчәлекләре» сәбәп булып тәнкыйтьчеләрне шундый ялгышлыкларга китергән: бу үзенчәлекләр ул вакытның актив иҗтимагый тормышына һәм Закир Рәмиевнең «сыйнфый чыгышына» туры килмәгән. Күрәсең, тәнкыйтьчеләр, материаль яктан бай кеше, шагыйрь булган очракта, анын иҗаты да эзлекле, актив һәм ышанычлы булырга тиеш дип уйлаганнар. 1927 елда Фатыйх Кәрими сүзләренчә, шагыйрьдән «Мин, димен мин!»—дигән сүзләрне көткәндә,[3] ул аның урынына «Зәгыйфь кырмыскамын...»—дип яза. Минемчә, Дәрдемәнднең чордаш тәнкыйтьчеләре дә, соңрак аның иҗаты турында язучылар да югарыда искә алынган бәяләргә китергән бер принципиаль хата җибәргәннәр: алар фикеренчә, шәхеснең реаль тормышы һәм шагыйрь тарафыннан тудырылган хыялый дөнья арасында артык зур аерма юк, һич булмаса, алар бер-берсе белән бик тыгыз, турыдан-туры бәйләнештә торалар. Мондый караш татар әдәби тәнкыйтендә социализм чорында гына формалашмый, аны без инде 1905 елдан доминант караш дип таный алабыз. Аның «дөреслеген» күп кенә шагыйрьләр, язучылар тормышы һәм иҗаты нигезендә раслаганнар. Мондый тәнкыйтьчеләр күзаллавынча, әдәбиятнын, һичшиксез, иҗтимагый вазифасы бар, авторның җәмгыятьтән аерылырга хакы юк, ә, киресенчә, ул үз иҗатында заманасының иң актуаль мәсьәләләрен күтәрергә һәм мөмкин кадәрле, көченнән килгәнчә шул сорауларга җавап бирергә тиеш. Рус әдәбиятында мондый карашлар инде XIX йөзнең соңгы чирегендә киң таралган булган, электән үк аларны яклаучылар да күп булган—мисал өчен Герцен, Белинский, Добролюбов һәм Чернышевскийларны атасак та җитә. Моннан аермалы буларак, татар әдәбиятында

[2] Шундый бәяләмәләрне инде искә алынган Ф. Кәриминең кереш сүзендә дә, шул ук томга кергән Фатыйх Сәйфи-Казанлы тарафыннан язылган «Ни өчен Дәрдмәнд әсәрләрен басабыз» дигән мәкаләсендә дә (101 б.) табып була. Бу фикерне якламаган тәнкыйтьчеләрдән берләнбер Галимҗан Нигъмәтине санарга мөмкин. «Шагыйрь Дәрдмәнд һәм аның әдәби иҗаты» дигән мәкаләсендә (шунда ук.- 19-37 б.) ул Дәрдемәнд турында, «күбрәк вакыт оптимист карашлар күрсәткән» дип яза.

[3] Татар укучысы бирөдә Ф.Кәрими тарафыннан кем үрнәк итеп куелганын аңлаган: 1905 елда басылып чыккан «Мин» дигән шигыре белән Сәгыйть Рәмиев бөтен татар җәмәгатьчелеген гаҗәпләндергән һәм шок хәленә китергән иде. Бу шигырьнең тулы текстын, алман теленә тәрҗемәсен, анализын һәм бик уңай бәяләмәсен кара: Baldauf, Ingeborg: Prometheismus in der circumrevolutionдren tatarischen Lzrik, in: Bamberger Mittelasienstudien. Hrsg. Bert G. Fragner, Birgitt Hoffmann, Berlin 1994, S. 25-26.

язучылар һәм, гомумән, зыялылар җәмгыять тормышы белән чын-чынлап бары тик 1905 ел революциясеннән соң кызыксына һәм шөгыльләнә башлыйлар. Нәтиҗәдә, аларның күпчелеге Русия мохите татарның дине, мәдәнияте, икътисады өчен бик аз мөмкинлекләр бирә дигән фикергә килә. Алар үзгәртүләрнең зарурлыгын таныган, алар үзгәртүләрне тормышка ашырганнан соң, киләчәк чынбарлыктан һәрхәлдә начаррак булмас дип фикерләгәннәр. Кадимчеләр дип аталганнары исә «алтын үткән заманаларны» кайтарырга хыялланса, җәдитчеләр төркеме «янарышка» өмет баглап яшәгән, ягъни көнбатыш, иң беренче нәүбәттә, рус тәрәккыяте казанышларын татар киләчәге өчен үзләштерү һәм файдалану максатын куйганнар. Менә шундый иҗтимагый җаваплылык тойгысы 1905 елдан соң татар җәмәгатьчелегенең киң катлауларын, бигрәк тә язучыларын һәм зыялыларын, мәдәният һәм әдәбият белән кызыксынучыларны чын мәгънәдә дәртләндергән. Прозаиклар, драматурглар, бигрәк тә шагыйрьләр, җәмгыятьнең тискәре якларын, шуларның сәбәпләрен фаш итә торган, мәгарифне битарафлык авыруына каршы, халыкны сазлыктан чыгара торган бердәнбер чара итеп күтәргән санап бетергесез әсәрләр язалар. Алар фикеренчә, бу авыру яңа уянып килгән, янадан аягына баскан татар милләтен богауда тоткан иң зур куркыныч. 1905-1907 еллар арасында аларның күпчелеге максатларыбыз тиздән реаль тормышка ашачак дип ышансалар һәм чын эйфория хисләренә бирелсәләр, 1908 елдан Беренче Бөтендөнья сугышы башланганчы "бар теләкләребез чәлпәрәмә килде, алда бер яктылык та күренми" дип тирән кайгы хисләренә чумганнар. Ике хис тә, эйфория һәм кайгы, ахыр чиктә алар иҗатында тулы чагылыш таба. Бу татар шагыйрьләре, бигрәк тә милли шагыйрь итеп танылган Габдулла Тукай (1886-1913), милләтнең киләчәген идеал итеп күзалларга тырыша, шул ук вакытта алар үзләре дә тулысынча диярлек реаль замана һәм аның хәрәкәте җимешләре булды. Алар өчен тормыш һәм иҗат бер иде, берләшкән иде.

Ләкин Дәрдемәнд андый түгел. Ул яшәгән һәм иҗат иткән вакыт аның өчен бернинди төп яки әһәмиятле роль уйнамаган. Һәрхәлдә, Октябрь революциясе, гражданнар сугышы һәм большевистик режим урнашканчыга кадәр. Аның шигырьләре үзгәреп барган чынбарлык турында сөйләми, алар вакытны бер очсыз-кырыйсыз бөтенлек дип кабул итә. Шуңа күрә Дәрдемәнд лирикасы вакытка буйсынмавы белән сокландыра. Сибгат Хәким сүзләренчә: «Дәрдемәнд миллион еллар, мәңгелек белән эш итә».[4] Дәрдемәнд бәяләр бирми, аның урынына ул турыдан-туры күзгә ташланмый торган хакыйкатьне сүзләр ярдәмендә тасвирларга тырыша һәм шул сүзләрдән күренешләр туа, музыка яңгырый кебек. Аның шигырьләре метафоралар белән тулмаса да, гаҗәеп бер моңга, хәтта кырысрак булган матурлыкка ия. Шигърияте Дәрдемәнд, рус символисты Вячеслав Иванов сүзләренчә, шундый бер «турылана торган спираль хәрәкәтен биргән» энергия буларак кабул иткән, күрәсең.

Шушы гомуми характеристиканы мин Дәрдемәнд иҗатыннан[5] мисаллар китереп конкретлаштырырга булдым. Шул унайдан, Дәрдемәнд иҗатын аерым төп темаларга бүлеп карарга тырыштым. Әйе, биредә шагыйрь лирикасы өчен хас булган иң әһәмиятле тема-мәсьәләләр китерелгән. Бер яктан, алар Дәрдемәнднең үз лирик иҗатында «мәңгелек темалар» белән кызыксынганын да, икенче яктан, аның үз вакыты һәм тормыш мохитен, традицияләрен («ватан») бик тирәнтен аңлаганын, аның иҗатында аларның яңгыраш тапканын да исбатлый.

---

[4] Хәким С. Шагыйрьнең осталыгы // Дәрдемәнд. Исә җилләр: Шигырьләр,истәлек-парчалар, вак хикәяләр. – Казан,1980. – 8б.

[5] Вафатына кадәр (9октябрь,1921 ел) Дәрдемәнднең бер генә шигырь китабы да дөнья күрмәгән. Бәлки,монысын ул үзе теләмәгәндер,бәлки башка сәбәпләр аркасында бастыручыларга рөхсәт бирмәгәндер. 1929 елда Исмәгыйль Рәми беренчеләрдән булып, Дәрдмәнд шигъри мирасын туплап,аларны бер җыентык формасында чыгара. (Дәрдмәнд әсәрләре. – Казан,1929- 108б.). Рәис Даутов редакциясендә 1980 елда Дәрдемәнд шигырьләренең моңа кадәр иң тулы җыелмасы дөнья күрде (Дәрдмәнд. Исә җилләр: Шигырьләр, истәлек-парчалар, вак хикәяләр. – Казан, 1980. – 254 б. – Түбәндә "ДӘ-1980" дип кыскартыла). Бу ике басма минем өчен төп чыганак булып торды. (М.Фридерих мәкаләсендә шигырьләрнең текстын 1929ел басмасыннан китерсә дә, мин шул ук шигырьләрдән цитата биргән вакытта укучыбызга танышрак булган 1980 ел басмасына таяндым һәм искәрмәләрдә бу басманы күрсәттем – Тәрҗемәче искәрмәсе).

Минемчә, Дәрдемәнд иҗаты—үз чорында да һәм әле дистәләгән еллар соңрак та, үз-үзе өчен тулысынча җавап бирә торган кыйммәт. Бу кыйммәтне шигырьләр язылган чорның иҗтимагый, сәяси шартларын, хәтта шагыйрьнең шәхесен белмәсәң дә таныйсың. Бу иҗат үзеннән-үзе бер даимилек буларак яши. Шуңа күрә мин Дәрдемәнднең шәхесенә дә, гомуми иҗатына да артык тукталмыйм, аның лирикасын башка шагыйрьләр иҗаты белән дә чагыштырмыйм.

Тагын бер искәрмә. Дәрдемәнд шигърияте эчтәлеге белән генә үзенә җәлеп итми, формаль яктан да, тел ягыннан да ул, минемчә, шул хәтле югары сыйфатка ия, татар әдәбиятында ул чорда да, соңрак та аныкына тиңнәрлек шигырьләр юк. Шуңа күрә аларны алман яки башка Европа теленә тәрҗемә итү үтә дә кыен эш булып күренә—монысы минем генә кулымнан килми. Тексттагы минем алманчага тәрҗемәләр дә—бары тик шигырьләрнең формаль бүленешен һәм эчтәлеген укучыга җиткерү өчен гади омтылыш кына.

Шагыйрь Дәрдемәнд өчен табигать бик зур әһәмияткә ия—монысы хәтта табигатьнең үз "авызыннан" сөйләткән шигырьләр санында да күренә. Дәрдемәнд табигатькә дан җырламый, ул аны аңлатмый да, аңа гаҗәпләнми дә. Ул табигатьне тынлый белә, табигатьне күрә белә. Аның шигырьләрендә укучы һәм тыңлаучы белән әңгәмә алып бара торган табигать ул бакчалар һәм ихаталар белән тулган «ясалма табигать» түгел, ул Закир Рәмиев үзе күргән Көньяк Урал тауларының, Орск, Оренбург, Уральск тирәләрендәге чиксез даланың «табигый табигате». Дәрдемәнд кабул иткән табигатьтә, шагыйрьнең лирик героен искә алмасак, кешегә урын юк—ул табигатьнең бер өлеше түгел, ул аның өчен чит.

*Ятам кай чаклары моңлап,*
*Һаваның тынлыгын тыңлап.*
*Килә өннәр, колак чыңлап,*
*Диямен: «Ни бу? Нидәндер бу?»*
*Җавап урынында – гөрли су,*
*Тирәклек тирбәнә, шаулый!*[6]

Дәрдемәнд җәйне тасвирламый. Ул бары тик узганнарга караш ташлар өчен бер чара гына. Җәйнең үз сыйфатлары юк, шулай да, ә бәлки шуңа да карамастан, җәй аннан соң килә торган фасылга караганда ягымлырак һәм матуррак:

*Җәй үтте...*
*Кар-яңгырлы көз урнашты,*
*Күк тугайның бавырына боз урнашты...*[7]

Кыш фасылына да шагыйрь игътибар итә һәм кыш аның өчен җансыз, гомерләр узып киткәннең бер символы:

*Картайды җиһан!*
*Гөлләр дә бетте...*
*Кичмәктә заман—*
*Кышлар да җитте.*

*Иелде ботаклар,*
*Карлар асылды*
*Таулар, болаклар—*
*Бар да басылды.*

*Күк бозлар катып,*
*Оешып ятып,*
*Чишмәкәй шымды,*
*Бар җиһан тынды.*

*Җилкенә яман,*
*Сызгыра, өрәдер*
*Һәм күктә йөзәдер*
*Бәс белән томан.*[8]

[6] Исемсез шигырь,Дәрдемәнд исән чакта басылмаган - ДӘ-1980. - 80 б. Җыентыкның редакторы «Табигатькә бәйләнешле моңсулар» дип исемләгән бүлектә берләштерелгән тугыз кыска шигырь арасында беренче шигырь.

[7] Исемсез шигырь, Дәрдемәнд исән чакта басылмаган - ДӘ-1980.- 93 б. Искәрмәдә шигырьнең тагын бер варианты бирелгән.

[8] «Кыш көннәре» // Шура. – № 23. – 1.12.1908. Шулай ук: ДӘ-1980.- 51 б. Бу шигырьне «Кышкы төн» шигыре белән дә чагыштырып була. Соңгысын Дәрдемәнд А.С.Пушкинның «Зимний вечер» шигыренә ияреп язган. Беренче тапкыр «Вакыт» газетасында (1907,№ 119) «Әдәбият капчыгы» рубрикасында дөнья күргән. Соңрак та басылган: ДӘ-1929.- 42 б.; ДӘ-1980.- 29 б.

Татар тәнкыйтьчеләре Дәрдемәнднең дөньяга карашын табигатькә бәйле шигырьләренә таянып бәяләделәр, һич булмаса аларда шул карашның кайтавазын эзләп карадылар.[9] Мондый логикага ияреп барсаң, шул тәнкыйтьчеләр шикелле кышның хәрәкәтсезлеген һәм жансызлыгын тасвирлаган Дәрдемәнднең фикерендә һәм ижатында төп мотив итеп чыннан да «өметсезлек»не билгеләп була. Дәрдемәнд дөрестән дә кышны да, жәйне дә сөймәгән һәм, минемчә, моның сәбәбе түбәндәгедән гыйбарәт: бу ике фасыл да статик, алар өчен тиз чәчәк ату да, шулай ук тиз сулу да хас түгел. Дәрдемәнд өчен исә хәрәкәтчәнлек бик якын—ниндидер максатка омтылыш хәлендә генә түгел, ә үзеннән-үзе туктаусыз хәрәкәт кадерле ана. Хәрәкәт тәмамлануы яна башлангычны аңлата, бу башлангыч шагыйрь күнеленә якын. Шуна күрә дә ул бөтен жаны белән язны сөя, аның каләменнән язга багышланган шактый күп шигырьләр "тамган".

*Бу ул матур, бу ул күркәм, бу ул,*  
*Бу ул—хуш исле яз!*  
*Бу ул—хуш исле таң жиле!*[10]



*«Шура» журналының тышлыгы*

Дәрдемәнднең «табигать шигырьләрендә» зур ишарәләр дә, чуар характеристикалар да юк. Аларда шагыйрь табигатьнең кысаларга сыймый торган гажәеп чагылышларын тасвирламый, хәтта «табигатьнең көндәлек тормышын» тел яисә формаль экстравагантлык аша күрсәтеп укучыны кызыктырмый, шигырьләрендә ясалма күренешләр ярдәмендә табигатьне аңлатырга тырышмый. Дәрдемәнд шигырьләре сүзнең иң унай мәгънәсендә «гади» һәм шул гадилек аркылы алардан тынычлык хисе сибелеп тора шикелле. Бу тынычлыкта табигатьнең әлегә ябылган (ябык) яшәеше чагыла—Дәрдемәнднең үзен дә шундый хисләр белән тулган дип фараз итеп була һәм бу халәт әсәрдә "ишетелеп" үк тора.

*Болыт үтте. Гөмбәрли күк еракларда,*  
*Сил шаулый, сулар гөрли болакларда,*  
*Тавышы —колакларда...*  
*Озакларда...*[11]

Дәрдемәнд тормышка актив катнашучыга охшамаган, ешрак без аны ияреп баручы, кайвакыт зарланып, сыкранып торучы күзәтүче итеп кенә күрәбез:

*Әгәр барсаң, саба жил, безнең илгә,*  
*Сәламләр әйт, сәлам ул нечкә билгә!*  
*Төшендә юл өчен чәчкәен тарасын,*  
*Гарибнең кайтарындан фал карасын,*  
*Ходаендан кавышмакны сорасын*  
*Сәламләр әйт, сәлам ул нечкә билгә!*

*Дәрийгъ, бер гомер икән сөргән элек без,*  
*Йөрер бергә, көлер-уйнар идек без.*  
*Бу көндә Сак белән Соклар кебек без...*  
*Сәламләр әйт, сәлам ул нечкә билгә!*[12]

---

9 Мәсәлән,«рәсми» «Татар әдәбияты тарихы»ның 3 томында Гали Халит мәкаләсен кара (Татар әдәбияты тарихы. – 3 т.: XX гасыр башы. – Казан,1986. – 194-214 б. (бигрәк тә 207-208б.)

10 Исемсез шигырь,Дәрдемәнд исән чакта басылмаган - ДӘ-1980.- 134 б.

11 Исемсез шигырь,Дәрдемәнд исән чакта басылмаган - ДӘ-1980.- 132 б.

12 Исемсез шигырь,Дәрдемәнд исән чакта басылмаган - ДӘ-1980.- 91 б.

«Халкын» һәм «туган ягын» Дәрдемәнд эчтән түгел, ә читтән күзәтеп тора. Шул "ерак"тан ул «ватанына» һәм «халкына» якынаерга да ашыкмый, ә «саба җилен» җибәрә, аның «туган илгә, нечкә билгә» сәламнәр тапшыруын үтенә. Бу хәлне ике төрле аңлап була: яисә шагыйрь туган илендә, халкы арасында түгел, яисә ул үзе «саба җиле» ролен үтәргә теләми яки хәтта үтәрлек хәлдә түгел. Шунысы да күренә: Дәрдемәнд якынрак килергә дә теләми, ул саубуллаша. Бу саубуллашу урынга гына түгел, ә вакытка да карый. Туган илен һәм халкын шагыйрь ерактан сәламли һәм сәламнәрен дә реаль чынбарлыкка җибәрми, ә үзенә бәхетлерәк булып тоелган чорга, узганнарга юнәлтә:

*Тәгәрәп-аунап*
*Буй үскән*
*Туган илем, исән бул!*
*Чәч кузгатып*
*Җай искән*
*Таңгы җилем, исән бул!*
*Йөгреп-йөгреп*
*Туктаган...*
*Яулык болгап*
*Сыктаган*
*Нәзкәй билем, исән бул!* [13]

«Караб» дип исемләнгән үзенең иң атаклы шигырендә дә Дәрдемәнд ватанының чынбарлыгын менә ничек тасвирлый:

*Шаулый диңгез...*
*Җил өрәдер...*
*Җилкәнен киргән караб!*
*Төн вә көндез*
*Ул йөрәдер:*
*Юл бара ят ил карап...*
*Чыкты җилләр,*
*Купты тулкын –*
*Ил карабын җил сөрә!..*
*Кайсы юллар,*
*Нинди упкын*
*Тарта безне җан сорап?!* [14]

Чиксез, рәхимсез диңгез уртасында кечкенә генә көчсез караб, дулкыннар аны капларга гына тора, җил котырына—бер татар шагыйре дә, минемчә, беренче рус революциясеннән соң хөкем сөргән билгесезлекне тасвирлау өчен мондый тәэсире ышандырырлык сүзләр таба алмаган. Нәрсә буласы—билгесез, киләчәкнең нәрсә китерәсе—билгесез... Татарлар өчен генә түгел, империянең һәрбер милләтеннән булган аерым кешеләр өчен дә киләчәк нәрсә әзерләгән? Кешеләр бары тик шунысын гына күреп тора: узганнар инде кабатланмас, ә бүгенге көн—ул бер көчеш чоры, ләкин ул көчешнең кая алып барасын беркем белми.

Менә шул билгесезлектә Дәрдемәнд ачыклык эзли. Кайвакыт ана, «менә, ниһаять, таптым!»—кебек тоела.

*Ни газизрәк—бу ватанмы?*
*Аh, туган каумем газиз!*
*Ул мокаддәс кан белән ул*
*Изге сөткә ни җитәр!..*
*Сөт калыр, ватан китәр!*
*Сөт калыр, ватан китәр!* [15]

Сәяси яктан билгеләнеп, административ чикләргә бүленә алырлык нәрсә—ул инде туган ил, ватан түгел. Кала торган нәрсә—ул биредә туган һәм яши торган кешеләр, алар үз бабаларының дан-шөһрәтләрен истә тоталар, шуларны буыннан-буынга саклап киләләр. Бу шигырендә Дәрдемәнд үзе һәм «халкына» булган

[13] Видагъ (аерылышу) (язылган датасы билгесез) // ДӘ-1980. – 90 б.

[14] Беренче тапкыр «Шура» журналынын 1 санында (10 гыйнвар 1908ел) дөнья күргән. Биредә түбәндәге басмадан алынды: ДӘ-1980. – 36 б.

[15] Исемсез шигырьнең икенче өлеше Дәрдемәнд исән чакта басылмаган - ДӘ-1980.- 92 б.

мөнәсәбәте турында сөйли.[16] Шул ук вакытта, минем өчен шунысы да көн кебек ачык: Дәрдемәнд «татар» милләтчесе яисә расист түгел. Ул үз халкы белән горурлана, ана ышанычын белдерә, шул ук вакытта, үз халкынын барлык үзенчәлекләрен танып, башка халыкларнын да, алар кайда, нинди мохиттә яшәсәләр дә, шундый ук үзенчәлекләргә ия булу хокукын таный. Димәк, мона таянып, Дәрдемәнднен өметен «идеаль дөнья-ватан» дип атап булыр иде.

Кешенең бу дөньяда тоткан урыны— Дәрдемәнд иҗатында төп урын алып торган мәсьәлә. Бу мәсьәлә, әлбәттә, үтә яна түгел—«дөнья» әдәбиятында да, татар әдәбиятында да аны кайбер «мәнгелек темалар» сафына кертеп була. Бу темага кагылышлы ике аспект та Дәрдемәнд иҗатында чагылыш таба: абстракт кеше-индивидуумга мөнәсәбәт («кеше үз-үзендә»); конкрет индивидуумнын, ягъни лирик геройнын яисә шагыйрьнен кеше буларак үзенең тарихи, җирле яки социаль мохитенә мөнәсәбәте.

Башка шагыйрьләр лирикасындагы кебек үк Дәрдемәнд шигъриятендә дә бу ике аспектны төгәл аеру һәрбер очракта да мөмкин түгел. Анын кайбер шигырьләре шул кадәр гомум төзелгән, аларны хәтта афоризм дип кабул итәргә мөмкин. Аларнын мәгънәсен нииндидер аерым бер тон белән генә анлатып булмый, аларны конкрет шагыйрь Дәрдемәнднең дөньяга карашын тикшергәндә, бертөрле генә темага да ялгап булмый. Фикеребезне өч мисал белән раслап була:[17]

*1) Түгел лаек яманлык яхшыларга;*
*Ярамасларга яхшылык ярамас.*

*2)Әгәр йөз напәсәнд эш кыйлса дәрвиш,*
*Йөз иптәшнең бер-бере алмый телгә;*
*Вә әгәр бер напәсәнд эш кыйлса солтан,*
*Аның даны очадыр илдән-илгә.*

*3) Бүген уйнап-көлүдән тыйма, зинһар.*
*Үләргә көн булыр—алда әҗәл бар!*
*Тыя күрмә—уен уйнар мәлендә,*
*Әҗәл эшләр эшен үз тәңгәлендә!*

Минемчә, башкачарак бер фикер түбәндәге юлларда янгырый:

*Күңел һәр җирдә гөл эзли,*
*Кадәр һәр җирдә тикән төзли...*

Бу икеюллыкнын тонына нииндидер гомумилек хас булса да, ул барыбер Дәрдемәнднең лирик «мин»е янгыраган шигырьләрен хәтерләтә. «Мин» яки «без» формасында булмасын, шагыйрьнең лирик «мин»е бик кин күләмле, кин офыклы—ул аерым бер шәхес белән генә бәйле түгел. Шул ук вакытта ике формадагы ул «мин» үзенең төп үзенчәлеген саклап кала—анын өчен киләчәккә генә карата түгел, бәлки бүгенге көнгә карата да күнел төшенкелеге, кәефсезлек, ышанычсызлык хисләре хас.

---

[16] «Халыкны» шагыйрь «кавем» дип атый, «милләт» дип атамый. Монысы очраклы түгелдер, чөнки «милләт» сүзе беренче рус революциясе елларында «модага» кереп,ачык сәяси эчтәлеккә ия булган. Ул (теләнгән) чынбарлыкка һәм киләчәккә килеп тоташа, һәм аны шулай ук Көнбатыш Европада кабул ителгән «Nation" концепциясен татарчалаштырырга яки татарга якынайтырга омтылыш дип бәяләргә мөмкин. «Кавем» төшенчәсе исә,беринди сәяси эчтәлеккә ия түгел,кешенең этник үзаңына кайтып кала,аны килеп чыгышы һәм үткән заманнар белән тоташтыра.

[17] Бу өч «шигырь» дә исемләнмәгән. Аларнын икенчесе генә Дәрдемәнд яшәгәндә үк дөнья күргән (*Шура. - № 10. – 10 май 1909*). Өчесе дә түбәндәге басмада басылган: ДӘ-1980.- 162,59,1086.

*Гомерләрдер... Өелмәктә сагышлар...*
*Дәвам итмәктәдер шиддәтле кышлар...*
*Һавалар тын... Кыеп очкан һома юк...*
*Азан ишетелсә дә, кыйбла-нөма*[18] *юк!..*[19]

Әлеге хис тагын да ачыграк булып түбәндәге юлларда күренә:

*Ничә багълар күңелләрдә төзелде,*
*Сары юллар булып гамьләр сызылды.*
*Өмидләр, кем, менеп башка тезелде,*
*Агарган кыл кебек бер-бер өзелде.*[20]

Күренә ки: «мин» нинди формада гына булмасын, узганнарга ул барыбер бик төшенке караш ташлый, узганнар нинди генә булмасын, алар киләчәктә дә оттырыш кына китерәчәкләр. «Шура» журналында 1910 елның 21 февралендә дөнья күргән «Без» дип аталган шигырь бу сүзләргә иң яхшы мисал:

*Гасырлар кичте китте... кичте еллар!*
*Нәбиләр, падишаһлар сөрде дәвран...*
*Гомерләрдер кучеп кәрван вә кәрван,*
*Килеп кичте жиһандан канча илләр!..*

*Сүнеп вәйран булып мәгъмур тияКләр,*
*Җир астында тезелде ку сөякләр!..*
*Исә җилләр, кучә комлар... бетә эз...*
*Дәрийгъ, мәхзүн күңел, без дә бетәбез!*

*Мөсафир, кем, жиһанга басты ботны,*
*Биетте ажгырып аны замана...*
*Өеп чергән өмидне... төртте утны—*
*Йотып утларны китте...яна-яна...*[21]

Шигырьнең ахырында Дәрдемәнд көнчыгыш шигъриятендә киң таралган мотивны куллана—кеше бу дөньяда бары тик кунак кына, шуңа күрә аның сөякләре моңа кадәр үлгән санаусыз кешеләр сөякләренә кушылып кына баралар, ул кешеләр дә бу дөньяда бернинди эз калдырмыйча юкка чыкканнар. Бу «уен» очсыз-кырыйсыз спиральне хәтерләтә: «иске»нең бетүе шул ук вакытта «яңа»ның башын аңлата.

Ләкин Дәрдемәнднең лирик «мин»е бөтенләй үк дөньяның бетергесез хәсрәтләреннән генә җәфаланып, җәрәхәтләнеп бетмәгән. Кайвакыт, бигрәк тә аерым шәхес белән бәйле булмаган формада чыкканда, ул кыю да, тәвәккәл дә була ала. Дөнья барышын үзгәртеп тә, туктатып та булмаса да, ана, теләк булса, ияләшергә мөмкин. Бу очракта шагыйрь түбәндәге «киңәш»ен бирә:

---

[18] Иран мифологиясендә нөма кошының (сакаллы тилгән) күренүе яхшы билге булып санала – әгәр дә кеше башына аның күләгәсе тиеп китсә,ул кеше падишаһ булачак диган сүз бар (The Encyclopedia of Islam,vol. III,Leiden,London 1979,S. 572).

[19] Исемсез шигырь,Дәрдемәнд исән чакта басылмаган - ДӘ-1980.- 137 б.

[20] Исемсез шигырь,язылган вакыты да билгесез,Дәрдемәнд исән чакта басылмаган - ДӘ-1980.- 70 б. Шул ук җыентыкта (69 һәм 71 битләрдә) "Өмидләр" дип (редакция тарафыннан?) исемләнгән бу шигырьнең янә ике варианты басылган.

[21] ДӘ-1980. – 38б.

*Җитәкләргә тырыш дөньяи дүнәнне,*[22]
*Икенең берсе: йә сине җитәкләр.*
*Алып барыр үзеңне бер чокырга,*
*Барырсың—бардырыр, тәртәр, этәкләр.*

*Моңа ни ул усал карчыкның име:*
*Ку артыннан ярыймы-юкмы диме!*
*Җитеп тә, бер сикертеп типсәң артын,*
*Дәни бит ул—үзен тигәнгә тими!*[23]

Беренче карашка бу юлларда шагыйрь кешеләрне дөньяда тулы канлы тормыш алып барырга, вакыйгаларнын барышына бирешмәскә, ә, киресенчә, аларны үз кулыңа алырга, үзенне кече итеп хис итмәскә, үз ихтыярын кушканча эш итәргә өнди. Ләкин, минемчә, шул ук юлларның ачы, сарказмлы янгырашы бу беренче караштa туган хисне чәлпәрәмә китерә. Закир Рәмиев игътибарсыз һәм ихтирамсыз кеше һәм эшкуар булмаган шикелле, шагыйрь Дәрдемәнд тә декадент шагыйрь булмаган. Бу шигырьдә, минемчә, шагыйрьнең тормышка һәм дөньяга карашы гына түгел, ә күбрәк шул вакытта җәмгыятьтә кин таралган мәнфәгатьләрне бәясенә карамыйча канәгатьләндерү философиясенең бәяләмәсе чагылыш тапкан. Көчлерәкләр алга узалар, ә көчсезләр артта кала баралар. Дәрдемәнд үзен шул көчсезләр сафында күргән, дөнья андыйларны танымаган, бәяләмәгән. Монысы бигрәк тә үз исеменнән, «мин» дип язган шигырьләрендә күренә:

*Гәрчә мин дә бар саналдым,*
*Ил катар сан алмадым.*
*Илдә йөрдем, хазлар алдым,*
*Уйласам – сан алмадым.*

*Янды Мәҗнүн, янды Фәрһад, –*
*Бер янып ат алдылар.*
*Мин, гариб, мең кат янып та –*
*Яндыга саналмадым.*
*Уйлагыз: мәгъшука меңләр!..*
*Мин гашыйк саналмадым!..*
*[...]*
*Әйттеләр, кем, бер бәхетсез*
*Илгә гашыйксың, фәкыйрь.*
*Бер кызардым, бер бузардым...*
*Ни таныйм – таналмадым.*
*Ни таныйм?.. Таналмадым!*
*[...]*
*Исте җилләр ил эченнән,*
*Иртә-кич салдым колак.*
*Җил-җиләсләрнең моңыннан*
*Зәукы әлхан алмадым.*
*[...]*
*Тез йөгендем, яшь тамыздым.–*
*Дәрткә дәрман алмадым.*
*Биэре милләт, маэи зәмзәм*
*Кузләдем еллар буе.*
*Җитте дәфнем вакыты,*
*Кәфнем бүзләрен маналмадым!..*
*Вәйля!..*
*Дәри-и-игъ!*
*Бүзләрем мана алмадым!...*[24]

Бу юлларда өмет өзелү, хәтта әрнү, ачы тойгы хисләрен сизми мөмкин түгелдер. Шул ук вакытта шигырьләрдә шунысы да ачык күренә: әдәбият белемендә андый бәяләр очраса да, шагыйрь үзе төзегән иҗат сараенда тормыш итү белән генә

---

[22] Бу урында 1929 ел басмасында да, 1980 ел җыентыгында да "дөньяи дүнәнне" дигән сүзләрне искәрмәләрдә "дөнья дигән ат" дип аңлатканнар. Минем уйлавымча, мондый аңлатма дөрес түгел. Беренчедән, ул шигырьнең үлчәменә туры килми (унбер иҗекле); икенчедән, мондый аңлатманың мәгънәсе сораулар тудыра; өченчедән, шигырьнең соңгы юлында "дүн" сүзе белән бәйле булган "дәни" сүзе килеп чыга–бу ике сүз гүя шигырьне ике яктан график чиклиләр; дүртенчедән, "дөньяи дүн" дигән гыйбарә төрек телендә кулланыла: һәм, ниһаять, бишенчедән, башка төрки телләрдә "дөнен-дүнән-дөнөн" сүзе өч (кыргыз телендә - дүрт) яшьлек хәйванны (атны) аңлата. Хәзерге татар телендә ул сүз кулланылмый, шулай да ул сүзне Оренбургта, казакъ даласы чигендә яшәгән Дәрдемәнд белмәгән дип әйтсәк дөрес булмас.

[23] "Нәсихәт" дип исемләнгән бу шигырь беренче тапкыр 1913 елда "Аң" журналының март санында басылган. Шулай ук: ДӘ-1980.–72 б.

[24] "Бүзләрен мана алмадым" (Шура. – 17 апрель 1908). – ДӘ-1980, - 48-50 б. "Кәфнем" сүзе белән башланган строфа, шигырьнең размерына туры килми – бирелә җиде иҗек урынына тугыз.

канәгатьләнми.[25] Ул да танылуга мохтаж, ләкин ул заманалар алышыну белән үзгәрә торган зәвыкка үз шигырьләрен яраклаштырырга теләми.

Ә бәлки танылуның җитеп бетмәве, инде шагыйрьнең үзе яшәгән чагында ук дошманнарының аңа гаеп ташлаулары артып китү, аның тирә-якка һәм үз-үзенә карашын тагын да чарлап җибәргәннәрдер. Монысын ул түбәндәге сүзләр белән раслый:

*Күңелемнең әзрәк кенә кинәсе бар,*
*Телемнең дә зәһәр очлы инәсе бар.*[26]

Һәм Дәрдемәнд бу очлы "инәне" куллана. Анын белән ул үзенә карата игътибарсызлыкка яки дин[27] мәсьәләсенә генә кагылмый, (ә бу темаларга аның рифма төзүче күпсанлы замандашлары бик яратып фикер йөрткәннәр), "инә" белән ул тәрәккыят идеясенә һәм милли эйфория хисләренә күмелгән коллегаларын кадый. Бу "инә" очыннан ачы көлү һәм ирония тамып тора. Мәсәлән, 1905 елдан соң килеп чыккан шагыйрьләрнең күплегенә һәм дөнья күргән бихисап шигырьләргә ул түбәндәге сүзләр белән аңлатма бирә:

*Мөгзе бар куйның бары да кучкар түгел,*
*Очкан кошның барысы да шоңкар түгел.*
*Кемнәр әйтмәс шигырьне, әйтер берүк,*
*Чукаңлаган аксак ишәк толпар түгел.*[28]

Яңа уянган һәм еш кына арттырып кабул ителә торган милли хис, "татарлык" белән артык горурлану Дәрдемәнд өчен бер химера булып тора. Татар милли үзаңын булдырырга тырышулар, татар милләтен күккә кадәр чөюләр ни дәрәҗәдә көлкегә әверелергә мөмкин икәнлеген Дәрдемәнд ачык иттереп "татар" этнонимы белән эш итү мисалында, түбәндәге шигъри юллар белән тасвирлый:

*Хәялдан сүз ачып, берничә галим*
*Ачык күрсәттеләр... аларда барны:*
*Очырдылар "тат"ын татар башыннан,*
*Чыгардылар бит "ар"лыкка татарны...*
*Гаҗәп түгел сабый—итә сабыйлык,*
*Гаҗәптер әмма галәмдә габилек.*[29]

Ләкин шул ук вакытта Дәрдемәнд артык заманча яшәү белән мавыгып, заманча дип, бары русларга ияреп баручы татарларны да, "татар" сүзенен "кыргый" сүзенең синонимы булуын искә алып тәнкыйтьли:

*Тагып күзлек, салып башка силиндер,*
*"Татар" ны нинди остардың сүгәргә!..*

---

[25] Кара, мәсәлән: Бурнаш Ф. Тукай шигырьләрендә иҗтимагый моңнар (Тукайның үлүенә 9 ел тулу мөнәсәбәте белән // Татарстан хәбәрләре. - № 87 (464). – 17 апрель 1922 ел; Мортазин С. Иске мирастан файдалану мәсьәләсе // Кызыл Татарстан. - № 280 (2650).–8декабрь 1929 ел; Хәсәнов Х.Х. Хөсәен Ямашев һәм татар демократик интеллигенциясе // Совет әдәбияты. –1952. - № 3.–58б.; Фасеев К.Ф. Әдәбиятта идеологик бозуларга каршы // Совет әдәбияты. –1954. - № 8.–76 б.

[26] ДӘ-1980.–149б.

[27] Бу сюжетка мин артык туктап тормыйм, чөнки аңа багышланган Дәрдемәнд шигырьләре шул темага язылган замандаш татар шагыйрьләре әсәрләреннән тел ягыннан булмаса да, эчтәлек ягыннан артык аерылып тормыйлар, бары тик кайбер исемнәрне атау белән генә чикләнәм: " Замана вагыйзенә", "Аллага тәвәккәл!", "Я китсен суфи мәктәптән...", "Иске чапан белән керле чалма".

[28] ДӘ-1980.–116 б.

[29] Шунда ук.–88б.

*Укы бер ел янә, күп арттырырсың—*
*"Явыз милләт"не дә ватыр, кырырсың!..* [30]

Мондый "модернизация" ирләр өчен генә хас булмаган икән, хатын-кызлар да ана актив кушылып киткәннәр:

*Буе зифа, йөзе күркәм, үзе яшь,*
*Күзе кара, озын керпек, каләм каш.*
*Йөзен якты күреп, сандым аны нур,*
*Булыр нур, баксам: ул—иннек тә акбур.* [31]

Агулы "инә" шагыйрьнең үзен дә кызганмый. Лирик "мин"нең "без"е икенче планга күчә һәм анын урынына "мин" килеп баса. Һәм шул "мин"не тасвирлау өчен табылган сүзләр ачыграк һәм үткенрәк була башлыйлар. Бу үзгәрешнен нигезен бары тик шагыйрьнең танылып житмәвендә генә күрәсе түгелдер, аны бәлки үзгәргән, бозылган заманаларда эзләргә кирәктер: ачлык, тиф эпидемиясе, Беренче Бөтендөнья сугышы, Февраль, ә аннан соң Октябрь революциясе, гражданнар сугышы—Закир Рәмиевнен шәхси тормышында бу вакыйгалар эзсез үтә алмаган шикелле, алар шагыйрь Дәрдемәнд ижатына да көчле тәэсир иткәннәр.




Унынчы еллар ахырында, искелек һәм яналык арасында көрәш гажәеп дәрәжәдә кискенләшкән чорда, Дәрдемәндне иң куркыткан нәрсә—искелекне югалту яки анын урынына ниндидер яна, ят нәрсә килү түгел, ә шушы ике бер-берсенә каршы тора торган ике нәрсә арасындагы каршылыкнын чишелү формасы. Кискенлек, дөньяны үзгәртү максаты белән күрсәтелгән чиксез ихтыяр көче, хакимияткә омтылыш—шул чорда болар барысы да үзенең чын йөзен ачты һәм алар шагыйрь өчен кабул ителми торган чит күренешләр. Аларга ул нәфрәт белән карый. Ә менә үзенең көчсезлеге аны сокландыра:

*Зәгыйфь кырмыскамын мин юлда яткан,*
*Түгел бал корты мин—чагып елаткан,*
*Ни зур бу дәүләт, кем, шөкер итәм чук.—*
*Минем беркемгә җәбер итәр көчем юк.* [32]

Көчсезлек бәхете—шагыйрь, күрәсен, мона ышанган яки, һич булмаса, өметләнгән—шәхси тынычлык һәм ирек гарантиясе булып тора:

*Әгәрчә дәүләтем юктыр җитәрлек,*
*Ишектәй һәм йөк астында түгелмен.*
*Үзем башмын, үзем түш һәр эшемдә—*
*Тынычлыкта торамын, хуш күңелмен!* [33]

Түбәндәге ике мәгънәле гажәеп кыска шигырьдә Дәрдемәнд үзен һәм янәшәдә яшәүче кешеләрне шулай итеп бәяли:

[30] Шунда ук.-41 б. Дәрдемәнднең тагын бер шигырендә ("Абдул Абдуличкә") татар һәм рус телләре арасында адашып калу күренеше турында сүз бара (Шунда ук. - 61 б.)

[31] ДӘ.-1980.-123 б.

[32] Шунда ук.-110 б.

[33] Шунда ук.-109 б.

*Талигымдыр та әзәлдән—*
*Һәр эшем бозгын төшәр;*
*Былбылә корсам тозагы,*
*Бәхтемә козгын төшәр![34]*

Ләкин мондый күпмәгънәлек замана рухына туры килми иде. Киләчәкнең чынбарлыгы ачыклык таләп итте. Һәм Дәрдемәнд кушыла алырдай бердәнбер шигъри аныклык—ул дәшмәүчәнлек:

*Җитәр инде, Дәрдемәнд, сүзне озайтма,*
*Катып кунган күңелләргә боз атма!*
*Дилең өчен телең булсын тозаклы,*
*Йөз аклыгың өчен—аузың йозаклы![35]*

Шагыйрь дәшми торучыларның урынын төгәл белә:

*Куанды ил, канат какты мәләкләр,*
*Шашып, аң-таң булып шайтан төкерде!..*
*Җитәр, җилкенмә, йолкынма, күңел, син,*
*Кияү булсаң да, ул туйга түгел син!*
*Җиһан тормыш туен иткән чагында,*
*Синең урның—үлекләр аймагында.[36]*

Шагыйрь Дәрдемәнд шулай дәшми калды. Закир Рәмиев 1921 елның 9 октябрендә Орск шәһәрендә дөнья куйды. Ул мәңгелеккә киткән йортның тәрәзәләре Урал елгасына карыйлар иде. Козгыннар башка очмадылар һәм аның туган иле хәзер инде ансыз яшәргә тиеш иде...

Язылган чоры өчен Дәрдемәнд шигырьләре—уникаль, кабатланмас күренеш. Әгәр дә без XX гасыр башы татар лирикасында аның белән чагыштырырлык мисал эзли башласак, бер чыгармадан башка бүтән бернәрсә дә таба алмаячакбыз. Сәгыйть Рәмиев (1880—1926) иҗаты гына Дәрдемәнднеке шикелле үк мөстәкыйль һәм аерым урын алып тора. Бу ике шагыйрьнең татар дип танылган һәм үскән лирикадагы аерымлыгы, бигрәк тә әсәрләренең мәгънәви, уйландыра торган эчтәлегендә, аларда чагылыш тапкан "дөньяга карашында" һәм өлешчә тел стилендә, сайланган шигъри формада күренә. Алар икесе дә татар эше өчен көрәшүче шагыйрьләр, язучылар, зыялылар арасында киң таралган "әдәбият иҗтимагый бурычлар үтәргә тиеш һәм ул тәрәккыят, модернизм символы булып тора, шагыйрьләр исә иҗатларын шул бурычка буйсындырырга, аңа хезмәт итәргә тиеш" дигән карашны кабул итмиләр. Шулай да Дәрдемәнд һәм Сәгыйть Рәмиев өчен шагыйрь игътибар үзәгендә тора: шагыйрь—иҗатында дөньяга карашны, дөньяны аңлауны, иҗтимагый һәм тарихи мохиткә карашны чагылдыра торган зат. Бу төп ышаныч ике шагыйрь өчен дә уртак. Әмма дөньяны аңлауда һәм шул дөньяда үз урынын аңлауда аларның карашлары аерылып тора. Дәрдемәнд шигырьләре гаҗәп дәрәҗәдә тыгыз, аларның һәрбер вак детале дә бер-берсенә бәйләнгән, шигырьләр музыкага салынган шикелле кабул ителәләр. Бу аның кешегә карашына да тулысынча туры килә: кеше ул—чиксез, ул—вакыт һәм киңлек ягыннан үлчәнә алмаган галәмнең бик вак, тиз үтеп китә торган кыйпылчыгы. Сәгыйть Рәмиев шигырьләре исә—экстатик кычкыру, алар сызгырган камчы тавышын, күк күкрәүне яки ачулы көлүне хәтерләтә. Аларның нигезендә бер нәрсә белән дә чикләнмәгән, тормышка ябышып яткан, үлем

[34] Шунда ук.–136 б.
[35] Шунда ук.–140 б.
[36] Шунда ук.–89 б. 1929 ел басмасында соңгы ике юл бергә һәм алдагылардан аерылып бастырылган (60 б.)

каршында да бирешмәгән "мин".[37] Биредә мисал итеп "Кабакта мәхәббәт" шигырен китерергә телим:

*Бетте баш, кипте яшь, китте бар рәхәт.*
*Китсен! Ни күрсәм, мин күрермен,*
*Язмыш ни язгандыр—белгән бер әхәт,*
*Аңар буйсыныр йөрәрмен.*
*Азармын, тузармын, шулай мин йөреп,*
*Язмышның бурчын тик үтәрмен...*
*Ахыр бер сәгать мин аңар баш орып,*
*Ләгънәт ди, ләгънәт ди үләрмен.*[38]

Әгәр дә без татар мохитеннән читкәрәк китсәк һәм шул чор төрки телле Урта Азия халыкларынын лирикасында охшашлыклар һәм Дәрдемәнд шигърияте белән параллельләр эзли башласак, минемчә, бары тик бер шагыйрь иҗатында гына без шундый охшашлыкларны таба алабыз. Ул—1897 елда Әндиҗанда, Фирганә үзәнендә туган Габделхәмид Сөләйман. "Чулпан" псевдонимы белән язган бу үзбәк шагыйре "XX йөз үзбәк лирикасы, драматургиясе, прозасында хәлиткеч роль уйнаган".[39] Дәрдемәнд шикелле үк Чулпан да үз шигырьләрен гади телдә яза һәм нәкъ шул гадилек аларны аерата тәэсирле һәм мәгънәле итә. Ләкин ике шагыйрьне тел белән гаҗәп оста эш итү генә якынайтмый, алар сайлаган мотивлар һәм метафораларда да без ачык параллельләр күрә алабыз. Чулпан шигырьләрендә дә табигать, ел фасыллары зур роль уйныйлар: икесе дә кышны сөймиләр, Дәрдемәнд өчен дә, Чулпан өчен дә карга—бәхетсезлек, кайгы, куркыныч әшәкелек турында хәбәр итүче кош.[40] Минем уйлавымча, ике шагыйрьнен "дөньяга карашы" да охшаш, гәрчә Чулпан иҗатында сәяси мотивлар һәм интерпретацияләр Дәрдемәндкә караганда ачыграк күренсә дә. Дәрдемәнднен тормышны килеп чыгулар һәм узып китүләрнен чиксез-кырыйсыз бер әйләнеше дип кабул итүен Чулпан иҗатында да күрәбез. Бу фикер бигрәк тә 1926 елда иҗат ителгән "Бәһарны сагындым" дип исемләнгән шигырьдә чагылыш таба: көз житте, кыш якыная, агачлардагы яфраклар саргая һәм коела башлыйлар, табигать үлемгә әзерләнә. Һәм без шагыйрь тавышын ишетәбез:

*Юк... Үлем юктыр!*
*Бары бер яну, бер сүнү бардыр.*
*Бер яныл, сүнеп... Яңадан яну бар.*

---

[37] Егерменче еллар башындагы "ультра-сул" интеллектуалларыннан башлап,алтмышынчы еллар ахырындагы совет әдәбият белгечләренә кадәр Сәгыйть Рәмиевне каты тәнкыйть уты астында тоттылар. Аны "агностицизмның" типик вәкиле дип атадылар, "анархо-индивидуалистлык" вәкиле буларак фаш иттеләр һәм " татар Есенины" дип хурладылар. Кара,мәсәлән: Сәйфи-Казанлы Ф. Г.Тукай әсәрләрендә пародия, сатира, ирония һәм юмор // Г.Тукай әсәрләре. – Т.3. – Казан, 1931. - XIX б.; Гали М. Сәгыйть Рәмиевнең иҗат һәм тормыш юлы // Совет әдәбияты. – 1940. - № 4. - 79 б.; Хәйри Х. Җавапсызлык хатына җавап // Совет әдәбияты. – 1948. - № 10. – 117 б.; Халит Г. XX йөз башындагы татар әдәби хәрәкәтенең кайбер мәсьәләләре // Совет әдәбияты. – 1950. - № 1. - 108б. "Мин" шигыре турында кара: Baldauf, Ingeborg: Prometheismus in der circumrevolutionдren tatarischen Lyrik, in: Bamberger Mittelasienstudien. Hrsg. Bert G. Fragner, Birgitt Hoffmann, Berlin 1994, S.25-66.

[38] Сәгыйть Рәмиев шигырьләре .–Уфа, 1918. – 32-33 б. 1913 елның язында татар милли шагыйре Габдулла Тукай "Кыйтга" дигән шигырен яза (Аң.–01.03.1913.-№ 6) һәм шул шигырьдә үзенең өметсезлеген, бигрәк тә үз иҗатыннан канәгатьсезлеген белдерә. Бу шигырьнең соңгы икеюллыгында укыйбыз: "Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч–шул булды эш". Минем уйлавымча, Сәгыйть Рәмиевнең шигыре Тукай сүзләренә сатирик бер реплика буларак кабул ителергә мөмкин.

[39] Ингеборг Бальдауфның әлегәчә басылып чыкмаган "Чулпон" дип аталган мәкаләсеннән.

[40] Чулпанның түбәндәге шигырьләрен кара: " Көз" (1921), "Яңадан кар" (1921? 1922?), "Кыш алдыннан" (1922), "Яшел яфраклар" (1923), "Кар" (1924), " Көз гөләнә" (1925) . (Чулпон. Яна олдым сузимни. / Ред. О.Шарафиддинов. - Тошкент, 1991. – 414, 424, 448, 482, 508, 511 б.

*Яңа язлар,*
*Яңа лаләләр,*
*Яңа, сез, әй, иркен теләкләр!*[41]

Ачык, гади тел, ирекле форма һәм "көнчыгыш зирәклеге"нең уңышлы синтезын булдыруда Чулпан өчен Дәрдемәнд кенә түгел, ә һинд шагыйре Рабиндранат Тагор да үрнәк булган.

Шул чорның Һиндстан һәм Иран фәлсәфи-мистик шигъриятен дәрт чыганагы буларак артык якын итмәгән Русия империясе төрки телле шагыйрьләреннән аермалы буларак, XIX йөз уртасы Көнбатыш шагыйрьләре үзләре өчен яңа "Көнчыгыш" дөньясы һәм аның шигъриятын ача башладылар.[42] Бередә, Дәрдемәнд белән чагыштырырлык бары тик бер шагыйрьгә игътибар итәсем килә—аның теле, шигъриятне аңлавы, "миндәге дөньяга" (мир в себе) карашы аны, һичшиксез, Дәрдемәндкә якын итә. Ул—Уолт Уитмен. Әйе, "Көнчыгыш" һәм шул исәптән, Дәрдемәнд белән "Көнбатыш" шагыйре Уитмен арасындагы күпер бер дә Уитмен—Тагор арасындагы күпердән тар түгел. Уитмен ул үз-үзен еш кына "Көнчыгыш һәм Көнбатыш арасындагы күпер" дип билгеләгән һәм үзеннән башка бер Америка шагыйре дә Көнчыгышның мистик рухын шулай яхшы аңламый дип ышанган.[43] Чыннан да, әгәр дә без бу Америка шагыйренең үз иҗаты турында әйтелгән сүзләрен алсак, алар турыдан-туры Дәрдемәнд шигърияте турында әйтелгән кебек тоела: "Бөтен яшәгән нәрсә—синдә, бездә, барыбызда—ул безнең барыбызда да бар: кешеләрдә, заманаларда, хайваннарда, үсемлекләрдә, ташларда. Без—ул бар нәрсә һәм бар нәрсә—ул без. Башлангыч һәм ахыр, туу һәм үлем—алар нәрсәләр соң? Бар нәрсә—ул мәңгелек хәрәкәт. Ашкыну, омтылыш, дәрт. Дөньяны тудыручы мәңгелек теләк". Бу сүзләр белән Иоһаннес Шлаф 1892 елда Уолт Уитмен һәм аның төп китабы "Үлән яфраклары"н бәяли.[44] 1907 елда Густав Ландауэр шулай дип язган: "Уитмэн шигъриятенең иң әһәмиятле ягы—ул фикер йөртергә өнди, укучы өчен аның һәрвакыт образлары әзер—алар дулкын кебек уйныйлар, йә якынаялар, йә ерагаялар".[45] 1857 елда басылып чыккан һәм поэзияне аңлауга багышланган "Демократик мөмкинлекләр" дип аталган эсседа Уитмен үзе дә нәкъ менә шул "ышандыру"ны, фикер йөртергә өндәүне чын шигъриятнең әһәмиятле һәм зарури билгесе дип аңлата: "Кеше фикере, шигърият яки мелодия ачык булмаса да, котылу юлларын күрсәтергә тиешләр, киңлеккә якын йомшак, нәфис булырга тиеш. Хыялланa белмәгән кеше аны аңлый алмаса да, ул барыбер югары максатка ирешү өчен зарури".[46] Һәм икенче урында: "Берәр теманы яки фикерне мин мөмкин кадәрле аз ачарга яки күз алдына аз китерергә һәм сезне, укучым, шул тема яки фикер атмосферасына кертергә, үз очышыгыз белән очыртырга тырышам".[47]

Үз алдына шундый максат куйган шагыйрь бик очлы күзле һәм хисле күзәтүче булырга тиеш. Бар дөньяны, тирә-якны, барлык матди һәм рухи күренешләрне ул бөтен күңеле белән кабул итәргә тиеш. Уитмен үзе шундый шагыйрь булган, Дәрдемәнд дә шундый. "Сәлам, дөнья!» дигән шигырендә Уитмен бар дөньяны кочып ала: "Нәрсә ишетәсең син, Уолт Уитмен? (...) Мин Сүриядәге чикерткәләр черелдәвен ишетәм. (...) Мәчет башыннан гарәп мөәзиненең тавышын ишетәм. (...)

---

[41] Чулпон. Яна олдым сузимни . - 522 б. (Үзбәкчәдән татарчага ирекле тәрҗемә. - Тәрҗемәче искәрмәсе).

[42] Arthur Christy, The Orient in American Transcendentalism. A Study of Emerson, Thoreau and Alcott, New York 1963.

[43] V.K.Chari, "Whitman in India", in: Walt Whitman and The World, ed. By Gay Wilson Allen, Ed Folsom, Iowa City 1995, S. 396.

[44] Walt Whitman and The World, ed. By Gay Wilson Allen, Ed Folsom, Iowa City 1995, S. 181.

[45] Шунда ук.–S. 192.

[46] Кара: James E. Miller, "The Poetics of the Cosmic Poem", in: Walt Whitman and The World, ed. By Gay Wilson Allen, Ed Folsom, Iowa City 1995, S.49-50.

[47] Кара: James Olney, The Language(s) of Poetry. Walt Whitmen, Emily Dickinson, Gerard Manley Hopkins, Athens-London 1993, S. 44-45.

Кайсы шәһәрләргә яктылык һәм жылылык барып ирешә, мин дә шул шәһәрләргә юл тотам! Кошлар оча торган барлык утрауларга да мин дә очып барам (...)".[48]

Бу очышны жинеләйткән һәм мөмкин иткән иң мөһим чара—ул тел. Әгәр дә шагыйрь мөмкин кадәр тизрәк укучының, бәлки дөресрәге, тыңлаучының йөрәгенә барып житәм ди икән —тавыш һәм яңгыраш бик зур роль уйныйлар. Дәрдемәнд һәм Уитмен—тел осталары. Бу ике шагыйрьнең дә теле—югары дәрәжәдәге ритм һәм рифмадан, ассонанс һәм аллитерациядән, сүзләр һәм жөмләләр тезелүендә сүзләрнең бер-берсен төрле темпта алмаштыруыннан, алар арасында яткан паузалар һәм туктап торулардан хасил. Бер яктан караганда, икесе дә "гади", без көнкүрештә сөйләшә торган телдә ижат итәләр, ләкин икенче яктан—стиль, сүз сайлау ягын алсак,—телләре борынгы прозаны хәтерләтә.[49] Бернис Слот мондый телне "борынгы телнең бер төре" (a kind of earth-language) дип атаган иде.[50] Әгәр дә бу характеристикадан соң без телне бер караштан "жиргә бәйле" итеп танысак, ягъни жирдә туган, жирдә тамырланган тел, икенче караштан, без аны "жирне кочарлык" хәлдә булган тел дип кабул итә алабыз. Ягъни бөтен жирдә танылырлык, кабул ителерлек тел. Минем уйлавымча, мондый характеристика Дәрдемәнд һәм Уолт Уитмен ижаты өчен бер дәрәжәдә.

XIX йөз ахырында Русиянең күп кенә зыялылары, язучылары, шагыйрьләре яңа офыклар, шул офыкларга алып бара торган юллар эзләү белән мәшгуль булдылар. Бу эзләнүләрнең төп юнәлеше —Көнбатыш,[51] яңалыкка сусауны басарга ярдәм итә торган чишмә—Уолт Уитмен иде: "XIX йөз рус мәдәнияте тарихында Уолт Уитмен ролен бик югары бәяләргә кирәк. Аның аудиториясе, аңа карата хөрмәт, аның йогынтысы гажәп зур иделәр".[52] Бу эзләнүләрнең төп максаты итеп рус шагыйрьләре "поэзиянең мәңгелек образын реабилитацияләүдә" күргәннәр.[53] 1906-08 еллар рус әдәбиятында хакимлек иткән символистларның идеологы булган Дмитрий Мережковский шагыйрьләрнең "баналь" фажигалектән китә алмауларын һәм актуаль темаларга карата сукыр булып калуларын фаш итте, сәнгатьнең әхлакый түгел, ә эстетик проблема икәнлеген яклап чыкты: "Сәнгатьнең иң югары әхлакый максаты ниндидер әхлакый тенденцияләрне чагылдыру түгел, ул—сәнгатьченең хакыйкатькә риясыз, сатылмас һәм тугры мәхәббәтеннән, аның бер нәрсә белән дә чикләнмәгән риясызлыгыннан тора".[54] Валерий Брюсов, 1894 елда чыккан "Русские символисты" дигән жыентыкның кереш сүзендә болай дип язган: "Символизмның максаты—бер-бер артлы алмашынып тора торган күренешләр аша укучыны гипноз хәленә кертү, үзенә күрә аның рухын үзгәртү".[55] Шуна күрә, Брюсов фикеренчә, шагыйрь өчен иң әһәмиятлесе—"дөнья күренешләре һәм әйберләре өчен дөрес исемнәр табу".[56] Бу "исемнәр", ягъни "символлар" , 1916 елда Вячеслав Иванов әйтүенчә, ниндидер яшерен, сихерле нәрсәләрне тасвирламыйлар, алар "бигрәк

---

[48] Walt Whitmen,Grashalme,Stuttgart 1996,S. 130-142. Биредә мин бераз ирекле рәвештә Дәрдемәнд ижатына географик яки мәдәни яктан якынрак булган цитаталарны сайладым.

[49] Уолт Уитменнның теленә шундый сүзләр белән Рәчел Полонски характеристика бирә ( Rachel Polonsky,"Translating Whitman,Mistranslating Bal'mont",in: The Slavonic and East European Review 75 (3) 1997,S. 409-410.

[50] Bernice Slote,"Start with the sun" ,in: James E. Miller,Karl Shapiro,Bernice Slote,Start with the sun 1960,S. 236.

[51] Мәсәлән,тәнкыйтьче Евгений Аничков (1866-1937) символист-шагыйрьләр турында түбәндәгечә язган: "Алар барлык мөмкин булган яңа Көнбатыш чыганакларыннан эчеп торганнар" (кара: Martin Bidney, "Leviathan, Earth-Titan, Eagle: Bal'monts Reimagining of Walt Whitman", in: Slavic and East European Journal 34 (2) 1990,S. 176.

[52] Stephen Stepancev,"Whitman in Russia",in: Walt Whitman and The World,ed. By Gay Wilson Allen,Ed Folsom,Iowa City 1995,S.300.

[53] Johannes Holthusen, Russische Gegenwartsliteratur I, 1890-1940. Die literarische Avantgarde, Bern-Mьnchen 1963,S. 10.

[54] Шунда ук.–S. 11.

[55] Кара: Johannes Holthusen,Studien zur Дsthetik,S. 16.

[56] Шунда ук. - S. 50.

тә магик тере реальлекне чагылдыралар, шулай итеп ул реальлек объектив яктан күрсәтелә һәм бәяләнә".[57] Нәкъ шушы фикерне Карл Шапиро Уолт Уитмен иҗатына карата да куллана: "Шигърият—ул дөньяның метафорик яки символик версиясе генә түгел, ул турыдан-туры реальлекне тасвирлау».[58] Димәк, монда сүз "дөреслек", "туры сүзлелек" турында бара. Бу рус символистлары тарафыннан югары бәяләнгән һәм алар тарафыннан Уолт Уитмен иҗатында табылган "яшәешнең тулылыгын бөтен яктан дөрес тасвирлау" принцибы "үз эченә барлык өстәмә процессларны да алып торган—җимерүне дә, яңарыш-тудыруны да".[59]

Әгәр дә биредә китерелгән рус символистларының һәм өлешчә аларның "остазларының" (мәсәлән, Федор Тютчев[60]) яшәештә поэзия урыны турындагы сүз-фикерләрен Дәрдемәнд лирикасы белән чагыштырып карасак, охшашлыклар һәм тәңгәл килүләр көн кебек ачык: әхлакый һәм сәяси аныклыктан баш тарту, аның урынына әдәбият һәм сәнгать өчен үзбилгеләнүне таләп итү, "реальлекне" "очлы" күз белән, барлык хисләр белән кабул итү, шул исәптән, узганнарны да, чынбарлыкны да; мәгънә һәм янгыраш берләшкән, укучыны бәйләми торган, киресенчә, аңа киңлек ача торган, уйланырга һәм ирекле кош кебек очып йөрергә мөмкинлек бирә торган төгәл һәм тыгыз мәгънәле тел. Мондый шигърият баштан ук чиксез дөньяның бар ягын кабул итүгә теләк һәм омтылыш белән аерылып тора.

Түгәрәк шулай итеп йомыла. "Очыш"ның башы, кайда һәм ул кайда тәмамлана— минемчә, бу сорауга җавап бирү бик кыен. Биредә мин кыскача "Дәрдемәнд һәм бөтендөнья әдәбияты" темасына кайбер фикерләремне белдереп, артык зур бәйләнеш конструкциясен төзеп куярга теләмәгән идем. Бу очракта минем өчен иң әһәмиятлесе шунысын күрсәтү булды: XIX йөзнең ахырында һәм XX йөз башында дөньяның төрле кыйтгаларында яшәп төрле тарихи, мәдәни, тел традицияләре булган шагыйрьләр нәкъ бер юнәлештә фикер йөртә башлыйлар. Алар иҗат иткән әсәрләр бер ритмда—"дөнья рухында"—сулыш ала, алар иҗат иткән һәм шул рухны чагылдарган тел—ул "дөнья теле". Шагыйрь Дәрдемәнд һәм аның иҗаты өчен бөтен дөнья Ватан булган.

Немецчәдән **Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ** тәрҗемәсе

[57] Шунда ук. - S. 32.

[58] Karl Shapiro,"Cosmic Consciousnes",in: James E. Miller,Karl Shapiro,Bernice Slote,Start with the sun 1960,S. 32.

[59] Martin Bidney,"Leviathan",S. 182.

[60] Кара: Almut Schulze,„Tjutevs Kurzlyrik,Mьnchen 1968,S. 9,14,37,42,80,84.

# СЕМБЕР ШАГЫЙРӘСЕ

## ИДЕЛБИКӘ ИҖАТЫНА БЕР КАРАШ

Сембер—борын-борынгыдан татарларның үз төбәге. Бирел бүген дә саф татар авыллары гына түгел, хәтта тулысынча диярлек милләттәшләребез генә яши торган Иске Кулаткы районы да бар. Бу төбәк Г. Кандалый, С. Сүнчәләй, С. Урайский, И. Нуруллин, Г. Сәгыйров кебек әдәбият әһелләрен бирде. Тагын шунысы сөенечле: узган гасыр ахырында бирелә дә милли йөзебезне саклау, мәдәниятебезне үстерү хәрәкәте җанланып китте. Мәктәпләрдә туган телебезне һәм әдәбиятыбызны укыту башланды, Ульяновск педагогия университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачылды. Бирелдәге милли телебездә иҗат итәргә омтылучылар әдәби берләшмәгә оештылар, Татарстан Язучылар берлеге белән элемтә урнаштырдылар. Бу исә яңа талантларны барларга, үстерергә мөмкинлек бирде. Шул дулкында инде байтак еллар иҗат итеп килгән Иделбикә дә рәсми рәвештә шагыйрә булып танылды. 2001 елда без аны Татарстан Язучылар берлегенә кабул иттек. Чөнки ул үзенең өлгергән иҗаты белән генә түгел, бәлки әдәбиятны изге күрүе белән дә аерылып тора. Иҗатташлары Г. Сәгыйров, Р. Хисмәтов һәм башкалар турында кайгыртып, аларның иҗатын популярлаштырып мәш килеп йөри ул. Аның чын исеме Лена Беньямин кызы Сабитова-Садыйкова. Ул әтисенең һәм хәләле фамилияләрен әнә шулай бергә йөртә. Монда да аның үзенә бер шәхес икәнлеге күренә. Иҗаты да татар шигъриятендә үз бизәкләре, үзенә генә хас тукымасы белән аерылып тора. Әмма язар өчен "азыкны" үзенең гаять бай тормыш чолганышыннан ала ул.



Иделбикә—шагыйрьлек миссиясен киң һәм зур итеп аңлаучы иҗатчы. Ул үз шәхесен дә, иҗатын да гомумкешелек даирәсендә карый:

*Кеше—Табигатьнең бер өлеше.*
*Кеше—Табигатьнең төн-өне.*
*Мин дә өермәнең бер бөртеге,*
*Гомерем җыйган хәтер төене.*

*Шигырьләргә төеннәрем чишәм*
*Җаннарыма иңгән бураннан.*
*Хәтеремнең төпкеленә төшәм,*
*Барлап: кайсы, нидән, ул кайдан?*

Шагыйрә егерменче гасырның иң күп өлешендә яшәп, яңа меңъеллыгыбызның менә бу беренче дистәсендә дә, шөкер, бик матур тормыш итә һәм иҗат ялкыны белән яна. Аның гаять бай тормыш һәм иҗат тәҗрибәсе бар. Шуңа күрә ул, үткәннең төбенә төшеп белгән кебек, бүгенгенең асылын һәм аның алга таба нинди хәлләргә алып киләсен төгәл чамалый. Вакытның әнә шул ике катламын, шагыйрьләрчә образлы итеп, капма-каршы куеп, чагыштырма рәвешчә күрсәтеп тә бирә. "Хатирәләр яши, хатирәләр" поэмасы шул ягы белән гыйбрәтле. Ул кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне тасвирлауга корылган. Тиздән бөек җиңүебезнең 65 еллыгын бәйрәм итәчәкбез. Әнә шул кырыгынчы елларның беренче яртысындагы

ачлык-ялангачлык, кайгы-хәсрәт шагыйрә хәтерендә ап-ачык сакланган.

Ләкин авырлыклар кешеләрдәге матур сыйфатларны юкка чыгара алмаган икән бит. Бигрәк тә аларның бер-берләренә булган самими мөнәсәбәтләре шагыйрә хәтерендә яңара. Шырпы булмаганлыктан, бер-берсенә утлы күмергә керүләр... Күршеләр бер-береннән көйрәгән күмер генә түгел, күңел җылысы да алып чыкканнар. Бары бергә, югы уртак булган шул еллардагы ихласлылык, гадилек, эчкерсезлек—бүген иң җитешмәгән нәрсәләр. Башкаларга күңеленең бар җылысын биреп тә үзен саклап кала алмаган Җиһан әбиләр бүгенге укучыга бик тә тансык булып кабул ителә.

*Көн аяусыз, авыр, әмма халык*
*Мәрхәмәтле иде, гөнаһсыз.*
*Чыгып китә иде ишек ябып,*
*Тик келәсен салып, йозаксыз.*

*Сату-алу тик базарда иде,*
*Сатулашмадылар берсе дә.*
*Тәүге угыз сөте булешенде,*
*Сыер бозауласа күршедә.*

Илне ярату, ягъни ватанпәрварлык, күршеңне, авылыңны, туган төбәгеңне яратудан килә. Бүген иң җитешмәгән әйбер—бер-береңә ышаныч, хөрмәт. Шагыйрә моның да сәбәбен чагыштыру ярдәмендә аңлата:

*Безнең буын Илне сөеп үсте:*
*Шифаханә, мәктәп, институт—*
*Барчасы да безгә бушлай иде,*
*Барчабызга булды бер хокук!*

"Юллар һәм уйлар" дип аталган сонетлар бәйләме. Аларның камиллеге күзгә бәрелеп тора. Циклның "такыя" дип аталуына да сәбәп бар. Дөресен әйткәндә, зур гына күләмле бу цикл лирик геройның тормыш юлындагы төп сәхифәләргә бәйле күңел кичерешләрен иңли. Әлеге цикл—егерменче гасыр кыз баласының үзе ана булганчы үткән тормыш юлын тасвирлаучы хикәя. Иделбикәнең бу очракта әлеге жанрда эшләгән Ш. Мөдәррис, М. Хәсәен, Ә. Синегул традицияләрен новаторларча дәвам иттерүен күрәбез. Себер, Ташкент, янадан Идел буена бәйле хәят илнең тулаем күренешен күз алдына китерә сыман. Алай гына да түгел, шул контекстта авторның газиз халкыбыз, туган телебез гаме белән януы да әлеге такыя бизәкләренә табигый үрелә. Әсәрнең сәнгать көчен арттыручы фәлсәфилек исә—авторның даими юлдашы. Лирик герой фәлсәфи уйлар ярдәмендә нык иманлы булып гәүдәләнә:

*Нилэр үзгәрсә дә, үзгәрмәм үзем.*
*Гомер юлым ачык—кызармас йөзем,—*

дип нәтиҗә ясый ул. Мондый каһарманлык, ныклы ихтыяр булу укучыны шагыйрьгә фикердәш, теләктәш итә.

Иделбикә иҗатының тагын бер игелекле ягы бар, ул да булса аның туган төбәгендәге шагыйрь элгәрләренә аерым бер мәхәббәт белән каравы. Әйтик, Г. Кандалыйның 200 еллыгы уңае белән язылган мәдхия аталы элгәренең шәхесен һәм иҗатын соң дәрәҗәдә олылавы белән кыйммәтле. Мәдхия жанры, гомумән, теге яки бу олы затны мактауга корылган әсәр булырга тиеш. Әмма Иделбикә биредә дә яңача элементлар кертеп җибәрә. Г. Кандалый әсәрдә, олы шәхес булу белән бергә, үз заманы мохитендә кичергән каршылыклары белән сурәтләнә. Ягъни бөек шагыйрьнең яшәгән чорына да гадел бәя бирелә. Әдәбиятта яңа борылышны башлап җибәргән Г. Кандалый, шул рәвешле, шәхес һәм иҗатчы буларак, вакыт яктылыгына куела. Нәкъ менә шушы як әсәрнең яңалыгын билгели. Шул ук вакытта

Иделбикә бер мәсьәләдә элгәр шагыйрь белән риза булмаганын да белдерә (бу исә мәдхия жанрында гадәттә очрамый торган күренеш). Шагыйрә Г. Кандалыйның авыл хезмәте белән көн күрүчене "мужик" дип атавы белән килешми. Шул ук вакытта Иделбикә шагыйрь бабабызның әлеге сүзне куллануының наданлыкка каршы чыгуы белән аңлатылуы сәбәпле, аны аңлавын да белдерә. Мәдхия киләчәктәге иҗатчыларга язар өчен мәүзуг бирү белән тәгалләнә:

*Калын китаплар язарлык Кандалыйга мәдхия,*
*Дини дөнья һәм шигърият бүген аңа баш ия!*

Сүз уңаенда әйтәсе килә: бүген Сембердә милли җанлы затларыбыз Кол Галигә һәйкәл куюга иреште. Г. Кандалый да мондый зурлауга бик тә лаек.

Шагыйрә шулай ук якташы Сәгыйть Сүнчәләй язмышын читләтеп үтә аламы соң? Иске Кулаткы районының Иске Мостаяк авылында туган, әмма тәкъдир тарафыннан ике яшендә үк читкә алып кителгән С. Сүнчәләй язмышы бер үк вакытта көнләшерлек тә, тетрәнерлек тә. Көнләшерлек—ул тормыш юлында Г. Тукайны очрата, аңардан иҗатына, гомумән, яшәү рәвешенә хәер-фатиха ала. Тетрәнерлек—чөнки мәхшәрле 1937 елның үлем тегермәненә эләгеп, илле яшькә дә житмичә, корбан була. Бөтен гаебе—киң карашлы, зыялы, илһамлы, дөньяга үз мөнәсәбәте булу. Г. Тукай аның шәхесенең төп үзәген әнә ничек оста итеп һәм кыска әйтеп биргән: "Шөбһә юк, Сездә милләткә яки шөһрәткә бик кызу мәхәббәт бар".

Иделбикә дә, С. Сүнчәләйнең шәхесенә, иҗатына һәм язмышына битараф кала алмаган, аның милләтебезгә, әдәбиятыбызга, төрки дөньяга иткән хезмәтләрен зурлап бәяләгән:

*Мәгърифәтче, тәрҗемәче, шагыйрь...*
*Татар, башкорт, Кырым, Төркия—*
*Сәгыйть күп белем яулаган яугир—*
*Асыл затка барча баш ия.*

Шушы ук контекстта Иделбикә Г. Тукайның язмышын да, нибары бер строфага сыйдырып, бөтен аянычлыгы белән әйтеп бирә алган:

*"Җир яшәрмәс, гөл ачылмас,*
*Төшми яңгыр тамчысы..."*
*Төшмәгән җанына якты яз,*
*Төшкән язмыш камчысы.*

Афоризм булып әверелердәй мондый строфалар Иделбикәнең шагыйрә буларак табышы булып тора. Күргәнебезчә, шагыйрә реаль шәхесләрнең шигъри образларын хисси мохиттә сурәтләүгә аерым игътибар бирә. Аның Мәләкәс (Дмитровград) шәһәрендә яшәп иҗат итүче Гакыйль Сәгыйровка 70 яшь тулуга багышланган "Өермәләр" исемле поэмасы да бар. Инде ничә дистә еллар ятакка, коляскага бәйле рәвештә гомер кичерергә мәҗбүр булган Г. Сәгыйровның 70 яшькә җитүе үзе бер могҗиза, әлбәттә. Биредә аны озын гомерле итеп нәрсә яшәтә дигән сорау да тумый калмый. Мин моны ачык итеп әйтә алам—аны иҗат яшәтә. Әлеге нәтиҗәгә мин аның үзен күргәч килдем. 2001 елда "Кабатланмас моң" һәм "Ике кояш" китаплары өчен Татарстан Язучылар берлеге аңа Г. Исхакый исемендәге премия бирде. Шул бүләкне без аңа Ульяновск шәһәренә барып тапшырдык. Коляскага сөенеп кенә ятып торган бу зат янына якын килгәч, башта аптырап та калдым. Лауреат дипломын кабул итеп алырлык куллары да юк бит (бар алар, ләкин хәрәкәтләнми). Әлеге кадерле документларны аның күкрәгенә куярга һәм хәрәкәтсез кулларын сыйпау белән чикләнергә туры килде. Шул вакытта мин аның күзләренә карадым. Г. Сәгыйровның бөтен хисләре, кичерешләре, уйлары, яшәвенең мәгънәсе әнә шул күзләрендә чагыла икән. Алар ихлас куанып, өмет һәм ышаныч белән балкыйлар

иде. Йомшак кына итеп "Рәхмәт!" дип куюы әнә шул күзләрдә чагылган шатлыкның табигый рәвештә сүзгә әверелүе иде.

Икенче тапкыр мин аны Мәләкәстә китапларын һәм рәсемнәрен тәкъдир итү кичәсендә—мәдәният сараенда күрдем. Ул ясаган рәсем-картиналарны карагач, исем-акылым китте. Мондый камил, зәвыклы картиналарны ике кулы сау булган кешеләрнең дә күпчелеге ясый алмый. Тешләре арасына карандаш кыстырып язган шигырьләр һәм ясалган рәсемнәр Кешене, чыннан да, табигать могҗизасы дип таныта иде.

Иделбикәнең "Өермәләр" поэмасы да әнә шул хакта. Г. Сәгыйров турындагы поэманың әнә шундый көчле исем—"Өермәләр" дип аталуы, ничектер, башта акланып та бетми кебек. Җисмән яктан кеше ярдәменнән башка кымшану мөмкинлеге дә булмаган затны әнә шундый фонга куеп сурәтләү ничек икән дип уйлап та куясың. Әмма юк, алай түгел икән! Г. Сәгыйров дөньяга килгән февраль аеның өермәле бураннар вакыты булуына бер ишарә икән бу. Әлеге ай җиргә М. Җәлил кебек дөнья өермәләре алдында да көчле рухлы булып калган каһарманнарны да бүләк иткән икән бит. Г. Сәгыйров күңелендә дә менә ярты гасыр инде (өермәләр—фикер-хис давылы—тынмый, ул янадан-яна шигъри һәм рәсем сәнгате әсәрләре булып дөньяга туа, яшәүнең мәгънәсен ача. "М. Җәлил, Г. Сәгыйров кебек шагыйрьләр өчен бер ныклы үзәк, асыл сыйфат хас булырга тиеш", ди шагыйрә. Ул да булса:

*Зиһен тамырлары булсын ныклы,*
*Үсеп, күк йөзендә яшьнәрлек,*
*Киләчәккә орлык чәчәрлек—*
*Буыннарга күчеп яшәрлек.*

Әйе, йөрәгендә шундый иҗат уты янмаса, кеше, киләчәк буыннарны гына түгел, үз заманы кешеләрен дә уйлары-хисләре белән мавыктыра алмый. Иделбикә дә үзенең элгәрләре, замандашлары белән чиксез горурлана, шушы иҗат каһарманнары сафында булу аңа да бәхет хисләре өсти.

*Февраль нинди юмарт талантларга:*
*Инде Гакыйльгә дә җитмеш яшь!*
*Кайчак зарлансам да заманнарга,*
*Күпме талант миңа чын иптәш!*

*Китап арты китап, рәсемнәрең,*
*Кем соң әйтер: болар теш эше?*
*Бар вөҗүдең акыл-аңга туплап,*
*Дөнья көзгеләткән син—Кеше!*

Күрәбез, нинди яна рифма табылган: теш эше—син Кеше. Нәтиҗәдә Г. Сәгыйровның кеше һәм иҗатчы буларак бөтен драматизмы ачыла да куя.

XX гасырның олы шагыйре Мостай Кәрим "мине Иделбикә иҗатының бертуктаусыз һәм ашкынулы хәрәкәте шатландыра" дигән иде. Борынгы Рим фәлсәфәчесе Сенеканың "Луцилийга әхлакый хатлар" дигән китабындагы 124 хатның һәрберсе үзәгендә торган фикерләрне алып, аларны алтышар юллы шигырьләрдә биргән циклын Иделбикәнең татар шигърияте алып килгән үз табышы буларак карарга кирәк. Моннан ике мең ел элек кәгазьгә теркәлгән фикерләр бүген дә заманча янгырый. Монда, әлбәттә, Иделбикәнең бүгенге яшәеш хасиятен бик тирән итеп белүе сизелә. Биредәге әсәрләр, дөресен әйткәндә, тирән уйлануларга, төгәл шигъри шәкелгә төрелгән акыл бөртекләре.

Шагыйрә бу китабында тәрҗемәче буларак та тәкъдим ителә. С. Дали, А. Пушкин әсәрләре аның тәрҗемәсендә татарча ипле килеп чыккан, фикерләр мөмкин кадәр оригиналдагыча сакланган. Шул ук вакытта Иделбикә үз кызы Лилия Юсупованың русча язылган шигырьләрен татар укучысына тәкъдим итә.

Әле 2005 елда Таулы Алтайда (Л. Юсупова шунда яши, табибә булып эшли) кызы тәрҗемәсендә Иделбикәнең "Дороги и думы" дигән шигырьләр җыентыгы дөнья күрде. Менә әнисе дә бурычлы булып калмаган. Лилиянең шигырьләрен татар телендә уку мөмкинлеге дә туды.

Шагыйрә балаларны да онытмаган. Алар өчен язганда, ул аеруча ихлас. Балаларның үзенчәлекле күңел дөньясын шактый сизгер тоя. Бу да әллә каян түгел, шул ук тормыштан. Лена ханым Лилия исемле кыз, Артур исемле малай үстергән, оныклары бар. Шуңа күрә аның балалар дөньясын әйбәт белүе һәр шигъри юлыннан сизелеп тора. Бигрәк тә "Унган кояш","Чулпан янгырда" кебек шигырьләре осталык белән язылган. Алар—татар балалар шигъриятенең табышы. Бередәге табышмаклар, санамышлар да балалар өчен кызыклы.

Әсәрләрне укып барганда еш кына тел җәһәтеннән дә аерымлыкларга юлыгасың. Алар Сембер ягы сөйләше үзенчәлекләренең кайбер төсмерләрен гәүдәләндерәләр. Баштарак, аларның мәгънәләренә төшенү өчен, туктап, уйланып та каласың. Аңлагач, халкыбызның тел мәсьәләсендәге талантына, тапкырлыгына тагын бер тапкыр хәйран каласың.

*Тауны сөям,*
*Егәр иткәнгәме?*

Әдәби тел нигезләнгән урта диалектта без болай дияр идек бит:

*Тауны сөям,*
*Көч биргәнгәме?*

Шул рәвешле тәмамлы эш (тәмамланган эш), егәр ат (көчле ат), уйгач кына аның каберен (казыгач кына аның каберен), юрга төшкән юлларыгыз (атлар чаба торган юлларыгыз), кышның хуплы карсыз булмавы (кышның әйбәт карсыз булмавы), шөкер, туган телебез сак-сак кайта (шөкер, туган телебез әкрен-әкрен кайта), ни эзләп анда менгәндер, тик төшү солын белми (ни эзләп анда менгәндер, тик төшү әмәлен белми) кебек тел күренешләре шагыйрә әсәрләренең үзенчәлеген тәшкил итә.

Бередәге тормыш юлын яктыртуга багышланган чәчмә әсәре исә шагыйрәне шәхес буларак аңлау юлында бик кирәкле өстәмә язма булып хезмәт итә.

Кыскасы, безнең алда шагыйрә Иделбикәнең иҗатын шактый тулы күз алдына китерергә мөмкинлек бирә торган китап. Ул үз укучыларын табар, моңа шикләнмәскә мөмкин.


**Фоат ГАЛИМУЛЛИН,**
*филология фәннәре докторы.*

# ДОГАЛЫ КОРТ ТЫЛСЫМЫ

Ф. Җамалетдинова күпләргә шагыйрә буларак таныш. Аның заман сулышын тоеп, фәлсәфә белән йөгертелгән шигырьләре "Толымлы ай", "Уйлы җил", "Яшен күзләре" китапларына тупланган. Ә менә "Догалы корт" китабында Ф. Җамалетдинова прозаик буларак ачыла. Ләкин безнең хәтергә аның түбәндәге юллары килә:

*Танып булмый бүген заманнарны,*
*Табып булмый үткән эзләрне.*
*Һәйкәлләр дә алмашынды хәтта,*
*Батырлар да хәтта үзгәрде.*

Әйе, дөнья үзгәрде, җәмгыять, кешеләр, кыйблалар, максатлар, омтылган офыклар үзгәрде. Һәм күпләр бу үзгәрешләр вакытында адашып, югалып калды. Үзләре табынган, ышанган кыйблаларын югалткач, кая барып бәрелергә белмичә изаланды. Әнә шундый геройлар белән очрашабыз без Ф. Җамалетдинованың "Догалы корт" китабында. Китапка авторның "Исәнме, байгыш", "Догалы корт" повестьлары һәм хикәяләре кертелгән. Язучы кешеләрнең югалып калу, үз урыннарын таба алмау сәбәпләрен эзли. Ул моны илдә алып барылган сәясәттә, динсезлектә, хәерчелектә, бер-беренә ышаныч бетүдә, хыянәттә, кешенең гомер буе инанган идеаллары юкка чыгуда күрә. "Исәнме, байгыш" повесте герое Фәрзәния дә—әнә шундый факторлар корбаны. Әсәрнең төп мәгънәсен ике хикәят билгели. Беренчесен Фәрзәниянең апасы сөйли. Ул яхшылык һәм яманлык турында. Әлеге хикәят белән танышкач, чыннан да, яманлыкны без үзебез "үстерәбез" икән бит дип уйланасың. Икенчесе Җәүһәрнең уйларында повесть буена кабатлана. Карчык башта аны тулысынча исенә төшерә. Соныннан хикәятнең аерым өлешләре повестьта искә алынган һәр вакыйганы тәмамлап куя. Шул рәвешле автор әсәрен үзенчәлекле итеп төзи.




Автор кешеләрнең "пирамида" уенына ышанып бик күп акчаларын югалтуының, заман афәте булган сектага килеп эләгүенең һәм бу заманга яраклаша, үз юлын таба алмыйча интегүенең сәбәпләрен эзли. Әмма бер урында да моның сәбәбе нәкъ шулар дип төртеп күрсәтелми. Автор герой тормышында булган вакыйгаларны искә төшереп, укучысын да уйланырга, фикер йөртергә этәрә. Һәр вакыйганың әлеге хикәяттән өзек белән тәмамланып куелуы аларның әһәмиятен тагын да көчәйтә һәм авторның үзенең дә шулар белән килешүен белдерә.

Беренче сәбәп итеп, Фәрзәниянең балачагы, гаиләдә алган тәрбиясе күрсәтелә. Кызның әтисе Шәрәфетдин—коммунист. Ул идеологиягә тулысынча инанган кеше. Аның өчен кызының кичерешләре, газап чигүләренә караганда, колхозы беренче урында булуы мөһим. Җәүһәр карчык олы кызларына "сез үскәндә атагыз коммунист түгел иде әле, аның бөтен авырлыгы төпчегенә төште дип",—искә ала. Фәрзәния кечкенәдән авыл кешесенең аз гына хезмәт хакына бил бөгеп яшәвен күреп үсә. Кызның күнелендә балачагыннан

Догалы корт: повестьлар, хикәяләр / Фирүзә Җамалетдинова. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. — 223 б.

бер вакыйга уелып кала: өйдәге ач сарыкларына ул ферма янына китереп аударган каен агачынын ботакларын җыеп кайта. Әтисе колхоз милкен алуда гаепләп кире илттерә. Яфраклар барыбер әрәм була, эссе кояш нурлары астында кибеп бетә. Бу вакыйгада кызны әнисе дә яклап чыкмый, дәшми кала. Әсәр дәвамында Ф. Җамалетдинова әлеге каенны символ дәрәҗәсенә күтәрә. Каен агачы Фәрзәниягә һәрвакыт балачагындагы күнелсез вакыйганы исенә төшерә.

Икенче сәбәп дин, Аллага ышану белән бәйле. Фәрзәниягә мәктәптә, университетта атеистик тәрбия бирәләр. Атасы да атеист, ул корбан гаетенә дә бармый. Әнисе Җәүһәр сандык төбендә Коръән китабы саклый. Ләкин кызын корбан гаетенә баручыларны карап калырга капка төбенә алып чыгарга җөрьәт итми. Фәрзәния шушы каршылыклар арасында бәргәләнеп үсә. Яна өйгә Коръән укырга чакырылган мулланың хәмер эчүе аның ышанычын тагын да киметә. Автор әсәр дәвамында Фәрзәниянең мәчеткә барырга омтылуын бернечә тапкыр кабатлый. Хатын үзен борчыган мәсьәләләрне чишү юлын бәлки шунда табармын дип уйлый. Ләкин бу шулай омтылыш кына булып чыга. Нәтиҗәдә Фәрзәния җиде юл чатында кала. Хәерчелек, иренең ташлап чыгып китүе, балаларын үстерерлек көче җитмәвен тою, бурычлар һәм, әлбәттә, кыйбласы, бу дөньяда нәрсәгә дә булса ышанычы булмау аны ялгыш юлга алып кереп китә. Гөлназ кебекләрнең тасма теленә ышанып, чарасызлыктан, җиңел юл белән акча эшлим дип, ул "пирамида" уенына барып керә. Алдану, акчаларын яндыру, бурычка бату Фәрзәнияне секта кочагына ташлый. Анда хатынны якты йөз белән каршы алалар. "Алар бит миннән акча сорамыйлар, китапларын бушка тараталар, ә Ислам турындагы китапларны мин аңламыйм да",—ди ул. Фәрзәния сектага яхшы мөгамәләгә, ягымлы карашка алданып килеп керә. Бу кырыс һәм рәхимсез дөньяда кешеләргә нәкъ менә шундый җылылык җитмәвен ассызыклый автор.

Фәрзәния үз тормышының иң авыр вакытында ялган җәтмәсенә килеп эләгә. "Фәрзәниянең җиде юл чатында басып торган чагы иде. Аңа ул көнне акча кирәк булды. Ике йөз, юк, йөз тәңкә дә җитәчәк иде. Төпчек улын балалар бакчасына йөрткән өчен бу айга исәп-хисап ясалмаган, эшендә дә хезмәт хакы тоткарлана башлаган чор иде. Тик кемнән сорап карыйсы соң? Аның күзләреннән, кыяфәтеннән, хәтта чәч бөртекләреннән дә шул уйны укырга була иде." Бу заманда күпләр Фәрзәния хәлендә калгандыр. Мондый халәттә кешеләр һәр ягымлы карашка, җылы сүзгә ышанучан була, алар хәйлә, мәкер турында уйларлык хәлдә түгел. Безнең чынбарлык шундый. Газета-журналлар, радио-телевидение аша һәр көн саен диярлек алдауларның төрле очраклары турында ишетәбез, ләкин барыбер ышанабыз. Ф. Җамалетдинова кешеләрне әнә шундый мәкердән, ялганнан сакларга омтыла. Фәрзәния сонарып булса да ялгышын таныган. Тик бу мәкер,алдау дөньясыннан "айный" алмаганнар безнең арабызда әле бүген дә бик күп.

Автор әсәрдә Җәүһәр уйлары аша үткән белән бүгенгене чагыштыра. Элек тә тормыш җиңел булмаган. Ләкин ачлык-ялангачлык, авыр хезмәт дөньяның гүзәллеген, кеше күңеленең матурлыгын җуя алмаган. "Кышын каз мамыгыдай ак кар белән капландылар, язын нарат сагызыдай ябышкак сазга чумдырдылар. Аңа карап берәү дә яна юл салмады, барысы да шуннан йөрде",—дип искә ала Җәүһәр асфальт юлга карап. Гадәттә юл символ буларак тормышны, киләчәкне белдерә. Ф. Җамалетдиновада ул башкачарак мәгънә ала. Димәк, бу кешеләрнең максатлары бер булган, бердәм булганнар, алар кая барасыларын анык белгәннәр, шул кыйблага тулысынча ышанганнар, җиңел юл эзләмәгәннәр. Ләкин бүген ул идеаллар юкка чыккач, Фәрзәния кебекләр югалып кала, кыйбласын билгели алмыйча изалана. Үзеннән-үзе "кем гаепле соң?" дигән сорау туа. "Заман" дип җавап бирер күпләр. Ф. Җамалетдинова исә Җәүһәр сүзләре белән "заманны кешеләр саташтыра шул, балам" дип җавап бирә.

Повестьта дөнья ваклыкларыннан, замана чуалышларыннан өстен бер образ бар—ул бәйгыш. Әсәр үзе дә "Исәнме, бәйгыш" дип атала. Кемгә мөрәҗәгать итә соң автор? Татар теленең аңлатмалы

сүзлегендә байгыш—кош, ябалак дип бирелә, күчерелмә мәгънәдә ярлы, мескен, кайгылы кеше дип аңлатыла. Әсәрдә исә Байгыш белән без Җәүһәр карчык хикәясе аша танышабыз. Хикәят дини мифологиядән алынган. Байгыш кешеләрнең мәңгегә килмәгәнлекләрен, кыска гына гомерне гөнаһ кылмыйча, башкаларны рәнҗетмичә яшәргә тырышырга кирәклеген, бу дөньяда кылган гамәлләрнең үзенә кире әйләнеп кайтачагын искәртергә тели. Гүя ул кешеләргә дөрес яшәү серләрен өйрәтә. Әсәр белән танышкач, "без боларның барысын да беләбез, тик ник үтәмибез соң?" дигән уйлар туа.

Китаптагы икенче повестьта да дини мифология чагылыш таба. Төрмәгә ире янына килгәч, Гөлсемнең әбисенә абыстай таш эчендәге корт турында сөйли. Аның догасын өйрәтә, ачлыктан коткара ди. Дини риваятьләрдән күренгәнчә, Муса пәйгамбәрдән Ходай Тәгалә таш янына килүен сорый һәм аны ярып карарга куша. Ул ташны яра. Шунда аның өч катлы булуын белә. Иң соңгысын ярганда, эченнән яшел яфрак белән корт килеп чыга, һәм корт Муса пәйгамбәргә шушы доганы өйрәтә. Доганың мәгънәсе—Аллаһны зурлау. Әлбәттә, бу дога гына кешеләрне ачлыктан коткара алмый, ләкин ул ышаныч тудыра, Аллаһның бөеклеген танырга өнди. Әбисе Илгизәгә укырга киткәндә корт догасы язылган бөти бирә.

Туган җирнең кадерен читтә генә аңлыйсың, ди халык. Илгизә дә шулай. Кыз яшьли әтисез кала. Әнисе шәһәргә китә. Тар гына тулай торак бүлмәсенә ул Илгизәне дә ала алмый. Кыз әбисе белән генә үсә. Әнисенең авылга кайтулары сирәгәя, кияүгә чыгамы ул, әллә башка сәбәпме, әсәрдә ул хакта әйтелми. Карчык кына бер урында "юлга акчасы юктыр инде" ди. Күрәсең, автор бу елларда авылда гына түгел, шәһәрдә дә халыкның начар тормышта яшәвен әйтергә тели. Илгизәнең балачагы, яшьлеге колхоздагы авыр хезмәт елларына туры килә: иксез-чиксез чөгендер басулары, күрше авылга иртә таңнан сыер саварга йөрү. Мәктәпне тәмамлагач, кызларны мәҗбүри рәвештә фермага эшкә алып калалар. Ләкин кызның күңеле авылга берегә алмый. Очарга дип яратылган кош очмый тора аламыни?! Ул һаман каядыр ашкына. Кызны шәһәр утлары үзенә тарта. Ачлы-туклы студент еллары да, эшләп уку да аны куркытмый. "Илгизәклегең белән әниеңә охшагансың",—ди әбисе. Илгизәнең исеме дә аның әчке халәтенә ассоциатив рәвештә сайланган. Ире аны "очыштагы кош", "кошлар нәселеннән" дип атый. Хәер, хатынны ирен, балаларын калдырып чит илгә чыгып китәргә тормыш үзе мәҗбүр итә. Һаман да җитмәүчәнлек. Илгизә—математика укытучысы. Дөнья базар мөнәсәбәтләренә күчә барганда ике баланы үстерергә, укытырга аларның эшләп тапкан хезмәт хакы гына җитми. Шуларның барысын да уйлап, Илгизә танышлары аркылы базарга сатучы булып урнаша. Әйе, үзгәртеп кору елларында безнең күп укытучыларыбыз шул юлдан китте. Илгизә дә Фәрзәния кебек бер ярдан икенчесенә ташлана.

Нәтиҗәдә, чит илгә чыгып, Грециядә бик күп авырлыклар күреп, бурычларын түләрлек кенә булса да, акча эшләп кайта. Әмма автор үз героеның бәхетен туган илендә тапканлыгына ышандыра. Моны аңлау өчен Илгизәгә бик күп газаплар аша үтәргә туры килә. Аны Грециядә каршы алмыйлар. Кесәсендә бер тиен акчасы булмаган, тел белмәгән хатын диңгез аръягында япа-ялгыз кала. Бәхетле очраклылык аркасында гына ул бер карт белән карчыкны карарга урнаша. Ләкин Ф. Җамалетдинова Илгизәнең чит илгә чыгып китү максаты акча эшләү генә түгел, ә үз урынын табу, яшәвенең мәгънәсен эзләү икәнен дә аңлата. Балачагында Илгизә әбисеннән таш эченә кортның ничек килеп керүе хакында сорагач, карчык болай җавап бирә: "Үзенчә яшәргә теләгән. Дөньяда һәр җан иясе нindидер могҗиза көтә, нидер эзли, ахырда барыбер үз-үзенә кайта. Менә без дә үз куышыбызга, өйгә кайтып барабыз ич..."

Әсәрдә безнең ил белән чит җир чагыштырыла. "Их, бездә булса, юлдан килгән кешене башта чәйгә чакыралар иде,"—дип уйлана Илгизә. Шунда ук "безнең илдә кешеләрнең кадере юк икән бит" дип тә уфтана.

Ф. Җамалетдинова кешеләрне таш эчендәге корт белән чагыштыра. "Төрмәдәге кешеләр дә таш эчендәге корт хәлендә" диелә әсәр башында.

Сөйгәне Әнваршаның әнисе улын ятим кызга өйләндермәячәге хакында ишеткәч, Илгизәнен хыял-өметләре җимерелә: "таш эчендәге корт хәлен аңлый инде мена хәзер. Мәхәббәте дә аның ап-ак корт булып йөрәгендә яшәр. Дөньяга да чыкмас, үлмәс тә..." Ана карап, Илгизә югалып калмый,үзен яраткан кешене очрата, гаилә кора. Ә Әнварша, әнисе сүзе белән яратмаган кызга өйләнеп, гомере буе Илгизәне сагынып яши. Автор мәхәббәтне акчага сатып алып булмавын үзенчә дәлилли. Чит илдә дә Илгизә үзен таш эчендәге корт кебек хис итә. Хатын телне белми, туган иленең мондагы әфлисун агачларыннан, тирән дингездән кадерлерәк икәнлеген аңлый. Ул тәрбияләүче карчык урын өстендә ята. "Карчык та кошлар нәселеннән, очасы килә, ә канатлары сынык... Рәхмәт сина, Ходаем, канатлар бирмәсән, мина да шулай кыен булыр иде." Илгизә таш эчендәге корт түгел, ә очыштагы корт икән бит.

"Адәм баласы бу дөньяда корт кебек таш эченә бикләнеп яши алмый. Игелек кылсаң, игелеген үзенә әйләнеп кайта,"— ди әбисе. Илгизә зиратка баргач, кәүсә буйлап тартыла-сузыла ап-ак кортның югарыга—кояшка таба үрмәләвен күрә. Бу сурәт хатынның таш эченнән чыгуын, үз дөньясын, үз юлын табуын аңлата. Ниһаять, ул аңлый—аның урыны туган илендә, гаиләсе янында, мәктәптә, укучылар арасында икән бит: "Чит дөньяга эләкми торып, канатлыларның шулкадәр күплегенә ышанып җитмәс иде ул. Болай әнә үз күзләре белән күрде. Канатлылар үзләрен беркайчан да бәхетсез хис итә алмыйлар икән бит. Дөньяның кайсы почмагына очып төшсән дә, бер кисәк икмәк, баш өстенә түбә, сусаганда су табыласына ышанды. Бары тик адәм баласының канатлары гына сынмасын икән! Тик бу түбә синен куышын түгел шул, кеше дөньясына яраклашырга тырышу гына. Ә һәркемнен үз дөньясы үз илендә икән..."

Ф. Җамалетдинова китаптагы хикәяләрендә дә тормыш, заман, әхлаклылыкның юкка чыга баруы, аның урынын мәкер, икейөзлелек алуы, катнаш никахларның милләт өчен нинди фаҗигага әйләнүе хакында уйлануларын дәвам итә. Аларда без газиз баласы өчен бөтен гомерен багышлаган ананы да, үзендә дөнья гыйлеме туплаган ташчы картны да, сугыш елларында тылда авырлыкларны нәфис җилкәләрендә күтәргән авыл хатыннарын да, хезмәте белән кешеләрнен күнелен күтәрергә тырышкан урам себерүчене дә очратабыз. Язучы тасвирлаган вакыйгалар безнен тормыштан алынган. Сукыр кызын дәвалау өчен гомерен юлларда үткәргән Миннисаны да без вокзалларда очратырбыз кебек, шәһәрдә балаларында торучы, авылын сагынып, урамнарда гармун моңын эзләүче карт та бәлки күрше йортта гынадыр. Бу китаптагы геройлар Ф. Җамалетдинова иҗатына хас булганча үзгә бер сихрилек белән уратылган.

**Гүзәл ГАЙФИЕВА**

---

## Авторларыбыз игътибарына

Редакциягә әсәрләр, мәкаләләрнен фәкать машинкада басылган яки компьютердан чыккан кульязмалары гына кабул ителә. Бер биттә 30 юл (компьютер текстында да!), бер юлда (сүз араларын да исәпләп) 60 тамга булырга тиеш. Кәгазьнең бер ягы буш кала. Машинка текстының беренче нөсхәсе генә кабул ителә. Компьютер текстының дискеты да булу кулай.

Хатлар исә, җинел танылырлык итеп, кулдан да язылырга мөмкин.

Редакциянен электрон адресына фәкать кечкенә күләмдәге язмалар (хатлар, документлар, фикерләр h.б.) гына кабул ителә.

Электрон адреска күләме 5 биттән арткан язмалар җибәрелгән очракта, почта аша аның оригиналын (кәгазьгә басылган вариантын) алгач кына әсәр кабул ителгән санала.

Әхмәт
Рәшит

# ҺӘРКЕМНЕҢ... ҮЗ СУКМАГЫ

ХАТИРӘЛӘР

## Җаваплылык өстәлә

Мәскәүдән кайтуга мин әдәби-драматик тапшырулар редакциясенә җитәкче итеп билгеләндем. Элеккеге өлкән редактор Рим Ширияздановны Ленинградтагы партия мәктәбенә укырга җибәрделәр.

Вазифалар артты, җаваплылык өстәлде. Шагыйрьләр, язучылар, әдәбият белгечләре, артистлар, режиссерлар белән уртак тел табарга өйрәнелгән иде инде— алар белән, Һ. Такташ әйтмешли, "дус абыйдай тату яшәдек". Шагыйрь Зиннур Насыйбуллинның музыкаль тапшырулар редакциясенә әдәби мөхәррир булып урнашуы күңелне тагын да үстереп җибәрде. Киңәш-мазар кирәккәндә, янәшәңдә бер таянычың, фикердәшең булу—зур бәхет бит ул.

Шагыйрь йөрәген чын-чынлап шагыйрь генә аңлый ала. Без, уй-фикерләребезне уртаклаша-уртаклаша, янәшә өстәлләргә утырып эшләдек. Шигъри шәлкемнәребез дә "Беренче карлыгачлар" сериясендә чыккан китапта бер-бер артлы урнаштырылган иде. Мин аның язганнарын ул вакытта ук кызыксынып укыган идем.

*Без—дөньядан иртә киткәннәрнең*
*Җиргә бүләк иткән буыны.*
*Дөнья никтер сугыш, үлем белән*
*Каршылады безнең тууны,*—дип язган иде Зиннур бер шигырендә.

Аны шәрехли башласаң, гади сүзләр артына яшеренгән асыл мәгънәләрне эзли башласаң, гаҗәеп хәл—баштан кичкәннәрне, тормышта татыган ачы җимешләрне, шыксыз тормыш чынбарлыгын пәрдә генә каплап тора икән ләбаса!

Бераз соңрак миңа ярдәмче булып әле университетның соңгы курсында гына укып йөргән Җәүдәт Дәрзаман килде. Студент елларында ук курсташы Тәслимәгә өйләнеп, башлы-күзле булган, гаиләсен алып бару өчен подвалдагы бәләкәй генә куыш бәрабәренә иртә таңнан йортлар идарәсенең себеркесен яки көрәген күтәреп өй-каралты тирәсен чисталыкта тотарга алынган, теләсә нинди кара эштән дә чирканмый торган унган егет иде ул. Аны безгә университет профессоры Ибраһим ага Нуруллин тәкъдим итте. "Армиядә дә хезмәт итеп кайткан, төпле егет",—диде. Чыннан да, Җәүдәт өйрәнчеклек чорын шактый җиңел кичерде—берничә айдан инде радио арбасына ныклап җигелеп тарта да башлады.

## Каләмдәшләр арасында

Мондый тәкъдимне бөтенләй көтмәгән идем. Литфондның ул вакыттагы җитәкчесе Лирон Хәмидуллин, эш бүлмәмә килеп керде дә: "Әхмәт, безнең Тукай клубындагы кичәләрне үзең дә беләсеңдер... Лариса апаң бик еш авырый—бу вазифаны өстерәп бара алмый. Синең оештыру сәләтеңне беләбез. Алын әле шул эшкә",—дип кодалый башлады. Дөресен әйткәндә, мине үгетләп торасы юк иде. Әле университетны тәмамлаган елны ук Гали абый Хуҗи миңа андый тәкъдимне

*Ахыры. Башы 2008 елның 8нче санында.*

ясаган, әмма башка, аннан дәрәҗәлерәк абзыйлар әлеге урынны инде бүтән берәүгә вәгъдә иткән булганга күрә, мин ул урындыкка утыра алмый калган идем. Әлбәттә, бу юлы инде бөтенесе алдан уйланылган, Язучылар берлеге житәкчеләре белән килешенгән, мин үзем дә бу җаваплы вазифаны тиешенчә башкарырга әзер идем.

Күңелдәге давыллар да тынычланды. Соңгы еллардагы күңелсез вакыйгалар да артка чигенде, йөрәк яралары да азмы-күпме төзәлде. Чөнки яшәргә, миемне бораулап азаплаган уй-фикерләрне ул читлегеннән чыгарырга, шигъри авазымны, ниһаять, бар көченә янгыратырга кирәк иде. Иң мөһиме, янәшәмдә мине аңлый алырлык тормыш юлдашым—инде танылган язучы Мәдинә Маликова бар иде. Аннан да мөһимрәге—бу ханымда минем тәртипсез тормышымны ниндидер тәртә арасына кертерлек ихтыяр көче дә юк түгел иде.

Клубтагы хезмәтем шагыйрә Сажидә Сөләймановага 50 яшь тулу уңаеннан аның кичәсен әзерләүдән башланды. Мин аның әсәрләрен инде күптәннән яратып укып киләм, үзе белән инде Лениногорск телестудиясендә эшләгән чагында ук танышкан, хәтта аның юбилее уңаеннан "Азат хатын" журналы өчен мәкалә дә язып чыккан идем. С.Сөләйманова иҗаты турында фикерем шактый югары булса да, Г. Тукай клубында шулай шаулап-гөрләп үтәр дип һич кенә дә башыма китермәдем. Язучылар клубы, беркайчан да булмаганча, шыгрым тулы иде—тамашачыларның кайсылары як-як стеналарга сыенган, кайберләре, бер-берсен кысрыклап, ишек төбенә елышкан иде. Аның турында җылы һәм тәэсирле итеп Илдар Юзеев сөйләде. Рәйсә Нуриева, Разия Гайнуллина, Мәсгут Имашев, Флүрә Сөләйманова аның сүзләренә язылган җырларны башкардылар, Нәҗибә Ихсанова һәм Гөлсем Исәнгулова зәвыклы итеп шигырьләрен укыдылар. Аннан шагыйрәнең үзенә сүз бирелде. Кичә инде ике сәгатьтән артык бара, халык инде аргандыр, дисәк—кая ул! Кул чабып тагын... тагын... шигырьләр укуын сорадылар. Соңгы вакытларда инде онытыла башлаган Г. Тукай клубына шул алкышлар тәэсирендә яңадан җан кергәндәй булды.

Шигырьләре белән ничектер сиздермичә, сак кына моңлаган шигърият дусларының күңелен биләп алган, эчкерсез һәм саф җырлары табыннарыбыз түренә күчкән, моң еллык татар поэзиясенә үз моңын, үз төсмерләрен өстәгән бәхетле язмышлы С.Сөләйманова башыннан кичкәннәрне дә, йөрәк кылына кагылып үткәннәрне дә башкаларга сөенеч итеп, моң итеп өләшә алды. Шуңа күрә 1977 елда шагыйрәнең иҗаты Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителгәч тә, мин һич икеләнүсез "Социалистик Татарстан" газетасында "Моң һәм төсләр бердәмлеге" дигән мәкалә язып чыктым.

Безнең "Әдәби җомга"ларыбыз берсеннән-берсе җанлырак, берсеннән-берсе кызыклырак үтә башлады. Казан тамашачысы Тукай клубына тәмам ияләшеп житте. Әлегрәк монда үткәрелгән чараларга ялындырыбрак йөргән әдәбият-сәнгать әһелләре киләсе очрашуларның кайчан булачагы турында алдан ук сораша-белешә башладылар. Мин биредә инде хәзер теге дөньяга күчкән Н. Исәнбәт, Г. Бәширов, Х. Туфан, М. Әмир, С. Хәким, Ә. Еники, Н. Арслан, Р. Ишморат, Н. Дәүли, Ә. Исхак, Ф. Хөсни, Г. Галиев, Ш. Маннур, А. Расих, Х. Вахит, М. Садри, С. Сабиров, М.Хөсәен шикелле өлкән буын язучы һәм шагыйрьләребезне, Бакый ага Урманчедай бөек сынчыбызны, Н. Жиһанов, З. Хәбибуллин, С. Садыйкова кебек композиторларыбызны, галимнәребездән Х. Ярми һәм М. Гайнуллинны, нәфис сүз осталары Ф. Юсупов белән Ә. Яһудинны, талантлары белән бөтен татар сәхнәсен шаулаткан Г. Шамуков, Г. Кайбицкая, Н. Даутов кебек артистларыбызны гына телгә алам. Аларның урта һәм яшь буын дәвамчылары исә тагын да ишлерәк иде—алар бергә-бергә сөйләшүләрдән байтак сабак һәм гыйбрәт алганнардыр.

Башкарган вазифам ничек кенә кызыклы һәм файдалы булмасын, миңа барыбер эш урынымны алыштырырга туры килде. Яңадан радионың әдәби-драматик тапшырулар редакциясенә эшкә килдем.

Биредә мөмкинлекләр зуррак, үзләре күренеп тормасалар да, безнең сүзне ишетүчеләр саны чагыштырмас дәрәҗәдә күбрәк иде. Радиога көн саен агылып торган күпсанлы хатлар аудиториябезнең бик киң икән турында искәртә. Бөтен сәнгати тапшырулар өчен җаваплы Зиннур Мансуров белән дә, мөхәррир Зиннур Хөснияр белән дә бик тиз уртак тел таптык—тарткалашырга, низаглашырга туры килмәде. Ә ике елга якын вакыт үтеп, З. Мансуров Татарстан Язучылар берлегенең рәис урынбасары булып сайлангач, әдәби-драматик, музыкаль, яшьләр һәм балалар

өчен тапшыруларны, ультра-кыска дулкыннарда барган программаларны, тавыш язу студиясен, фонотеканы үз эченә берләштергән баш редакция белән җитәкчелек итүне мина тапшырдылар. Аз-маз тәҗрибәм бар, кадрлар бөтенесе таныш—чөнки баш мөхәррир ялга киткән чакларда мин аны күп тапкырлар алмаштыргалый идем инде. Бераздан телевидениегә баш мөхәррир булып күчкән Рөстәм Фәйзуллин да янадан үзенен элеккеге урынына—әдәби-драматик тапшырулар редакциясенә кайтасы итте. Әдәбият-сәнгать кешеләре белән якыннан аралашып яшәгән шагыйрә Шәмсия Җиһангирова музыкаль тапшырулар бүлегенә, соңгы елларда иҗат белән актив шөгыльләнгән Дания Гайнетдинова балалар өчен тапшырулар редакциясенә килде. Коллективта минем (хәер, минем генәме икән?!) эчне пошырган бер генә кеше бар иде. Ул да булса, "Коръән серләре" дигән китабы белән бөтен Ислам дөньясының бәддогасын алган язучы Гариф Гобәй кызы Эльза. Әтисенә фикердәш булып, рус яшьтәшләре белән аралашып үскәнгәме, ул кирәгеннән артык "бәйнәлмиләл", татар милли хәрәкәтендә катнашып йөрүчеләрне җене сөйми һәм шул фикерләрен еш кына үзе алып барган русча әдәби тапшыруларда үткәрергә дә тырыша иде. Сәләтле иде үзе—анысын һич инкарь итә алмыйм. Әмма шул без өнәп бетермәгән карашларын, җитәкче инстанцияләргә барып булса да, кайчакларда барыбер үткәрә иде. Ә мина бик еш кына радиотынлаучылардан шикаять хатлары килә—"нишләп ул Э. Гобәйдуллинага алай ирек куясыз?!" Гел генә талашып, сүгешеп тә булмый бит. Җитәкчеләр дә конфликтны куертмаска тырышалар.

Шулай да башка 28 хезмәткәрем белән без бер фикердә идек. Ул чорда әзерләнгән тапшырулар бик күп радиотынлаучыларның күңеленә хуш килде—моны редакциягә алынган хатлардан, телефоннан шылтыратып, хуплау сүзе әйтүләрдән, "Турыдан-туры элемтә" тапшыруларында үз фикерләрен җиткерергә тырышулардан да белеп була иде. Безнең редакциягә караган мөхәррирләр республикабыз суверенлыгы өчен көрәшнең алга сафында булдылар, вакыйгаларны оператив төстә яктырттылар, халык белән бергә яшәделәр. Милли мәнфәгатьләрне үзәккә куеп, җитәкче абзыйларга катлаулы мәсьәләләрне дөрес хәл итәргә юнәлтелгән гамәлдәге цикллар да ачыграк, конкретрак төс ала барды.

Гаяз Исхакый мирасын халкыбызга кире кайтару буенча беренче адымнарны ясаганда кыенлык килеп туды. Татарстан Фәннәр Академиясенең мирас комиссиясе, бертавыштан диярлек мәсьәләне унай хәл итү ягында булса да, таяк тыгарга, комачауларга, партия органнары фикеренә таянырга кирәклеге турында лыгырдаучы "акыллы башлар" да юк түгел иде. Бөек классигыбызны яклап сүз әйткән "Вечерняя Казань" газетасыннан башка матбугат органы юк иде әле. Мин бу темага телевидение һәм радиотапшырулар комитеты рәисе И. Хәйруллин белән кат-кат сөйләштем. Илгиз Кәлимулла улы, үзе демократик рухтагы кеше булса да, "Исхакыйның Польша җитәкчесе Пилсудский белән элемтәсе турында кире каккысыз дәлилләрне үз күзләрем белән укыдым, бераз көтик әле" дип тынычландырырга тырышты. Аннары, барыбер, бирелергә мәҗбүр булды. Гаяз Исхакый турында татар телендә иң беренче тәфсилле хәбәр радио дулкыннарында яңгырады. Аннан курка-курка, шикләнә-шикләнә генә газета-журнал редакцияләре кузгалды. Искелеккә ябышып яткан кичәгеләр Гаяз Исхакыйның яманатын саткан, республикабызның иң зур түрәсе аны "татар халкының беренче номерлы дошманы" дип атаган еллар бу—анын шунысын да онытырга ярамый.

Татар халкынын милли аның уятуда тарихка багышланган һәм кырыктан артык тапшыруны эченә алган "Еракка китеп кара"циклы, "Веков связующая нить", "Кардәшлеккә чикләр юк", "Татар теле дәресләре", "Мирас", "Музыкаль сәхифәләр", "Таныш моңнар", "Хәерле иртә", "Яшьлек радиодулкынында", "Танышу", "Көмеш кыңгырау", "Уйныйбыз да, җырлыйбыз да" тапшырулары мөһим роль уйнады. Мин үз кул астымда эшләгән иҗатташларыма, теләктәш булганнары өчен генә түгел, яна чор биргән мөмкинлекләрдән тиешенчә файдаланып, вазифаларын чын күңелдән башкарганнары өчен бүген дә рәхмәтле. Танылган журналист-мөхәррирләр Рөстәм Фәйзуллин, Р. Ильясов, Ш. Җиһангирова, С. Латыйпова, Н. Мөштәри, Р. Гаффаров, М. Айтуганова, Д. Гайнетдинова, Ф. Гыймадов һәм башкалар ул чорда татар әдәбиятын һәм сәнгатен пропагандалауда гына түгел, халкыбызның югалган дәүләтчелеген кайтару буенча кискен көрәшендә дә алгы сафта булдылар.

## Йөрәккә уелган эзләр

Ачы мизгелләре байтак булса да, мин язмышымнан зарланырга җыенмыйм. Минем иң зур байлыгым—дусларым. Картайган көнендә аеруча нык сизәсең икән дусларның кирәклеген. Дөрес, кайберләре инде теге дөньяларга да китеп бардылар.

Шөкер, исәннәре дә бар әле. Кайсылары инде миннән өлкәнрәк, кайсылары әле миңа энекәш яки сеңелкәш кенә тиешле. Ләкин без барыбер, бер заман кешеләре. Аларның да кадерен белеп яшәргә кирәк. Болай да инде кайчакларда минем иҗатка беренче булып үзенең ихлас мөнәсәбәтен белдергән Гамил Афзал, романтик рухы белән күпме булачак шагыйрьне үз артыннан ияртә алган Илдар Юзеев, шашкын хисләре белән безне тормыш ваклыкларыннан аерып, күкләргә ашырган Рәшит Әхмәтҗанов, Рахмай Хисмәтуллин, Фәннур Сафин, гади тормыш манзараларыннан, авыз читенә кунган гап-гади елмаю аша да көлә белгән Фаил Шәфигуллин, кара җирнең кара туфрагына гашыйк булып, үзе калада яшәсә дә, күңеле белән авыл җирендә калуны кулай күргән Рәшит Гәрәй, бөек О'Генриның иҗат өлгеләрен татар хәятына яраклаштыра белгән Хәсән Сарьян, гомеренең соңгы елларында, ниһаять, чын әдәбиятның олуг хакыйкатен аңлаган Мәхмүт Хәсәнов, татар әдәбиятының тәрәккыяте өчен җан атып йөргән Гариф Ахунов, бик күп талантларны әдәбиятыбызның олы юлына бастырган Барлас Камалов, кисәк кенә прозабызның якты йолдызы булып кабынган Мөхәммәт Мәһдиев, драматургиядә үз юнәлешен булдырган Шәриф Хөсәенов... шигърияттә Мөдәррис Әгъләм, Зөлфәт кебекләрне сагынып кына искә төшерәбез. Һәй, саный башласаң... Саный башласаңмы?.. Шуның өстенә тагын әле бүген дә кулларына көрәш сөлгесе тотып мәйдан уртасында басып торган Равил Фәйзуллинны, Ренат Харисны, Рөстәм Мингалимне, Рәдиф Гаташны, Гәрәй Рәхимне, Зиннур Мансуровны, Газинурны, Ркаилне... алардан да яшьрәкләрне өстә! Аның композитор, рәссам, артист, режиссер дигәннәре дә шул безнең кавемнән бит әле... Һәммәсе дә шул бердәнбер йөрәкнең иң нечкә кылларына кагылып тора бит аларның... Укучым мине гафу итсен—әлеге исемнәрне санаганда, мин, А. П. Чеховның "Ранглар турындагы табель" хикәясендәгечә, аларны төрле категорияләргә бүлеп маташмадым—хәтеремә ничек килә, шулай тезеп чыктым. Рангларга бүлү—анысы инде Ходай Тәгалә һәм аның гадел бизмәне—Вакыт галиҗәнапләре эше. Әдәбият баскычының кайсы төшендә кем торганны киләчәк кенә күрсәтер.

Гомеремнең төп өлешен яшәргә насыйп булган егерменче гасыр ничек кенә катлаулы, анда барган вакыйгалар күпме генә чуалчык булмасын, мин бу чорны, барыбер, тарихның иң якты сәхифәсе итеп саныйм. Ул кешелеккә әллә никадәр ачышлар алып килде, дөньяның бар кыйтгаларында яшәүче халыклар, ниһаять, азатлыкның, бәйсезлекнең чын тәмен татый алдылар, адәм балалары канкойгыч зур сугышлардан күпмедер вакытларгача баш тарттылар. Безнең татар халкы өчен дә ул бәхетле дәвер булды. Беләм, беләм, бу чорны, анда яшәгән кешеләрне, күренекле шәхесләрне гаепләүчеләр дә табылыр. Күпләрне "искелеккә ябышып ятуда" гаепләрләр. Юк, мин дә замандашларымны хатадан хали дип исәпләмим. Ләкин... алар булмаса, без булмасак, сез булыр идегезмени?! Кичәге көн булмаса, бүгенгесе булыр идемени?! Тарихны яңабаштан язып булмый. Аның үткәне киләчәккә ялганган. Кичә булган ялгышлар иртәгә кабатланмас дип тә кистереп әйтеп булмый бит әле. Бу хакта хөрмәтле укучым алдында акыл сатып маташтым бугай инде. Ничек кабул иткәннәрдер—анысы алар эше. Һәрхәлдә, мин шактый озын гомерем сабакларын, тормыш тәҗрибәмне аңлатырга тырыштым.

♣

Фирдәвес
Гарипова

# АВЫЛЛАРЫБЫЗ ТАРИХЫ

## Иске Мичән, Яңа Мичән һәм Мичәнбаш авыллары

Атамаларында «мичән» берәмлеге булган авыллар Саба районында урнашкан. Иске Мичән авылы Сабадан—15, Яңа Мичән—12, Мичәнбаш 19 чакрым ераклыкта.

Мичән берәмлеге белән ясалган барлык өч авыл да тарихи, тарихи-статистик, тарихи-географик чыганакларда шактый еш очрый. Иске Мичән авылы зиратыннан якынча XV йөзгә мөнәсәбәтле кабер ташы табыла.

Иске Мичән һәм Яңа Мичән авыллары халкы июнь ае ахырында күршедәге Олы Шынар, Кече Шынар, Югары Симет, Түбән Симет, Тимершык, Мингәр, Сабай, Чулпыч, Түлешкә, Казаклар, Олы Кибәхуҗа авыллары белән бергәләшеп Шынар җыены яки икенче төрле Симет җыены үткәргән. Ә менә Мичәнбаш авылы халкы җыенның икенче исемлесенә катнашкан. Күршедәге Курсабаш, Кырбаш, Олыяз, Пүкәл, Өтернәс, Өзмә, Иске Шекше, Яңа Шекше, Мишәбаш, Явлаштау, Сәрдә, Иләбәр, Көек, Бөкмеш авыллары белән алар Калатау җыены (июнь уртасында) бәйрәм иткәннәр.

Авылның өлкән буыны Иске Мичән авылы тарихын болай сөйли.

Элек татарлар һәм чирмешләр яшәгән бу урынга Биләр алпавытыннан качып килгән Максут исемле яшь бер ир авыл нигезләгән. Авылда абруйлы һәм зур нәсел—Максут нәселе хәзер дә дәвам итә.

Авылның хәзерге зиратында Максут бабай кабере бар. Әтисе үлгәч, бу зират тирә-юнен (XIX йөзнең беренче яртысында) Максутның улы Садыйк койма белән тотып алган.

Зираттагы иң зур каен Максут бабай каберендәгесе булган. Ул каенны сугыштан соң фермага ягарга дип колхоз рәисе кистергән. Ләкин Курса разъездында көн итеп ятучы Максут нәселенең Габдулла исемле кешесе каенны мичкә ягарга рөхсәт итмәгән, ул шул урында черегән.

Максут бабайның Әхмәтша исемле улы зират тирәли чыршы агачлары утыртып чыккан.

Музейда саклана торган 7 нче ревизия материаллары күрсәтүе буенча, авылда Максут түгел, ә Мәсагут Суюшев исемле кеше теркәлгән. Ул 1754 елда туган, 1816 елда үлгән. Аның мондый исемдәге балалары булган: Баязит (1777 елда туган), Морат (1787), Садыйк (1808), Тимеркәй (1809), Мөхәммәтша (1810); оныкларыннан: Ибәтулла (1799), Гайнулла (1804), Үзбәк (1816), Әптекәй (1822). Садыйк абзыйның үз балалары да санап кителгән.

Өлкәннәр сөйләве буенча, XX гасыр башында авылда Максут—Мәсагут нәселенә килеп тоташа торган 48 капка булган.

Иске Мичән авылы урынында элек чирмешләр (марилар) яшәгән булса кирәк. Чирмеш нәселеннән булган гаиләләр XIX гасырда барысы да бер тирәдәрәк, авылның уртасыннан ага торган инеше белән чишмә арасындагы урында тупланган булганнар. 1834 елгы ревизия мәгълүматларына караганда, бу нәселнең олыларыннан берсе—Корбанай Раимкулов 1819 елда үлде дип күрсәтелә. Авылда кайбер нәселләрне чирмеш нәселе дип тә йөртәләр. Димәк, кайбер чирмешләр бу урынны

*Дәвамы. Башы 2006 елның 6 нчы санында.*

калдырып күчеп киткәннәр (халык аларны Кукмара ягына киткәннәр дип сөйли), икенчеләре ислам кабул иткәннәр һәм монда яшәп калганнар.

Авыл халкы чирмешләрне, көчләп чукындыру башлангач, качып киткәннәр дип сөйли. Ул заманнарда авыл каршындагы тау бите калын имән урманы белән капланган булган. Чирмешләр ашыгып качып киткән вакытта «әкәй» дип атала торган баш киемнәре имән ботакларына эләгеп төшеп калган имеш. Чирмешләр: «Әкәем кала, әкәем кала»,—дип елый-елый йөгергәннәр имеш. Авыл янындагы Әкәй тавы атамасының килеп чыгышын халык менә шулай аңлата.

Шушы таудан көчле Кирәмәт чишмәсе агып төшә. Ерак та түгел, болын суының икенче ягында (авыл урнашкан ягында) Урта зират яки Чирмеш зираты дип йөртелә торган борынгы зират булган. Зират аркылы көнчыгышка таба кыйгачлап сузылган юл аны икегә бүлгән. Бер ягында—мөселман каберлеге, икенче якта чирмеш каберлеге булган дип сөйлиләр. 1970 нче елларда карт чыршылары корый башлаган иске зиратны колхоз бетергән, сөрелгән жирдә хәзер элекке зиратның 2 чыршысы гына басып калган.

Авыл янында тагын Әкәй юлы, Кирмәт елгасы исемендәге топонимнар булу да, бәлки, бабайлар сөйләгәнне дәлиллидер.

1816, 1834, 1850, 1858 елларда уздырылган халык санын алу (ревизия, перепись) документларында Иске Мичән авылында шул елларга нисбәтән 40, 43, 45, 53 хужалык күрсәтелә. 1891 елда авылда яна мәчет салу хәстәренә керешкәндә барлыгы 65 хужалык булган. Шунысы игътибарга лаек, бер хужалыкта еш кына 3-4 гаилә, 20-28 кеше исәпләнгән очраклар күп.

1904 елда авылда 89 хужалык булып, аларда 236 ир-ат һәм 223 хатын-кыз яшәгән. 1 мәчет һәм Орымширмә авылыннан да 54 кешене үз эченә алган мәхәллә булган.

Татарстан Дәүләт музеенда саклаган мәгълүматларга караганда, Иске Мичән авылындагы мәчетнең тарихы болайрак булган.

1855 елда мәчет дөрләп яна. Мәчет янганнан соң авыл халкы 25 ел буена вакытлыча салынган авыл йортында гыйбадәт кыла.

1875 елның 18 нче мартында авылның 81 кешесе үз исәбеннән мәчет салдыру максатыннан приговор төзедерә. 1875 елның 3 нче июлендә Оренбург духовное собраниесе Иске Мичән авылы халкына мәчет салырга ризалыгын биреп жавап язып жибәрә.

1875 елның 8 нче гыйнварында Югары Мичән авылы халкы (80 хужалыкта яши торган 203 ир-ат) жыелыш үткәрә һәм Арча өязенең Наласа авылында яшәүче Фазуллин Мөхәммәтгарифны (туган елы 23/XI 1853) үз авылларына мулла, имам-хатыйб итеп билгеләүне сорап приговор жыя. Аның әтисе, ягъни шушы авылда (Югары Мичәндә) муллалык хезмәте башкарган Фазулла Габдерәхимов 1874 елның язында үлеп китә.

1875 елның 21 нче мартында Казан өязе вице-губернаторы Хитров кул куйган кәгазьдән күренгәнчә, 22 яшькә житмәү сәбәпле Фазуллин Мөхәммәтгарифның Югары Мичән авылына имам-хатыйб итеп билгеләнә алмавы турында әйтелә.

Казан губерна идарәсендә 1875 елның 2 нче декабре датасы белән Мөхәммәтгариф Фазуллинның патшага язган хаты теркәлгән. Ул патшага тол калган әнкәсенең берләнбер баласы булуы нәтижәсендә хәрби хезмәттән азат ителүен, хәзер инде мулла буып эшләргә яше житүен, заманасында Казан губерна идарәсенең яше житмәве аркасында аны Югары Мичән авылына имам-хатыйб итеп куймавын хәбәр итә.

1875 елның 4 декабре датасы белән Казан өязе идарәсенең протоколы карарында, Оренбург мөфтиятенең каршы килмәве һәм Югары Мичән кешеләренең теләген искә алып, Мөхәммәтгариф Фазуллиннан ислам дине кануннарын белү дәрәжәсен билгеләү өчен имтихан тоту кирәклеге искәртелә.

1786 елның 14 гыйнвары числосы белән Оренбург мөфтиятеннән алынган документта Фазуллин Мөхәммәтгарифның имам-хатыйблыкка, мөәзинлеккә һәм мөгаллимлеккә имтиханны әйбәт бирүе турында хәбәр ителә.

Казан губерна идарәсенең 1876 ел 20 гыйнвар протоколыннан күренгәнчә, Фазуллин Мөхәммәтгариф Югары Мичән авылына мулла итеп билгеләнә һәм аңа мулла булып эшләргә хокук бирә торган ант кәгазе бирергә (присяжный лист) дигән карар чыгарыла.

1876 елның 8 февраль аенда Фазуллин Мөхәммәтгарифка указ бирелә һәм ул

Югары Мичән авылында имам-хатыйб булып эшли башлый (Фонд 2, опись 2, дело 717).

1890 елда Иске Мичән авылы халкы, имзалар җыеп, үз авылларында яңа мәчет салдыру артыннан йөри башлый. Мәчет яңа нигездә, авылның уртасында, ике урам чатында салына. 1930 елларда бу мәчетнең манарасы киселә, заманында Мөндеш авылы тимерчесе куйган көмеш ае (шул турыда айда язуы да булган) тимер-томыр арасында ятып, сугыштан соң юкка чыга. Мәчет бинасы күп еллар клуб булып хезмәт итә. 1990 еллар башында тузып сүтелә.

Элек авылның тирә-юне тоташ урман булган. Әле дә ул вакытларның истәлеге булып агачлар исеме, урман белән бәйләнешле елга-сулар сакланып калган. Зелпелек елгасы, Урман елгасы атамалары шул турыда сөйли.

Авыл янында тагын Му юлы елгасы, Тирән елга, Сай елга, Каравыл елгасы һ.б. бар. Чишмәләрдән: Чыгарылыш чишмәсен, Олы чишмә, Шәйдулла чишмәсен, Канюшин чишмәсен һ.б. атап әйтергә мөмкин.

Авылда хәзер 65 ләп хуҗалык бар. Анда колхоз идарәсе, мәдәният йорты, урта мәктәп эшли. Газ кертергә хәзерләнәләр. Авылдан асфальт юлга 2-3 чакрым чамасы.

Авылда мәчет нигезе салына башлаган. Аны төзү озакка сузылмас дип уйларга кирәк. Халык әби-баба ята торган зиратны карап, чистартып, тирә-юнен тотып, тәрбияләп тора.

Атамалары составында мичән берәмлеге булган авыллар арасында Иске Мичән борынгырак булырга тиеш. Иске Мичән белән Яңа Мичән арасында Иске зират бар. Югарыда әйтеп кителгәнчә, Иске зиратлары, Йорт өсте урыннары булган авыллар гадәттә борынгы булалар.

* * *

Олылар сөйләве буенча, Яңа Мичән авылы Иске Мичәннән күчкән. Элек авылның тирә-юне урманлы булган. Хәзерге ферма урыннарында элек урман шаулап утырган. Урман юлы, Кабан киеге юлы, Каенсар юлы, Каенсар ягы (басу исеме) һ.б. топонимнар урман белән бәйләнешле рәвештә барлыкка килгән. Авыл тирәсендә әле дә Симет урманы, Түгәрәк урман, Яңа җир, Юмгалак урманнары бар.

Авыл әйләнә-тирәсе төрле географик объектларга бай, гомумән, ул матур урынга утырган. Су-инешләре, чишмә-күлләре, болын, сазлыклары, дугайлары, үзәннәре һ.б. авыл халкы күңеленә якын.

Су-инешләрдән Иске Мазар елгасын, Фәхерниса, Карт бабай, Аерчалы, Коры, Еланлы, Тәскирә яисә Зелпе һ.б. елгаларын атарга мөмкин.

Авыл янында Кызыл яр болыны, Сәүкә тегермәне, Сәүкә алды, Бокыр болыны, Кызыл яр һ.б. болыннар бар.

Болардан башка тагын Мәхшәр күпере, Югары оч күпере, Мулла сазы, Тирән үзән, Ат дугае, Бәдретдин дугае исеме алган географик берәмлекләр очрый.

Элек авылда киндер һәм тула сугу кярханәсе дә булган. Аны Камали фабрикасы дип йөрткәнәр.

Хәзер авылда мәчет эшли. Элекке мәчет пычкы чыкканчы ук салынган булган.

Һәр авылның үз талантлары булган кебек Яңа Мичәндә дә талантлар булган һәм бар.

* * *

Мичәнбаш олылары авылларын шактый борынгы һәм Иске Мичәннән күчкән дип исәплиләр. Авылны беренче нигезләүче 3 бабаның исемнәрен Ишми, Мөрәс һәм Хәлил дип беләләр.

Мичәнбаш авылында да татарларга кадәр чирмешләр яшәгән дип сөйлиләр. Татарлар бергә җыелып күбәя башлагач, алар икенче урыннарга күчеп утырганнар. Авыл янында чирмеш зираты бар. Элекке вакытларда атлар авырса, чирмеш зиратын берничә тапкыр әйләндереп кайта торган булганнар. Акай исемле чирмеш булган дип искә алалар. Авылда Акай елгасы да бар.

Элек Кырбаш авылы урынында арлар (удмуртлар) яшәгән дип искә алалар. Авыл басуында Ар тавы бар. Алар бу урынны ни сәбәптәндер ташлап киткәннәр.

Мичәнбаш басу-кырларында Мулла елгасы, Сирази үзәне, Сөләйман, Габделгани, Гәрәй, Таллык, Үләт, Күперле, Кардон суы елга-инешләре ага. Кайберләре хәзерге

көнгә кипкән дә инде. Исемнәре генә калган.

Чишмәләрдән түбәндәге исемләләрен күрсәтергә мөмкин: Ашах чишмә, Зөбәйдә, Акайлык, Кадыйр, Гайнетдин, Нәжми, Шәрәфи чишмәсе, Гайфи чишмәсе һ.б.

Авылда 50 ләп хужалык. Авылга әле үзәкләштерелгән газ кермәгән, юлларга асфальт түшәлмәгән.

Мичәнбашта башлангыч мәктәп, балалар бакчасы, медпункт һәм кибет эшли.

Соңгы берничә ел эчендә авылның зурая һәм үсә башлавы күзәтелә. Авылга шәһәрдән яшь гаиләләр күчеп кайта башлаган, бәхет эзләп чыгып китүчеләр саны да азайган.

Әлегә авылда мәчет юк. Элек анда мәчет гөрләтеп эшләгән. Революциядән соң мәчетнең манарасы киселгән, үзе җимерелгән, муллалар читкә сөрелгән. Элек мәчет урнашкан калку урынны халык әле дә Мәчет тавы дип йөртә.

Халыкның тормышы матур, йортлары, башка каралты-куралары нык. Авыл киләчәккә карап яши.

Авыл халкы зиратны карап һәм чиста тота. Корыган агачлар киселә, печәне чабыла, тирә-юне төзекләндереп торыла.

Билгеле булганча, кушамат бирү һәр авылда бар, ул инде халыкның канунлашкан сыйфаты. Мичәнбаштагы кушаматлар бик гади тоела: бүре, көчек, чыпчык һ.б.

Авылга үзәкләштерелгән газ килгән, юллар асфальтлансын, мәчет һәм мәдрәсә ачылсын дигән теләктә калабыз.

*Дәвамы киләсе саннарда.*

---

# *Киләсе санда укыгыз*

Журналыбызның 5 саны шактый бай булачак.

Биредә Башкортстанда яшәүче каләмдәшләребез әсәрләренә кин урын бирелә. Аерым алганда, **Әмир Әминев**нең “Танкист” повесте, **Сабир Шәрипов**ның “Карак”, **Талха Гыйниятуллин**ның “Суга баткан кеше”, **Фәрзәнә Акбулатова**ның “Атай икмәге”, **Рәмис Уразголов**ның “Сандык” хикәяләре, **Рәмил Йәнбәк, Гөлнур Якупова, Тамара Гәниева** һ.б. шигырьләре дөнья күрәчәк.

Шигърият сөючеләрне Халык шагыйре **Равил Фәйзуллин**ның яңа шигырьләре көтә.

Киләсе санда шулай ук **Равил Рахмани**ның **Миргазиян Юныс** белән әңгәмәсе, **Миркасыйм Госманов**ның Чыңгыз Айтматовка бирелми калган сораулары, **Марсель Әхмәтҗанов**ның Нәкый Исәнбәт турындагы хатирәләре, **Лирон Хәмидуллин**ның Оренбургтагы татар авыллары турындагы мәкаләсе урын алган.

Әдәби тәнкыйть бүлегендәге “түгәрәк өстәл”дә бүгенге заман хикәяләре турында сөйләшү булачак. Сәнгать сөючеләр исә **Дания Гыйманова**ның режиссер Фаил Ибраһимов турындагы язмасы белән таныша алачак.

Болардан тыш, Мәхмүт Хәсәновка килгән хатлар, Фаил Шәфигуллин турында истәлекләр, журналыбызның яшь укучылары өчен “Ак җилкән” сәхифәсендә **Камил Кәримов**ның “Яшел читлек” исемле хикәясе дә бар.

# *«Татар энциклопедиясе» битләреннән*

# З

**ЗЫЯТДИНОВ** Фарсель Сәхап улы (1.6.1937, элекке Калинин р-ны Качкын ав. туа), язучы, икътисад белгече, икътисад фән. докт. (2002), ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1992). Казан ун-тын (1965) һәм Казан авыл-хуҗалыгы ин-тын (1966) тәмамлый. 1964-70 елларда ТАССР МС ның радиотапшырулар һәм телевидение к-тында эшли, 1970-86 да Татар авыл хуҗалыгы фәнни тикшеренү интында бүлек мөдире,бер үк вакытта Казан у-тында да укыта (1978-87). 1986 дан Казан финанс-икътисад ин-тында, 2004 тән житештерү икътисады кафедрасы профессоры, бер үк вакытта 1993 елдан Татар энциклопедиясе ин-тында (2003кә кадәр икътисад һәм халык хуҗалыгы тарихы бүлеге мөдире) һәм 2003 тән Икътисад, идарә итү һәм хокук ин—тында икътисад кафедрасы мөдире. Беренче әсәрләре 1960 еллар башында басыла башлый. Балалар өчен атап язылган «Кызык дөнья» (1974), «Гыйльми белән Белми» (1983), «Онытылмас авазлар» (1988), «Икътисад әлифбасы» (2000) исемле шигырь һәм хикәяләр җыентыклары авторы. Туган жиргә мәхәббәт һәм тугрылык хисләре белән тулган лирик шигырьләре «Тагын килде язлар» (1991) җыентыгын тәшкил итә. «Изге йорт» (1997) повесты селекционер галимнәргә багышланган. «Кырлар батыры» (1975), «Яшәү мәгънәсе» (1998), «Через тернии к звёздам» (1999) җыентыкларына кергән документаль хикәя һәм повестьлары публицистик янгырашлы. З.—АПКда жир, материальтехник, хезмәт ресурсларын бәяләү һәм нәтиҗәле куллану проблемалары буенча тикшеренүләр авторы. ВДНХның көмеш медале, ТР Почёт грамотасы белән бүләкләнгән.

Хезм.: Интенсификация и трудовые ресурсы колхозов. К., 1974; Слагаемые рентабельности. К., 1977; Крупяное поле Татарии. К., 1979; Уровень квалификации и производительность труда сельского механизатора. К., 1979; Ресурсный потенциал АПК: анализ, оценка и эффективность использования. К., 2001.

Әд.: Маннапов Ш. Туган жирдән көч алып // Казан утлары.1997. №6; Фәйзуллин Р. Фарсель Зыятдинов турында // Идел. № 11.

*Г.М.Габделхакова.*

**ЗЫЯТДИНОВА** Сәйдә Закир кызы (27.3.1941, Теләче р-ны Шәдке а.), язучы, ТАССРның атказ. мәдәният хезмәкәре (1991). 1968 дә Казан ун-тын тәмамлый. 1971 дән "Яшь ленинчы" г-тасында, 1983 тән "Азат хатын" ж-лында эшли, 1993-97 дә "Татарстан" ж-лында мәдәният бүлеген житәкли. "Айның туган чагы" (1991) шигырьләр җыентыгы, "Кайнар сукмаклар" (1990), "Кар карасы" (1994) повестьләре, хикәя, очерк, публицистик мәкаләләр авторы.

Әд.: Айның туган чагы // Социалистик Татарстан. 1991. 16 июль; Хужин М. Ямь һәм гамь // Казан утлары. 2001. №2.

**ЗЫЯТДИНОВА** Фирая Гали кызы (5.9.1945, Әтнә р-ны Мамыш ав.—22.4.2006, Казан), шагыйрә, тәрҗемәче. Казан. ун-тын тәмамлый (1968). 1969-2001 елларда Татарстан кит. нәшриятында редактор. Беренче шигырьләре 1950 еллар ахырында республика газета-журналларында басыла башлый. «Матур буласым килә» (1986), «Язгы ярсу» (1988), «Ташкын» (1991), «Мин кояшка елмаям» (2000), «Утның яшисе килә» (2005), балалар өчен «Айнур» (1995) исемле шигырь җыентыклары авторы. З.ның шигъриятенә нечкә лиризм хас, ихласлык һәм туган жиргә мәхәббәт хисләре белән тулы. Аның шигырьләренә композиторлар Ә.Бакиров, Ф.Әхмәтов, Л.Батыр-Болгари, Р.Кәлимуллин, М.Шәмсетдинова, Р.Әхиярова һ.б. популяр жырлар ижат иттеләр. З.—К.Г.Паустовскийның «Дождливое утро» («Яңгырлы иртә», 1985) хикәяләр җыентыгын, шулай ук мәктәпләр өчен тарих, икътисад һәм география фәннәре буенча дәреслекләрне татар теленә тәрҗемә итүче дә.

Әд.: Габиди Ә. Мәхәббәт яктысы // Казан утлары. 1988.№4; Вәли М. Кызлар йөрәге // Мәдәни жомга. 2000. 2 сент.; Мулланурова Р. Яме бар бит күзләрнең дә // Сөембикә. 2001.№8.

*Г.М.Габделхакова.*

**ЗӨЛКАРНӘЙ** (Зөлкарнәев) Фәиз Мәүлит улы (4.12.1951, БАССРның Бакалы р-ны Сөендек ав.—18.7.1997, Казан), әдәби тәнкыйтьче, язучы, ТРның атказ. мәдәният хезмәткәре (1994). Казан ун-тын (1979) һәм А.М.Горький исем. Әдәбият ин-ты каршында Югары әдәби курслар (Мәскәү, 1989) тәмамлый. 1980-83 елларда «Ялкын» ж-лы мөхәррире, 1983-87 дә Татарстан китап нәшриятында өлкән мөхәррир. 1989-97 дә «Идел» ж-

*Дәвамы. 2005 елның 4нче санынннан басылып килә.*

лында (1990 нан баш мөхәррир). 1969 елдан районнар һәм республикада чыга торган вакытлы матбугатта язмалары басыла башлый. 1979 дан «Идел» альманахында, «Казан утлары», «Ялкын» ж-лларында әдәби-тәнкыйть мәкаләләре белән чыгыш ясый. Татар язучыларының иҗатына багышланган, хәзерге әдәби процессын чагылдырган «Кешем, асылын кем?» (1984), «Әверелеш: шигырь парадокслары» (1988), «Чакма чакмый ут чыкмый» (1991), «Күләгә күбәләге» (2002) китаплары, «Мәхәббәт алмасы» (1997) исемле шигырь җыентыгы авторы.

Әд.: Корбанов Р. Шигырь эзләп китте // Идел. 2001. №11; Латыйфи Ф. Кеше китә—жыры кала // Идел. 2001.№12.

*Г.М.Габделхакова.*

# И

**ИБРАҺИМ** Сабит угылы (19 йөзнең 1 нче яртысы), шагыйрь. Кулъязмада сакланып калган «Кыйссаи Хөсәен разый Аллаһе ганһе» (1833) исемле дини—тарихи поэма авторы. Әсәрдә тарихи шәхес—шигыйләр имамы Хөсәеннең (626—80) тормыш юлы, өмәвиләр хәлифәсе Йәзидкә каршы көрәше һәм шул көрәштә газаплы үлем б—н дөньядан китүе сурәтләнә. Хөсәен имам әсәрдә гади халык мәнфәгатьләрен гәүдәләндерүче булып тасвирлана.

*М.В.Гайнетдинев.*

**ИБРАҺИМИЯ** (Ибраһимова) Рокыя (19 йөз ахыры—20 йөз башы), шагыйрә. 1913—16 елларда «Аң», «Сөембикә» ж—лларында басылган шигырьләренең кайберләре «Өмет йолдызлары» (1988) исемле җыентыкка кергән. Иҗатында Г.Тукай йогынтысы сизелә. И. аның идеяләрен һәм карашларын уртаклаша. Шигырьләренең төп мотивы—белем алуга, шәфкатьлеккә, гаделлеккә өндәү («Теләк», 1914; «Бәйрәмме бу?», 1915 һ.б.). Г.Тукай истәлегенә багышланган «Китте шагыйрь» (1914) шигырендә ул аны «хатынлар хамисе», «милләтнең каһарманы» дип атый.

Әд.: Өмет йолдызлары: XIX йөз ахыры һәм XX йөз башы татар хатын-кыз язучылары әсәрләре. К., 1988.

**ИБРАҺИМОВ** Галимҗан Гыйрфан улы (28.2.1887, Уфа губ. Эстәрлетамак өязе Солтанморат а.—21.1.1938, Казан), язучы, галим, дәүләт эшлеклесе, Хезмәт Батыры (1928). Башлангыч белемне авыл мәдрәсәсендә һәм өч сыйныфлы рус мәктәбендә ала. 1898—1905 елларда Оренбургта Вәли мулланың мәдрәсәсендә, 1906—08 дә «Галия» мәдрәсәсендә укый. 1909 да Казанга килә, вакытлы матбугатта хезмәттәшлек итә. 1912 дә Киевка китә, мөселман студентлары җәмгыяте эшчәнлегендә, аларның Бөтенроссия съездын оештыруда катнаша. 1913 нең 17 апрелендә сәяси эшчәнлек алып баруы өчен кулга алына. Шул ук елда азат ителә һәм Казанга кайтып «Аң» ж-лында җаваплы сәркәтип булып эшли. 1914 тә кабат Киевка китә, аннан Уфага кайта һәм 1915-17 дә «Галия» мәдрәсәсендә укыта. 1917 елгы Февр. рев-циясеннән соң актив рәвештә иҗтимагый-сәяси тормышта катнаша башлый. 1917 дә язучы Ф.Сәйфи-Казанлы һәм журналист Ш.Сүнчәләй б-н бергә «Ирек» г-тасын чыгаралар. Татар-башкорт мөселман сул эсерлар партиясенең оештыручылары һәм җитәкчеләренең берсе була. 1917-18 дә Милләт Мәҗлесе һәм Учредительный собрание депутаты. 1918 дә М.Вахитов һәм Ш.Манатов б-н берлектә РСФСР ның Милләтләр эшләре буенча халык комис-ты карамагында Үзәк мөселман комис-тын оештыруда катнаша, комиссар урынбасары була. 1919-20 дә Үзәк мөселман хәрби коллегиясе әгъзасы, бер үк вакытта РКП (б) ҮК каршындагы Шәрекъ халыклары коммунистик оешмаларының Үзәк бюросында матбугат бүлеге редколлегиясе җитәкчесе, «Кызыл Шәрекъ» ж-лы хезмәткәре. 1920 дән ТАССР Мәгариф халык комис-тында. «Безнең юл», «Мәгариф» ж-ларының оештыручысы һәм мөхәррире, 1925—27 дә Гыйльми Үзәк җитәкчесе, бер үк вакытта Татарстан төбәкләрен өйрәнү бюросы рәисе. Бөтенроссия һәм ТАССР ҮБК Президиумнары әгъзасы. Авыру сәбәпле 1927 дә иҗтимагый-сәяси эштән читләшә.

И. әдәби иҗатының башыннан ук чынбарлыкка романтик мөнәсәбәт хас. «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (1907), «Гыйшык корбаны» (1908), «Татар хатыны ниләр күрми» (1909; рус теленә тәрҗемә 1935) исемле беренче хикәяләрендә язучы кадими мәдрәсәләрдә яшәп килгән укыту һәм тәрбия принципларын, яшь буынны тормышка әзерләүдәге кимчелекләрне кискен тәнкыйтьли, шәхесне изелүдән коткару һәм хатын-кыз эмансипациясе мәсьәләләрен куя.

Язучының иҗат потенциалы бөтен көче б-н Казанда ачыла. «Яз башы»

(1910), «Дингездә» (1910), «Сөю—сәгадәт» (1911) исемле хикәяләрендә ул көчле рухлы романтик геройлар иҗат итә. Алар кешенең рухын изүче мохит б-н каршылыкка килеп, тормыш мәшәкатьләреннән, шәһәр ыгы-зыгысыннан туеп, табигать кочагында ялгыз калып тынычлануга омтылалар, матур, гадел тормыш турында хыялланалар, бертуктаусыз идеал, тормыш мәгънәсен эзлиләр.

И. ның тәнкыйди романтик буларак язучылык таланты аеруча «Яшь йөрәкләр» (1912; рус теленә тәрҗемә 1980) романында тулы ачылды. Әсәрнең идея-тематик пафосын аталар һәм балалар конфликты (автор үзе язганча, «янаның искелек б-н көрәше») тәшкил итә. Ул Җәләш мулла һәм аның улы Зыя мисалында ачыла. Зыя—яшь буын идеаллары вәкиле, аның дөньяга карашы 20 йөз башындагы социаль тетрәнүләр б-н билгеләнә. Татар җәмгыяте тормышындагы искелек калдыклары б-н көрәшү инструменты итеп Зыя шәхес иреген саный, мәхәббәт культын игълан итә, кешеләрнең рухи-әхлакый камиллеген патриархаль җәмгыятьнең наданлыгына каршы куя. Романда ш. у. язучының иҗат палитрасын реалистик буяулар (төсмерләр) б-н баетырга омтылуы сизелә.

1912 дән башлап И. актив рәвештә социаль мәсьәләләрне күтәрә, хезмәт кешеләре образларын («Карт ялчы», 1912; «Көтүчеләр», 1913 хикәяләре) тудыра. Аның социаль проблемаларга игътибары соңрак язылган хикәяләрендә дә чагыла («Табигать балалары», 1914; «Мәрхүмнең дәфтәреннән», 1914; «Габдрахман Салихов», 1916).

И.ның иҗат биографиясенең яна чоры «Безнең көннәр» романыннан (1919; 2 нче ред. 1934; рус теленә тәрҗемә 1962) башлана. Роман 1914 тә үк тәмамланса да, аны нәшер итү тыела. Автор язылу датасын 1914—20 дип куя, чөнки шул елларда ул аны яңадан эшкәртә. Бу әсәр И. иҗатының рев-циягә кадәрге чорына гына нәтиҗә ясамый, бәлки татар әдәбияты тарихының яңа, совет этабына башлангыч бирә. Әсәрдә автор үзгәрә барган тормышны, аның төп вакыйгаларын күрсәтергә, яңа геройлар—яшь рев-ционерлар образларын тудырырга омтыла. Романда татар җәмгыяте тормышының төрле яклары: мәгарифнең торышы, шәкертләрнең уку-укыту өлкәсендә реформалар өчен көрәше, татар зыялыларының идея эзләнүләре (рев-ционерлар Даут Урманов, Хәбиб Мансуров, Баязит Кари мисалларында), иҗтимый-сәяси тормышка татар хатын-кызларын (Нәфисә, Гөлбикә, Һаҗәр образлары) тарту мәсьәләләре чагылыш таба.

Идел буе һәм Уралдагы гражданнар сугышы темасына «Яңа кешеләр» драмасы (1920) һәм шул ук вакыйгаларның биш авылдашны баррикаданың ике ягына басарга мәҗбүр итүен чагылдырган «Кызыл чәчәкләр» повесте (1921; рус теленә тәрҗемә 1986) багышлана. Соңгысында авыл сәүдәгәре улы Гали Колчак гаскәре сафына баса, чыгышы б-н мулла гаиләсеннән булган Фазыл, ак армиянең һәлакәткә дучар булуын аңлап, Совет хакимияте ягына чыга. Балта остасы улы Гыйлаҗи акгвардиячылар тарафыннан үтерелә; ярлы крәстиян вәкилләре Солтан һәм Шаһбаз язмышларын яңа строй б-н бәйлиләр, яңа тормыш төзүдә актив катнашалар.

Татар әдәбиятында ул заман милли прозасында якты эз калдырган «Алмачуар» (1922) хикәясендә автор үзенчәлекле, якты, истә калырлык крәстиян малае образы тудыра, аның психологиясен, татар авылы халкының хисләр һәм кичерешләр дөньясын ачып бирә.

1924 тә И.ның традицион романтик мәхәббәт темасы табигый рәвештә социаль проблематика б-н үрелгән «Казакъ кызы» романы (1911 елда Оренбургта, 1913 елда Киевта конфискацияләнә; рус теленә тәрҗемә 1934) романын бастыра. Анда ул казакъ даласы халкының рев—циягә кадәрге тормышын тасвирлый, колониаль изү, социаль ризасызлык күренешләрен сурәтли. Төп геройлар—Карлыгач-сылу һәм Арысланбайның традицион романтик мәхәббәте темасы социаль мәсьәләләр б-н үрелеп бара. Бу роман казакълар тормышында яңа мөнәсәбәтләр урнашуны тасвирлауның беренче үрнәге, СССР төрки халыклар әдәбиятлары үсешендә мөһим этап булып тора.

И. совет шәрекъ язучыларыннан беренчеләрдән булып социаль роман жанрына нигез салды. «Тирән тамырлар» (1928) романында татарларның нэп чорындагы тормышының социаль-сәяси асылына сәнгати анализ ясала.

1920 елларда И. әсәрләренең жанр үзенчәлекләрен, проблематикасын һәм эчтәлеген әдәбиятка катгый рәвештә марксистик-ленинчыл эстетика адептлары тарафыннан кертелгән социалистик реализм ысулы билгеләде. Шулай да И. иҗатының бу чорына чынбарлыкны киң колач б-н күзаллау, реаль тормыш вакыйгаларын барлык катлаулыгы һәм каршылыклары б-н яктырту хас. «Казакъ кызы» романы, яңадан эшкәртелгән «Татар хатыны ниләр күрми» повесте һәм Идел буенда 1921-22 елларда булган ачлыкның реаль вакыйгаларын тасвирлаган «Адәмнәр» (1923) повесте—моның ачык мисалы.

Әдәби әсәрләрдән тыш И. бай публицистик һәм әдәби-тәнкыйди

мирас калдырды. 1910 елларда язылган мәкаләләрендә үк ул милли әдәбият үсешенең принципиаль мәсьәләләрен күтәрә, әдәбиятның «милли рухның һәм характерның көзгесе» буларак билгели. Әдәбиятның эчтәлеген һәм сәнгати формаларын баетуда И. фольклорга зур әһәмият бирә. Ул татар зыялыларының мөһим бурычын халык массаларын рус, Шәрекъ һәм Европа классик әдәбиятлар байлыкларына тартуда күрә.

И.ның рев-циягә кадәрге романтик эстетикасы С.Рәмиев, Дәрдемәнд, Г.Тукай иҗатларын анализлауга багышланган «Татар шагыйрьләре» (Оренбург, 1913) исемле тәнкыйди мәкаләсендә ачык чагыла.

И.ның «Галия» мәдрәсәсендә эшләгән еллары эстетика теориясен һәм әдәби тәнкыйтьне аңлау, төшенү һәм үстерү өчен аеруча нәтиҗәле була. Бу күләмле теоретик мәкалә өстәп, И. «Альбом мөнәсәбәте белән бер-ике сүз»хезмәтен бастыра (1915) һәм әдәбият теориясенә караган, зур әһәмияткә ия булган «Әдәбият кануннары»н (1916) яза.

Октябрь рев-циясеннән И.ның игътибар үзәген мәдәни мираска мөнәсәбәт, яңа чор татар әдәбияты үсеше мәсьәләләре били. Алар И.ның «Имла, тел, әдәбият мәсьәләләре» (1924), «Пролетариат әдәбияты турында» (1924), «Кара маяклар, яки Ак әдәбиятлар» (1924) исемле китапларында чагылыш таба. Бу хезмәтләрендә И. татар әдәбият белемендә марксистик-ленинчыл методология принципларын раслый. Бу методологии кысаларында ул милли мәдәниятләрнең асылын һәм үзенчәлекләрен, аларның пролетариат диктатурасы шартларында үсеш перспективаларын тирәнрәк өйрәнергә омтыла («Татар мәдәнияты нинди юл белән барачак?», 1927).

И.—татар филологиясенә һәм тел белеменә караган «Татар сарыфы» (1911), «Татар телен ничек укытырга?» (1916), «Имла-хәреф мәсьәләсе» (1924) хезмәтләре авторы.

Аерым хезмәтләрендә И. татар халкы тарихының, революцион хәрәкәтенең һәм мәгърифәтчелегенең этапларын яктырта. Алар арасында «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре (1905)» (1925, рус теленә тәрҗемә1926) билгеле бер урын алып тора. Ул Ш.Мәрҗани, К.Насыйри турында мәкаләләр, «Шәрекъның бөек революционеры Мулланур иптәш Вахитов» (1919), «Бөек Октябрь революциясе һәм пролетариат диктатурасы» (1922), «Татар студентлары хәрәкәте тарихыннан» (1922), «Урал һәм уралчылар» (1927) һ.б. тарихи һәм тарихи-публицистик хезмәтләр яза.

Гомеренең авыру б-н бәйле соңгы елларын И. Кырымда уздыра. 1937 дә «Үн троцкийчы милләтчеләрнең совет хакимиятенә каршы оешмасы» эшендә катнашуда гаепләнеп кулга алына. Авыру хәлендәге И.ны Казанга алып кайталар, ул хастаханәдә үлә. Вафатыннан соң аклана.

И. әсәрләре СССР һәм чит ил халыклары телләренә тәрҗемә ителде. Аның иҗаты казакъ, үзбәк, әзәрбайҗан, төркмән, башкорт һ.б. әдәбиятларга зур йогынты ясады.

ТР ФАнең Тел, әдәбият һәм сәнгать институты И. исемен йөртә (1967 елдан). 1987 дә туган авылында язучының музее ачылды.

Әсәр.: Әсәрләр: 9 томда. К., 1974-2000; Избранное. К., 1957; Советские писатели: Автобиографии. Т.3. М., 1966.

Әд.: Валидов Дж. Очерки истории образованности и литературы татар. М., 1923; Коган П.С. Поэт красоты и свободы // Вестн. Науч. об-ва татароведения. 1928. №8; Саади А. Г.Ибрагимов и его литературное творчество // шунда ук. С.23-50; Халит Г. Галимджан Ибрагимов // История татарской советской литературы. М., 1965; Гимадиев У. Галимджан Ибрагимов — журналист. Уфа, 1967; Нуруллин И. Путь к зрелости. К., 1971; Хасанов М.Х. Галимджан Ибрагимов. К., 1977; шул ук. Ученый, писатель, революционер. М., 1987; Писатель, революционер, ученый: Материалы науч. конф., посвященной 90-летию Галимджана Ибрагимова. К., 1980; Поварисов С. Система образных средств в художественной прозе Г.Ибрагимова. Уфа, 1980; Габсалямова Ф.Г., Гимадиев У.И. Галимджан Ибрагимов: Библиогр. указатель (1907—1977). Уфа, 1979; Сәйфи Ф. Галимҗан Ибраһимов // Яңалиф. 1928. №4; Хәсәнов М. Галимҗан Ибраһимов. К., 1964; Г.Ибраһимов турында истәлекләр. К., 1966; Мөхәммәдева Г. Олы юл. К., 1994; Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман. К., 2003.

*М.Х.Хәсәнов.*

*Дәвамы киләсе саннарда.*

Ренат
Гаффар

# МАНЗАРАЛАР

## Хәмфери



Башкалага, бәйрәм белән бергә, һәр җәйне ел саен Килкинградтан бер иптәш килеп төшә. Минем Раил атлы дусның чыбык очы туганы Хәмфери ул. Шофер. Әнисе белән генә торалар. Кырыкка житсә дә һаман буйдак. Үзе әйтмешли, яртылаш өйләнгән-өйләнүен. Исемен әйтмим әле. Кушаматы да житеп торыр. Йә кешене үпкәләтерсең, хәтерен калдырырсың, йөрерсең аннары Сабан туйларында кызык таба алмыйча.

Ә аның белән, чыннан да бергә-бергә ял итүе аңлата алмаслык дәрәҗәдә рәхәт. Ишетмәгәненне ишеттерә, күрмәгәненне күрсәтә. Безнең компаниянең терәү баганасы. Биергә, җырларга да аңа куш, әллә ниткән мәзәк хәлләр сөйләп көлдерер, сыныңны катырыр. Бу кеше уйнап яши, уйнап эшли. Күзенә генә каратып тота һәммәнне. Мин аның караңгы чагын хәтерләмим. Алай да күңелсезләнгәне бар-барын...

Моннан өч ел элек Казан Сабан туена кош тоткан шикелле килеп төшкән иде. Өйләнеп өлгергән, чукынмыш, каяндыр читтән алып кайткан кәләшне.

—Тау хәтле!—дип сөенеченнән сырпалана Хәмфери. Авылда нигезен янартып җибәргән. Ак кирпечтән ташпулат житкезеп куйган, хан сарае хәтле, имеш. Хәзерге заманда өй кузгаткан мондый иргә бишәүләп чабып килерләр, билләһи! Былтыргы бәйрәмдә кош тотканнан болай шатланган иде "чыбык очы". Сыра белән шәп бара, дип, бу юлы күчтәнәчкә мул итеп күгәрчен пешереп алып килгән. Ферма янында казан асып эш иткәннәр кичә.

—Котылдым, малай, тегеннән!—ди үзе.

—Кемнән!

—Хатыннан инде.

—Ни булды тагын?

—Артык юанаеп китте, балакаем, кочакка сыймый башлады. Андыйны кеше барыбер кулда тотмас иде. Безнең якта ир-ат бик мут...

Килкинградына кайтып киткәч, Аллага тапшырып, тагын тәвәккәлләгән теге—Чаллы якларыннан берәүне Сабан туе житкәндәрәк түшәк-ястыгы белән төяп тә кайткан. Сөенештек инде ишеткәч без дә.

Быел "чыбык очы"н ялгыш кына Казан базарында очраттым. Яз иде. Бәрәңге сата. Авыз җырык.

—Яшь кәләш килмәдеме соң булышырга?—дим.

Дәшми. Көлә генә.

—Быел Казанга—Сабан туена ияртерсең ич хатыныңны,—дип кылларын чиерткәлим.—Безгә дә күрсәт инде бер нурлы йөзләрен. Эгоист булма...

—Әйтсәм әйтим, яшьти,—ди сәүдәгәрем,—булмый. Аның белән дә борчак пешеп үк бетмәде бит әле. Күрсәтеп булмас алай, дим...

—Чү! Ник инде тагын? Быел бәйрәмнең яме юк икән алайса.

—Илтеп куйдым мин хатынны кире, алган урынына. Бөлдерә башлады, явыз. Бер чынаяк чәйгә жиде кашык шикәр сала, малай!

Можга якларына чыгып кергәнием әле менә. Түшәк-ястыгынны төйни тор, дип әйтеп кайттым берсенә. Туйга акча кирәккә килдем базарыгызга...

## "Чөйкәлтәм"

Бу мәйдан тоткан батырларны әйтәм әле. Алардан да гаярьрәк һәм куркаграк тагын кем булыр икән?

Бер елны шулай үзебезнең Әшнәк Сабан туена кунак егете алып кайттык. Үз акчасына яллаган тән сакчысы белән. "Казан жулигы" дип йөртәбез без аны. Башкалада туган. Әртис. Шамил атлы. Тинчурин театрында, Минзәләдә һәм Тыва башкаласында шактый еллар тамашачыны тоткан кеше.

Андагы гәүдә, буй-сын, килеш-килбәт, шәп, гөлдерек тавыш. Эченә әз-мәз генә әче бал чүпрәсе дә керсәме? Бетте! Бушлай спектакль әзер!

Ә бу тамашасы...

Ун ел вакыт үтеп киткән, ә авылдашлар һаман искә төшерә аны...

—Кайда теге "чөйкәлтәм"егез? Алып кайтыгыз әле тагын шуны. Сагындырган...— диләр.

Ә ул чакта...

Автобустан төшкәч, жиде чакрым жирне жәяүләп үтәсе. Атлый торгач, өшәндергән. Туган нигез болдырында гаилә белән тиз-тиз генә чәйләп алгач, тауга—өч авылның бергә үткәрелә торган Сабан туена күтәреләсе бар.

—Жегетләр, яшь тәкә итеннән авыз итәсезме?

Кунак Шамилнең череп беткән тешле авызыннан шул сүз ышылдап чыккач, абыем Әхәт колагын шенкәйтте:

—Ню!

(Сорау бирүе идеме шул рәвешле, тегене хуплавымы—аңламый калынган).

—Мәйданга чыгам, жегетләр! Көрәшергә,—диде әртисебез, күбенгән чебешкә тартым шешәдән "Бренди" уртлый-уртлый.—Тәкә алам бүген, чөйкәлтәм батырларыгызны!

Гадәтенчә, уйный бу, дисәк, чынлап торып мәтәштермәкче икән.

Жиненә кызыл таккан комиссия әһелләре татарча көрәш хәстәре күрә башлау белән кунагыбыз мәйдан уртасына шортыдан гына чыгып та басты. Аягында—кырык бишле галушы, гәүдә —аю. Тән язасы, иелеп-бөгелеп аласы урында бу, и пычагым кергере, бокс һәм каратэ остасы сыман бәрү хәрәкәтләре ясый башламасынмы! Аһ итте халык. Вакыт туктап калды. Таллыктагы сандугачларга хәтле тынды инде менә, валлаһи!

—Болай булгач тәкә безнеке,—диде Әхәт абый озын мыек чылгыен чәйни-чәйни.

Казан, Чаллы, Мәскәү, Сөхәлин ише калалардан ук көрәшергә дип ясканып кайткан якташ батырлар, пәһлеваннар әллә кайларга юкка чыкты шунда. Юк көрәшкә язылучы! Берсенең генә дә үзен тән сакчысы аяк очында гына утырган килмешәк спортчыдан имгәттерәсе килми.

Ул да булмады, минем кулга кайсыдыр ки бер такырбашы язу тоттырып китте. Укыйбыз. "Әгәренки бу кешегез мәйданнан үз теләге белән чыгып китмәсә, баста, бетәсез".

Дуэльгә дәшүләре иде бу.

Бездә кеше усал. Шөпшәдән хуже. Үзебез дә шушы туфрактан. Ничек тиеш, шулай итеп жавап сүзе сырлап жибәрдек инде секундант аша: "Гомер ике килми. Без әзер. Кайда? Кайчан?"

Комиссия әһелләре, аксакал бабайлар тыз да быз чабыша. Юк кына бит теге иләмсез әртискә каршы чыгучы! Янымда утырган әбигә хәтле әйтеп салмасынмы: "Болар Казанда шишка тота икән, анаем, бу баланың тешләрен шунда разбурки чыккачтын коеп бетергәннәр икән, бичаракаем, име"...

Болай булса, тәкәне бил алышмыйча гына каяндыр килеп төшкән һәм эт тә белмәгән

килмешәккә чыгарып тоттырасылар. Жиде йөз дә сиксән ел гомер сөргән, Борынгы Болгар авылы булган Әшнәк моның ише хурлыкны, юк, күтәрә алмаячак иде.

Ә Шамил һаман әртисләнүен белә: ул хәрәкәтләре, минсинаййтим, име, бала йоннарыңны торгызырлык.

Ул да булмады, уртага тәбәнәк буйлы, ябык тәнле кара егет Фәрит чыгып басты. Әтисе мәрхүм исеме белән "Гали батыр" дип йөртәләр. Алдагы елларда тәкә ашаштыргалаган малай, Казанда шофер булып эшли.

—Жә бетәм, жә бетерәм!—ди.

Бу—аның соңгы сүзләре иде.

Кунак вәкарь белән генә базык Фәритнең сыртына кып-кызыл сөлгесен китереп салды. Ә Гали батыр кече теленнән чыккан нечкә тавышы белән яман итеп чинап алды да, үз ролен нәкъ Станиславскийча затлы башкарып, дөньяның артына тибеп яши торган әртисебезне өстерәп йөртте-йөртте дә, Путинча манчыды, лыркылдатып салды һәм мәйданнан ничек кергән—шулай чыгып та китте.

Тәкә безнеке түгел иде инде...

## Кавалерлар

Сабан туе житкән саен шул бабайлар искә төшә. Шәп кеше иде алар. Урыннары ожмахта булсын...

Без студент булып йөргән элеккерәк елларда баштан үтте бу. Тау хәтле автобуста үзебезнең Әшнәккә кайтып төшү белән елга аръягындагы болында ерак-ераклардан ук сәйләнләп чигүле татар түбәтәен хәтерләтеп торган Сабан туе мәйданына килеп кердек. Таныш-белеш, дус-иш, туган-тумача һәм, әлбәттә инде, авызы тулы тимер тешләрен кояшта жемелдәтеп елмайган, Черчилль кебек йөреш-торышлы, үтә дә гаярь, ком гарәбе ише Гыймай дәдәй белән күрешүләр. Гыймай дәдәй—әтинең, үзләренчә әйтсәк, двоюрдные. Теге хәтәр елларда, кайчандыр Жәмәлжән алпутында приказчик булып торган Гаффар бабаебызны кулак итеп талагач, әти белән Гыймай дәдәй Питерга чыгып сызганнар. Көн күрергә, эшләргә дип инде.

Гыймай дәдәйнең йөзе шома, олы яшьтәге кеше димәссең. 1914 елгы сугышта егетлекләр кылып кайткан, йөрәкле; Георгий тәресе кавалеры! Бу Сабан туенда аның чордашы, шулай ук кәттә зат—Георгий тәреле, агач аяклы Гәрәй бабай да ияргән. Болар—Әшнәктә икәү генә. Кәрәшкә чыкмакчылар.

—Әйдә соң,—дим ахирәтләргә,—әнә, кибетче Тәзбирә апа—белгән кеше. Машина әржәсендә астан гына шәп "Вермут" сата. Сыйлыйм. Сабан туе хөрмәтенә?..

—О-о, юк, олан. Бармый,—диде Гыймай дәдәй,—Сара жиңгәгез сизенсәме? "Китәм!"—дип, айн момент төенчеген төйни башлый. Аннары... Тын бетә, адышкы. 14 нче елда Пиримишелдә бет симертеп окопта яткан чакта тирләгән көе, тамакка булмагач, бер кәтилүк чит жир кары ашалынган.

—Адышкы, диган буласың. Үзең, ачуым да бер килмәгәе, йөзгә житеп, көрәшкә чыкмакчы. Ничек шулай мәңгелек булып була ул, Гыймай дәдәй?

—О-о, олан. Гади ул бик. Алабута, ат колагы, кычыткан, балтырган ашаган чакта рационга онытмыйча гына ара—тирә черек бәрәңге кәлжемәсе кушарга кирәк икән ул. Иртән дә, кичен дә, ятар алдыннан да, эчең бунт кузгата башлау белән үк шушы рецептны даими кабатлыйсың и эшең бетте!

—Ә син, Гәрәй бабай, кем әйтмешли, йөз дә иллегә житеп, ничек шулай Кавказ кешесе ише япь-яшь кала алдың соң?—дим.

—Берние юк аның, наным. Бәйрәмнәрдә алабута кушылган кара ипи ашап, мүкләк кәжә сөте эчеп кенә качтык без картлыктан, име. Йокларга ач көе ятуың шарт түлке. Ә витамин урынына Гыймай бабагыз әйткән әлеге дә баягы яшеллек булды инде. Эсписеккә кузгалак белән жуаны, иренжаргыч белән сасы көпшәне, кукы белән мәче борчагын кертергә онытты Гыйматдин.

—Болары аның, бик беләсең килсә, кордаш, сиңа калдырган булсалар, таба алсаң гына тәти,—ди Гыймай бабай юкарып калган эче ертылганчы хихылдап.—Аннары искә төшкән саен аралаштыра-аралаштыра нимеч, акчех, венгр, румын, әгелчән, итальян, фин, әмеркән, дөберән ише бәдбәхетнең ипи шүрлегенә менеп-менеп

төшүне гадәткә кертү шарт. Бу кадәресе тәнне үтә дә ныгыта икән. Главный, олан, кешедән калмаска! Кеше чапса, мылтыгынны болгый-болгый, яман акыргалый-акыргалый (Әшнәккә тиклем ишетелерлек булсын!) чабасың. Кеше качса, мылтыгынны куак арасына бәреп, акырмый-нитми генә качасың. Бу хәдәресе ач карынга гына эшләнә, олан, ишетсен колагың. Ашаган-эчкән булсаң, качкан чакта, шапы да шопы килеп, эченнең өнен ала түлке. Жайсыз...

Шулчак янибыздан гына, Сабан туе мәйданына ышкынып, аякларын лыштырдата-лыштырдата, тәмам таушалган бер карт үтеп китте.

—Танымадым,—мәйтәм,—кем бу?

—Ә, бумы? Бу, олан, кырык ягына авышкан авылдаш бабай, заман карты. Озак яшәве шуна: моның иртәнге ашка—тәмәке белән "Вермут", әбәдкә—әче бал (тәмәкесез генә), ә кичкегә—әлеге дә баягы, өйборынча эзләнеп, трай тибеп, аяк мускулларын ныгыту. Белдеңме шуны?

Ул чакта Сабан туе уза торган тугайны янгыратып көлгәнебезне күргән булсагызмы? И—и—и ул чакта...

## Экзекуция

Ике жырчы ханым (кемнәр икәнен әйтмим әле, жәмегез) очрашкан икән дә ләчтит сатарга керешкән.

—Кичә житәкчебез Хәмферидә кунакта булдым бит әле,—дигән берсе.—Күз алдына китереп кара: хужага ике сәгать буена романс жырлаганмын инде.

—Шул кирәк ул башлык ләгыйньгә!—дигән икенчесе.—Ул бәндәне мин үзем дә күралмыйм...

## Күрде инде башлар

Авылдан калага кунакка килеп төшкәч йөзьяшәр Әгъләметдин бабайны Чыршы бәйрәменә—Казан "Пирамида"сына алып барганнар. Гомер күрмәгән затлы залны мактый-мактый тел шартлатып, хөкүмәтебезгә рәхмәт укый-укый йөри торгач, бабайны зурлаганнар, сыйлаганнар, аңлашыла инде, кулына бик шәп призлар китереп тоттырганнар, Салават белән дә таныштырганнар.

Авылына кайтып егылгач, күрше-күләне Әгъләметдин бабайга сорау арты сорау яудырырга керешкән:

—Чыршы бәйрәме ошадымы соң? Кемнәрне күрден? Президент ни диде? Ни бирделәр? Тамагың туйдымы?..

—Күрде инде башлар,—дип жаваплаган йөзьяшәр бабай.—Әммәсен сүләп чыгарга сулыш житеп бетмәстер. Вәләкин шунысы шәп булды: бәйрәмнәре беткәч, кием өләшә торган төштә матур, кызмача кызлар абзагызга берьюлы бик шәп өч тун китереп тоттырды, малай. Яхшы икән хәзер калада тормышлар.

## Артист шөһрәте

*(Этюд)*

*Реформатор ролен уйный иде –*
*Каз йомыркасы аттылар...*
*Гитлер булып чыккан гына иде –*
*Аяк тибеп кул чаптылар.*

Алмаз
Хәмзин

# ШАЯН ХИКӘЯЛӘР

### Иртәгә нинди бәйрәм?

Өйдән урамга чыгуым булды, подъезд төбендәге сәрхүшләр: “Бәйрәм белән, күрше!”—дип сәлам бирделәр. Үзем дә берни анламыйча жавап сәламемне ыргыттым. Эчтән генә: “Нинди бәйрәм икән?”—дим. Беләм тегеләрнең тел төбендә бер яртылык акча кирәклеге ятканын. ”Ниме, күрше?..”—дип сүз башлаулары булды: “Юк шул”,—дип жавап бирдем. Чырайлары сытылды. Мин алга ыргылдым. “Халыкара наркоманиягә каршы көрәш көнендә дә жмутлана”,—дигән сүзләре янына әллә ниндиләрен өстәп сүгеп калдылар.

Үтә гомер. Менә 8 Март—Халыкара хатын-кызлар көне дә килеп житте. Әйбәт бәйрәм. Язның беренче бәйрәме. Ир кеше булсам да, бәйрәм белән котладылар, рәхмәт яугыры! Беркөнне базарда кирәк-ярак эзләп йөрим. Берәү мине күрде дә: “Бәйрәм белән, кордаш!”—диде. Нинди бәйрәм икән инде тагы, мәйтәм. Аптырап торганымны күргәч: “Русиянең Эчке эшләр гаскәрләре көне”,—дип өстәп куйды. “Ә-ә, беренче апрель белән котлыйсың дип торам”,—мәйтәм. Вәт кешеләр әллә нинди бәйрәмнәр беләләр, ә мин сабантуйны да Яңа елны гына. “Әйдә, бераз”,—дип, тамагына чиртеп күрсәткән иде дә, мин: “Юк шул”—дигәч, аерылыштык.

Бер ай чамасы каты-коты кимереп, тишек-тошык ямап, тормышның очын очка ялгап, бәрелеп-сугылып йөри идем, берәү: “Сәлам, Алмаз, бәйрәм белән!”—дип кычкырды. Таныш та түгел бугай. Алдым сәламен, үзенә жибәрдем. Май бәйрәме белән котлавыдыр инде. Ул да, мин дә хезмәт ияләре бит—безнең бердәмлек көне. Безне бит шул хәерчелек берләштерә. Алай түгел икән. “Нинди бәйрәм?”—дигәч, “Радиация һәлакәтләрендә һәлак булганнарны искә алу көне. Мин генә исән калдым бугай инде”,—диде. “Чернобыльдәнме?”—мәйтәм. “Әйе, көнгә бер стакан “кызыл” кабып кына исән йөрим, синең юкмы?—ди. Бирми нишлисең шундый каһарман кешегә. Бирдем дә сыздым.

Атна үтмәде, эштәге Нәсим: “Сәлам, брат, бәйрәм белән”—ди. Иртүк өйдән чыгып китәр алдыннан үземә акча бары тик транспортка гына дип установка куйган идем. “Син сержантмы әле? Бүген бит Россия Федерациясе Кораллы көчләре оешкан көн. Һәй, брат, шуны да белмисең”,—дип, мине оялта башлады Нәсим. “Кит аннан!”—дип гажәпләнгән булам.—Нинди зур бәйрәм! Ләкин акча юк шул!” “Их,—диде Нәсим, уфтанып,—шундый яхшы бәйрәм иде, боздың”. “Ә мин сине Жиңү бәйрәме белән тәбрик итәсең дип торам бит, кордаш, 9 май белән”, “Аның белән дә ярый”,—ди Нәсим. “Менә аның белән булса, мин дә сине бәйрәм белән тәбрик итәм. Әйдә, билгеләп үтәбез. Әтинең дә сугыш ветераны икәнен искә алабыз. Аның исәнлеге өчен чәкештерәбез”.

Ул көнне лычкылдап өйгә кайтып кердем. Менә, ичмасам, бәйрәм! Икенче көнне махмырга берсекөнгә булачак Кара дингез флоты бәйрәмен дә билгеләп үттек. Бәйрәм атна буе барып, 19 май—СПИДтан үлгәннәрне искә алу көнен дә онытмадык. Чик сакчылары көне дә шунда керде, бу бәйрәмнәр сабантуйларга ялганып, ай ярым дәвам итте. 22 июнь сугыш башланган көнне айнымакчы идек тә, Хәтер һәм кайгы көне икәнен белеп, тагын баш төзәттек. Июль ахырларында гына анга килдем. Берәү 27 июль көнне Хәрби дингез флоты көне дип, бәйрәм белән котлап, сәлам биреп калды, алмадым сәламен. Ишетмәмешкә, күрмәмешкә салышып киттем. Ике ай буе бәйрәм итеп йөрүләр колакка да, күзгә дә, башка да зыян китергәндәй тоелды. 1 августта Кораллы көчләрнең тылда хезмәт итүче гаскәрләре көнендә урамга чыкмадым. Күршеләр минем тәрәзәләргә сәлам биреп йөрделәр йөрүен. Нигә дисәң, бер чыксаң, 1 август 4 числодагы Һава десанты гаскәрләре көне белән ялганып китәргә мөмкин. Аннан 12се—Хәрби һава көчләре көне килеп житә. Жәй ахырындагы кебек онытылып "бәйрәм итәргә" ярамый. 30 августтагы Татарстан Республикасы көнен күреп каласы килә. Аннан соң 4 сентябрь Аеклар көне икән бит. Язучы Гаффар 1 сентябрь—Белем көнен яхшылап билгеләп үтәргә тәкъдим ясады. Тәкъдимен бертавыштан кабул итеп алдык та шул ук көнне берочтан Бөек Октябрь социалистик революциясен дә искә төшердек. Аның хәзер әллә нинди Бердәмлек көне икәнлеге дә ярап куйды. Күп "төшерелгән". Милиция көне дә, Ракета гаскәрләре, артиллерия көне дә, Дингез пехотасы көне дә, Россия хәрби даны көне дә, Стратегик юнәлештәге гаскәрләре көне дә. Әллә каян гына Яңа ел килеп житкәнен сизми калганбыз. Ураза да онытылган.

Житәр. Туктарга вакыт. Яңа елдан яңача яши башларга исәп. Кирәкми бәйрәмнәр!

Яңа елның беренче ундүрт көнен өйдә әвәрәләнеп үткәрдем. Ике атна буе мәжбүри ял иттерделәр. Эшләтмиләр. Яңача яшибез. 27 гыйнварда бер танышым: "Киләчәк бәйрәмнәр белән!"—дип караган иде дә, эндәшмәдем. "Чирлисезме әллә?" Корбан бәйрәме белән котлаган икән. Рәхмәт. Инде бәйрәм белән тәбрик итүчеләрдән кот чыгып тора. Менә 23 февраль житте—Ватанны саклаучылар көне. Иртүк—кыңгырау. Куркып кына ишек ачсам, фатирга счет-фактура тотып, берәү: "Берүк егыла күрмәгез, бәйрәм белән! Фатирга түләү арткан!.."—диде. Күзләр маңгайга менде.—Мең тәңкәгә!..

Әһә,—минәйтәм,—кемнәрдер бәйрәм итә!..

## Гармун белән сөйләшү

Яратам шул сволочны.

Инде ниләр генә эшләп бетмәдем бит. Утка-суга да салдым, астым да кистем дә үзеңне, ярый әле чыдыйсың, гармункаем. Соң, үзе котырта бит. Янәмәсе, мин синнән башка—нуль. Соң, ананның сипкелле сыеры, мәйтәм. Мин караштырып йөрмәсәм гомергә кысыр каласы нәрсә, бетчә басу!..

...Төннәр буе йоклый алмый ятам...
Әллә чишмә чылтырап акканга.
Әллә кошлар моңлы сайраганга,
Әллә яшьлек...

Ачудан сине тәрәзә каршыларында үскән өянкегә асып киттем. Икенче көнне күреп, өйләренә алып кергәннәр. Китереп биргәч, дуслаштык. Ярый әле син бар...

Яратам шул сволочны!

Беркөн ванныйларында кер юып маташа. Менә син “Сарман” көен болай җырлыйсың, ди.

Сандугачлар сайрый, кайда сайрый?..

Ә ничек җырларга кирәк, мәйтәм.—Менә болай җырларга кирәк,—ди.

Сандугачлар сайрый, кайда сайрый?..

—Соң, мин дә шулай җырлыйм бит инде.
—Юк, син менә болай җырлыйсың. Синеке минеке төсле түгел.

Сандугачлар сайрый, кайда сайрый?

Ах, ананның сипкелле сыеры, дидем дә, синеке минеке төсле булмаса, минеке болай, дип башы-ние белән ванныена тыгып куйдым. Ике арага син дә эләккәнсең. Нәрсә инде кеше арасына кысылырга. Җебеп-җепшеп ямьшәеп беткәнсең. Атна буе мунча ягып киптердек үзеңне.

Төннәр буе йоклый алмый ятам
Әллә чишмә...

Сине кызганып дуслаштык.
Яратам шул сволочны!
Беркөн әнисе белән утын кисәләр. Күңелләре булсын дип мин дә яннарында гармун уйнап тордым. Әйбәт кенә уйнап торганда алды да бәрде утын пүләне белән башка. Ах, ананның сипкелле сыеры, дидем дә гармун белән җиппәрдем тегеңә. Аерылдың да төштең. Менә хәзер камыт бавы белән тегеп куйган килеш йөрисең. Нишлим инде гармун уйный белгәч, кәнишне гармун уйныйм. Гармун уйный белсәләр утын кисәрләр иде мени?

Төннәр буе йоклый алмый...

Яратам шул сволочны!..
Беркөн көтү чираты житте. Әйбәт кенә көтеп ятам, гармун уйнап. Мин гармун уйнап көтәргә яратам бит. Сыерлары кайткан да әйткән, көтүдә гармун уйнап утыра, дип. Нәрсә инде лыгырдарга, кайтырга иде дә мыштым гына утарга кереп ятарга иде. Ә бу “му!”да “му-у!” Әй, мин сиңа әйтим, пырлап килеп житте теге. Мин какрас шашлык кыздырып, гармун уйнап ятам. Гармунны алды да учакка бәрде. Өстенә шашлык ишелеп төште. Чытырдап яна башлагач тартып алдым үзеңне. Менә хәзер синнән шашлык исе килеп интектерә. Телгәләп ашыйсы килә үзеңне.

Төннәр буе...

Яратам шул сволочны.

# ЯШӘСЕН МИН!

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

***

**Мин** үзем турында татарның киләчәге булган һәм, һичшиксез, Тукай йолдызлыгыннан булган зур шагыйремен дип уйлыйм. **Мин** бүген татарның иң күп укыла торган шагыйре, прозаигы, публицисты һәм ихтирам ителә торган җәмәгать эшлеклесе... **Минемчә**, монда арттыру юк. Болай уйлаучылар, **минем** белүемчә, татар бар җирдә бихисап. **Минем** үземне болай итеп тануымнан **миңа** көнеллеме соң? Юк. Көнелсез, ай-һай монсу **миңа**! **Миңа** иптәшкә үзем кебек тагын да бер-ике, өч-дүрт язучы кирәк булыр иде! Бирче, Аллаһ!

**Айдар ХӘЛИМ,**
*"Балачак әдипләре".*
*Биобиблиографик белешмәлек.*
*Икенче китап. 2004 ел.*

***

Юк, **мин** әдәбиятны сайламадым,
Әдәбият **мине** сайлады.

**Ренат ХАРИС,**
*Ялкын. 4 сан. 2008 ел.*

***

Кайбер депутатлар игелек эшләсә, икенче көнне үк газетада рәхмәт хаты бастырып чыгара, рәхмәт яздырта. Ә **минем** нинди игелекләр эшләгәнемне беркем дә белми кала!

**Роберт МИҢНУЛЛИН,**
*"Шәһри Казан".*
*26 апрель, 2009 ел.*

***

Эдит Пиаф и Анна Франк – **мои** собутыльники. Когда **я** достигаю определенного алькогольного уровня, **я** слушаю песни Пиаф, думаю о ее жизни, заполненной мужчинами и песнями, о ее разбитом сердце, **мне** становится тепло-тоскливо. **Я** плачу.

**Лилия ГАЗИЗОВА,**
*"Звезда Поволжья".*
*N 2. 2009 г.*

***

Тукай Гаязга эндәшкән,
**Мин** соң кемгә эндәшим?


**Ркаил ЗӘЙДУЛЛА,**
*(Гаяз Исхакый юбилеенда*
*сәхнәдә сөйләгән шигырьдән)*
*декабрь, 2008 ел.*



Опера һәм балет театры янында үткәрелә торган Шигырь бәйрәменнән күренеш. Тукай һәйкәле янында чыгыш ясаган шагыйрьләр (уңнан сулга): Рәдиф Гаташ, Марк Зарецкий, Нияз Акмал, Нәби Дәүли, Разил Вәлиев, Дания Зарипова (КПСС өлкә комитеты вәкиле). 1988 ел.



Йолдыз Нигъмәтуллина (Галимҗан Нигъмәти кызы) – әдәбият галиме, профессор. Казан университетында укытканда, ул вакыттагы студентларга– хәзерге байтак кына күренекле язучыларга– дәресләр биргән шәхес.



Мөхәммәт Мәһдиевнең туган авылы Гөберчәк (Арча районы) күренеше.



*Татар ПЕН-үзәге әгъзалары.*
*Сулдан уңга–Марсель Галиев, Әхәт Мушинский,*
*Миркасыйм Госманов, Нур Әхмәдиев.*
*Словения илендә. 2007 ел.*




*Замандаш. Армия генералы*
*Мәхмүт Гәрәев. 1993 ел.*



*Камал театры артистлары "Яшь Ленинчы" газетасы редакциясендә. Сулдан уңга–Равил Шәрәфиев, Рауза Хәйретдинова, журналистлар–Сәйдә Зыятдинова, Саимә Ибраһимова, Мәҗит Вәлиуллин, артистка Вера Минкина. 1963 ел.*

## Марат Кәбиров



Кәбиров Марат Рафил улы 1970 елда туган. Балачак һәм үсмер еллары Актаныш һәм Илеш районнарындагы Чуракай һәм Сеңрән авылларында үткән. Сеңрән авылы мәктәбенең сигез сыйныфын тәмамлагач, Үрге Яркәйдәге (Башкортстан) һөнәр училищесында белем ала. Соңрак башкорт педагогия институтының татар филологиясе бүлеген тәмамлый.

Яшь авторның матбугатта күренә башлавы үткән гасырның 80 нче еллар ахырына туры килә. 1987 елда күренекле шагыйрь Әнгам Атнабаев кереш сүзе белән "Кызыл таң" газетасында яшь шагыйрьнең күләмле шигырь циклы басылып чыга. 90 нчы еллардан башлап ул үзе дә матбугатта эшли башлый: башта—"Башкортстан пионеры", соңрак—"Өмет" газетасында әдәби хезмәткәр, бүлек мөдире вазифаларын башкара.

Марат Кәбиров—актив иҗат итә һәм төрле жанрларда мәгълүм бер уңышларга ирешә. Берәүләр аны шагыйрь дип таный, берәүләр — яңа төр проза вәкиле дип белә, берәүләр—әдәби-тәнкыйть өлкәсендә эссе-уйланулар иҗат итүче публицист дип саный. Һәрхәлдә, Марат Кәбиров утыз биш-кырык яшьлек язучылар арасында үз фикере булган үзенчәлекле шәхес.

Марат Кәбировнең китаплары 1993 елдан бирле даими чыгып килә. Алар унга якын: "Онытма таңнарыңны", "Серләшик әле бер", "Күнелле табын", "Өзәңгегә баскан чак", "Иң күнелле китап", "Мәхәббәт янгыры", "Сагындым. Кайт инде"... Китапларның күбесе Уфада басылган, соңгы елларда Казанда нәшер ителә башлады.

Марат Кәбиров эшчәнлеге сәхнә, эстрада белән дә нык бәйле: ул—нәфис сүз остасы, конферансье буларак, күренекле сәнгать осталары белән татарлар яши торган төрле төбәкләрдә чыгыш ясый, халык белән аралаша, тамашалар өчен сценарийлар, көлкеле монологлар, җыр-шигырьләр иҗат итә.

Язучы буларак, Марат Кәбировне җәмәгатьчелек күптән таныган иде инде. Ул 1995 елдан бирле Башкортстан Язучылар берлеге әгъзасы санала. Ике ел элек Казанга күчеп килде. Үткән ел ахырында безнең язучылар да аны үз сафына алды —Язучылар Идарәсе Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы итеп кабул итте.

*Котлыйбыз!*

**Гафур Каюмовка 50 яшь**

# УЛ ҮЗЕ БЕР ТЕАТР...



Күнеле дингездәй ярсу, хыялы йолдызлар арасында, максаты–матурлык тудыру. Дөньяны һәлакәттән матурлык кына коткарыр! Аның барлык гамәли нияте шуңа корылган.

Ин элек биографиясенә күз салып үтик. Гафур Шәкүр улы Каюмов 1959 елның 2 мартында Арча районының Яңа Сәрдә авылында дөньяга килә.

1983 елны Казан театр училищесында актерлык осталыгы буенча укый. 1994 – 1999 елларда Мәскәүнең мәдәният һәм сәнгать режиссерлары әзерләү институтында "драма режиссеры" белгечлеге ала, 2000 елда Болгариянең София шәһәрендә "Крьето Сафаров" Театр һәм кино сәнгате милли академиясен режиссура буенча тәмамлый.

Драматург һәм артист Гафур Каюмов исеме бүген күпләргә таныш. Ул К. Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрында, аннан Г. Камал исемендәге академия театрында артист булып эшләп алды. Артист җаны рольләр уйнап кына тынгылык тапмый, Гафур кулына каләм ала һәм пьесалар язарга керешә. Г. Каюмов бүгенге драматургиядә иң актив эшли торган иҗади шәхесләрнең берсе. Аның беренче әсәрләре үк ("Язмышлар ярында", "Мирас") тирәнтен уйланырга, кеше күнелендәге җәрәхәтне үзенеке итеп кабул итәргә сәләтле, тынгысыз бер җанның драматургия дип аталган гаять четерекле бер өлкәгә аяк атлавы турында хәбәр бирде. Аннан соң сәхнә күргән "Һинд кызы" комедиясе театрларыбыз өчен чын-чынлап бәрәкәтле булды–ул 5 театрыбызда куелды һәм һәркайсында да зур уңыш белән барды. Балалар өчен язылган "Сарык-арслан" әкият-риваяте 4 театрда, шулай ук "Их, Алла боерса..." музыкаль комедиясе һәм "Соң инде" драмасы Татарстан һәм Башкортстанның берничә сәхнәсендә бара.

Ул бик кызык кеше, бер генә дә инде безнең мохиттә яшәми, зур хыяллар белән яна. Хәзерге көндә Гафур Каюмов милли камера театры оештыру уе белән ашкынып йөри. "Сәхнә" дигән журнал чыгару, язучыларны, рәссамнарны, театр әһелләрен, композиторларны бер түбә астына җыеп, үзара аралашу өчен шартлар тудырасы килә аның. Мәктәпләрдә уку-укыту программаларына театр сәнгате нигезләре турында мәгълүматлар кертелсә, моның киләчәктә театр тамашачысын тәрбияләүдә зур булышлык булачагына иманы камил.

"Галиябану" спектаклендә (М. Фәйзи) Исмәгыйль, "Ташкыннар"да –Мирзахан, Ш. Хөсәеновның "Әни килде"сендә–Сәяр, француз драматургы А. Лябиш "Тол ханымда тукталыш" спектаклендә–Месье Танкарель "Зөләйха" спектаклендә (Г. Исхакый) – Сәлимҗан, М. Гыйләҗевнең "Казан егетләрен"дә –Алмаз,–Әйдә барыйк, кызлар карыйк"та (Р. Вәлиев) – тракторчы егет, Н. Исәнбәтнең "Портфелендә"–прокурор Хасбуллин һ. б.; М. Фәйзинең "Галиябану" телефильмында–Хәлил, "Зөләйха" нәфис фильмында–Сәлимҗан образлары Гафур Каюмовның чын мәгънәсендә күпкырлы талантлы артист, милләт җанлы олы шәхес икәнлеген кат-кат раслый.

Г. Каюмов 1998 елдан Язучылар берлеге әгъзасы, 2003 елда "Упкын өстендә уен" дип аталган пьесалар китабы чыгарды.

Баш бирмичә, милләт кыйбласына йөз тоткан драматург һәм сәнгать әһеле буларак, без Гафурга уңышлар телик.

**Алмаз ХӘМЗИН**

Исәнмесез, хөрмәтле "Казан утлары" хезмәткәрләре!

Мин–сезнең журналыгызны ихлас күңелдән, яратып, даими укып баручы Булат абыегыз.

Илләр, көннәр тыныч булып, шундый тирән эчтәлекле журналыгыз халыкка рухи азык бирүен дәвам итсә, милләтебез яшәр, иншалла!

Сезгә Фәнис Яруллинга багышлап язылган шигырь салуымның хикмәте бар.

Ун еллап элек язган шигыремдә "Көл булган язмышка үч итеп" дип әйтүем зур хата булган. Моны "Аяныч язмышка үч итеп"–дип төзәтеп язарга булдым.

Шушы, төзәтелгән шигырьне журналыгызда бастырсагыз, мин Фәнис алдында да һәм үземнең вөҗданым алдында да тыныч булыр идем.

**Булат ӘЮПОВ.**

*Атказанган нефтьче, "Почет билгесе" ордены йөртүче.*
*Сарман районы, Җәлил бистәсе.*

## Яралы бөркет

*Упкыннар шаулаган төбәктә,*
*Болытлар өстендә – кыяда*
*Яшь бөркет, канатын кагынып,*
*Һәр таңда очарга уяна.*

*Түбәнгә атыла ул таштай,*
*Тырнаклар ялтырый кадактай.*
*Очканда сызгыра гәүдәсе*
*Җәядән атылган чын уктай.*

*Ул күрә яшеннең ташын да,*
*Күзләре яналар очкындай.*
*Кагылса, ут чыга таштан да,*
*Томшыгы коелган корычтай.*

*Беркөнне иртәнге томанда*
*Очканда бер мизгел ялгыша.*
*Тизлектән, өлгерми, бәрелә,*
*Яшьлек тә ватыла, язмыш та.*

*Упкыннар шаулаган тавышка*
*Яшь бөркет тиз килә аңына.*
*Каушамый, батыра тырнагын*
*Канатын сындырган ташына.*

*Үрмәли, кыяга юл эзли,*
*Эчәргә су тапмый сызлана.*
*Ул әле ышанмый үзе дә*
*Канаты мәңгегә сынганга.*

*Ачудан бәрә ул томшыгын*
*Мүкләнгән, дымланган ташларга.*
*Ярыктан тамчылап су саркый,*
*Ә алда тар сукмак башлана.*

*Аяныч язмышка үч итеп,*
*Чишмәләр чыгара тау тишеп.*
*Төннәрен оча ул хыялда,*
*Таңнарда талпына онтылып.*

*Күп еллар менә ул кыяга,*
*Йөзләгән чишмәләр чыгара.*
*Саф сулар кушыла түбәндә,*
*Болыннар чәчәккә күмелә.*

*Һаман да бу бөркет кыяда,*
*Ул туган тавында, ояда.*
*Очарга канатлар сынса да,*
*Сынмасын сабырлык дөньяда,*
*Син бары очсаң да хыялда...*

## ТӨРКИЯ ПРЕЗИДЕНТЫ КАЗАНДА

14 февральдә Төркия Республикасы Президенты Абдуллаһ Гөл кыска вакытлы визит белән Татарстанга килде. Делегация составында 200 дән артык кеше иде. Югары дәрәҗәдәге кунакларны "Казан" аэропортында Татарстан Республикасы җитәкчеләре каршы алды.

"Без бүген тарихи вакыйгада катнашабыз: һәрвакытта да зур абруйга ия булган Төркия дәүләтенең Президенты үзенең хәләл җефете белән республикабызга килде. Шулай итеп, без ике кардәш халык тарихында яңа сәхифәне ачтык", - диде Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев.

Мәгълүм булганча, 1995 елның маенда Төркия белән Татарстан республикалары арасында сәүдә-икътисад, фәнни-техник һәм мәдәни хезмәттәшлек турында хөкүмәтара килешүгә кул куелган иде. 1996 елда исә Казанда Төркия Республикасының Генераль консуллыгы ачылды. 1997 елның сентябреннән башлап Төркиядә Татарстанның тулы вәкаләтле вәкиллеге эшли башлады. Гамәлгә ашырылган чаралар нәтиҗәсе буларак, 2007 ел белән чагыштырганда, үткән елда ике республика арасында сәүдә әйләнеше ике тапкыр артты һәм ул хәзер 3 миллиард долларга якынлашты.

Төрек кардәшләренең визит программасы үзәгендә Татарстан-Төркия бизнес-форумын үткәрү иде. Ул "Корстон" сәүдә-күңел ачу комплексында узды. Эшмәкәрләр форумы кысаларында "Алабуга" махсус икътисади зонасында хезмәттәшлек итү буенча Төркиянең "Тракья Жам Санайи" һәм "Кастамону Энтегре" компанияләре белән беркетмәләр имзаланды.

Төркиянең тышкы икътисади элемтәләр советы башкарма комитеты рәисе Рона Йыржалы әйтүенә караганда, Татарстанда хәзер 266 төрек фирмасы эшли, алар 20 миллиард долларлык проектларны гамәлгә ашырдылар инде. Кунаклар Универсиада корылмалары төзелешендә катнашырга да теләк белдерделәр.

Татарстан җитәкчесе М.Шәймиев Казан шәһәренең 1000 еллыгына әзерлек чорында төрек төзүчеләренең эшчәнлеген югары бәяләде. Аларның сыйфатлы һәм арзанлы итеп төзүләрен билгеләп үтте. Илбашыбыз Универсиада - 2013 корылмаларын торгызуда да аларны җәлеп итү мөмкинлеген карарга вәгъдә бирде. Президент карашынча, Татарстан белән Төркия арасында яңа хезмәттәшлек күперләре салына.

Форумнан соң Казан Кремлендә эшлекле сөйләшүләр дәвам итте. Абдуллаһ Гөл фикеренчә, Төркияне Татарстан белән мәдәни һәм тарихи элемтәләр берләштерә, алар бу ике ил арасында үзенчәлекле күпер булып тора. Мәдәни элемтәләрне тагын да ныгыту өчен Төркиядә - Татарстанның, Татарстанда Төркиянең мәдәни үзәкләре булдырылачак.

## ОЕШТЫРУ КОМИТЕТЫ ТӨЗЕЛДЕ

РФ Премьер-министры В. Путин 2013 елда Казанда XXVII Бөтендөнья җәйге Универсиадасына әзерләнү һәм аны үткәрү буенча оештыру комитетын төзү турында боерыкка кул куйды.

Моннан тыш, ул оештыру комитеты составын да раслады. Комитетка Россиянең беренче вице-премьеры И. Шувалов җитәкчелек итәчәк. Аның составына шулай ук ТР Премьер-министры Р. Миннеханов, Казан мэры И. Метшин, Яшьләр эшләре, спорт һәм туристлык министры М. Бариев, Россия Студентлар спорт берлеге президенты О. Матыцин һ.б. рәсми кешеләр керде. Оештыру комитетының эшчәнлеген тәэмин итү Россия спорт һәм туристлык министрлыгына йөкләнде.

Универсиаданы 2013 елның июль азагы – август айларында уздыру күздә тотыла. Ул 20 көн чамасы дәвам итәчәк. Бу чарада дөньяның 150дән артык иленнән 10 меңнән күбрәк спортчы катнашачак.

## САЙЛАУЛАР ҮТТЕ, ДЕЛЕГАТЛАР АЧЫКЛАНДЫ

2009 елның 1 нче мартында Татарстан Республикасы Дәүләт Советына сайлаулар булып узды. Дүртенче чакырылыш Татарстан Дәүләт Советына 100 депутат (Республика сайлау округы буенча – 50 һәм бер мандатлы сайлау округлары буенча – 50 кеше) сайланды.

Рәсми мәгълүматлар буенча, республикада исемлеккә кертелгән сайлаучыларның 78,4 проценты участокларга килгән һәм шуларның 79 проценты "Бердәм Россия" партиясен яклап тавыш биргән. Ә КПРФ – 11,1, "Гадел Россия: Ватан /Пенсионерлар/ Тормыш" партиясе - 4,8 һәм ЛДПР

3,08 процент күләмендә хуплау тапкан. Бермандатлы округларда тавыш бирү нәтиҗәләренә килгәндә, биредә "Бердәм Россия" партиясе тәкъдим иткән кандидатларның 43е, ә үз-үзләрен тәкъдим иткәннәрнең 7се җинеп чыккан. Шулай итеп, Татарстан парламенты, нигездә, "Бердәм Россия" вәкилләреннән торачак. Яна сайланган депутатлар арасында өч язучы да бар. Алар – Туфан Миннуллин, Роберт Миннуллин, Разил Вәлиев.

Дүртенче чакырылыш Татарстан Дәүләт Советы депутатларын сайлауларына әзерлек һәм үткәрүгә 143 миллион сум акча сарыф ителгән.

### МИЛЛИ МӘГАРИФ ХАЛЫКАРА ЯКЛАУГА МОХТАҖ

ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин Мәскәүдә "Федераль дәүләт мәгариф стандарты - күпмилләтле җәмгыятьнең ныклы үсешенең стратегик ресурсы: Россия Федерациясе субъектларынын закон инициативасы" темасына багышланган парламент тыңлауларында катнашты. Мөһим бу чарада Россиянең 55 субъекты вәкилләре бар иде. 2007 ел ахырында Дәүләт Думасы тарафыннан мәгариф процессында "милли компонент" төшенчәсен юкка чыгару турында федераль закон кабул ителде. Татарстан парламенты, федераль мәгариф стандартында милли компонент янадан торгызылырга тиеш дип саный һәм Дәүләт Думасына, закон инициативасы буларак, федераль законның тиешле проектын җибәрде. ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин парламент тыңлауларында милли мәгарифне яклауга аргументлар китерелгән доклад белән чыгыш ясады.

Парламент тыңлауларында РФ Дәүләт Думасының милли мәсьәләләр буенча комитет рәисе Валентин Купцов, Россия мәгариф һәм фән министры урынбасары Юрий Сентюрин, РФ Дәүләт Думасының мәгариф комиссиясе рәисе Григорий Балыхин, Башкортстан республикасы Премьер-министр урынбасары Илдус Илишев һ.б. чыгыш ясады.

Әлбәттә, милли мәгариф системасында законлы таләпләрне кире кайтару юнәлешендә бу чараның әһәмияте зур, әмма төп мәсьәлә әлегә хәл ителмичә, ачык кала бирә.

### ЯҢА ЛАУРЕАТЛАР

М. Җәлил исемендәге Республика премиясе комитеты чыгарган нәтиҗәләр нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2009 елның 13 февралендә 2007-2008 елгы конкурс йомгаклары буенча М. Җәлил исемендәге Республика премиясен түбәндәге кешеләргә бирергә карар кылды:

яшьләрне патриотик рухта тәрбияләве, актив иҗтимагый эшчәнлек алып баруы өчен "КамАЗ" ААЖнең Махсус техника департаменты оештыру һәм идарә бюросы башлыгы, автоузышчы **Кәбиров Фирдәвес Зариф улына**;

яшьләрне эстетик тәрбияләүдә нәтиҗәле эшләве, дәүләт яшьләр сәясәтен тормышка ашыруга зур өлеш кертүе өчен "Мгновение" бию театры сәнгать җитәкчесе **Ишбулатова Елена Петровнага**;

бүгенге татар драматургиясен үстерүгә зур өлеш кертүе өчен драматург **Зәйниев Илгиз Газинур улына**;

талантлы яшьләргә актив ярдәм итүләре өчен язучылар **Бикчурова (Гыйматдинова) Нәбирә Миңнеәхмәт кызына** "Бер тамчы мәхәббәт" повестьлар һәм хикәяләр җыентыгы өчен); "Салават күпере" балалар журналын, татар телендәге "Сәхнә" театр һәм эстрада журналын нәшер итүдәге, балалар өчен китаплар иҗат итүдәге күпьеллык эшчәнлеге өчен **Хөснетдинов Зиннур Зыятдин улына (Зиннур Хөснияр)**.

### ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ХАЛЫКАРА ҖЫЕНЫ

18 февральдә Мәскәүдә элеккеге СССР Язучылар берлеге бинасында (Поварская 52) "Язучылар оешмаларының халыкара Берлеге"нең чираттагы съезды булып узды. Халыкара бу җыенга ерак чит, БДБ илләреннән, шулай ук Россиянең төрле төбәкләреннән 47 оешма вәкилләре җыелган иде. Съездда Татарстаннан делегатлар сыйфатында Татарстанның халык шагыйре, "Казан утлары" журналының баш мөхәррире Равил Фәйзуллин, Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, "Мәгариф" нәшрияты директоры Мөдәррис Вәлиев катнашты. Съездны совет әдәбияты классигы, 96 яшьлек Сергей Михалков ачты. Хисап докладын халыкара оешманың беренче секретаре Иван Переверзин ясады. Фикер алышулардан соң Берлекнең яңа җитәкчелеге сайланды. Идарә җитәкчелегендә әлләни үзгәреш булмады. Башкарма комитетка (идарәгә) Татарстаннан Илфак Ибраһимов сайланды.

### ЮГАРЫ ДӘРӘҖӘДӘГЕ ЫШАНЫЧ

Россия Президенты Дмитрий Медведев расланган кадрлар резервындагы 100 кешенең кемнәр икәнлеге ачыкланды. Мәскәү Кремле исемлегенә 36 федераль, 23 төбәк җитәкчесе, 31 эшкуар, 10 фән, мәдәният, дин әһеленең теркәлүе билгеле булды.

"Йөзлекта" Татарстаннан да яшьләре 25-50 тирәсендәге, югары белемле, җинаять җаваплылыгына тартылмаган, зур эшләр башкарган ике вәкил бар. Болар – Казан мэры Илсур Метшин һәм ТР Мәгълүмати технологияләр үзәге директоры Николай Никифоров.

### РОССИЯ ФӘНЕ КӨНЕ

8 февраль - Россия фәне көне. Әлеге карарга Россия Президенты 1999 елда кул куйды һәм ул дәүләт белән җәмгыятьнең үсешендә илебез фәненең югары ролен тану көне буларак билгеләп үтелә.

Шул унайдан Россия Фәннәр академиясенең Казан фәнни үзәгендә һәм Татарстан Фәннәр академиясендә тантаналы чаралар узды.

Казан фәнни үзәгендә аның рәисе академик Олег Синяшинның чыгышы һәм академик Александр Коноваловның «Супрамолекуляр системалар һәм тормыш» дигән фәнни доклады тыңланды.

ТР Фәннәр академиясе президенты Әхмәт Мазһаров исә үзе җитәкләгән академия коллективының эшлекле рух белән сугарылуын, моның үз чиратында фәнни тикшеренүләрне яңа дәрәҗәгә күтәрергә ярдәм итәчәген билгеләп узды. «Финанс кризисы шартларында, монарчы ирешелгәннәрне югалтмыйча, республиканың интеллектуаль куәтен үстерергә кирәк», - дип белдерде ул.

Тантанада фәнни династияләрне бәйрәм белән котладылар, ТФАнең исемле стипендияләре дә тапшырылды. Моннан тыш «2008 елның иң яхшы галиме» һәм «Иң яхшы яшь галим» бәйгеләрендә җиңү яулаган галимнәрне бүләкләделәр.

### БӨЕК ГАЛИМГӘ БАГЫШЛАП

Шушы елның январь аенда бөек мәгърифәтче, галим, әдип, рухани Ризаэддин Фәхреддиннең тууына 150 ел тулды. Бу унай белән Татарстанда һәм Башкортстанда төрле чаралар уздырыла. Шундыйларның берсе февраль башында галимнең туган ягында үтте. Ул "Ризаэддин Фәхреддиннең иҗади мирасында толерантлыкның рухи нигезләре" дип аталган фәнни-гамәли конференция. Аны Әлмәт дәүләт муниципаль институты нигезендә Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Фәннәр Академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге тарих институты һәм Бөтендөнья татар конгрессы уздырды. Конференциянең пленар утырышында Р. Фәхреддин эшчәнлеге, аңа бәйләнештә рухи мирас, тарих, мәдәният, дин, мәгариф, әхлак мәсьәләләре буенча Мәгариф министры вазыйфаларын башкаручы Данил Мостафин, Әлмәт шәһәр һәм район хакимияте башлыгы Ришат Әбүбәкеров, академик Мирфатыйх Зәкиев, профессор Хатыйп Миңнегулов, галим Әнвәр Хәйри һ.б.лар чыгыш ясады.

***

16 февральдә Казан дәүләт университеты укытучылары һәм студентлары Ризаэддин Фәхреддинне искә алу кичәсе уздырдылар. Аны алып баручы профессор Хатыйп Миңнегулов үзенең кереш сүзендә болай диде: "Соңгы 60 елда Татарстанда 3 млрд. тоннадан артык кара алтын чыгарылды. Әмма ул байлык халкыбызның үзеннән бигрәк, читләргә озатылды; берничә дистә ел буе Советлар империясенең төп терәкләреннән берсе булды. Татарстан нефть төбәгенең үзәгендә туып үскән Ризаэддин Фәхреддин исә татарның күп гасырлык рухи байлыгын туплап, үз күңеле аркылы чыгарып, иң әүвәл халкыбызның үзенә кайтарды, аның зиһенен баетты..."

Академик Миркасыйм Госманов Р.Фәхреддиннең мирасын өйрәнү тарихы, бу затның шәхси үзенчәлекләре хакында гыйбрәтле мисаллар китереп сөйләде, аны "әхлаклылыкның, инсанилыкның кабатланмас бер үрнәге" дип атады. "Рухият" нәшрияты соңгы елларда бөек галимгә мөнәсәбәтле берничә китап чыгарды: "Ризаэддин Фәхреддин. Фәнни-биографик җыентык (1999), "Асар" (I том, 2006; II - том, 2009. Татар һәм рус телләрендә) һ.б. Болар хакында нәшрият хезмәткәре Рамил Миннуллин сөйләде. Кичәдә шулай ук профессорлар Резедә Ганиева, Тәлгат Галиуллин, доцент Әлфәт Закирҗанов чыгыш ясады; әдипнең әсәрләреннән өзекләр укылды; студент-шагыйрьләрдән Рифат Сәлах, Резедә Гобәева, Эльвира Һадиеваның Р. Фәхреддингә багышланган шигырьләре яңгырады.

### ФАТИХ КӘРИМНЕ ОЛЫЛАУ

2009 елның 9 гыйнварында күренекле татар шагыйре Фатих Кәримнең тууына 100 ел тулды.

Шагыйрьнең юбилеена багышланган күптөрле чаралар ел дәверендә республикабызда һәм аннан читтә дә үткәреләчәк.

Шундый чараларның иң беренчесе шагыйрьнең Ватан сугышында батырларча һәлак булган һәм җирләнгән урынында - Калининград өлкәсенең Багратионовск шәһәрендә үтте. Татарстан Мәдәният министрлыгы, Язучылар берлеге һәм Кинематографиячеләр берлеге тарафыннан оештырылган делегация составында Язучылар берлеге рәисе, шагыйрь Илфак Ибраһимов, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис, кинооператор Максим Мальков һәм Фатих Кәримнең кызы Ләйлә Кәримова бар иде. Алар башта Калининград өлкәсенең тарих музеенда Фатих Кәримнең каберенә полкташлары тарафыннан куелган язу тактасын карады, шәһәрне фашистлардан азат итүгә кагылышлы тарихи документлар белән танышты, Фатих Кәрим һәлак булган урында булды. Ә инде 9 гыйнварда, ягъни шагыйрьнең туган көнендә, кунаклар Багратионовск шәһәренең туганнар каберлеге мемориалында Фатих Кәрим

өчен махсус төзелгән һәйкәлгә һәм Фатих Кәрим урамындагы мемориаль тактага чәчәкләр салуда һәм митингта катнашты. Соңыннан шәһәрнең үзәк музеенда өлкә һәм шәһәр җәмәгатьчелеге белән очрашу үткәрелде. Очрашуда Калининград өлкәсе мәдәният министрының беренче урынбасары Андрей Попов, Калининград өлкәсе Язучылар берлеге рәисе Виталий Шевцов, Багратионовск шәһәре башлыгы Владимир Башкатов, Балтыйк буе казаклары атаманы Юрий Зинченко, шәһәр мәдәният идарәсе җитәкчесе Людмила Коншина, өлкәнең язучылары, шагыйрьләре һәм шул төбәктә яшәүче милләттәшләребез катнашты.

***

Татарстан Милли музееның әдәби салонында патриот-шагыйрь Фатих Кәримнең тууына 100 ел тулуга багышлап, "Соңгы дәфтәр" дигән факсимиль басманың дөнья күрүе уңаеннан кичә үткәрелде.

Нибары 36 ел яшәгән шагыйрьнең бар тормышы фаҗигаләр һәм иҗади фидакярлек белән сугарылган. Кичәдә катнашучы язучылар һәм галимнәр — Ренат харис, Зиннур Мансуров, Тәлгат Галиуллин, Фоат Галимуллин һ.б. нәк шул хакта дәлилләп сөйләделәр. Мәдәният министры урынбасары Гөлшат Нигъмәтуллина "Соңгы дәфтәр"нең әһәмияте зур булуын әйтеп, шагыйрьнең кызы Ләйлә Кәримовага чәчәкләр бүләк итте. Милли музейның генераль директоры Гөлчәчәк Нәҗипова патриот-шагыйрьнең музейда саклланган ядкәрләре турында сөйләде.

Әдәби салон утырышын музей хезмәткәре Флера Дәминова алып барды.

## ИСКӘ АЛУ КӨНЕ

Инде күп еллар дәвамында 15 февраль халкыбызның каһарман улы Муса Җәлилне искә алу көне буларак билгеләп үтелә. Язучылар берлеге рәисе Илфак Ибраһимов, Җәлилнең тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнүче галим һәм тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харис һ.б. каләм ияләре, сәнгать әһелләре, ветераннар, мәктәп укучылары, студентлар шагыйрьнең Казан Кремле алдында - 1 Май мәйданындагы һәйкәленә һәм җәлилчеләр барельефына быел да чәчәкләр салды.

Шул ук көнне Татарстан Милли музеенда атаклы "Моабит дәфтәрләренең төп нөсхәләрен кин җәмәгатьчелеккә тәкъдим итү тантанасы да булды. Бирерә антифашистик каршылыкта катнашкан Җәлил һәм аның көрәштәшләре турында сөйләүче "Батыр беркайчан да үлми" исемле күргәзмә дә оештырылган иде.

Искә алу мәрәсимендә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, мәдәният министры урынбасары Гөлшат Нигъмәтуллина катнашты.

## УДМУРТИЯДӘ ТАТАР МӘДӘНИЯТЕ ҺӘМ ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

Удмуртия Республикасында татар мәдәнияты һәм әдәбияты көннәре Можга шәһәрендә Удмуртия татарларының милли-мәдәни мохтәрияте идарәсенең киңәйтелгән утырышы белән башланып китте. Анда Удмуртия татарларының бүгенгесе һәм киләчәге турында җитди сөйләшү булды. Утырышта Удмуртия Республикасының милли сәясәт министры В. Завалин, Можга шәһәре мэры С. Пантюхин катнашты.

Кичен Можгадагы "Дубитель" мәдәният сараенда җирле рәссам А. Фазлыйнуровның иҗаты белән танышу, шушы шәһәрдә яшәүче шагыйрь, композитор, автор-башкаручы, җәмәгать эшлеклесе Илгиз Кадыйровка 70 яшь тулу уңаеннан иҗат кичәсе булды.

Икенче көнне татар мәдәнияте һәм әдәбияты көннәре Ижауда дәвам итте: Халыклар дуслыгы йортында Удмуртиядә татар мәдәнияте һәм әдәбияты көннәрен рәсми ачу тантанасы булды. Аны милли-мәдәни мохтәрият идарәсе рәисе И. Шәрипов ачып җибәрде. Тантанада катнашучыларны Удмуртия Республикасының Премьер-министр урынбасары И. Бикбулатов, Ижау шәһәре мэры В. Балакин тәбрикләде. Татарстан делегациясе исеменнән Татарстан мәдәният министры урынбасары Г. Нигъмәтуллина чыгыш ясады.

Кичен кунакларны Сарапул кабул итте. Анда зур әдәби-музыкаль кичә булды.

Удмуртия Республикасында татар мәдәнияте һәм әдәбияты көннәрендә Казаннан - Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты вәкилләре Р. Сафин, Г. Шәйхи, З. Зиннәтуллин, Татарстан язучылары — В. Имамов, В. Нуриев, Ш. Мостафин, И. Иксанова, Удмуртиядә яшәүче каләмдәшләребез Р. Баттал, Г. Сафин, З. Нуртдинов һ.б. катнашты.

## ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ— ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

Берничә буын язучыларның аңына сеңгән шигар бу. Чыннан да, гомумкешелек рухи кыйммәтләрен уртаклашуда, гомумхәзинәне баетуда әдәбиятның роле гаять зур. СССР таркалгач, соңгы дистә елларда төрле дәүләтләрдә, өлкәләрдә яшәүче язучылар белән үзара мөнәсәбәтләр кими төште. Шулай да, Башкортстан язучылары белән элеккеге күркәм традицияләр әлегәчә уңышлы дәвам итә. Дистә еллар дәвамында Башкортстан язучыларының китаплары Татарстанда, һәм киресенчә, Татарстан әдипләренең китаплары Башкортстанда элекке рәвештә даими басылып килә.

Язучылар делегацияләре дә үзара йөрешеп тора. Күптән түгел Уфада чыга торган "Агыйдел" журналы татар язучыларының әсәрләрен мул итеп бастырып чыгарды. Анда Р. Фәйзуллинның "Казан утлары" турында кереш мәкаләсе, К. Кәримовның "Ком сәгате" романы, шагыйрьләр Г. Рәхим, Р. Вәлиев, Г. Морат, Ф. Мөслимова, Л. Янсуар шигырьләре, прозаиклар— З. Зәйнуллин, Р. Рахман, Р. Габделхаковаларның хикәяләре, новеллалары урын алган. Кунак ашы—кара каршы дигәндәй, "Казан утлары" да киләсе май санында Башкортстан әдипләре иҗатына багышланган махсус сәхифә чыгарачак. Анда Ә. Әминов, Р. Янбәк, Т. Гыйниятуллин, С. Шәрипов, Т. Ганиева, Ф. Акбулатова, Г. Котыева һ.б. әсәрләре бар.

### ТӨРЕК КИНОСЫ ФЕСТИВАЛЕ

5-6 мартта Казанда Төрек киносы фестивале узды. Әлеге унайдан 4 мартта Казанга Төркия Республикасы делегациясе килде. Аның составында Кинематография һәм авторлык хокуклары дирекциясе генераль директоры Сеих Абдурахман, Төркия дәүләт телерадиокомпаниясе генераль директоры урынбасары Зейнел Коз, Төркия Кинематографистлары берлеге рәисе Исмаил Гюнес һәм башкалар бар иде.

«Исәнмесез» дип исемләнгән фестивальдә Төркиянең иң яхшы фильмнары тәкъдим ителә. Моннан тыш казанлыларга язучы Чыңгыз Айтматов әсәре буенча төшерелгән «Подаренный судьбой» дигән картина да күрсәтелде.

Казанда әлеге чара Азия илләрендә оештырылган "Төрки телле илләр» дигән турне кысаларында үтте. Башкалада фестиваль «Сувар-Плаза» сәүдә үзәгенең «Гранд-синема» кинотеатрында узды.

### УРМАНЧЕ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

Мәгълүм булганча, 1998 елны Татарстан мәдәният министрлыгы тарафыннан мәшһүр сынчы-рәссам Бакый Урманче премиясе булдырылган иде. Ул ике елга бер мәртәбә бирелә. Моңа кадәр мәртәбәле бу бүләккә 15 рәссам лаек булган иде. Быелгы конкурс аеруча киеренке булды: лауреатлык өчен 62 рәссам көрәште. Инде алтынчы тапкыр үтә торган конкурста быел 4 рәссам — Ирина Антонова, Фәрит Суюров, Илдус Гайнетдинов һәм Елена Ермолина җиңеп чыкты. Лауреатларны бүләкләү тантанасы "Хәзинә" милли сәнгать галереясында узды.

### ЕЛ КЕШЕСЕ

ТР Дәүләт симфоник оркестрының баш дирижеры һәм сәнгать җитәкчесе Фуат Мансуров 2008 ел нәтиҗәләре буенча «Ел кешесе» дип табылды.

1995 елдан бирле ана М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры директоры Р. Мөхәммәтҗанов, дирижер Р. Абязов, музыка белгече Г. Кантор лаек булган иде.

Ф. Мансуровның эшчәнлеге Алматы, Казан, Мәскәү шәһәрләре белән бәйле. 1968 елдан бирле ул М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры оркестрын, ә 1989 елдан дәүләт симфоник оркестрын җитәкли. Экспертлар фикеренчә, әлеге коллектив Россия төбәгендә иң яхшылар рәтендә. Узган ел ахырында һәм бу ел башларында Ф. Мансуров җитәкчелегендәге оркестр Италия, Испания, Швецария, Нидерланд илләрендә гастрольләрдә булып кайтты.

### ЮБИЛЕЙ УҢАЕННАН

12 мартта А. М. Горькийның әдәби-мемориаль музеенда язучы Әмирхан Еникиның тууына 100 ел тулуга багышланган кичә узды. Бередә әдипнең архивы, китаплары, кулъязмалары аерым урынны алып тора. Язучының кызы Флера аларны музейга бүләк итте.

Кичәдә катнашучылар язучының тормыш юлы һәм иҗаты белән махсус әзерләнгән видеороликны карап танышa алдылар. Театр училищесы студентлары аның әсәрләреннән өзекләр укыды.

### МУЗЕЙ АЧЫЛДЫ

ТР Эчке эшләр министрлыгының мемориаль-мәдәни комплексы биләмәсендә музей-иҗтимагый үзәге ачылды. Аның беренче катында - ТР ветераннар советы, Эчке эшләр бүлегенең хәрби хәрәкәтләр һәм ТР Эчке гаскәрләр ветераннары берләшмәсе, руханилар өчен кабинетлар, икенче катында исә музей урнаштырылган. Музейда йөзләрчә кыйммәтле экспонатлар саклана. Алар арасында металлодетектор, алкотестер, мотоцикл, заманча уен автоматы һ. б. бар.

### УКУЛАР БАШЛАНДЫ

Казанның «Сөләйман» мәчете каршындагы начар күрүчеләр һәм күрүдән мәхрүм калганнар өчен тернәкләндерү үзәгендә чираттагы укулар башланды. Мәчетнең имам хатибы Илдар Баязитов белдерүенчә, бу юлы укуларга Казаннан, Татарстанның Түбән Кама, Алабуга, Бөгелмә һәм Арча районнарыннан, шулай ук Башкортстанның Сибай, Дүртөйле, Салават шәһәрләреннән һәм Волгоград өлкәсеннән, Түбән Новгородтан, Грозныйдан барлыгы 16 ир-ат килгән.

Бирегә килүче дин кардәшләребез Луи Брайль системасы буенча ислам нигезләрен үзләштерәчәк һәм Коръән укырга

өйрәнәчәк. Моннан тыш, алар биредә компьютерда эшләргә дә төшенәчәк, шулай ук әйләнә-тирәдә ориентлашу һәм үз-үзләренә хезмәт күрсәтү күнекмәләре дә алачак. Курсларга йөрүчеләрнең барысына да мәчет каршындагы тулай торакта яшәү мөмкинлеге бирелә, алар көненә 4 тапкыр кайнар ризык белән тәэмин ителә. Шул ук вакытта дин кардәшләребезнең юл чыгымнарын да мәчет житәкчелеге үз өстенә ала. Әйтергә кирәк, болар барысы да иганәчеләр ярдәме белән тормышка ашырыла.

### МӨСЕЛМАНЧА ЯШИБЕЗМЕ?

Россия Ислам университетында "Исем кушу", 'Никах" һәм "Женаза" кебек мөселман тәртип-йолаларына багышланган документаль фильмнар циклын төшерү тәмамланды. Якын араларда әлеге өч фильмны тәкъдим итү тантанасы үткәреләчәк. Киләчәктә мондый мөселман фильмнары проектын дәвам итү дә күздә тотыла.

Документаль фильмнар төшерүнең төп максаты - дин кардәшләребезгә тормышта еш кулланыла торган мөселман тәртип-йолалары турында киң мәгълүмат бирү һәм аларны өйрәтү. Фильмнарның барысы да режиссер Рәмис Нәжмиев житәкчелегендәге профессиональ төркем тарафыннан эшләнгән.

### МАЛАЙЗИЯДӘ ДӘ КОЛ ШӘРИФ БАР

Бөек мәчетне Казанга килеп күрә алмаучылар хәзер Малайзиягә бара ала. Яңа ачылган ислам цивилизациясе паркында дөньядагы иң зур, иң матур 12 мәчетнең макеты урын алган. Шулар арасында Мәккәдәге – Әл-Хәрәм, Иерусалимдагы - Әл-Акса, Һиндстандагы Тадж Мәхәл, Испаниядәге – Альхамбра, Истамбулдагы – Сөләйман мәчетләре һәм безнең Кол Шәрифнең дә макеты бар. Мәчет-һәйкәлләрне урнаштыру малайзиялеләргә якынча 75 миллион долларга төшкән.

### МИЛЛӘТТӘШЕБЕЗНЕ ИСКӘ АЛУ

Фольклорчы галим, язучы һәм җәмәгать эшлеклесе Рәшит Ягъфәровка багышланган укулар аның туган ягы Пермь крае Барда районында булды. Әлеге мәдәни чараларда крайның татар теле һәм әдәбияты укытучылары, үзешчән сәнгатьтә катнашучы һәвәскәрләр, җәмәгатьчелек вәкилләре, мәктәп балалары катнашты.

Барда мәдәният сараендагы тантаналарның йомгаклау өлеше зур бәйрәмгә әверелде. Биредә яшь иҗатчыларга Р. Ягъфәров исемендәге премияләр һәм истәлекле бүләкләр тапшырылды. Фойеда сәнгать мәктәбендә шөгыльләнүче яшь рәссамнарның күргәзмәсе эшләде.

Рәшит Ягъфәров исемен мәңгеләштерү йөзеннән, ул укыган мәктәп һәм ул эшләгән редакция биналарына истәлек такталары куелды. Барданың бер урамына аның исеме бирелде.

Пермь краенда әдип истәлегенә багышлап үткәрелгән чараларда Казаннан килгән кунаклар – язучылар – В. Нуриев, Р. Мулланурова, галимнәр – Ә. Хәйри, Н. Нәккаш, җырчы-композитор М. Имашев, шулай ук Р. Ягъфәровның хатыны Тәкълимә ханым, уллары Илдар һәм Юлдаш катнашты.

Барда муниципаль районы хакимияте башлыгы И. Урстемиров сүзләренә караганда, "Ягъфәров укулары" һәр елны үткәреләчәк.

***

2009 елының 23 февралендә журналист, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Ватан сугышы ветераны **Мәрдегалләм Галләм улы Рафиков (Мәрди Рафиков)** 82 яшендә вафат булды.

***


2009 елның 3 мартында мартында шагыйрә, педагог, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы **Энҗе Илалетдин кызы Мөэминова** 85 нче яшендә вафат булды.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Беренче биттә: "Акмулла".* А.Абзгильдин эше.

*Дүртенче биттә:* галим **Әнвәр Хәйри**.

# Яңа китаплар




From Lips of the Tatar People: Proverbs, Sayings, Aphorisms, Literary Miniatures / Compiler **A. Mushinsky**, Translator **A. Sakharov**. – Kazan: Magarif, 2009. - 239 p.

Татар ПЕН-үзәге "Мәгариф" нәшриятында "Татар акылы" дип исемләнгән ике китап чыгарган иде инде. Алар татар һәм рус телләрендә басылды. Ә бу китап, сан буенча өченчесе – инглиз телендә нәшер ителгән. Анда татар халык мәкальләре, татар язучыларының афоризмнары, хикмәтле сүзләре, фәлсәфи уйланулары тупланган. Тирән һәм үткен фикерне җыйнак, сурәтле итеп әйткән афористик иҗатны эченә алган әлеге җыентык сүз сәнгате хәзинәсен барлау, туплау һәм бүгенге, киләчәк буыннарга җиткерү максатыннан чыгып төзелгән. Бүләк басманың төзүчесе – Ә. Мушинский, инглиз теленә А. Сахаров тәрҗемә итте. Кереш сүзне Т. Миңнуллин язган.




**Харис Салихҗан** (Х. С. Салихов) А. Пушкин, Г. Тукай иҗатында Коръән вә бүгенге рухи тәрбиянең бер мәсьәләсе. – Казан: "Идел-Пресс", 2008. – 192 бит. Тиражы – 1000 данә.

Харис Салихҗан – Ватан сугышы ветераны, полковник, дин эшлеклесе, "Хәтер" мәчетенең (Татарстан Эчке эшләр министрлыгы карамагында) имам-хатыйбы. Автор, ислами мәгърифәттә беренчеләрдән булып, ике бөек шагыйрь –Пушкин һәм Тукай иҗатында Коръән-Кәримнең ни дәрәҗәдә урын алуын дәлилләп күрсәтә алган. Бу хезмәт мәктәп укучыларына, мәдрәсә шәкертләренә, гомумән, ислами тәгълиматка ихтирам кылганнарга файдалы әсбап санала ала.



Әнвәр Хәйри

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)